# казан утлары

10
ОКТЯБРЬ - 1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

10
ОКТЯБРЬ
1972

## Бу санда

З. НУРИ. Уйланулар дәфтәреннән. Шигырьләр . 3
М. ХӘБИБУЛЛИН. Тау белән тау очрашмаса да... Повесть . . . . . 8
Г. РӘХИМ. Көтмәгәндә. Шигырьләр . . . . . 78
Р. ВӘЛИЕВА. Толымнарың... Шигырь . . . . 82
Ә. ГАФФАРОВ. Ике хикәя . . . . . . . . . 84

ДУСЛАР ҖЫРЫ

А. ТВАРДОВСКИЙ. Ленин һәм мич чыгаручы. Шигырь . . . . . . . . . 89
Н. СТРИЖЕВСКАЯ. Үткәннәргә тимә... Шигырьләр. 93
ШӨҺРӘТ. Кеше һәм туфрак. Шигырьләр . . . . 93
В. АЛЕКСАНДРИ. Родика. Шигырь . . . . . . 95
М. ЕМИНЕСКУ. Ник син, урман, чайкаласың! Шигырь . . . . . . . . . 95
А. ЛУПАН. Пахом коесы. Шигырь . . . . . . 96
Н. КОСТЕНКО. Бөтен шәһәр кызыл... Шигырь 96
Д. ЛАЛЕВА. Карт ана. Шигырьләр . . . . . 97
М. ЛАЛЕВ. Тынгы бармы. Шигырьләр . . . . 98

ОЧЕРКЛАР

М. РАФИКОВ, Р. ЗӘКИЕВ. Батырлык каласы . . 99
М. ЗАРИПОВ. Саран катламнар хәзинәсе . . 110

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

Р. МОСТАФИН. Җәлилнең рухи туганнары . . 118
Г. МИНСКИЙ. «Казан кызы» яфрак ярган якларда . 127
И. ҮТӘБАЕВ. Игезәк халыкларның уртак упы . . 129

СӘНГАТЬ

Д. ГЫЙМРАНОВА. Үз моңы, үз тавышы белән . . 137

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. ГЛУХОВ. Татар графикасы . . . . . . . 145

КПСС ның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**И. ИЛЯЛОВА.** Кеше — җирнең бизәге . . . . . 151
**Ф. МУСИН.** Документаль материал һәм автор фантазиясе . . . . . . . . . . . . . . 158

## ЯҢА КИТАПЛАР

**М. ВӘЛИЕВ.** Диңгездә сыналу . . . . . . . . 168
**Ә. МӘХМҮДОВ.** Тамырлар дымга сусамасын . . 169

## БЕР КИТАП ТУРЫНДА ИКЕ ФИКЕР

**Р. ЛОТФУЛЛИН.** Томонимнар турында яңа хезмәт 170
**Й. ГӘРӘЙ.** Күтәреләсе үрләр күп әле . . . . . 173

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА

**Ф. ЯРУЛЛИН.** Кешене кешеләр күтәрә . . . . 175

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Р. ГӘРӘЙ.** Ул һаман да безнең арада . . . . . 179
**К. ФӘСӘХОВ.** Коммунист кадрлар мәктәбе . . . 180

## ЮМОР-САТИРА

**Г. НАСЫЙРОВ.** Әле ярый хатын бар. Юмореска . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
**Г. ЛАТЫЙП.** Ике күрше. Шигырьләр . . . . . 185
**Х. ГАТИН.** Үкенечле үтенеч. Шигырьләр . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 188

Оренбург шәле. Нотали җыр. **Җ. ФӘЙЗИ** көе. **С. ХӘКИМ** сүзләре . . . . . . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь—2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 10/VII-1972 ел. Басарга кул куелды 24/VIII-1972 ел. ПФ 14120. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 86046 экз. Заказ Г-470. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

## Зәки Нури

# УЙЛАНУЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

## Син килгәнсең...

Син килгәнсең кебек бу дөньяга
Йөрер өчен таңнар аттырып:
Елмайганда син үтәдән-үтә
Күренәсең кебек яктырып.

Син килгәнсең кебек бу дөньяга
Былбыл булып таңда сайрарга
Һәм әйтергә: матур чәчәкләрне
Кайда, ничек, кайчан сайларга.

Син килгәнсең кебек бу дөньяга
Очыртырга безне биеккә —
Гел кояшка карап мен син! дип тә,
Егыла күрмә, җаным! диеп тә.

Син килгәнсең кебек бу дөньяга
Ялкын көчен җырга кушарга,
Кисәтергә безне һәр адымда:
Буш эштән, дип, кирәк бушарга.

Син килгәнсең... үзең ауганда да
Күтәрергә безнең күңелне...
Бу дөньяга син килгәнгә күрә
Бу дөньяда яшәү күңелле!

## Җыр турында

Күкләрдә йолдызлар
Җыр булып кабынсын.
Гашыйклар бер-берсен
Җыр көйләп сагынсын.

Без яккан учаклар
Җыр булып дөрләсен.
Җырсыз көн — нурсыз көн
Төшкә дә кермәсен.

Сокланыйк чишмәгә:
Чишмәләр — җырчылар!
Эндәшик урманга:
«Җыр көйлә, җыр чыгар!»

Яңгырлар көткәндә
Ялварыйк болытка:
«Җир синнән җыр көтә,
Җыр җибәр, онытма!»

Озатыйк очкычны —
Зәңгәр күк батырын:
«Юлыңда җыр булып
Гүләсен моторың!»

Син, үлән, җыр көйләп
Иелгән үлән бул.
Син, болын, җыр белән
Чигелгән келәм бул.

Җыр булып шауласын
Суларда дулкыннар —
Ул җырны җан сөяр,
Ул җырны ил тыңлар.

Җыр булып сибелсен
Күзләрең чаткысы.
Кем җырны ят итә —
Ул безгә ят кеше.

Җыр! Йөре, юл йөре! —
Дип иссен җилләр дә:—
Йөрәктән йөрәккә,
Илләрдән илләргә...

Яшибез җыр белән
Серләшеп, гөрләшеп,
Җыр — канат, җыр — хыял,
Җыр — илче, җыр — бәхет!

## Мәхәббәтемә

Йөргәнем бар кысан урамнарда,
Күргәнем бар тыкрык тарлыгын.
Юлларымны ләкин син киң иттең!
Синең булу, синең барлыгың
Ашыктырды мине мәйданнарга,
Киң офыклы биек үрләргә.
Сәфәрләргә син озаттың мине
Барып җит, дип, ерак җирләргә.
Сүзең хак сүз: «Сафка мин бастырдым,
Син онытма шуны, ир егет!»
Юк, онытмам! Сиңа сыенып үстем,
Тамырым белән сиңа берегеп.

Рәхмәт сиңа — авыр эшләр куштың,
Этәрмәдең вакка, юк-барга.
Кирәк булды — тирән сулар кичтем,
Кирәк чакта — кердем утларга.
Котырса да ачы язмыш җиле,
Канатларны йолкып-каерып,
Юк, әйтмәдем синең исемне мин
Исемемнән илнең аерып.
Сыйганың бар тап-тар окопка да,
Киң галәм дә сиңа тар сыман.
Син чәчәк тә кебек һәм чәчкә дә
Кунасың син кырпак кар сыман.

## Әйтте шагыйрь

Язны күреп дулкынлангач
Һәм кулына каләм алгач,
Давылланган уе белән
Тик икәүдән-икәү калгач,

Әйтте шагыйрь: — Ак кәгазьгә
Саф хыял шәүләсен сызам.
Шигырь юлы сузам түгел,
Тормыш юлы буйлап узам.

Ерганак үзәнгә ташый
Күпме пычрак, күпме шапшык!
Ә тауга менсәң була бит,
Салават күперен капшап.

Таң булып атты күңелдә
Язның якты, тирән хисе:
Ул — бөре ачылган тавыш,
Ул — яфрак һәм үлән исе.

Әнә туфрак. Ул әйләнер
Бер тузанга, бер балчыкка.
Менә хәзер учта уып
Кара аны, кырга чык та.

Орлык салсаң — шытмаячак,
Туфрак салкын, юеш әле.
Җан-тәнгә ул кояш нурын
Сеңдерергә тиеш әле.

Әйтер тиздән:— Бураэна сыз!
Бөртегеңне әйдә сал! — дип.
Ә бөртек өстәр үзеннән:
— Берне сал да күпне ал! — дип.

Җир — юмарт ул. Тир генә түк!
Юк, куркытмый озак көтү.
Җир һәм кешенең эше бер:
Илгә муллык иҗат итү.

Сорардай булам күңелдән:
«Ник кыр кебек син киң түгел?..»
Юк, кояш белән җир көчен
Зурламаска мөмкин түгел.

Ашыктыра сыман җилләр,
«Йөрешеңне тизләт!» диеп.
Кошлар сайрый гүя: «Сине
Мактыйбыз без, хезмәт!» диеп...

Сүзләрен яз әйтеп тора,
Ничек инде мин җыр язмыйм!
Әллә инде мин язныкы,
Әллә инде үзем яз мин?!

...Шулай диде шагыйрь. Җыр бит —
Язның алтын фикере ул.
Әйе, җыр — йөгрек ерганак,
Җыр — салават күпере ул.

## Салкын бар һәм...

— Салкын, дисең, нәрсә дулый,— дисең,—
Циклонмы бу, антициклонмы? —
Шигырь белән җавап бирмәм, иркәм,
Көтмә миннән андый циклны.

Шуны әйтәм — чөнки сүз җае бар,
Әйтәм бары шуның өченгә:
Алլануын август алмасының
Күрү кирәк февраль көчендә.

Белер өчен җылы җәйләр кадерен
Һәм яратыр өчен ялкынны,
Без узарга тиеш кышлар аша
Һәм тоярга тиеш салкынны!

Җәйләр килмәс кышлар үтми торып,
Ләйсән яумый яфрак юылмас.
Салкыннар һәм ялкыннарны җыңсәк,
Безнең ара мәңге суынмас.

## Мин шулай күрәм...

Күрәм сине җирләрдә мин,
Күрәм сине биектә.
Чәчәктер диеп тә уйлыйм,
Уйлыйм таңдыр диеп тә.

Бер күрәм — син күк йөзе дә,
Син ул болыт та кебек.
Бер күрәм — ай булдың да син
Качтың болытка кереп.

Көндез эшеңдә күргәнне
Төнлә төшемдә күрәм,—
Безнең ике йөрәк бер пар
Булсын өченгә күрәм.

Күрен әле — тирә-якта
Хуш ис аңкысын әле.
Күрен әле — күкләремдә
Ал таң балкысын әле.

## Укучы дуска...

Ачам сиңа китап битләремне,
Йөрәгемне учка салган төсле.
Шәфкать көтмим: әгәр алдаласам
Чын дип әйтеп берәр ялган төсне.

Балык судан, су балыктан курыкмый!
Сүзеңне әйт дус һәм якын итеп:
Күңел аны киңәш диеп аңлар,
Кирәк икән — санар закон итеп.

Ләкин, зинһар, чыгып чыгырыңнан,
Ялгышма һәм күккә чөя күрмә.
Иң яманы шулдыр: яманымны
Яхшы белән бутап сөя күрмә.

Хис ятмасы — серле, тирән ятма,
Дөрес юллар салып үтә белик.
Гадилекне катлауландырмыйча,
Катлаулыны гади итә белик.

## Җавабым бер

Дәлилләрнең китереп зурларын,
Күз-колагым, аяк-кулларым
Катгый сүзләр тезеп китәләр —
Менә нәрсә исбат итәләр:
— Без булмасак әгәр — күзләрең,
Күрмәс идең тормыш эзләрен.
— Без булмасак әгәр — аяклар,
Барыр идең җирдә кай якка?
— Без булмасак әгәр — колаклар,
Тавыш килгән якка кем атлар?!
— Без булмасак әгәр — кулларың,
Язалмыйсың шигырь юлларын...
Җавабым бер шул дүрт керешкә:
— Һәркайсыгыз кирәк-кирәген...
Һич ярамас иде җыр эшкә,
Тудырмаса аны йөрәгем.

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ТАУ БЕЛӘН ТАУ ОЧРАШМАСА ДА...

ПОВЕСТЬ

## I

Ислам Зөлфәтне борылышка йөз метр кала уза башлады. Биредә узу тыела, каршы яктан машина килеп чыгу куркынычы бар иде. Һәм ул шулай булды да. Зөлфәтне уза башлаган машина юл сорап сигнал бирергә өлгермәде, каршы юлда куәтле КрАЗ күренде. Ул ничектер җир астыннан калкып чыкты кебек. Өч машина юлга сыймый, җитмәсә, алда борылыш, бу очракта аларның берсе кюветка төшеп кенә котыла ала иде.

Зөлфәт көзгегә күз төшереп алды. Аны узучы МАЗ инде юлга борынын тыгып та өлгергән. Хәзер, нәкъ менә шул секундта, Зөлфәт машинасын кюветка бормаса, ул, һичшиксез, каршы килгән КрАЗга чәпәләчәк. Аннан эзлә син кем хаклы да, кем гаепле икәнен. Ә КрАЗ үз ягыннан дөрес баруына ышаныпмы, аз гына да читкә алмыйча якынаюын белә, менә ул инде килеп тә җитә...

Шул мизгелдә Зөлфәт тормозга басты һәм кинәт машинасын уңга алды. Нәкъ менә шунда корычның корычка орынуы, нәрсәнеңдер шартлап сынуы ишетелде, Зөлфәтне узучы машина аның кузовына бәрелеп китте. Моны Зөлфәт күрмәсә дә тоеп белде, хәтта ул машинасының сул көпчәкләре күтәрелә башлавын сизде. Ниндидер афәт тоеп, ул бар көченә рульгә ябышты. Шул мизгелдә аның бөтен сын-буыны чуендай катып киткәндәй булды.

КрАЗ каты итеп сигнал бирде, алда Зөлфәтне узучы машинаның тәгәрмәчләре, кузов капкачы күренеп калды. Бәхеткә каршы, зур авария булмады. Алгы көпчәкләр кюветка төшү белән, тып итеп мотор сүнде. Машина, ярга бәрелгәндәй, төртелеп тынып калды. Зөлфәтнең аркасы тирләп чыкты, руль тоткан бармаклары җиңелчә биешә башлады.

Ул алга күз ташлады. Аны узып киткән үзбушаткыч, борылышны үтеп, турыга чыгып бара иде инде. Шулай да Зөлфәт аның кузов капкачына төшерелгән «42-13» санын күреп өлгерде. Һәм: «Тагын Ислам!» дигән уй зиһенен көйдереп алгандай булды.

Үзе белән бер бригадада эшләүче шофер Байтимеров Исламның Зөлфәтне беренче тапкыр гына кыен хәлгә калдырып узуы түгел иде инде. Соңгы көннәрдә Ислам тәмам шашты: күзенә ак-кара күренми чаба, теләсә кай төштә, теләсә кемне уза. Бер көнне хәтта генеральный директорның йөз километр тизлек белән барган «Волга»сын да узган дип сөйләделәр. Шәп йөри, кызу йөри һәм нормасын да йөз илле-ике йөз процентка үтәп килә. Шуна бераз һавалана, шоферлар белән үзен эрерәк тота.

Кыскасы, Исламга якын килерлек түгел хәзер. Автохуҗалыкның партоешма секретаре Петрович «сынок» дип кенә дәшә үзенә. Димәк, үз итә, якын итә. Комсомол секретаре турында әйтеп тә торасы юк. Ике көннең берендә Исламга тинләшергә өнди. Ә Бабай, автохуҗалык начальнигы Сәгъди Вәлиевич, гел улы урынына күрә икән үзен!..

Ә Зөлфәт кем?

Зөлфәт — бригадада иң артта сөйрәлүче шофер. Нигәдер тотрыклы гына эшләп китә алмый! Әллә җиңел машинадан соң авыр йөк машинасына ияләнә алмый инде, әллә курка, әллә чынлап та әкрен йөри? Артта сөйрәлгәне өчен аңардан көлүчеләр дә бар. Беренчесе — шул ук Ислам. Иртән путевка алырга керүе була, Ислам аңа төрттереп ала.

— Ну, егетләр, йоклый да бу безнең Казан таксисты. Кичәгенәк тагын кыерган — 96 процентка үтәгән. Йөк машинасында эшләүне такси йөртү дип белдеңме әллә син, Зелпеәхәт?! — дип исемен үк бозып үрти.

Зөлфәт дәшми. Ул путевка алырга чиратка баса. Ә Ислам ул килүгә һәрвакыт путевкасын алган булыр, машинасын кабызып, диспетчерлык бинасы каршына килеп туктаган булыр.

Әнә шуларның барысына да Зөлфәт ачулы. Ул кайчак үкенеп тә ала. Бер кыз өчен бит! Бер чәчби аркасында бирегә килеп җәфалана һәм әр-үртәү ишетә! Ә Байтимеров Исламга ул үзен мыскыл итүе һәм кюветка кысуы өчен генә ачулы түгел. Зөлфәтнең аңа башка ачуы бар, мәңге кичермәстәй эш эшләп ташлады Ислам аның өчен — сөйгән кызын тартып алды...

— Их! — Зөлфәт йодрыгы белән руленә сукты.

Шунда берәү аның кабина ишеген шакыды.

— Ач әле ишегеңне!

Чәченә чал төшкән автохуҗалык начальнигы Сәгъди Низамовны күрүгә, Зөлфәт киереп ишеген ачты.

— Кем иде ул сине кысучы? — дип сорады начальник төксе генә, гүя бу хәлдә аны кысучы Ислам гаепле түгел, Зөлфәт гаепле иде.

— Белмим, танымадым,— диде Зөлфәт, начальникның шактый кырыс соравыннан каушый калып. Ул белә иде: шофер шоферны әләкләмәскә тиеш. Машина йөртүчеләр өчен язылмаган закон сыман бер нәрсә инде ул.

— Байтимеровмы әллә?

— Абайламый калдым...

Начальник, шоферның ялганлавын сизеп, кашын җимерде, шап итеп МАЗ канатына сугып алды.

— Белмисең, абайламый калдың? — диде ул, ирен чите белән мыскыллы елмаеп куйды һәм машина тирәли әйләнеп килде. Зөлфәт җиргә сикерде һәм машинасына карап катты.

— Нәрсә оедың, ниемә шаккаттың? Әйдә, кабыз да артка чык,— диде аңа Низамов бу юлы ягымлырак тавыш белән.

Зөлфәт машинасын юлга чыгарды һәм моторны сүндерде дә кабинадан төште.

— Мә, мастерскойга кереп ябыштырып чыгарсын. Күрәм, ару чәкашкәнсез. Бу төштә юл тарракмы әллә, юлга сыймый башладыгызмы?

— Юл тар түгел, кайберәүләрнең күңеле тар,— диде Зөлфәт.

— Синеке кинме? Киң булгач, нигә юл бирмәдең? Юл бирсәң, ул сине кысмаган булыр иде...

Начальник, беравык сәерсенеп, машинасы тирәсендә уралган Зөлфәткә карап торды да, шофер янә кабинасына утырырга иткәч:

— Иртәгә миңа кереп чык әле, Вахитов,— диде һәм, җавап та көтмичә, борылып машинасына таба китте.

Зөлфәт аның чак кына бөкрәя төшкән гәүдәсенә, чалара башлаган чәченә Низамов УАЗга утырып киткәнче карап торды. Һәм квартира хозяйкасы Диана әйткән сүз исенә төште.

«Сезнең начальникмы? Зрә дә сәер кеше диләр аны. Казанда өч балалы бер хатынга йортка кергән булган. Балаларны үстереп кеше иткәч, тегеләр кайсы кая таралуга, кинәт кенә хатыны үлеп киткән. Шул кайгыдан бирегә килгән, имеш».— дип сөйләгән иде.

Зөлфәт начальник биргән сынык ыргакның авырлыгын белергә теләгәндәй кулында сикерткәләп алды һәм яңадан машинасын әйләнеп чыкты. Яңа МАЗга әллә ни булмаган: арт капкачның бер ыргагы сынган да кузов буявы сыдырылган... Ыргакны ябыштырып булыр, ә менә өр-яңа машинаның буявы сыдырылуы...

Моны күргәч, Зөлфәтнең бөтенләй кәефе кырылды. Исламга булган ачуы янә кабарып, йөрәккә тиеп китте. Әйе, Ислам аның канына тоз сала белде, ә менә хәзер Зөлфәт ни белән кайтарыр?...

## 2

Икенче көнне начальник янына кереп барганда Зөлфәт механикны очратты.

— Кичә нишләп ташладың тагын, Вахитов? Ну, егетләр, шома йөрмисез дә соң! Өр-яңа машина бирдек үзеңә. Бер ай йөрмәдең, ала сыер ясагансың... Орды-бәрде йөрүенә күрә, Байтимеров шикелле норманы арттырып үтсәң иде хет!.. Ипле йөрмисез... Әйт-әйтмә, тыңламыйсыз,— диде Петрович.— Бар, Бабаңа кер, бераз тозласын үзеңне, тозсыз нәмәстә! Норманны Гатифәдән дә арттыра алмыйсың бит,— дип ачуланып ташлады.

...Бабай берүзе өстәл янында утыра иде. Кабинеты иркен, өстәлләренең өсте көзгедәй ялтырап тора, шул өстәлләр артында чал чәч, яңаклары баткан чандыр йөзле начальник.

— Әйдә, түрдән уз...— диде ул, Зөлфәт килеп керүгә.

Зөлфәт түр урындыкка барып утырды, кепкасын салып, бөтәрләп кесәсенә тыкты һәм: «Әйдә, сөйлә, начальник, чакыруың нигә?» дигәндәй шактый кыю итеп Бабайның күзләренә карады. Зөлфәт кичәге хәлдән соң төнозын юньләп йоклый алмаган иде, Исламга булган ачуын начальникка актарып салырга дип ниятләп килгән иде. Бу хәлдә ул үзен гаепле санамый, борылышка йөз метр кала йөк машинасын узарга ярамый. Һәркемгә мәгълүм кагыйдә бу! Нигә яклый ул Исламны?!

— Сине кичә Байтимеров кыскан икән, үзе әйтте,— диде начальник, кулындагы карандаш белән өстәлгә суккалап.— Узарга теләгән машинага юл бирмәү шәп түгел, Вахитов. Байтимеров бу хәлдә сине гаепли...

— Мине ул борылмага җитәргә йөз метр кала уза башлады. Ә бу ярамый...

— Куй, вакланма. Эш узуда түгел, Вахитов. Эш меңә нәрсәдә. Син нигә әле койрыкта сөйрәләсең алай? Менә кара,— дип, Низамов өстәлдә яткан кәгазьгә күз төшереп алды.— Үткән ун көнлек норманы 97 процентка, аннан алда 93 процентка үтәгәнсең. Бу ни дигән сүз?.. Нәрсә син, йөк машинасында эшләгәнең юк идеме әллә?

— Юк иде,— диде Зөлфәт, турсая биреп. Начальник сөйләгән саен аның кәефе кырыла, үз-үзенә ачуы чыга бара иде. Чынлап та, нигә соң әле ул иң артта сөйрәлә? Дөрес, машина таныш түгел, кыенрак. Ләкин бит хатын-кыз булып хатын-кыз да аннан алда бара...

— Казанда таксида эшләгәнсең дип ишеттем. Хакмы шул?

— Эшләдем...

— Эшләгәч. Беләсеңме сугыш вакытында иң яхшы танкистлар кемнәр иде? Таксистлар...

— Мин үзем дә танкист булып хезмәт иттем...

Начальник текәлеп Зөлфәткә карап алды, алдындагы кәгазен читкәрәк этәрде.

— Нигә әле син, Вахитов, минем белән тырт-мырт сөйләшәсең? Аннары нигә Байтимеров белән тынышмыйсыз? Нәрсә бүлә алмадыгыз сез анда?..— Низамов сәгатенә күз төшереп алды.— Миңа нәрсә, Вахитов, давай син артта сөйрәлмә. Синең кебек танкист егеткә оят бу, туган. Инде ул бригадада эшләмим дисең икән, рәхим ит, башка коллективка күчерәбез үзеңне...

— Сәгъди Вәлиевич, минем яшьләр бригадасыннан китәсем килми...

— Шулай булгач, тырыш, күрсәт булдыра алуыңны. Тугызынчы котлован сезнең бригада өстендә. Җитмәсә, комсомол бит әле син. Котлован декабрьның егермеләренә әзер булырга тиеш. Ишетәсеңме, сездән тора аның вакытында әзер булуы...

Начальникка килгәндә күсәк тотып керердәй ачулы булса да, аннан чыкканда Зөлфәт сүрелгән иде инде. Дөрес, бераз ялкаулыгы да булды, эшкә соң килде, көлүләренә бик үк игътибар итмәде, кыскасы, кабаланмады. Ә ул әнә ничек икән?..

Зөлфәт Гатифә машинасы белән куышуын күз алдына китерде. Ни басты газга Зөлфәт, ни тырышты Гатифәне уздырмаска, теге барыбер узды. Исламны инде әйтеп тә торасы юк, МАЗына самолет моторы куйган диярсең. Йөк белән дә, йөксез дә уза...

«Әллә соң минем двигатель чынлап та көйсезме? Нигә тартмый? Болай бит үзе тәтәми дә кебек? — дип уйлады Зөлфәт, начальник яныннан чыгып машинасына таба атлаганда.— Юк, китте! Исламнан яңадан мыскыл иттермим! Үлсәм үләрмен, мәгәр сүземне сүз итәрмен. Йөзгә генә түгел, ике йөз процентка үтәячәкмен бүген норманы!» — дип, йөрәк белән эшкә чыгып китте Зөлфәт. Әмма барыбер әллә ни кыра алмады. Ислам аны барыбер узды, барыбер тиз йөрде.

Кич эштән кайтканда ул Мәснәвияне исенә төшерде. Кайчандыр сөйгән кызы булган кешене Ислам кочагында күз алдына китерү кыен иде ана. Шуңа йөрәге сулкылдады, шуңа бәгыре теленде. «Юк, юк, ул аннан үч алыр. Исламның бу мәкерле эшен болай гына калдырмас! Чәкәшер көннәре алда әле аларның, алда!..»

## 3

Әбиләр чуагы. Көннәр, алтын көзнең бөтен муллыгына, барлык хозурлыгына һәм булган рәхәтенә оеп калган кебек, җылы, коры, аяз, тын тора. Һавада өрфәдәй пәрәвез җепселләре оча. Төрле төсләрне үзенә җыйган урманы гүя йокыга талган. Баскан саен аяк астында кызгылт-сары «буяу» иңгән яфрак кыштырдый, саргаеп, кибә башлаган үлән астыннан башын тертеп сипкелле гөмбәләр калыккан.

Алтын көз. Басуларда хәрәкәт сүрелгән. Игеннәр урылган, сугылган, тракторлар җир сөрәләр, икенче төрле әйтсәк, туңга каплаталар. Шулай да колхозда эш бетмәгән әле. Әнә тегендә, Ык елгасы буенда, кешеләр, тракторлар, арбалар... Күрәсең, бәрәңге, чөгендер алалар.

Зөлфәт автобустан төште дә туган авылына, аның кырларына, Ык

елгасына хәйран калып карап торды. Менә ул тагын әнисе янына, туган авылына кайтты. Ничәмә-ничә кайтканы бар Зөлфәтнең авылга, әмма барыбер менә шунда житү белән кинәт дулкынлана башлый. Һәм ничәмә-ничә киткәне бар, һәрчак биредән утырып китүе моңсу була аңа.

Туган авыл, туган як. И кадерле дә соң син! Хәер, бер аның өчен генәме! Бу ашкынуны аның һәр читкә киткән авылдашы тоядыр, мөгаен?! Әлбәттә, тоя.

Көн жылы. Хәтта бераз бөркү кебек. Ләкин Зөлфәт белә. Көзге көн ул — кияү холкы. Кайчан иртә-кич шундый суытып жибәрә, тышта калган чиләктәге сулар туңа, бөтен яшеллекне ак бәскә киендереп кырау төшә. Шул чак агачлар Яңа ел чыршысына охшап кала. Ә инде көн туып, кояш күтәрелә төшкәч, аяк асты янә кипшерә, агач ябалдашларына кунган бәс эреп, тып-тып тамчы тама. Шунда, шул вакытта менә бу урман эченә керсәң — тамаша: аяк астында сукыр тычкан кыштырдый, агач ботакларында уйнаучы купшы, кызылтүш, үрмәләч, жизкалфак кошлары күзгә күренеп китә. Ул да булмый, якын-тирәне яңгыратып саескан шыркылдый башлый, аңа кушылып тукран тукылдарга тотына.

Кыр ышыклау өчен утыртылган урман буеннан атлаганда Зөлфәт янә шуларны исенә төшерде: үткән сабый чагы, малай вакыты хәтерендә калыкты. Әнә ул оныта алмаган ямьле Ык елгасы! Ул бормалана-бормалана ага. Кармак салам дип, шушы елга буенда күпме таңнарны йокысыз үткәрде Зөлфәт. Ярларыннан шуып, күпме күлмәк-ыштан туздырды. Аяк-куллары чебиләнеп, әнисеннән никадәр әр-кызгану ишетте...

Зөлфәт, хискә бирелеп, кайтыр юлында туктап калды һәм урман эченә кереп, плащын жиргә ташлады да сузылып ятты, төпсез зәңгәр күккә карады.

Менә ул, ниһаять, тагын кайтты. Бүген кич белән үк ул Мәснәвияне күрер һәм алар кулга-кул тотынышып елга буена төшәрләр. Төшәрләр дә Зөлфәт аңа куанычлы бер сүз әйтер...

Ничек башланды соң әле? Бергә кинода утырулар, ояла-тартына күзгә-күз карашып алу, Ык буена төшү, иңне-иңгә куеп, яр кырыенда басып тору...

Бу көнне Мәснәвия аңа аеруча якынлык тойды бугай. Ул еш кына сулыш ала, Зөлфәтне үсендереп, аңа назлы караш ташлый, шул ук вакытта юашлана, күндәмләнә килеп, аның кочагына сыена бара иде.

Зөлфәткә бу минутларда рәхәт иде, ул бәхетле, шат иде, күрәсең, кыз да моны тойды. Кызның күндәмләнеп калуын сизгән Зөлфәт Мәснәвиянең биленнән кысып алды да куе үлән эченә ятты. Егет кызны кочты, сөйде дә кисәк тынып калды.

Икесенең дә йөрәкләре күкрәк читлегеннән чыгардай булып тибә, икесе дә кинәт кенә ташып киткән мул тойгыдан гүя исереп калганнар иде.

Кояш баеп бара. Тирә-юньдә кошлар сайрый, сандугач чутылдап куя, аръякта яр карлыгачлары чыркылдашалар.

Шунда Зөлфәт төбәлеп кызга карады. Кыз да аңа, сирпелеп, күзйөзе белән елмаеп куйды. Һәм Зөлфәткә шул житте. Ул кызның сизелер-сизелмәс кенә үзенә сыена төшүен тоеп, аның биленә кулын салды. Мәснәвия аңа кисәтүле-моңсу караш ташлады. Аннары керфекләрен каккалап:

— Кирәкми, Зөлфәт,— диде.

Ләкин бу кисәтү-үтенүне Зөлфәт үзенчә аңлады. Ул кызны янә кочагына алды һәм үлән тәме аралаш хуш ис тоя-тоя үбә башлады. Кыз үзен иркәләүдән наз таба һәм егет сөйгән саен йомшара, кайнарлана, юашлана бара иде.

— Зөлфәт,— диде кыз пышылдап, хуш истә исергән күбәләктәй, тавышсыз гына егет кочагына сеңә барып, күзләрен йомды.— Син мине гел шулай яратырсыңмы?

Нәкъ менә шунда Зөлфәтнең күңел түрендәге шофер Касыйм салган тиле-ярсу коткы чаткысы чәчрәп китте. Касыйм аның белән бергә, бер хуҗалыкта эшли иде, ана Мәснәвияне яратуы турында сөйләгәч, ул: «Ычкындырма кызны, үзеңнеке ит»,— дигән иде. Шул сүз Зөлфәт зиһенендә кабатлана башлады. «Үзеңнеке ит, үзеңнеке ит...»

Шушы коткыга, аннары назлаган-сөйгән саен күндәмләнә барган кызның карусызлануыннан Зөлфәт тәмам кыюланды, үз-үзен тыймас хәлгә житте... Шул минутта Мәснәвиянең йөрәген кинәт курку алды. Күз ачып йомганчы, кыз аның кочагыннан ычкынды да аягүрә басты. Итәгенә кунган үләннәрне каккалаган булды да яр кырыена таба китте.

Зөлфәт оятыннан йөзтүбән капланды да тынып калды. Аның бу хәрәкәтен күз кырые белән генә күреп, күзәтеп торган Мәснәвия егет янына килде, тезләнде һәм чәченнән сыйпый-сыйпый:

— Әйдә кайтыйк, Зөлфәт, кич житте инде,— диде.

Кызның якын итеп дәшүенә егетнең күңеле йомшарып китте, күзенә яшь килде. Ахыр түзә алмады, әйләнеп, чалкан ятты. Егет күзендә яшь күргәч, Мәснәвия бер мизгелгә аптырап калды.

— Зөлфәт, кирәкми, мин куркам синнән...

Зөлфәт аңа яшьле күзләре белән томыраеп карап торды. Кыз моны күрде һәм бу мизгелдә аңарда егетне кызгану хисе уянып китте. Ул Зөлфәтнең күз яшен сөрткәндәй итте һәм үзе үк иелеп үбеп алды. Аннары ул аның чәч-битеннән сыйпаштырды, Зөлфәт бу иркәләүгә оеп, күзен йомды.

— Мәснәвия, әйдә минем белән Казанга?

— Казанга? — диде Мәснәвия һәм бер тын офык читендәге кара болытлар астына кереп барган кояшка карап торды. Елга өстендә моторлы көймәгә утырган өч кеше күренде. Берсе бишгәр-әйберләр өстенә менеп утырган да гитарада уйный, икенчесе авыз эченнән генә жырлый, өченчесе мотор янында кайнаша.

«Ватылган»,— дип уйлый Мәснәвия, ә үзе күңел түреннән хәзер генә Зөлфәт әйткән тәкъдимне алып ташлый алмый иде.

— Әйдә Чаллыга, Зөлфәт. Анда зур төзелеш башлана, ди. Кайт шунда...

Зөлфәт терсәгенә таянып, күтәрелә төште, авызына үлән өзеп капты.

— Уйлап карарга булыр. Таксида эшләү төшемле бит. Жәл бераз... Казан... Такси...

— Ә син жәлләмә...

— Чаллыга күчсәм, син анда килерсеңме соң?..

— Башка берәүгә гашыйк булмасаң, кайтып алырсың, яме?..

...Икенче көнне Мәснәвия аны автобус тукталышына кадәр озата килде. Саубуллашулары бераз сәеррәк чыкты. Кеше күплектәнме, үз эшләре янында картлар булгангамы, Мәснәвия үбәргә үрелгән Зөлфәттән оялып-тартынып китте.

— Кирәкми, Зөлфәт абый. Мин оялам.

Ә инде, әрсезләнеп, Зөлфәт кочып үбә башлагач, саубуллашмыйча йөгереп китеп барды.

Мәснәвия аңа «абый» дип беренче тапкыр әнә шунда дәшкән иде. Ләкин Зөлфәт анда моңа гел игътибар итмәгән булды. Ул соңга табарак моның сәбәбен белде: Казанга киткәннән соң Мәснәвиядән хат килми башлагач төшенде.

Хәер, Зөлфәт тә эш белән мавыгып, беразга онытылып йөрде түгелме? Бер-ике тапкыр таныш кызлары белән кино-театрга баргалады бугай. Әмма берсен дә яратып китә алмады. Күңеле авылга тартты, Мәснәвияне күрәсе килде, аны юксынды. Әнә шул юксыну аны Чаллыга алып кайтты.

«Күчеп берәр*ай эшлим дә кайтып алам үзен»,— дип эшкә керешкән иде Зөлфәт, ул дигәнчә булмады. Машина бирмиләр. Ул гынамы, җитмәсә, өч-дүрт көнгә туган авылына ялга җибәрми йөдәттеләр.

Әмма хәзер инде барысы да артта, барысы да анда калды, ул туган авылы кырында, ярты сәгатьтән әнисен, кич белән Мәснәвияне күрәчәк. Күрәчәк һәм...

Шуның өчен, шул чәчби өчен Казанын, менә дигән «Волга»сын ташлап Чаллыга кайтты түгелме? Эше эш булса иде — слесарь. Әле кайчан машина бирәләр, бер алла үзе дә Бабай гына белә.

Зөлфәт эшкә кергән автохуҗалык начальнигын һәммә шофер Бабай дип йөри, әйтерсең аның исем-фамилиясе дә юк иде; Зөлфәт тә аны шулай дип йөри башлады.

Шулай уйланып-хыялланып ята торгач, ул мотоцикл тавышы ишетте. Башын күтәреп караса, бишекле «өчтәгәрмәч» килә. Зөлфәт торып басты да кулын күтәрде. Бу — колхоз бригадиры, Мәснәвиянең абыйсы Фатих иде. Зөлфәтнең эче жуу итеп китте.

— Тпру-у, нәгаләт! Кара син аны, килеште моңа колхоз бензине, һич тыймалы түгел үзен,— дип сөйләнә-сөйләнә, Фатих мотоциклыннан төште һәм Зөлфәткә кулын сузды.

— Исән-сау кайтып килүме, Зөлфәт энем?!

Зөлфәтнең бу кешедән башта сеңелесе Мәснәвия турында сорарга теле кычытып торса да, яхшысынмады, тыелып калды.

— Болай ярыйсы кебек. Кайтып киләм менә...

— Әйдә, утыр бишеккә, апкайтам үзеңне. Сөендерим әле Кәшифә түтәйне. Әле кичәгенәк кенә синең турыда сөйләшеп торган идек. Үпкәләгәндәй итә, имеш, тегеләй дә, имеш, болай...

...Мотоцикл өй янына туктауга, Зөлфәтнең күзенә түр тәрәзәдәге әнисенең аклы яулыгы күренеп китте. Икенче мәлдә ул бәрелә-сугыла җил капканы ачты һәм ашыгып-кабаланып ишектән чыгып килүче әнисенә каршы китте.

— Балам, бәбкәм!..— Кәшифә түти яулык читен күзенә тидереп алды, аннары улын сөя-сөя: — Исән-имин кайттыңмы, улым?..— диде.

— Таштай-тукмактай мин, инәй. Шофер кешегә ни булсын...

— Алла диген, улым...

...Улы кайту куанычыннан нинди ризык-нигъмәтләр хәзерләргә, Зөлфәтенә нинди яңалыкларны баштан сөйләргә белми аптырап калган иде. Зөлфәт әнисеннән Мәснәвия турында сорарга дип берничә тапкыр ымсынып куйса да, ничектер, базмады, кодрәте җитми торды. Яхшысын да, яманын да әнисе авызыннан ишетергә теләүдән түгел иде бу, аңа шатлыгын, аның өчен изге булган кавышу минутларын кисәргә теләмәүдән сорарга кыймый утыруы иде.

Шулай да табын әзер булгач, ризык-нигъмәт янына утыргач, Зөлфәт аңа өйләнергә теләве турында әйтте.

Кәшифә түти үз гомерендә бик күп нужа-хәсрәт күргән, сугышта яраланып кайткан ир-канатын берничә елдан үз кулы белән җирләгән, дөньяның ачысын да, төчесен дә күп татыган кеше иде, ул Зөлфәтнең тел төбен ике сүзеннән үк аңлады һәм, күңеленнән улының бераз тернәкләнеп китмичә ашыгып өйләнүенә рәнҗесә дә, бердәнбер баласының бәхетенә күләгә төшерергә теләмәде, күрәсең:

— Нишлисең инде, бәбкәм, бик теләсәң өйлән. Югыйсәң, өлгерер идең. Тозы булса, кызы булыр иде әле,— диде.

Зөлфәт моны: «Әни Мәснәвиягә өйләнүемә риза»,— дип кабул итте.

Әмма ана гел алай юрамады. Улым шәһәрдә берәрсен тапкан да өйләнергә ниятләп киңәшергә кайткан, дип уйлый иде.

Кич житүгә Зөлфәт клуб янына ашыкты. Биредә таныш-белешләр, яшьләр белән күрешкән арада ул кинәт берүзе бер якта басып торган Мәснәвияне күрде. Күрде һәм, чәчен кистереп, аны әллә ниләр эшләтеп күпертеп жибәрүенә шаккатып, бер мәл аптырап торды.

Зөлфәт кызга таба китте. Мәснәвия аңа шул кыяфәтендә тагы да чибәрләнеп, сылуланып киткән кебек тоелды. Тик нигәдер Зөлфәт килә башлауга, кыз, тынычсызланып, як-ягына карангалап алды, аннары клуб ишеге ягына таба ымсынып куйгандай итте. Йөзенә курку билгеләре чыкты. Ләкин Зөлфәт аның янына килеп житүгә, Мәснәвия тагын һаваланып китте, башын чөя төшебрәк басты.

«Һавалы кылана. Чибәр. Һич авыл кызы димәссең үзен,— дип уйлап өлгерде Зөлфәт.— Һаваланма, кызыкай, иртәгә үк муеныма сарылырсың... Беләмсең, мин бирегә ни өчен кайттым?! Сине алып китәргә... Өйләнәм мин сиңа, пумала баш. Ирең булам!»

Шул вакыт клуб ишеге ягыннан Мәснәвиягә таба борын астына кызлар кашы хәтле генә кара мыек үстергән, төз гәүдәле, жете кара чәчле, тутсылрак йөзле берәү килде һәм тәкәллефсез генә итеп кызны култыклап алды. Зөлфәт шунда ук әчке бер сизенү белән аңлады: бу егет Мәснәвиягә чит-ят кеше түгел. Ул моны кызның кара мыекка үз итеп, яратып каравыннан ук күрде. Шулай да Зөлфәт кул сузды.

— Исәнлекме, Мәснәвия! — диде Зөлфәт, кара мыекка игътибар итмәскә тырышып.

Мәснәвия башта «кара мыек»ка сирпелеп, күзләре белән рөхсәт сорады: «Янәсе, күрешимме, гаеп итмәссеңме?» Әмма «кара мыек» елмаеп баш каккач, ул тиз генә кул бирде. Кызның кулы Зөлфәт уч төбенә эләгү белән калтырый башлады. Зөлфәт әлеге егетнең Мәснәвиягә кем булуын бу юлы сизеп, күреп кенә түгел, тоеп белде һәм Мәснәвиянең хат язмау сәбәбенә шундук төшенде.

«Кияүгә чыккан!» — дигән шик туды аның күңелендә.

— Таныш булыгыз, Зөлфәт абый, минем ирем,— диде Мәснәвия кызарынып.

«Кара мыек» Зөлфәткә кулын сузды.

— Ислам!

Зөлфәт аның нык, каты кулын тотуга ук эчке икәнлеген сизде. Шунда бер мизгелгә генә күңеленә яшерен юаныч ингәндәй булды. «Әллә кемне тапмагансың, безнең иш»,— дип әйтеп куйды ул эченнән. Әмма йөрәге сулкылдап кыса башлады.

Бу минутта ул көндәше турында шулай дип уйлау буш юаныч кына икәнен дә белә, ләкин башкача була алмый иде.

Мәснәвияне ул һаман ярата иде. Зөлфәт ашкына-каплана аны алырга дип кайтты бит. Ә ул...

«Сөйгән ярны күз түгел, йөрәк сайлый,— дип әйткән иде аңа берәү.— Ялгышмадымы икән Мәснәвия бу чибәр егетне сайлап? Чибәр кулы уртак була, диләр ич. Уртаклашыр кешең булса нишләрсең?..»

## 4

Чаллыга ул котырынган йөрәк белән кайтты. Китәм дип кайтты. Икенче көнне эшкә чыгуга, аны Петрович чакырып алды һәм Гатифәгә булышырга жибәрде.

— Хатын-кыз хатын кыз инде, баядан бирле су насосын сүтә алмый, бар әле, Вахитов, ярдәм ит шуңа,— диде ул. Әмма моңа каршы

җавап итеп Зөлфәт гариза сузгач, карт механик күзләрен түгәрәкләкләрде.

— Бер кешене икегә ярырга торганда, нишләвең бу?.. Әллә квартираңнан куалармы?.. Юк. Шулай булгач... Менә нәрсә, Вахитов. Атнаун көннән безгә яңа машиналар кайта, түз шуңа кадәр. Өр-яңасына утыртабыз үзеңне, нульдән башларсың.

Зөлфәт икеләнә калды. Кичәге ачуы бераз сүрелә төшкәндәй булды. Партоешма секретареның нык ышандыруы аның күңелен йомшартып җибәрде.

— Вәгъдәгездә торырсызмы соң?

Карт механик гаҗәпләнеп аңа текәлде.

— Минем әле моңа кадәр берәүне дә алдаганым булмады... Комсомол бит син?..

— Әйе...

— Шулай булгач. Кал, Вахитов. Менә мин карт коммунист, сорыйм синең биредә калуыңны. Минем өчен генә түгел, ил өчен, Ватан өчен... Кызыл сүз сөйли дип көлмә син, егет... Хагы шул. Бөтенләе белән комсомол төзелеше бу. Я инде, комсомоллар да ташлап китсә, кем төзергә тиеш бу гигантны? Американ дяданмы?. Кал, Вахитов...

Зөлфәт гариза кәгазен ерткалап ташлады. Юк, ул Петровичның үгетенә бирелмәде, ул аның үз итеп, гади итеп дәшүенә йомшарды.

— Мин менә пенсиягә чыгарга бер ел калгач булса да эшлим. Шулай кирәк, туган...— диде Петрович, аның гаризасын ертып ташлавын күргәч.

Гатифә эшләгән МАЗның алды яньчелеп, изгәләнгән булса да, спидометрына караганда машина күп йөрмәгән иде әле. «Хатын-кыз хатын-кыз инде, машинасын да карый белми»,— дип уйлады Зөлфәт. Әмма ул килеп туктауга, Гатифә аңа хәтта күтәрелеп тә карамады. Хатын кабина баскычына утырган да су насосын сүтәргә маташа иде.

— Сәлам!

— Әйдә, дускай. Петрович җибәрдеме?

— Әйе. Булышырга, ди. Хатын-кыз ирләр ярдәменнән башка яши дә, эшли дә алмый, ди.

Гатифә аңа төртелеп карап алды.

— Авызыңны сөрт башта.

— Нәрсәкәй?

— Ирен читеңне сөрт дим. Йомырка сарысы каткан...

Зөлфәт ялт кына машина көзгесенә күз төшереп алды. Чынлап та, ашханәдә яңа гына куырган йомырка ашап чыккан иде, бер валчыгы мыекка эләгеп калган икән...

— Рәхмәт. Петрович янында ун минут басып тордым, әйтмәде.

— Ул карт ни күрсен. Биш адымнан карчыгын танымый бит ул. Бер көнне эштән кайтканда каршысына килгән карчыгы белән исәнләшеп киткән. Карчыгы: «Ваняша, это ведь я, что ты здороваешься как с чужой?» — дигән үзенә.

— Ха-ха-ха!..

— Көлмә. Картлык ул сиңа да килер.

— Килсен. Барыбер кызык. Кая, бир насосыңны, хәзер сүтеп җыябыз аны...

— Мә. Каһәр төшкән насос булды бу! Икенче фибраны ашап бетерә инде...

Зөлфәт Гатифәнең май-дегеткә буялган кулларына һәм ничектер юанаебрак торган гәүдәсенә күз төшерде дә: «Әллә үзе юан, әллә йөкле бу нәмәстә?» — дип уйлап алды.

— Алайса, җегеткәй, син сүтә тор, ә мин складка барып фибра алып килим.— диде Гатифә.

— Мәйле, һоп!
— Таҗикмы әллә син?
— Юк, үзбәк. Урта Азиядә танк училищесы бетергән идем.
— Шулаймыни? Алайса, әйдә, башта танышыйк,— диде Гатифә, кулын сузып.— Мин үзем Гәрдәледән. Яшь чагымда мин дә шул якларга кияү эзләп барган идем...
— Әллә анда кияүгә чыгу җиңелрәкме?
— Берни булса безнең татар кызлары Урта Азиягә китәләр иң. Безнең авылның берәү әнә китте дә бер үзбәккә кияүгә чыкты. Утыз ике яшендә, җиде баласы бар инде. Кышлакта тора. Ире туганнары янына да җибәрми үзен. Җүдә яфрагыдай агарып калган тегә. Ни йөзе, ни сыны, ни үзе калмаган. Иөри шунда шәүлә булып. Шуны күрдем дә мөнә туган ягыма кайттым. Ә бит Урта Азиягә мин дә шундый ният белән барган идем. Мине дә бер үзбәк димләгән булды, чыкмадым үзенә. Өен күрсәтте. Өе өй булса иде: тирәли дувал, кеше кермәле, кеше күрмәле түгел. Юк, мин әйтәм, рәхмәт әкә, мин туган ягыма кайтам... Үзегез ашагыз йөземегезне, безгә аны әрмән-грузин да китереп тора, базарга барсаң ерып йөрмәле түгел, дидем...
— Шәп әйткәнсең!
— Нәмәрсә?
— Калмыйча шәп иткәнсең дим... Бар, тизрәк китер фибраңны...
Зөлфәт валикны сүтә алмагач, бокска китте. Ул әйләнеп килүгә, машина янында бер тамаша күрде. Бугаз төере тәртеп торган Бакыйҗан атлы слесарь белән Гатифә тарткалаша. Хатын слесарьның якасыннан эләктергән дә ачкычлар даулый иде.
— Ничәле ачкычны чәлдең, Бакый? Ташлыйсыңмы, юкмы син шул гадәтеңне, мөртәт нәмәстә!..
— Ипи мөнә, җир упсын, бер әйберенә тимәдем, Гати. Мөнә бу кешене күрергә дип кенә килгән идем. Сигарет сорарга дип... Бир әле, парин, берне, үләм инде, иртәннән бирле тартмаган... Җибәр әле, җибәр изүдән, Гати.
Гатифә, аны ычкындырып, ачкычларын барлый башлады.
— Унҗиделе, уидүрт тә уникеле ачкычларым юк, ә егерме икеле торсовый ачкыч кая?.. Их, мут йөрәк, синең эшең бу, Бакый!
— Гатикә җаным, зинаһарлап әйтәм, не ыскарбләй ир-атны. Бакыйҗан абыең шуның белән ваклана торган кешеме! Теләсәң, хәзер бер сумка ачкыч китерәм үзенә, җаның кайсын тели шунсын ал...
— Миңа кешенеке кирәкми, син миңа үземнекеләрне бир!..
— Мөнә алама хатын, иманы юктыр моның, тиктомалга яла яга бит, ә!..
— Әле аламамы! Аламамы мин, умач бурзае! — дип, Гатифә аны кинәт тәртеп җибәрде. Зөлфәттән сигарет кабызып маташкан Бакыйҗан артына утырды, аннары әллә юри, әллә чын — сузылып ук ятты.
— Бирәсеңме, юкмы ачкычларны, ут борчасы?!.
— Гати, нишләвең бу! Ай-ай-ай!
Гатифә кулына зур ачкыч алып, баш очына күтәрде.
— Кая ачкычлар?.. Әйт! Югыйсә, башыңны сугып ярам!..
Бакыйҗан яткан килеш ике кулын күтәрде, ялына-ялвара башлады, ләкин күренеп тора: ул моны юри Гатифәне үртәү өчен кылана иде. Гатифәнең моңа ачуы чыкты, чәбәләнеп яткан Бакыйҗанның өстенә утырды.
— Ай-ай-ай!.. Тор өстән, албасты. Сытасың ич... Әйтәм Толик минем кебек чандыр, син җәфалыйсың икән аны...
— Эһ, тинтәк, умач бурзае, әле дә син мине Толик белән үртисеңме?!
Гатифә кулындагы ачкычын җиргә ташлады да Бакыйҗанны ике куллап кытыклый башлады.

— Ал-ла-ла... Гати жаным, ка-гыл-ма тә-не-мә... Кы-ты-гым ки-лә...
— Әһә, син, мөртәт, җитмәсә, көнче икәнсең...
Бакыйҗан, кытыклауга түзә алмыйча, үрле-кырлы сикерә-сикерә чәбәләнергә тотынды...
— Җи-бәр, җибәр дим... Га-ти... Эһ-эһ-эһ...
Шунда Бакыйҗанның итек кунычыннан бер ачкыч төште. Моны күреп, Гатифә анын өстеннән сикереп торды да итекләрен салдырып алды. Итек эченнән шыбырдап тимер-томыр, ачкыч-отверткалар коелды. Боларны күргәч, Гатифәнең күзләре шар булды.
— Әнекәем, фибралар! Ә мин гараж бетереп фибра эзлим. Менә, менә минем ачкычлар да... Ф-у, бур шайтан!..
Гатифә кулындагы сыңар итек белән Бакыйҗанга җилпеп алды.
— Чистый иблис икәнсен! Карасана, ничаклы фибра җыйган!..
Сыңар итеген кияргә өлгергән һәм бер аягында титаклап сикергәләп торган Бакыйҗанга Гатифә бу юлы чынлап торып итек кунычы белән сыптырып җибәрде.
— Каравыл! Үтерәләр!..— дип кычкыра башлады Бакыйҗан. Шул авазны ишетепме, гаражның теге башында Петрович күренде.
— Кит, җан көеге!
Гатифә кулындагы итекне болгап читкә атты. Бакыйҗан тырт-тырт итек артыннан йөгерде.
— Тәмам бастылар бу албасты хатыннар ирләрне, тәмам изделәр,— дип сукрана башлады ул икенче итеген киеп алуга.— Карале син аны, узыныпмы-узына, сыта язды, билләһи. Эч авырта башлады... Хәзер врачка барам... Петрович,— диде Бакыйҗан, үзенә таба килүче механикны күреп.— Мин врачка киттем, ал корсак арт корсакка ябышты...
— Бар, бар, анда сине сүтеп ташлаган «Волга» көтә... Эшләп җибәр әле тизрәк... Иөдәтте инде тәмам шалтыратып...
— Кем?
— Кем булсын, икенче идарә начальнигы Сабитов...
Бакыйҗан киткәч, Петрович Гатифә янына килде.
— Ну, буламы?
— Булды кебек, Петрович...
— Машиналар җитми ди анда. Тагын берсе туктаган икән. Форсункалары янган диме... Вахитов, сиңа барып кайтмыйча булмас, ахры...
— Я, киттек, алайса, якташ,— диде Гатифә, насосны куйгач. Су салып, двигателен кабызды.— Утыр...
— Үкертмә әле шул тиклем двигателеңне,— дип кычкырды аңа Петрович.— Дулатма дим!..
Механик Зөлфәткә бер төргәк сузды.
— «53 тә 44» кә бирерсең...
— Әллә Толик туктаган? — дип сорады Гатифә.
— Туктаган шул. Фибра каян таптың? — диде Петрович.
— Бакыйҗан бирде. Толикның дусты бит. Мәгез, интеккәннәргә бирерсез...
— Рәхмәт әйттеңме хет үзенә?..
— Әйттем, әйттем...
Зөлфәт Гатифәнең кинаяләп сөйләшүенә тыела алмый шырк-шырк көлә башлады.
— Җилкуар ул сезнең Бакыйҗаныгыз, Петрович...
— Бакыйны эшкуар?..
— Юк, менә бу егет, Вахитов...
— Кеше кимчелексез булмый. Аның караvы, биредә двигатель көйләүче бердәнбер слесарь ул... Ярый, бар, китегез...

Машина Яңа Чаллының үзәк урамына килеп керде. Бер якта тугызар катлы өйләр, икенче якта бишәр, алтышар катлы биналар, клублар... Әнә шәһәр читендәге бер өй янында шкаф-шифоньерлар, өй җиһазлары төягән машиналар тора, тыз-быз кешеләр йөри, бала-чага урала.

— Төзүчеләребез бүген тагын бер өй тапшыралар,— диде Гатифә күрсәтеп.— Бәхетлеләр квартир ала...

Участокта аларны күптән көтәләр иде инде. Зөлфәт машинадан төшү белән, МАЗ үзбушаткычның кабинасын мәтәлдереп куйган егет:

— Озак йөрисең, Гати,— дип үпкәсен белдерде.

Гатифә аның янына килеп, аяк очларына басып, үрелеп, егетнең битеннән үбеп алды.

— Ачуланмасана, Толик җаным. Су насосым бозылды бит. Иртән кабызып чыгуым булды...

— Булдымы соң, ясадыңмы?

— Ясадык. Рәхмәт, менә бу егет булышты. Таныш бул, яңа слесарь.

Толик майлы кулын Зөлфәткә сузды.

— Әйдә, дускай. Эшләп куйыйк әле шул форсункаларны. Югыйсә, искеләре төти башлады, чыдарлык түгел...

Аннары ул Гатифәгә таба борылды.

— Кил әле, Гати. Үп тагын берне... Үп-үп!

— Я инде, кыланып маташма,— диде аңа Гатифә.

— Үп дим, югыйсә, әйтмим.

— Ни әйтмисең?..

— Сөенче. Куанычлы хәбәр! Ишетү белән үрле-кырлы сикерерсең менә...

Гатифә тәкәллефсез генә аны ике битеннән үбеп алды.

— Менә ал, түш кесәсендә,— диде Толик.— Ал инде!

Гатифә аның кесәсеннән бер бит кәгазь тартып чыгарды, укыды һәм чыннан да бала-чага кебек үрле-кырлы килеп сикергәләнә башлады.

— Толик җаным, Толик җаным. Квартир, квартир... Уф! Кил әле, кил тагын бер үбим үзеңне... Ммм-м!.. Менә... Кайчан бирделәр?

— Үзем дә белмәдем... Бабай чакырып алды да, Петрович та шунда утыра, Нәгыйм абый да... Мә, Никулин, сезгә квартирага ордер, ди. Түбәм күккә тиде... Ышанмадым башта, шаярталар дип торам... Ә ул шунда ордерны кулга тоттырмасынмы!.. Шатлыктан барысын үбеп чыктым.... Әйтерсең нәниебез буласын белгәннәр, шайтаннар...

— Толик, Толик җаным, бүген үк күчәбезме!

— Юк, эштән соң өлгереп булмас...

— Бүген, бүген, Толик... Төне буе йокламасам йокламыйм... Хәзер нишлим соң мин?..

— Нишлисең? Эшлисең. Егетләр яналар анда, машиналар житми...

Гатифә киткәч, Толик үзалдына елмаеп Зөлфәткә сөйләп китте:

— Син безгә шаккатма, дус кеше. Гатый минем хатын ул. Бүген менә квартир бирделәр. Бала көтәбез. Яңа квартир алып, шунда тапсам иде дип хыяллана иде. Инде куанып бетә алмас...

Анатолий авыз суын корытып бала турында, Гатифәсе турында сөйләде дә Зөлфәттән:

— Үзең слесарьмы, әллә шофермы? — дип сорады.

— Шофер. Армиядә танк йөрткән идем. Күргәнең бардыр, шәт, суда да йөзә торган... Аннары Казанда таксида эшләп карадым...

— Шәп машина,— диде Анатолий хәрби техникага соклануын яшермичә.— Шул техниканы бирегә кайтарсаң иде икән. Әйтик, бөтен дөньядагы хәрби техниканы тынычлыкка эшләтсәң... Бер елда димим, ике елда кешелек коммунизмда булыр иде...

Анатолий беравык зәңгәр Һавага, сирәк-мирәк күренгән ак болытларга карап торды.

— Инде күз дә житте, һаман яңгыр яумый. Озакка сузылды бу әбиләр чуагы быел... Үзеңнең правың бармы?

— Бар.

— Ничәнче класс?

— Өченче.

— Ярый өченче дә. Ләкин, машина бирсәләр, КрАЗга утырма, МАЗга утыр. КрАЗлар әнә карьердан да чыкмыйлар, сукыр тычкан кебек гел шул тирәдә әйләнәләр... Шофер ул тизлекне тоеп эшләргә тиеш... Кайда хезмәт иттең?..

— Урта Азиядә, аннары ГДРда...

Шул чак алар янына күксел төстәге МАЗ килеп туктады. Кабина ишеге ачылуга, Зөлфәтнең йөрәге кысылып, эче жуу итеп китте. Шофер кеше Ислам иде.

— Толик, тизрәк маташ, өлгермибез! — диде ул һәм, Зөлфәтне күрүгә, авыз чите белән генә елмаеп куйгандай итте.

Зөлфәт бу очрашуны көткән иде, әмма Чаллыда, үзе эшләгән автохужалыкта түгел. Ул аны я монтажчы, я ташчы дип юраган иде, ә ул әнә кем икән — шофер. Димәк, Мәснәвия дә Чаллы кешесе булып китте болай булгач. Димәк, теге көнне алар әби белән бабай коймагын ашарга һәм мәтрүшкәле, хуш исле каен себеркеләр белән булап куйган кияү мунчасына керергә генә кайтканнар?.. Нигә соң әле бер айга якын эшләп, аның бу Исламны күргәне булмады? Хәер, шофер кеше бокска керәмени ул. Машинасы көйле йөрсә, кайтып та йөрми. Шулай да бер тапкыр күзенә чалынды бугай. Тик аны Ислам булыр дип ул вакытта башына да китермәгән иде Зөлфәт.

Анатолий киткәч, Зөлфәт олы юлга чыкты һәм юл кырыеннан гаражга таба атлады. Ләкин ерак та китә алмады, аны бер машина куып китте, туктады. Шофер Зөлфәт ягындагы ишеген ачты да:

— Әйдә, утыр, бажай, апкайтам үзеңне,— диде.

Зөлфәт бөтен тәнендә ачу кайнавын тоеп, бүртенеп чыкты. Моны Ислам да күрде булса кирәк.

— Утыр, утыр, мин барыбер гаражга кайтам,— диде ул гафу үтенгән тонда.

Кабинага менеп утыруга, Ислам аңа дымлы кулын сузды.

— Я, исәнлекме? Әйдә, күрешик, ирләрчә булсын, ни әйтсәң дә кардәшләр — бажалар бит без...

Зөлфәт дәшмәде. Ислам кырын күз белән генә аңа сирпелеп алды да:

— Димәк, бер жирдә эшлибез? Шәп! — диде.

Ислам өчен моның нәрсәсе шәп буладыр — Зөлфәт белмәде. Ә менә Зөлфәт өчен бу бер дә шәп түгел иде. Бер аңлашмыйча булмас моның белән. Аңлашмый булмас, Зөлфәтнең әллә каян эче сизеп тора моны...

## 5

Әнә шундый хәлдә ул Исламны Чаллыда күрде. Аннары Зөлфәткә өр-яңа машина бирделәр. Петрович дөрес әйткән икән, ул, чынлап та, буяу исе дә бетмәгән МАЗга утырып эшли башлады. Аны Ислам эшләгән комсомоллар бригадасына беркеттеләр. Әйе, хәтта биредә дә язмыш аларны аермады.

Эшләп китүе Зөлфәткә кыен булды. Бер өйрәнгән, инде гадәтләнеп беткән җинел машинадан йөк машинасына күчеп утыру әйбәт түгел икән. Нигәдер машина сине тыңламый, бераз киреләнә, кирәк төштә кинәт кенә туктамыйча инерция белән бара кебек. Беренче уңайсызлык-

тә ул нибарысы житмеш процент бирде. Бу хәлне бригада шундук күреп алды.

— Зөлфәт, син бераз куалый төш, күкәй ташымыйсыңдыр бит! — дигән булды аңа бригадир Анатолий.

— Син ул двигательнең Бакыйжанга күрсәт, үзенчә көйләп карасын әле. Өшкерә белә ул моторларны,— диде аңа беркөнне Гатифә.

Бүген ул иртәрәк уянган иде, ашыга төшкән иде, барыбер путевканы иң соңгылар белән алды.

Капкадан болай жилле чыгып китте. Теләге эшләп карау иде. Двигатель әйбәт тарта кебек. Ә менә йөк салдыңмы, тыела да кала, әйтерсең суларга һава житми.

Котлованга житәрәк ул машинаның тизлеген баса төште һәм үзбушаткычын экскаватор чүмече астына куюы булды, аны көтеп алган машинист:

— Озак йоклыйсың, Вахитов, әнә Байтимеров икенче рейска кайта инде,— дип, болай да кайнап торган Зөлфәтне үртәп алды.

«Әллә соң бу Исламга кимрәк саламы?» — дигән шик төште Зөлфәткә.

— Ничәне тондырыйм? Барыбер әкрен йөрисең, әйдә, берәрне ким салыйм булмаса,— диде машинист кычкырып.

— Теленә салышма, кешегә күпме саласың, миңа да шулай сал,— диде Зөлфәт, йөрәге кабара баруын тоеп. «Соң нигә әле аңардан барысы да көләләр?»

Экскаваторчы юри әкрен маташты һәм чынлап та берне ким салды бугай.

— Сал тагын берне! — дип жикерде аңа Зөлфәт, кабинадан чыгып.

— Жилле егет син, Вахитов, билләһи менә. Мә соң, балчык жәлмени! Тик кара аны, соныннан миңа үпкәләмә!..

— Төкерәм мин сезнең барыгызга да...

— Төкермә, авызың кутырлар,— диде экскаваторчы.— Нигә дулыйсың әле син? Тиктомалга мине сүгәргә кем сиңа права бирде! Бик узынсаң, ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә күп сорамам мин...

— Янама, дус кеше. Без дә төшеп калганнардан түгел. Әйдә, төявеңне бел!

Экскаваторчы жил-жил төйи башлагач, Зөлфәт чынлап та шиккә калды. «Әллә берне артык тондырды инде бу мәртәт!»

Йөк артыгы белән авыр иде. Моны машина кузгалу белән сизде. Двигатель төтенли башлады, кабинага янган май, солярка исе тулды. Котлован үрен менгәндә Зөлфәт беренче тизлеккә күчте, әмма барыбер мотор сыкранды, тартмады. «Бу ни бу? Нигә тартмый?» — дип уйлады ул, курка калып. Үр шактый текә, тар, машинаның туктап, салулап китүе бар иде. Ярты үргә житмәде, кабинага ят ис тулды.

«Муфта яна!» — дигән уй зиһенен телеп үтте Зөлфәтнең.

Йөк авыр салынса, МАЗның рессорлары каерылып төшә, көпчәкләр тимер әржәгә тиеп, кайчан көйгән резин исе чыга торган иде. Ләкин Зөлфәт әйбәт белә: резин исе түгел иде бу.

Куркыныч уй кинәт килде. «Муфта өзелеп, машина түбән тәгәрәсә! Дөрес, тормоз бар... тик бу тикле авыр йөкне тормозлар гына тота алырмы?»

Зөлфәтнең күз алдына өч көн элек таудан мәтәлеп төшкән КрАЗ шоферы килде. Егерме-утыз тонналы машина башта салулап китә, аннары каплана. Шофер исән кала калуын, ләкин кеше була алырмы? Сынмаган сөяге калмаган, диделәр.

Зөлфәтнең аркасына салкын тир йөгерде. Ә бит муфта өзелсә, яки янып чыкса, машина котылгысыз төстә артка шуачак. Анда инде зур афәтне көт тә тор.

Зөлфәт газга баса төште һәм ялгыш эшләде. Мотор кинәт кенә бушка әйләнеп алды. Ул да булмады, двигатель, бер бушап, бер жигеләп, үкереп-үкереп җибәрә башлады. Бу инде муфта януга сигнал иде. Үр менәргә ун-унбиш метр кала машина шып туктап калды, нәкъ шул мизгелдә мотор янында нидер чынлап, чәчрәп китте.

Зөлфәт тиз генә тормозга басты, кул тәбәлдереген тартып куйды. Ул, тын алырга куркып, машинаның туктап калуын тикшерде. МАЗ бер урында тора иде. Шуннан соң гына көзгедән артка карады. Аның артыннан тып басып Анатолий килгән икән, Зөлфәт туктауга, ул да туктаган икән.

— Ни булды? — дип кычкырды ул, кабина тәрәзәсеннән башын тыгып.

— Муфта таралды.

Анатолий чак кына артка чикте дә, моторын үкертеп, Зөлфәтнең узбушаткычын уза башлады. Биредә юл тар, узуы бик тә хәтәр иде. Зөлфәт Анатолийны туктатырга дип кабинадан сикереп төште, кул күтәрде.

— Тукта, кая керәсең, мәтәләсең ич!

— Кит аннан!.. Кит! — дип кычкырды Анатолий.

Анатолий аны ишетмәде дә, тыңламады да, Зөлфәткә юлдан китәргә кушып озын сигнал бирде. Шунда гына Зөлфәт үз машинасына игътибар итте. Үзбушаткыч, тәгәрмәч астына кыстырган ташны изәсыта, артка шуыша башлаган иде. Моны күрүгә, Зөлфәтнең чәче үрә торды.

— Харап булабыз бит, Толик!

Машина әкрен генә Толик узган якка шуыша, Анатолий үтеп өлгермәсә, аны да иләртеп котлован төбенә мәтәләчәк иде. Зөлфәт, афәт килүдән гаҗиз калып, җилкәсе белән кузов читен терәде. Җилкәсенә корыч кузов почмагы басканнан-баса барды.

Ләкин Анатолий әйтерсең аны күрмәде дә, ишетмәде дә. Аның бөтен дикъкате тар юлда иде.

Зөлфәт аңа: «Мәтәлә бит, харап була бит!» — дип коты алынып карап торды, ә үзенең машина астына керә баруын абайламый иде әле.

Менә Анатолий машинасы Зөлфәтнеке белән тигезләште, көпчәк астыннан кинәт җир убылып киткәндәй булды, шул секундта ук Толикның үзбушаткычы кырыная башлады.

— Толик, Толик, газ бир, газ!

МАЗ үкереп куйды — мотор капот астыннан очып чыгардай булып дулап алды. Һәм инде кырыная башлаган машина кинәт турайды, юлга чыкты.

— Толик, Толик, тизрәк!.. Трос китер, трос!..

Машина һаман шуыша, бер як читкә тая-салулый бара иде. Зөлфәт өстенә таба килгән машинаны җилкәсе белән терәп тормакчы итте.

— Җүләр баш, кит аскы яктан, машинан авып, сытыласың киләмени! — дип суырып алды Анатолий аны.— Мә, тот трос. Сүт, сүт тизрәк...

Ниһаять, трос сүтелде, ике ыргакка да эленде.

— Әйдә, утыр машинаңа. Тиз!

Зөлфәтнең үзбушаткычы убылгы төшкә килеп җиткән, тик ниндидер аңлашылмаслык бер көч белән генә ычкынмыйча тора иде.

Анатолий тросны тарттыра башлады. Бер дюймлы корыч трос гитара кылыдай тартылып китте.

— Тарт!..

...Үр артта калгач, Анатолий туктады һәм кабинадан төшеп, Зөлфәт янына килде.

— Тартырга бармы?
Зөлфәт аңа сигарет сузды.
— Тәвәккәллек үзеңдә, Толик,— диде Зөлфәт, сигарет сузып.
— Аны, туган, син дә шулай эшләр идең,— диде Анатолий. Ул берни булмаган кебек кыланырга тырыша иде, әмма Зөлфәт аның тәмәке кабызганда калтыранган кулларын күреп, үзәлдына оялып китте.
— Гафу ит,— диде ул.
— Ни өчен?
— Мин уңмаган нәмәрсә аркасында тормышыңны кыл өстенә куйдың...
— Шофер эше бәла-казалы ул, Зөлфәт. Шуңа күрә бар кеше дә шофер булып эшли алмый.
— Анысы шулай,— диде Зөлфәт, колакларына ут капкандай кызарынуын тоеп. «Әллә соң мин дә йөк машинасында эшли алмыйммы, әллә соң китәргәме?» — дип уйлап алды ул.
— Сине, бәлки, гаражга илтергәдер? — диде Анатолий.
— Вакытың алмаммы соң?
— Вакыт?.. Изгелеккә киткән вакыт җәл түгел ул...
Зөлфәт, ике слесарь ярдәме белән, яңа муфта дискасын караңгы төшкәндә генә куеп эшен бетерә алды. Кайтышлый Иске Чаллының шәһәр уртасындагы сыраханәсенә керде. Бу сыраханә кадим заманында салынган иде булса кирәк. Зөлфәт бирегә кергән саен колач житмәстәй бүрәнәләрдән күзен алалмый. «Кемнәр күтәреп салды икән шуларны, нинди газиз башлар хезмәте икән?»
Шунда аның җилкәсенә берәү кагылды.
— Әйдә, Вахитов, безнең компаниягә. Син, парень, ят кешедәй гел ялгызың йөрисең... Әйдә, әйдә, Ислам бүген премия алды, бөтен бригада монда...
Зөлфәт теләр-теләмәс кенә Анатолийга иярде.
— Менә Вахитов та килде,— диде аны күреп Гата.
Экскаваторчы Зөлфәткә янәшәсеннән урын бирде. Ул уң ягында утырган Әнәс атлы шоферның җилкәсеннән кочкан иде.
— Әйдә, Зөлфәт, утыр, менә Әнәснең дә синең белән саласы килә...
Зөлфәт дүрт-биш өстәлне янәшә куеп утырышкан шоферларга, слесарьларга күз йөртеп чыкты. Бакыйҗан аны күрүгә:
— Ба-а, братцы, Вахитов. Син дә дөньяда бармыни?! — дип шаулап күтәрелде.
— Синең хәер-фатихада яшим әле менә...
— Минем хәер-фатиханы алмаганга соңга калдың да син бүген, малай актыгы...
— Җәмәгать,— дип торып басты Ислам.— Без монда бүген тикмәгә генә кермәдек. Минем көрәп алган акчаны туздырырга моннан башка да урын табылыр иде. Без бирегә, дуслар, коллективның бердәмлеген сынау өчен килдек. Ләкин бездәге кайберәүләр нигәдер коллективтан читләшәләр. Үз итмиләр димме?..
— Кызыл сөйләмә әле, Ислам,— диде Бакыйҗан.— Иртәгә Бабай алдында сөйләргә калдыр бу сүзләреңне. Менә өстәлдә пиво бетте, шуңа ниишлибез?..
— Һәй, апасы, кил әле бире! Кил әле, кил! — дип, Ислам сыра сатучыны чакырды.
Мичкә ачып кайнашкан хатын аңа таба хәтта әйләнеп тә карамады. Исламга бу ошамады. Ул, кузгалып, сатучы янына килде.
— Карале, апасы, сезгә дәштем түгелме мин?..
— Миңа булса соң! Сез монда йөзәү, ә мин берүзем... Ни кирәк, әйт, күзеңне алалардырма, иремнән дә тук...
— Менә бу мичкәдәге пивоның бәясе күпме?

— Йөз литрмы?
— Күпме тора шул?..
Хатын бәясен әйтте һәм китмәкче итте.
— Туктале, апасы...
Ислам кесәсеннән бер уч акча чыгарды.
— Мә, санап ал, житмәсә — әйтерсең.
Сатучы хатын моңа бер ышанырга, бер ышанмаска белми аптырап калды.
— Мә, мә!..
Ислам учындагы акчаларны мичкә өстенә сипте.
— Сана!
Ислам артына килеп баскан Бакыйжан «урра!» кычкырып жибәрде һәм сырага акча түләүчене чөяргә тәкъдим итте. Бер төркем егет Исламны элеп алды да чөяргә кереште.
— Раз, два — молодец! Три, четыре — молодец!
Егетләр чөеп туктагач, Ислам эре генә кыяфәттә өстәл янына килде, кәефләнеп өлгергән Бакыйжан аның янында бөтерелә башлады.
— Ну, жегет тә соң үзен, билләһи-валлаһи, ә?! Ну, әйтегез әле, егетләр, кайсыгыз шулай булдыра ала шуны, кайсыгыз?! Юк, булдыра алмыйсыз!. Молодец, Ислам, мең яшә!..
Бераз кәефләнеп алгач, Ислам Зөлфәт янына килеп утырды.
— Арумы, бажай?
— Бер көйгә.
— Бүген муфтаң очкан дип ишеттем.
— Очты...
— Нигә син, Зөлфәт, алай бик төксе сөйләшәсең минем белән. Әллә тагын Мәснәвия өченме?..
— Аның өчен минем сиңа ачу тотканым юк, Ислам.— Чынында исә Зөлфәтнең нәкъ әнә шуна ачуы килә иде күп вакытта.— Ә менә кирәкле-кирәксез төштә кысуың өчен гафу итә алмыйм.
— Гафу итә алмыйм, имеш. Ярый соң... Безнең үпкәләшүдә минем гаебем зуррак икән, син, Зөлфәт, ир егет булсаң, кичер мине...
Зөлфәт Исламнан моны көтмәгән иде, кисәк күңеле йомшарып китте.
— Без күкәй ташымыйбыз, Зөлфәт. Инде эшкә керешкәнсең икән, безнең йөзгә кызыллык китерергә тырышма... Анатолий ул йомшак күңелле, синең күзеңә бәреп әйтергә ояла, ә мин — юк. Жебегән син, Зөлфәт. Жебегән булып уләрсең дә...
Зөлфәтнең чигәсендә сулкылдап кан тибә, ачуы кабара башлады.
— Син кәперәймә, Ислам. Мин сине тиздән ярышка чакырачакмын!..
Ислам аңа беравык текәлеп карап торды. Аннары:
— Бирсен ходай! — диде һәм тәкәллефсез генә торып китте.
Сыраханәдән алар шактый соң чыктылар, әмма кояш баемаган иде әле. Барысы да кәефле, һәммәсенең дә сүзе күбәеп китте. Тротуарны иңләп атлаган төштән каршы килүче бер кызны күреп, Бакыйжан егетләрне ике якка аерды.
— Юл бирегез, юл, егетләр. Хан кызы килә!..
Кыз аптырап калды, ике якка аерылган төркемнең әле берсенә, әле икенчесенә карап алды да, шофер егетләр икәнен танып, кыюланып алга атлады. Бакыйжан аңа юл бирү генә түгел, комплимент та әзерләп куйган икән. Кыз аның янына житүгә, ул:
— Ә без, сылукай, бередән Чаллының чибәре үтәргә тиеш дип, иртәдән бирле көтеп торабыз,— диде. Кыз теләсә-теләмәсә дә, бөтен күзе-йөзе белән елмаеп, керфек астыннан гына егетләргә өздереп карап үтте.

— Һай, чибәр дә соң шайтан! Зифалыгын күр син аның!..— диде Гата. Ислам аның кепкасын күзенә төшереп куйды.
— Сукыраеп куюың бар...
— Ну, Бакыйҗан, төчеләнә беләсең дә үзең,— диде Анатолий.
— Төчеләнү түгел бу, егетләр, хатын-кыз күңелен күрә белү. Хатын-кыз күңеле суга сусаган гөл кебек, тәмле сүзгә сусап йөри. Ни усал хатынга әйт син берәр комплимент — эри дә китә.
— Ә мин аны булдыра алмадым инде. Мәгәр барыбер тигәнәк кебек ябышалар. Хәзер дә шулай. Ә менә сине, Бакыйҗан, хатының ташлап китте түгелме соң әле?
— Муены баш астына килсен, уңмадым мин ул хатыннан, егетләр...
— Дөнья ул, Ислам, кара аны, сиңа да килмәгәе шундый хәл,— диде Гата.
— Һа-һа-һа! Юк, булмас ул, Гата абый, булмас! — дип җикеренде Ислам гайрәтләнеп.

## 6

Үз бүлмәсенә кайтып, караватка аугач, Зөлфәт: «Ни өчен бу Ислам бәйләнергә генә тора?.. Нишләп ул шул хәтле һавалана?» — дип озак уйланып ятты. Аның һәр көн булып торган низаг-әргә күңеле тынычсызлана, тотнакланып эшләп китә алмавына эче поша иде. Ә бит ул бирегә зур хыял-өметләр белән килгән иде: Мәснәвияне алып килү, квартир алу, матур-таза гаилә корып җибәрү...
Зөлфәт сәгатенә күз салды. Диана кайтырга иртәрәк иде әле. Соңгы вакытта квартир хуҗасы Диананы күрүгә, Зөлфәттә сәер бер хис туа башлады. Бу юксыну да түгел бугай. Нәрсә булыр соң? Нигә Зөлфәт һәр кичне капка төбенә чыгып, көтеп ала аны?
Зөлфәт бирегә беренче тапкыр килеп керүен исенә төшерде. Финнарча салынган бу өйдә бер балалы семья һәм култык таягына таянып йөри торган авыру апа яши, диделәр.
Алар аны нигәдер теләми генә кабул иттеләр. Бәлкем, өйдә авыру кеше булганга шулай кыланганнардыр. Авыру апа кайбер көннәрдә төннәр буе йокысызлыктан җәфаланып чыга, сукрана, кемнедер тиргәп тә ала, гел юк-барга рәнҗи, җәберләнә, ә кайчак төнозын, тилмереп, тәрәзәдән айлы төнгә карап утыра.
Авыру хатын башта Зөлфәтне гел күрмәгәндәй кыланды, гүя ул аның өчен юк иде. Хәзер ул ачылып китте. Зөлфәт кулыннан килгән кадәр йорт-каралты тирәсендәге эшләрне карый иде, биш сотый булса да бакчаларын казып ташлады, урам як ихатаның ике черек баганасын алыштырды, кер эләргә багана утыртып, баулар рәтләп бирде, бакчага кечкенә кызларын алырга баргалады. Хуҗа хатын Диана үзе көн-төн эштә, иртә китә, кич кайта, барысын да эшләргә кулы да, вакыты да җитми иде, күрәсең. Ә менә шул эшләрнең берләзын булса да Зөлфәт карый башлагач, авыру хатын аңа акыллым дип дәшә башлады, ягымлыланып китте.
Сәгать сигез тулып килә, Диана тиздән кайтырга тиеш иде. Зөлфәт курткасын җилкәсенә салды да акрын гына аскы катка төшә башлады.
— Кем йөри анда? Зөлфәт, синме? — диде авыру хатын. Ул үзе бала белән сөйләшә, әмма авыру булса да колакка бик сак, өйдәге һәр хәрәкәтне ишетеп, күреп тора иде.
— Бу — мин, апа.
— Ә, синмени әле. Диана кайтып та җитәр инде...
Хатын: «Шуңа дип чыгасыңмы, аны каршы алыргамы? Һәр көнне... Нигә?!» — дип сорар кебек тоелды Зөлфәткә һәм ул ниндидер уңайсызлану тойды. Гүя ул әхлакка сыймаган начар бер нәрсә эшли һәм

моны авыру хатын күрә, күрә генә түгел, ул моңа рәнҗи, хәтта бу хәлдә Зөлфәтне гаепле сыман иде.

Тышта җил туктаган, аның каравы, ябалак-ябалак кар ява башлаган иде. Кар бөртекләре ишегалдындагы лампочка яктысында ак күбәләкләргә охшап тирбәлә-тирбәлә очыналар, ләкин дымлы җиргә җитү белән эреп китәләр иде.

Зөлфәт капка каршындагы эскәмиягә утырды да сигарет көйрәтеп җибәрде. Хәзер әнә теге чаттан Диана күренер. Ул да Зөлфәтне күрер. Һәр көнне үзен көтеп алуга ул да гадәтләнеп китте, Зөлфәт чыга алмаган көнне, керү белән, аңа сәер караш ташлый, ирен чите белән генә елмаеп куя, хәтта кайчак, уенын-чынын бергә кушып, бармак янап алгандай итә. Аның шулай шаян итеп, үз итеп үртәве Зөлфәткә ошый. Туктале, ошый гынамы, ул моңа гадәтләнеп бара түгелме инде? Диана кайбер көнне вакытыннан соңга калганда Зөлфәт нигәдер борчыла, сигарет артыннан сигарет тарта. Нигә булыр бу? Юк, юк... Диананың анда гел кайгысы юк. Аны күп вакытта озата киләләр. Кемнәр? Ни өчен? Зөлфәт белми ич аларны.

Күптән түгел берәү Диананы капка төбенә кадәр озата килде. Моны күреп алган Зөлфәт тиз генә ишегалдына кергән иде. Аларның һәр сүзе Зөлфәтнең йөрәгенә ук булып кадалды. Диана шырык-шырык көлә, аңа рәхәт, аңа күңелле иде. Теге кешенең мавыгып сөйләвеннән үк аңлады Зөлфәт: бу адәм Дианага чит-ятлардан түгел, я бергә эшлиләр, я бер тирәдә торалар, я...

Соңгысын Зөлфәт нигәдер уйларга курыкты. Күңел алай булуын теләми иде.

Ә шунда Диана: «Мин туңам, Харис»,— диде бугай. Һәм алар пышылдап кына сөйләшә башладылар. Аннары озатучы адәм Дианага тун, киез итек алырга кушты, кыш быел салкын буласы дип, акыл сатып торды.

«Акча юк бит, Харис»,— диде моңа каршы Диана, назлана төшеп.

...Икенче көнне Зөлфәт авыру хатынга квартир хакы кертеп бирде. Әмма хатын аны орышып ташлады.

— Шул тиклем ярдәм иткән кешедән акча алу оят булыр. Без синең үзеңә бирергә сөйләшкән идек әле,— диде.

Зөлфәт шунда битенә ут капкандай кызарып:

«Я, алайса, мин сезгә берәр машина тирес алып кайтырмын, бакчагызның җире таштай катып киткән, черемә кертергә кирәк»,— диде.

Хатын аңа:

«Кул-аягың сызлаусыз булсын, изге бәндә буласыдыр син»,— диган иде.

Зөлфәт шуны да белә: Дианага авыру хатын белән торуы гаять кыен. Кайбер төннәрне авыруның хәле начарланып китә, ыңгыраша, уфтана. Фин өенең икенче катындагы бер бүлмәсендә яшәгән Зөлфәткә аның җәфалануы, Диананың авыруны юатуы, дарулар биреп, укол кадап тынычландырырга тырышуы ишетелеп тора. Андый төннәрне Зөлфәт тә начар йоклый.

Чатта бер кеше күренде, ләкин бу хатын-кыз түгел иде. Зөлфәт аяк астына карап янә уйга калды...

— Утырасыңмы, бажай?

Зөлфәт сискәнеп китте. Ул бу кешене үтеп баручы дип уйлаган иде. Караса — каршында Ислам басып тора. Ул капрон курткасын җилбәгәй җибәргән, эт теле кадәр генә калдырып таккан галстугын бөтереп тора.

— Утыр, әйдә,— диде Зөлфәт, янәшәсеннән урын биреп, эскәмиянең икенче башынарак күчте.

— Эч поша, малай. Үз-үземә урын табалмыйм.

Исламның гади сүзләре Зөлфәтнең күңелен йомшартып җибәргәндәй булды. Ул аның үзе янына ни өчен килүен белми иде. «Бәлкем ул Мәснәвия белән үзен бәхетсез тоядыр?» — дип уйлады ул.

Көнләшү — борын-борыннан килгән чир. Көнләшү чире кешегә үзеннән өстенгә бәһа биргәндә аны түбән итеп күрергә теләүдән килә. Иң яманы шул: көнче көндәшендә кимчелек күрүдән үз күңеленә шифа таба.

Бу минутта Зөлфәт тә шуңа охшаш бер хис кичерде. Исламга карата юашланып китүе әнә шул хиснең күңеленә бәлзәм шифасыдай тәэсир итүеннән иде булса кирәк.

— Эчеп кара, аракы юса юа инде ул кайгыны,— диде ул тәрттергәндәй, аннары өстәп куйды: — Син дә, Ислам, үз бәхетемне тапмадым дисәң инде, җир убар үзеңне!

Ислам көрсенеп куйды.

— Сәгъди абый: «Кеше — сер тубалы ул, аны белү өчен ай да, ел да, хәтта ун ел да аз», ди. Бәхетне һәркем үзенчә тоя бит аны, Зөлфәт... Бүген әнә өйгә кайтышлый берәүгә юлыктым. Һәр көн хатын артыннан иярен килә. Мәснәвиягә шул турыда әйткән идем — еларга ук кереште. Нишлим соң инде? дигән була. Имеш, минем аңа дәшкәнем дә юк, караганым да юк, имеш, үзе иярен килә. Бүген әләктереп алдым үзен. Кызмача бит инде мин. Ямадым берне. Гафу үтенә, хашәп, мин аның кияүдә икәнен белмәдем, дигән була... Дуслар юк минем, Зөлфәт... Аның урынына син озатсаң, бер сүз әйтмәс идем. Бәлкем Мәснәвия дә алай ук еламас иде. Син беләсең, хатын-кыз елавын күрсәм, җенем кузгала минем. Ишекне шапылдатып яптым да чыгып киттем...

Зөлфәт бу тәкәббер һәм һәрчак горур кыяфәтле кешенең кылт кына үзгәреп китүенә аптырап калды. Шул ук вакытта Мәснәвиягә: «Шулай кирәк, шулай кирәк сиңа, Мәснәвия. Менә таптыңмы инде эзләгәнеңне, таптыңмы?!» — дип әйтәсе килә иде.

Ислам битенә ишегалдындагы лампочка яктысы төшә. Чибәр шул Ислам. Мәснәвия кызыкмаслык та түгел.

— Син дә хатыныңнан канәгать булмасаң инде, Ислам... Белмим, кем генә бу дөньяда аның кебекне табар икән... Фәрештә димим, әмма, миңа калса, ул алама хатын булмаска тиеш. Яратмыйсыңдыр син аны, Ислам... Яратсаң болай дип әйтмәс идең...

Ислам сигаретын сындыргалап җиргә ташлады, икенчесен алып кабызды.

— Их, әллә соң чынлап та эчеп карыйсымы?!..

— Син аңа бармаячаксың, Ислам. Син кырмавык кебек хатын-кыз итәгенә ябышырга торасың, өйләнгәч тә шуны куасың... Икенче берәүгә барып ябышсаң ябышырсың, әмма эчмәячәксең син, Ислам...

— Көнлисең син миннән, Зөлфәт. Шуның өчен күрә алмыйсың... Башта сөйгән кызыңа өйләндем... Хәзер...

— Нәрсә хәзер?..

— Бер нәрсә дә юк... Мин синең белән ачуланышырга дип килмәдем, Зөлфәт.— Ислам Зөлфәтнең җилкәсенә кулын салды.— Мәснәвия сине дә ятим үскәнсең диде. Сине әнә сугыш этисез калдырган, мине — шахта. Әти минем Урта Азия шахталарында эшләп үлде. Илле елын да тутыра алмады. Силикоз. Беләсеңме ни ул? Кешенең үпкәсе бетонга әверелә, сулыш алалмый башлый. Их!.. Соңгы көнендә янына чакырып алды. «Улым,— ди,— туган авылыбызга, туган илебезгә кайт, әҗәлең җитсә, ичмасам, йомшак туфракка салырлар үзеңне»,— ди. Чыкырдап торган таш эченә күмеп калдырдым үзен. Ичмасам, күзгә сөртергә кара туфрагы булсын иде. Әни унҗиде ел элек киткән булган. Мин аны белмәдем дә... Яратмаган ул якны, ике ел торган да аерылып кайтып киткән. Алтмыш җиденче елны аның янына кайттым. Кияүдә, биш

баласы бар, мин балигъ нәрсә — сыймадым. Сыяр да идем, бәлкем, көнелемә яткан эш тапмадым. Ятимлекнен ачысын күп татыдым мин, Зөлфәт. Кыйналу-кыерсытуларны да күрмәдем түгел, күрдем. Шуңа курка да белмим. Дорфалыкларым да шуннандыр, мөгаен...

Ислам бер тын болытлар астыннан килеп чыккан айга карап торды.

— Мин, Зөлфәт, Диананы онытa алмыйм... Теге вакытта да үзенә чүт өйләнми калган идем...

Исламнан бу сүзләрне ишетүгә, Зөлфәт гүя телдән язды, хәтта ул аңардан читкәрәк тайпылгандай итте.

— Ышанмыйсың? — дип сорады Ислам, Зөлфәтнең тайпылып куюын күреп.

Зөлфәт сабыр булырга тырышты. Ул түзәргә тиеш. Бигрәк тә көтелмәгән яңалык иде шул бу аның өчен. «Мәснәвия, кемне яраттың син? Кем белән язмышыңны бәйләдең?!»

— Мәхәббәт сәбәп эзләми, диләр, Ислам. Мин синең Диананы яратуыңа шикләнәм. Чуар күңелле кеше син. Мәснәвия сине ялыктырган кебек, Диана да тиз туйдырачак. Бу — синең чираттагы мавыгуың гына. Мин беләм, Ислам, хатын-кызны син эзләп җәфаланмагансың, алар сине эзләгән, алар сине тапкандыр. Шуңа кадерләрен дә белмисең. Тик шуны бел, Ислам: Диана сиңа алданмаячак. Хатын-кыз сиңа тигәнәктәй сарыла икән, бу әле, дускай, барысы да сине өзелеп яратырга, барысы да синең кочагыңа чумарга тора дигән сүз түгел...

— Сайра, сайра, тыңлыйм... Матур сайрыйсың болай...

Зөлфәт, минем сүзем бетте дигәндәй, кул селтәп кереп китмәкче иде, Ислам аның җиңеннән эләктереп алды.

— Чүп син, Зөлфәт. Көнлисең син миннән...

— Ярый. Кемнең кем икәнен киләчәк күрсәтер...

— Ә син миңа янама!..

— Бусы гел артык. Мин сиңа янамыйм гына түгел, минем синең турыда уйлаганым да юк...

— Җитмәсә бит, минем белән ярышмакчы буласың. Минем белән — Ислам белән — син! — Ислам күкрәгенә сукты. — Мине узмакчы буласың, мине?! Гомердә булачак түгел ул! Ишетәсеңме, честно ярышсак, гомердә булмаячак ул хәл!..

— Ни пычагыма кирәк миңа ул ярыш! Миңа димәгәең гел йөз белән чап, көн саен норман ике йөз процентка үтә. Әнәсеңне дә калдырма.

Әнәс атлы егетне күптән түгел генә Бабай алар бригадасына җибәргән иде. Башта нигәдер егеткә бәйләнеп йөргән Ислам соңгы вакытта тегене яклый башлады. Бу хәл Зөлфәткә ошамады. Нигә икейөзләнгән буласың дип, Исламны үртәп алган иде.

— Ярый, анысын, кем әйтмешли, күрербез... Ә Әнәс турында яңадан миңа сүз катасы булма, Зөлфәт...

Ислам кинәт борылды да китеп барды. Зөлфәт ишегалдына керде. Болдыр янына килеп сигарет кабызды. Һич юктан диярлек Ислам белән әйтешеп китү аның гел кәефен бозды. «Менә, тинтәк, нервыга тиде», — диде ул үзалдына.

Һәм күңеленә бер шик төште... Диана да, Мәснәвия кебек, Исламга алданса?.. Дианага да янып алу табигый түгелмени?..»

Ул арада урам якта ике кеше сөйләшә башлады. Берсе, сорау бирүчесе Ислам иде. Зөлфәт аны ялварулы тавышыннан ук таныды. Зөлфәт, бөтен әгъза-тәненә гарьчел бер хис коелуын тоеп, баскан җирендә катып калды. Хәтта йөрәге кагуын ишетте.

— Диана! Бер генә минутка туктагыз әле? — диде Ислам...

Диана башта дәшмәде. Зөлфәт шунда Исламның Диана артыннан килүен күз алдына китерде. Кинәт аңа Диана менә-менә туктар, тук-

тар да ягымлы тавыш белән сөйләшә башлар кебек тоелды. Шуңа йөрәге кысылды. Ләкин Диана туктамады, ул Исламга каршы шактый кырыс тавыш белән:

— Ислам, сезне соң берничек тә кеше итеп булмас микәнни?.. Җибәрегез мине,— дип ачуланып дәште.

Шул сүзне ишетүгә, Зөлфәтнең бөтен тәненә рәхәт коелгандай булды. Аның бу сүзләренә Зөлфәтнең никадәр горурлануын Диана үзе белсә икән?

— Хәерле кич, Зөлфәт! Һавага чыгып утырдыгызмы? — диде Диана, капкадан кергәч, болдырга сөялеп басып торган Зөлфәтне күреп.

— Нигәдер баш авыртып тора, шуңа чыккан идем әле,— диде егет.

Диана, перчаткасын салып, Зөлфәтнең маңгаена кагылып алды. Аның кулыннан дару исе килә иде.

— Тәнегез кайнар түгел кебек,— диде Диана, баскычтан менә башлап.— Әйдәгез, керегез, баш даруы бирермен...

Зөлфәт аңа ияреп болдыр баскычын менгәндә «баш авыртып тора» диюенә үкенеп алды.

Өйгә керү белән Диана өс-башын салды, кухняга кереп, стакан белән су алып чыкты һәм Зөлфәткә бер таблетка бирде.

— Менә бу таблетканы эчеп ятыгыз, иртәнгә җиңеләймәсә, поликлиникага килерсез...

Зөлфәт таблетканы тел өстенә салды да Дианага карады.

— Ай-яй, әче икән даруыгыз!..

— Әче булмаса бар да эчәр иде аны...

Диана Зөлфәтнең йөз чытуын күреп рәхәтләнеп көлеп җибәрде һәм зәңгәр күзләре белән егеткә текәлеп карап торды. Ул көлүгәме, теге бүлмәдәге хатын тамак кырды.

— Тсс! Әни уянды,— диде Диана, бармагын авызына куеп. Бу хәлдә ул өч яшьлек Язилә кызына охшап китте. Язилә дә әнисе кебек зәңгәр күзле һәм, бер-бер хәл булса, әбисеннән нәрсә булса яшерергә теләсә: «Тсс, Зөлпәт абый, әбине уятасың»,— ди иде.

— Тыныч йокы сезгә...

— Сезгә дә...

Зөлфәт үз бүлмәсенә менгәч, аннан-моннан гына капкалады да сәгатьне алтыга шалтырарга куеп, чишенеп ятты. Ятты, әмма күзләренә йокы кермәде. Диананың мөгамәләсе, үз итеп, якын итеп ярым үртәп дәшүе, Исламны куып җибәрүе аңа яхшы гына тәэсир иткән иде. Шуңамы, юрганын башыннан ала бөркәнеп ятса да, тиз генә йокыга китә алмады.

Бу якшәмбедә Зөлфәт яңа шәһәргә барып кайтырга булды. Чаллы көне белән түгел, сәгате белән үсә. Ял саен аның урамнарын йөреп кайту, бөтен илебез почмакларыннан дөньяда тиңе булмаган автогигант — КамАЗны төзергә җыелган төрле милләт кешеләрен күрү үзе бер сәяхәт иде.

Әнә шулай кибетләргә кереп йөргәндә котмәгәндә аның каршына Мәснәвия килеп чыкты. Ул өстенә болонья плащ кигән, аягында ялтыравык итек. Очрашулары икесе өчен дә шул хәтле көтелмәгәндә булды, күрәсең, хәтта икесе дә шып туктап калдылар.

— Исәнме, Мәснәвия!

— Саумысыз, Зөлфәт абый...

— Авылга кайтканың бармы?

— Теге атнада кайтып килгән идек...

— Кая барасың?

— Менә...

Мәснәвия Исламны каршы алырга чыккан иде, бу турыда Зөлфәт-

кә әйтергә оялды, яхшысынмады. Шул ук вакытта ул Зөлфәтне очратуына шат та кебек иде.

Алар янәшә атлап киттеләр.

— Әйт әле, Мәснәвия, Исламга чыгуыңа үкенмисеңме?

Мәснәвия Зөлфәткә кырын күз белән генә карап алды.

— Юк, үкенмим, Зөлфәт абый... Тормышка ничек тә җайлашырга кирәк бит...

— Холкы начар Исламыңның. Шулаймы?

Мәснәвия, туктап, тирә-юненә карады. Һәм бер бакча кырыенда эскәмия күреп, шунда таба кузгалды.

— Зөлфәт абый, утырыйк әле. Әллә нигә эчем поша минем.

— Нигә алай, ни булды?

Мәснәвия эскәмиягә утырды, тезен-тезгә терәп, кыска итәген тартыбрак куйды.

— Мин сине оныта алмыйм, Мәснәвия. Нигә син шулай иттең, нигә көтмәдең? — диде Зөлфәт. Ләкин болай әйтеп ташлавына шунда ук үкенеп тә куйды.

— Зөлфәт абый, булдыра алсаң кичер мине, үтенәм?!. Сихерләде бугай Ислам мине... Әни дә шулай ди...

«Ә бит мин сине, Мәснәвия, акыллы дип йөри идем»,— дип әйтергә теләгән иде, әйтмәде.

— Кыйнамыймы?

— Кыйнамый кыйнавын...

Мәснәвия аякларына текәлеп башын иде, бармагы белән күз яшен сөртә башлады.

— Яшермисеңме, дөресен әйтәсеңме?

— Юк-к... Чиерткәне дә юк... Усаллыгы гына бар... Кайчак көннәр буе сөйләшми... Кыйнаса, ичмасам, җаным бизәр иде үзеннән...

— Кит син аңардан, Мәснәвия. Әйдә Себергә, Урта Азиягә, кая телисең!..

Мәснәвия аңа күтәрелеп карады һәм яшь аралаш:

— Минем аңардан балам булачак, Зөлфәт абый,— диде.

Зөлфәт дәшмәде. Баеп барган кояшка карады. Үтүче-сүтүчеләр аларга игътибар итә башлады, ахрысы, Мәснәвиянең елап утыруын сизенүләре иде бугай.

— Шулай гомер буе җәбер күреп яшәрсеңме?..

— Нишлим соң инде, Зөлфәт абый, нишлим!.. Кайчак үз-үземә кул салыр хәлгә житәм... Ниндидер хатын янына йөри... Әйт әле, Зөлфәт абый, кем ул, син беләсең, диделәр!

Зөлфәт һич моны көтмәгән иде — бер мәлгә аптырап китте. «Кем янына йөрер бу Ислам? Инде шундый хатын яныннан да читләргә чапса!..» — дип уйлады ул, Мәснәвиянең күзләренә карарга тырышып, терсәкләрен тезенә куеп утырды.

— Исемен беләсеңме?

— Диана, врач диләрме үзен... Элек ул аларда квартирда торган... Хәзер дә ике көнгә бер шунда чаба...

— Диана? Юк, анда йөрми ул, Мәснәвия... Мин үзем ул хатында квартирда торам...

Зөлфәттә Диана өчен гарьчел бер хис уянып китте. «Мәснәвия Исламны Дианадан көнли? Гаҗәп-сәер хәл. Юк, Мәснәвия, синең Исламың аның янына йөрми... Алар арасында берни дә булмаган. Чөнки моны Зөлфәт үз күзе белән күрде, үз колагы белән ишетте.

— Мәснәвия,— диде Зөлфәт, аңа туры карап.— Син миңа ышанасыңмы?

Мәснәвия еш-еш керфеген каккалап алды, Зөлфәткә өмет тулы караш ташлады, шул ук вакытта ниндидер сәер курку да иңгән кебек иде аның күзләренә.

— Чынмы шул, йөриме?..

Мәснәвиянең ике күзе дә мөлдерәп яшь белән тулды.

— Юк, Мәснәвия, йөрми ул анда...

— Беркемем юк бит минем бирелә, бер киңәшер кешем юк, Зөлфәт абый!..

— Елама, Мәснәвия, тынычлан. Ислам аның янына йөрми... Башка бүтән янына йөрсә йөридер, әмма, ышан миңа, анда күргәнем юк минем аны. Шунда яшәгәч, бер күрмәсәм бер күрер идем...

— Кая китеп югала соң ул кич җитсә?

— Ә син аның үзеннән сора...

— Ә-ә, баҗай! — дип, алар каршына килеп басты Ислам. Ул каяндыр җир астыннан килеп чыкты кебек.

Мәснәвия куркынып китте, тиз-тиз күз яшен сөртте дә торып басты, китмәкче булды.

— Тукта!

Ислам аны терсәгеннән эләктереп алды. Мәснәвия башын иде, карусыз буйсынды.

— Мәхәббәт янарту өчен аулаграк урын эзлиләр аны, баҗай,— диде теш арасыннан ысылдап Ислам.

— Ислам, кыланма! Мәснәвия минем авылдашым, без сөйләшеп утырдык...

— Көпә-көндез үбешер идегез тагын! Һа-һа-һа!..

— Ислам! — диде Мәснәвия.— Котырма!

Ислам Мәснәвиягә ялт итеп карап алды һәм аның кара күзләреннән гүя чаткылар чәчрәп киткән кебек булды.

— Бар, Зөлфәт, яхшы чакта кит моннан! — диде ул, усаллана барып.

Мәснәвия ике кулы белән Ислам беләгенә ябышты.

— Ислам, нишләвең бу?

— Тик тор! — дип җикерде аңа Ислам.

Зөлфәт торды да бер сүз әйтмичә һәм Мәснәвия белән Исламга күтәрелеп тә карамыйча китеп барды.

— Ислам, җаным, нигә син аның хәтерен калдырдың? — диде Мәснәвия, иренең күзләренә карап.

— Пәрмәсен сөйрәлеп, мәхәббәт корбаны,— диде Ислам һәм тагын шул сүзләре өчен күңелендә үкенү хисе калкып китүен тойды.— Әйдә, кайтыйк, арыдым мин...

Мәснәвия иренең җете кара күзләренә карады һәм тыелгысыз төстә аңа таба тартылып куйды, күкрәгенә башын салды.

— Гафу ит, Ислам, мин аңардан әни турында гына сорашкан идем.

— Әни турында. Ялганла?! Диана турында диген!..

— Юк, юк, Ислам!..

— Ярый, әйдә кайтабыз, мин арыдым...

Ире кузгалуга, Мәснәвия ике кулы белән аның беләгенә сарылды һәм хуҗасы янына килгән песидәй ялагайланып:

— Мине генә яратасыңмы син, Ислам? — диде.

Ислам янә аңа усал караш ташлады һәм әчкерсез тонда:

— Җүләр син, Мәснәвия.— диде.

Мәснәвия дәшмәде. Ул оялып киткәндәй булды. «Әллә соң ул аны гел юкка көнлиме? Юкка рәнҗетәме? Шулай дип уйлады уйлавын, әмма күңел төрендә барыбер ниндидер шом торып калды. Ислам аңа нәрсәнедер әйтеп бетерми, аңардан нидер яшерә кебек иде. Ул аны күзләреннән үк күрә бит. «Нигә соң син, Ислам, кич җитте исә каядыр чыгып китәсең? Нигә, кая баруың турында сорагач, күз агың белән карап куясың? Нигә? Мин яратам да, синнән куркам да, Ислам? Кайчанга хәтле шулай барыр бу? Нигә син минем өчен һаман сер тубалы булып каласың? Әйт шул турыда? Миңа хәзер әйт?»

Шулай дип уйласа да, Мәснәвия иренә бу турыда авыз ачып сүз әйтергә базмады. Өйгә житәрәк Ислам аңа таба борылмый гына:

— Иртәгә Сәгъди абый белән урманга гөмбәгә барабыз, Нажия апалардан кәрзин сора,— диде.

— Чынлапмы?

— Юк, юри,— диде моңа каршы Ислам.

Ләкин иреннең бу уртәве Мәснәвия йөрәгенә сары май булып ятты. Исламның шаярып әйтмәгәнен ул әйбәт белә иде.

## 7

Кич эштән кайткач, Зөлфәт Язиләне алырга китте. Диана кайтмаган иде әле. Авыру хатын китап укып ята. Ләкин бакчада Зөлфәткә баланы бирмәделәр. Тәрбияче апалары елмая-көлә: «Язиләнең кеме буласыз соң сез?» — дип, Зөлфәтне урынлы-урынсыз кызарырга мәжбүр итте. Аннары Зөлфәтнең колакларына кадәр кызаруын күреп:

— Ата-анасы рөхсәтеннән башка без баланы беркемгә дә биреп жибәрә алмыйбыз,— диде шактый житдиләнеп.

— Мин аның этисе,— диде Зөлфәт кыюланып.

Тәрбияче кыз башта шаярмагыз дип, елмаеп, бармак янап алды, әмма Зөлфәт бу сүзне икенче кабат әйткәч:

— Гафу итегез, минем Язиләнең этисен күргәнем юк, аны алырга гел әнисе килә иде,— дип акланып алды.

Зөлфәтне Язилә фаш итте.

— Зөлпәт абый, әни эштәме әле? — дип сорап куйды.

Тәрбияче кыз шырык-шырык көлә башлады.

— Этисе дигән була бит әле, алдакчы,— диде ул, кинәт кенә Зөлфәтне үз итеп, «син»гә күчте.

Баланы киендергәндә аларның башлары-башка тиеп китте. Шуңа күзгә-күз карашып, көлешеп алдылар.

— Сөзешергә кайда өйрәндең? — диде Зөлфәт.

— Мин сабый чакта кәжә бәтиләрен өйдә тоталар иде. Ә алар буздә бишәү-алтау була иде. Көн буе сөзешә идем үзләре белән...

— Алайса синең белән сөзешүе хәтәр, тәжрибәң зур икән...

— Фи-и, оныттым инде мин аны!.

Тәрбияче кыз баланы киендерде дә чытлыкланыбрак Зөлфәт янында тора башлады. Аның өстендә ак халат, халат астыннан алсу күлмәк якасын чыгарып куйган, йөзе кара тутлы, чегән кызларына тартым, сул битенә берсеннән-берсе кара ике миң кунган.

Кыз, Зөлфәтнең үзенә карап торуын сизүгә, соклангыч нәфис хәрәкәт ясап, башын чак кына кырын салды да балага:

— Язилә, бу абый кем әле сиңа? — дип сорады.

— Зөлпәт абый, машина йөлтә... О-о... зул! — диде бала, кулларын жәеп.

— Әллә безнекеннән дә зур...

— Зул, зул...

— Күпмегә?

Язилә берәм-берәм бармакларын саный башлады.

— Өскә, дултка...

Кыз янә керфек астыннан гына Зөлфәткә сирпелеп куйды. Аның бу карашы гүя: «Менә әйттем бит син Язиләнең этисе түгел дип. Син егет кеше, ә мин менә кыз кеше... Күрмисеңмени, нинди чибәр мин!.. Миңнәремә кара, миңнәремә! Һи-и, үзе уртәшкән була, үзе карамый да, бигрәк инде!» — ди кебек иде.

Зөлфәт, кызның төймә кебек жете кара күзләренә, кыйгач кашына, бит чокырларына карый-карый, бер нәрсәне аңлады: кызның аның

белән танышасы килә. Кыз үз кыяфәтеннән бик канәгать, әле тегеләй, әле болай сыгылып, таза балтырларын күрсәтеп йөреп килә. Ул да түгел, юка кашларын сикертә, иннәрен җыерып куя.

— Чаллыга күптән килдеңме соң үзең, ошыймы яңа шәһәр?

— Шәһәр ошый. Бераз карарак булсалар да, кызлары чибәр, сулары татлы. Сулары татлы булгач, шул суларны эчеп үскән кызлары да татлы булырга тиештер дип килү иде,— диде Зөлфәт кызга, кызның очкынланып киткән күзләрендә наянлык күреп.

— Телгә шома егет булдың әле син... Алай булгач, танышыйк. Язиләне кем алып китте дисәләр, ичмасам, Былтыр атлы егет алып китте диярмен...

Бала сабырсызланып апасының итәгеннән тарткалый башлады.

Шул чакта ишектә Диана күренде. Ул бер балага, бер Зөлфәткә, бер тәрбияче кызга карап алды да баласын күргәннән соң аналарда туа торган куаныч белән:

— Карале, кызым, сине Зөлфәт абыең ала килгән икән ләбаса. Мин сине алырга дип кадала-каплана йөгерәм тагын... Әбисе дә әйтмәде, ичмасам, гел килмәгән булыр идем. Исәнмесез, Хәят апасы, Язилә бик көйсезләнмиме?.. Кайчак аның кәҗәсе килеп китә...

— Минем кәҗәм юк, әнием,— диде Язилә.

— Шулаймыни, нәнием, кәҗәң юкмыни? Менә әйбәт... Менә молодец,— диде Диана һәм, бала белән сөйләнә-сөйләнә, кызын иләртеп чыга башлады.— Сау бул инде, Хәят апасы... Кул изә, саубуллаш апаң белән, кызым!..

Язилә ишеккә җитәрәк туктап кул изәп алды да тизрәк тышка чыгарга ашыкты.

— Сау бул, Хәят апа...

Ишектән чыгу белән Зөлфәт баланы кулына алды, аннары җилкәсенә үк утыртты.

Язилә:

— Зөлпәт абый, кулькам, кулькам,— дигәч, ул аны кулына төшерде. Бала аның муеныннан кочаклап алды.

— Кызым, әйдә, җәяү кайт,— дигән булды Диана.— Ләкин бала Зөлфәтнең муеныннан кыса гына төште.

— Юк, әни, мин Зөлпәт абыйга ултылып кайтам...

Шуңамы, әллә бүтән бер нәрсәгәме, Дианаының рәхәттән йөрәге кысылып куйды. Ул бер Зөлфәтне кочаклаган бала кулларына, бер аның канәгать, көләч йөзенә карады да кинәт кенә күзенә йөгергән яшьне тыя алмыйча читкә борылды.

«Вәли укырга китмәгән булса, бәлкем, газиз балам үз әтисен кочып кайтыр иде»,— диде.

— Кызым, әллә утырып кайту яхшыракмы? — дип сорады Диана һәм, күз яшен яшермичә, Зөлфәткә карап алды.

Зөлфәт бу хәлдән оялып, кызарынып китте һәм, моны күрмәгәндәй, бала белән уйный-шаяра башлады. Ул Язиләне әле култык астына кыстырды, әле җилкәсенә атландырып ат булып чапты, бер аркасына асты, бер кулларын урындык ясап, шунда утыртты.

— Әнием, әнием, мин Зөлпәт абый кулына утылып телебизол калыйм,— диде бала куанып.

Бала куанычы сагышланып кайткан анага да күчте, ул, яшь аралаш елмаеп, көләргә тотынды.

Төнлә белән Зөлфәт сискәнеп уянды. Астагы катта шау-шу, авыру хатын елый, сыкрана иде. Зөлфәт чалбар-күлмәген киде дә түбән төште, ишек янына килде. Авыру хатын яшь аралаш кемнедер каргый, Диана аны еламсырап юата, тынычландырырга тели иде.

Зөлфәт ишекне шакыды да, «керегез» дигәнне ишеткәч, бүлмәгә үтте.
Диван-караватъ. Аның янында идәндә авыру хатын ята, Диана аны караватка күтәреп салмакчы итә, әмма көче җитми, шуна тәкатьсез калып, тегесе дә, монысы да еламсырыйлар.
Хаста хатын такмаклап-көйләп елый, гаҗизләнеп китә, Дианадан үзен идәндә калдыруын үтенә иде.
Зөлфәт керә-керешли үк гафу үтенде һәм түргә узып, авыруны күтәреп алды да иплән кенә урынына салды. Авыру нидер укый-укый рәхмәт әйтә башлады, ахырда стенага сыенып, тынып калды. Диана читкәрәк китте һәм башын иеп идәнгә текәлде.
— Рәхмәт, Зөлфәт,— диде ул Зөлфәт чыга башлауга һәм, каударланып, халат сәдәфләрен элэктерә башлады.

## 8

Бүген ул гадәттәгедән иртәрәк уянды. Төнозын диярлек Ислам белән саташып чыкты. Бер ул аның белән машинада узышты, бер Мәснәвияне кыйнавын күреп, аны якларга ташланды. Иртән шул турыда уйланып ята торгач, түгәрәк бер фикергә килде: Бакыйҗанга мөрәҗәгать итәргә, күпме сораса да сорар, моторны аңардан көйләтеп карарга... Мотор тарта башласа, ул да йөреп карар иде бер...
Бүлмәсеннән чыгып аскы катка төшүгә, кухня ягыннан алъяпкыч бәйләгән Диана килеп чыкты.
— Хәерле иртә, Зөлфәт!
— Иртә хәерле кебек, Диана.
Хатын егетнең үзенә «Диана» дип дәшүенә бераз сәерсенде, ахрысы, йөзенә беркадәр гаҗәпләнү билгеләре чыкты, әмма Зөлфәтнең китәргә теләвен күреп, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, аңа табарак үтте.
— Минем сезгә бер үтенечем бар иде, Зөлфәт.
— Нинди үтенеч?
Диананың кыйгач кашлары нигәдер калтыранып алды.
— Гафу итегез, Зөлфәт. Мена икенче ай торасыз инде, «син» дип дәшәргә яхшысынмый йөрим, ярыйдыр бит? — диде Диана. Шулай диде дә, башын кырын салып, тәҗрибәле хатын-кызларга хас мөлаемлек белән елмаеп куйды.— Зөлфәт, әйтегез әле, шофер булып эшләве бик авырмы?
— Әллә шоферлыкка укырга исәбегез бармы?
— Шутник сез, Зөлфәт.
— Шофер булып эшләгән кеше министр постына утырырга да теләми, диләр. Мин канәгать, югыйсә. Мәгәр министр итсәләр дә, баш тартмас идем...
— Ха-ха-ха... Ә нигә, миңа калса, шофер булу бик мактаулы эш,— диде Диана.
— Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диләр бит...
— Син аларны беләсең, Зөлфәт. Шуңа сиңа бер йомышымы, йомыш түгел инде ул, эш кушарга исәп иде...
— Нинди эш?
— Бүген дә баланы алырсың әле. Җыелыш була безнең. Ул уннарга кадәр сузылачак... Аннары, ни, әйдә әле ишегалдына.
Диана аны ияртеп ишегалдына алып чыкты, кече капка янына килде.
— Менә монда, Зөлфәт, бер келә сыман әйбер кирәк. Келәсе бар иде аның, сынган, әнә. Шуңа, чак кына җил булдымы, капка төне буе

шыгырдап чыга. Әни дә йоклый алмый, мин дә... Бүген, энә, сине дә борчыдык... Ясап алып кайт әле шунда бер келә...

— Ярар, бүген үк эшләргә тырышырмын, тик безнең бик кысан вакыт. Яңа елга хәтле төзүчеләргә ике зур цехның котлованын казып өлгертергә тиешбез. Чабабыз, кем әйтмешли, тәгәрмәчләрдән ут чыга...

— Бер барып карыйм әле шул завод урынын...

— Килегез, чынлап та, күреп китәрсез...

— Ислам да сезнең бригададамы?.. Аның турында радиодан да, телевизордан да еш сөйлиләр...

Ислам исемен ишетүгә, Зөлфәтнең йөзенә күләгә кунды. Моны, әлбәттә, Диана да сизми калмады, Зөлфәтне юатырга теләгәндәй:

— Я, ярый, Зөлфәт, эшеңә кит, я соңга калырсың,— дип, сүзне гел йомды да куйды.

Диана апа, башын чак кына кырын салып, көлемсерәп карап калды.

«Барысын да Исламның кем белән эшләвен белү өчен сорашкан,— дип уйлады Зөлфәт, автобус тукталышына таба атлаганда.— Үзе сораша, үзе көлә...»

Зөлфәт юл буе әлеге сөйләшү хакында уйлап барды. Гаражга житкәч, теләсә-теләмәсә дә, күз үнкөнлек күрсәткечләр тактасына төште. Биредә биш бригада ярыша. Биш бригада шоферларының фамилиясе, исеме, үтәгән нормасы... «Иа хода, бригадада иң соңгы урында торам бит! Хәтта хатын-кыз булып хатын-кыз Гатифә дә миннән алда бара. Хурлык! Әнә кара Исламны! Беренче урында!..»

Бокс янында аны Анатолий куып җитте.

— Зөлфәт, сәлам! Карале, минем урынга анда икенче берәү барыр. Исламга әйт, юк-барга төртенмәсен. Ату аның яңа кешедән көлә торган гадәте бар...

— Ә син нигә?

— Мине, Зөлфәт, начальник иттеләр...

— Котлыйм, алайса...

— Рәхмәт... Шуны әйт әле, яме! Толя үтенде диген...

— Әйтермен...

— Карале, Зөлфәт. Бакыйҗанны күр әле син... Двигателеңне көйләргә алынмасмы. Минемчә, ниндидер дефект белән ул синең машина моторы... Бакыйҗаннан өшкертеп карат, анда да булмаса, заводка язарбыз...

...Зөлфәт машинасына кайнар су салды да мотор җылына торсын дип бокска, Бакыйҗан янына китте. Аның уенча, Бакыйҗан моторны әллә ни үзгәртә алмас кебек иде, ләкин Анатолий сорагач, сынап карарга булды. Ул ишетте: имеш, Ислам машинасы двигателен ике айга бер мәртәбә Бакыйҗаннан көйләтеп ала. Бәлкем, чынлап та, берәр әфсенен беләдер бу Бакыйҗан.

Бакыйҗан бокста «Волга» машинасының двигателен көйләп маташа иде.

— Сәлам, Бакый абзый...

— Мәгаләйкүмәссәлам, Вахитов. Нинди йомышың төште?..

— Бәлкем, йомышым юктыр, болай, хәлеңне белергә генә килгәнмендер...

— Һы,— Бакыйҗан Зөлфәткә карап алды, кулындагы отверткасын читкә куеп, чүпрәккә үрелде.— Миңа, брат, йомыш төшмичә килүчеләр аз...

— Төшсә дә гаеп түгелдер бит?..

— Гаеп түгел дип... Дөнья булгач, йомыш төшми тормый инде ул... Моторны көйләтергә исәбеңме?..

— Әйе.

— Әүвәл болай. Бер савыт та бер тавык...

— Тавыгында эш тормас... Эшлә генә,— диде Зөлфәт, аңа якыная төшеп.

— Тукта әле, тукта. Син миңа ул тиклем якынайма. Мин болай да чукрак түгел, аллага шөкер, әлегә ишетәм...

Бакыйҗан «Волга» канаты өстенә кырын төште.

— Бакый абзый!..

— Иң әүвәл мин сиңа, Ислам әйтмешли, Зөлпиәхәт туган, абзый түгел, ә яшьти. Инде торып, икенчедән, ни, син өйләнгәнме әле?

— Юк.

— Алай булгач, мин сиңа абзый икән шул. Икегә өйләнеп карады инде абзаң... Тик уңмадым мин мөртәтләрдән... Түзмиләр, чыдамыйлар, йомшак металлдан ясаган булып чыктылар.

Якын-тирәдә бокс идәнен себерүче апа йөри иде, Бакыйҗанның бу сүзләрен ишетүгә, якынрак килде һәм:

— Уф аллам, яра бит ярманы ярпач, синең кебек тел бистәсе белән кем тора алсын соң!..— диде.

— Карале, Җәмиләттәй, ни бит инде ул, корыч белән кургашны чагыштырып булмый. Алар кургаштан эшләнгән булып чыктылар, ә мин корычтан... Менә кара, минем аяк балтырларын, сеңерләрне кара, сеңерләрне. Корыч аркан кебек кабарып торалар... Ышанмасаң, менә тотып кара... Корыч та корыч, бу да корыч...

Бакыйҗан капотка яны белән яткан төштән кузгалды да чалбар балагын күтәреп, йон баскан чандыр балтырын күрсәтте.

— Кит, юньсез! — диде Җәмилә, себеркесе белән селтәнеп.— Ыштаның салып күрсәт тагын...

Зөлфәт, түземлеген җуеп, Бакыйҗанның җиңенә кагылды.

— Я, ничек?

— Эһем... Моторның әйләнешен аз гына, бер-ике сырга үзгәртсәң, форсункаларны сүтеп корсаң, насосны, клапаннарны... Соң сиңа тизлек җитмимени? Ирек бирсәң, билләһи-валлаһи, бу шофер халкына, машиналары белән канатсыз очарлар иде.— Бакыйҗан, бармагы белән түшәмгә төртә-төртә: — Беләсеңме, иптәш Вахитов, сезнең МАЗыгыз сәгатенә ничә километр белән чаба? — диде.

— Алтмыш биш, җитмеш тирәсе...

— Иштең... Сиксән, завод күрсәтмәсе буенча сиксән!.. Ә инде аз гына форсункаларны көйләп, клапаннарны карап, мотор әйләнеше көйләгечен бер-ике сырга тартып куйсаң,— йөз, йөз ун, хәтта йөз егерме километр белән чабачак!.. Җитәме шул сиңа, ә?!

Бакыйҗан Зөлфәтнең кабыргасына төртте дә, Җәмилә ягына карап, мәгънәле генә итеп күз кысты:

— Болай да көн-төн мастерскойдан китмисең. Шуңа синең хатыннарың да яратмадылар үзеңне... Мотор җене кагылгандыр инде үзенә,— диде Җәмилә.

— Яратунымы? Андый нәрсәне белмим мин, Җәмиләттәй. Нәрсә белән ашыйлар аны? Нинди табынга куеп була! Төсе-йөзе, тәме-яме, күләме-чамасы ни белән үлчәнә ул яратуның?

— Тел бистәсе...

— Бар, бар, Җәмиләттәй... Әй, тукта! Миңа сигарет алып кил әле. Менә сиңа бер сум, сдача кирәкми...

Җәмилә киткәч, Бакыйҗан Зөлфәтне җиңеннән тотты.

— Менә нәрсә, Зөлфәт. Кил син иртәгә эштән соң...

— Ә бүген?

— Бүген — юк. Бүген киногa барам, «Освобождение»гә. Ну, ярый, кил. Тик бит, Зөлпиәхәт, мотор көйләгеченә тияргә ярамый... Петрович белсә, беләмсең — нишләтәчәк мине?.. Белмисең... Тю-тю... Китәр тикшерену, Бабайга җиткерерләр. Нигә завод пломбасын алдың, ни хакың бар, кем рөхсәт итте?.. Аннан миңа...

Бакыйҗан муенына элмәк ясап, түшәм астындагы балкага ташлагандай итте дә, башын бер якка салып, телен чыгарды, күзләрен акайтты.
Зөлфәт тыела алмыйча көлә башлады, шунда алар янына Петрович килде.
— Вахитов, нәрсә болай озак китми йөрисең әле син? Вакыт үткәнне белмисеңме әллә? Әлдерт тизрәк моннан! Ислам анда өч рейс ясагандыр инде...
— Хәзер, хәзер, Петрович,— диде Зөлфәт һәм Бакыйҗанның колагына: — Я, ярый, Бакый абый, кичкә кадәр...— дип пышылдады.
— Сәгать биштән дә калма. Мин ашап килүгә бирергә бул! — дип калды аңа Бакыйҗан.

## 9

...Эш бетү белән Зөлфәт квартирына кайтты да иртән тимерчегә ясап куярга кушкан келәне капкага какты, аннары машинасы белән үк бакчага Язиләне алырга китте. Бакча каршына килеп туктауга, аны Хәят күреп алды һәм баланы капкага кадәр йөгертте.
— Язилә, әнә Зөлпәт абыең сине машина белән алырга килгән...
Бала кул чаба-чаба куанырга тотынды, Зөлфәткә каршы йөгерде. Зөлфәт баланы йөгереп килү уңаена кулына күтәреп алды да, чөеп җибәреп, җилкәсенә утыртты.
— Киендереп каршы алган өчен рәхмәт, Хәят апасы,— диде Зөлфәт баланы озатырга чыккан тәрбиячегә.— Морожный алып бирермен үзеңә...
— Фи-и, морожный! Берәр кап шоколад диген, ичмасам. Имезлек ташлавыма биш былтыр инде минем...
— Шулаймыни! Менә бит син аны. Ярый соң, шоколад булыр. Па хода, бигрәк һавалы булды әле бу Хәят апаң, Язилә акыллым,— дип көлде Зөлфәт.
Хәятка аның кинаясе ошады, бөтен йөзе белән елмаеп җибәрде.
— Язилә, я, хуш, апа, диген. Хуш, Хәят апасы!..
— Исән йөрегез. Исән бул, Язилә. Мине дә бер йөртерсең әле, абыйсы...
— Ярый, ярый. Син дигәндә мин рульдә...
...Зөлфәт Язиләне өйдә калдырды да гаражга китте. Анда аны Бакыйҗан көтеп тора иде инде.
— Кая югалдың, яшьти? Эшләгәндә йөрәгең җилкенсен, ашаганда колагың селкенсен, дигән безнең бабайлар. Синең эштән кайтуына ике сәгать була, әле булса чабасың... Кабинаңны күтәрергә иде, моторын сөрткәләргә, форсункаларны, насосны алып куярга... Акрын-сабыр кеше син, Вахитов. Кыен булачак сиңа шофер булып эшләве. Машина ул чәчрәп торган егетләрне ярата.
— Гафу ит, Бакый абзый, квартир хозяйкасы эш кушкан иде, эшләмәсәң яхшы түгел...
— Ә-ә, теге Ислам өйләнәсе иткән врач хатынмы?
— Әйе... Ислам аңа өйләнмәкче идемени?
— Нидер булып алган бугай алар арасында. Бабай туктаткан, диләр...
Бакыйҗан җиң сызганып эшкә тотынды. Үзе һаман сөйләнде:
— Моторның җегәрен арттырырбыз инде аны. Мәгәр, Вахитов, үзең кымшанмасаң, ай-һай, дускай, шофер чыкмас синнән. Ничек танкист булып хезмәт иттең син?
— Биш-алты значогым бар иде, ярышларда җиңеп алдым.
— Ай-һай, нигәдер күңел ышанмый. Тактада иң аста кайнашасың түгелме?

— Әйе...

— Белмим, белмим... Печергә Исламнан өйрән син... Күзәт... Ничегрәк кузгала, кай төштә куалый, кай төштә тыя төшә... Шофер эше ул четерекле нәмәстә. Иң әүвәл сиңа юлны тоя белергә, өйрәнергә кирәк... Искәрдеңме? Менә иртәгә шуннан башла...

Зөлфәт өчен бу көн аеруча үзгә булды. Дөрес, кичә соңрак кайткангамы, йокы туймаганга бераз баш авырта иде, ләкин ул гына күңел җилкенүен төшермәде. Бүген ул ярты сәгатькә иртәрәк килде. Путевканы беренче булып алды диярлек, һәрхәлдә, яшьләр бригадасыннан берәү дә килмәгән иде әле.

Машинасын кабызып капкадан чыкканда, путевкага кул куйган механик та аның юлга иртә чыгуына бераз аптыраган кебек булды.

— Барысы да иплеме?

— Гөлләр кебек.

— Гөлләрен гөлләр. Әнә һәр көнне диярлек чәкәшеп торасыз. Ипле йөре, кара аны!..

Зөлфәт юлга төшү белән сизде: МАЗ йөрешен бөтенләй үзгәрткән — газга басу белән ухылдап суырып алып китә. «Юкка сөйләмиләр икән бу Бакыйның осталыгы турында»,— дип уйлады ул, тизлекне арттыра барган саен моторның көчәнмәвен тоеп. Ләкин бу бушлай иде, менә йөк белән ни әйтер?

Экскаватор чүмече астына беренче булып килеп туктавына машинист та аптырады.

— Ба-а, Вахитов. Кояш бүген кире яктан чыгар, ахры...

Зөлфәт, «син сорама, мин әйтмим», дигән сыман башын чөеп куйды.

— Эшләп күрсәтергә исәп әле бер...

— Әллә Исламны узарга уйлавыңмы?

— Ә нигә?

Машинист җилкәсен җыерып куйды.

— Тырышып кара. Бәлкем, медаль ук биреп куярлар. Ислам, әнә, орденга тырыша ди...

Котлованга Ислам килеп җитте. Ул экскаватор чүмече астындагы Зөлфәт машинасын күрде дә, туктауга, төшеп, машинист янына килде.

— Биредә отметкага җиттек дидең ич, яңа урынга күчмисеңмени?

— Хәзер күчәм.

— Күч. Мин шунда барып туктыйм.

Зөлфәт боларны ишетмәде, кабинада утыруын белде. Ул мыек астыннан гына Исламнан көлә иде.

Ул арада экскаваторчы икенче төшкә күчте. Ислам анда аны көтеп тора иде инде. Аның артына Гатифә килеп басты, Зөлфәт шунда гына ни булганын шәйләп алды.

— Нәрсә бу? — диде ул, экскаваторчы янына килеп, ачулы тавыш белән.

— Бас Гатифә артына. Юкса, әнә тагын берәү төшеп килә,— дип кычкырды машинист.

Ислам каш астыннан гына Зөлфәткә карап көлемсерәп тора иде. Моны, әлбәттә, барысы да күрделәр. Менә Ислам машинасының әрҗәсе дә тулды, тик ул нигәдер ашыкмый. Икенче машинист белән тәмәке тартып тора. Үзен бригадада һичкем уза алмаячагына ул ышана иде, күрәсең.

Әмма күңел сизгерлеге дигән нәрсә бар. Ислам да бүген нигәдер Зөлфәткә шикләнебрәк карый иде кебек. Иң әүвәл, ул аның иртә килүенә гаҗәпләнде булса кирәк. Ләкин барыбер көлде. Дөрес, сүз әйтеп түгел, үзалдына, мыек астыннан гына көлде. Моны барысы да күрде, аңлады.

Ислам белә иде: Зөлфәт нык тырышса да, көнлек нормасын йөз егерме процентка үтәр, әйтик, йөз утызга, әмма аның кебек йөз илле, йөз житмешкә житкерә алмас! Ислам моңа нык ышана иде.

Зөлфәтнең ачуы кайный башлады. Ул нихәтле генә борчылмаска, тыныч булырга тырышса да, булдыра алмады, гасабиланып, моторын үкертте... Ахырда сигнал бирде. Янәсе, әйдә тизрәк, тоткарлама.

Ислам кузгалды, әмма читкәрәк китеп туктады, төште, Әнәс янына килде. Ул бары тик Гатифә кузгалып киткәч кенә аңа иярде.

Ниһаять, Зөлфәт машинасының да әрҗәсе тулды. Ул чын-чынлап дулкынлана иде. Гүя ул яңа самолет сыный!..

Беренче тизлек. Машина акрын гына кузгалып китте. Менә икенче тизлеккә күчте, өченчегә...

Үр.

Бу үрне Зөлфәт гел беренче тизлек белән менә иде, ә бүген машина икенче белән дә жиңел генә бара. Зөлфәт газга баса төште. Машина тагы да тизрәк menә башлады. Юк, чынлап та могжиза иде бу. Чынлап та, алтын куллы икән бу Бакыйжан!

Үр дә менелде. Тизлек артканнан-арта башлады. Алда Ислам машинасы күренде. Зөлфәт Гатифәдән километр чамасы калып барган Исламны куа китте. Ул бүген Ислам биргән кадәр рейс ясарга тиеш. Бүген аның язмышы хәл ителәчәк. Инде бүген дә булмый икән, димәк, бу бригададан китәргә генә калачак. Күпме артта сөйрәлергә мөмкин. Бабай белән Петровичның бригадасы иң алдынгы итеп күрәселәре килә.

Газга баскан саен тизлек арта барды. Зөлфәт үз йөрәгенең дә мотор ритмына ияреп тибүен тоя. Тизлек арткан саен йөрәге дә ешрак тибә кебек иде. Менә спидометр угы сиксәнгә житте, туксанга... Зөлфәт бөтен тәне буйлап рәхәт кымырҗу коелуын тоя иде.

Йөз, йөз дә бер...

Ислам машинасы күзгә күренеп үсә башлады. Зөлфәт Исламны узу өчен сигнал лампочкасын кабызды. Менә ул аны куып житте, узды, Гатифәне куа китте, аны да узды. Алда юл буш иде. Спидометр угы йөз ун километр тирәсендә калтырап тора башлады.

Бушату урынына барып житүе булды, кызыл флаг тоткан кыз кай төшкә йөкне бушатырга дип урын күрсәтте һәм Зөлфәт туктауга йөгереп килеп, кабина баскычына басты.

— Исәнме, Ислам абый! — Ләкин кабинада Зөлфәтне күреп: — Атакаем, Вахитов икән,— диде һәм шундук кире йөгерде.

«Бирелә дә аның беренче йөрүенә өйрәнеп беткәннәр»,— дип үртәлеп алды Зөлфәт. Ләкин бу уен шунда ук онытты да. Ул йөген бушатты да кире борылып чапты.

Өйләгә кадәр Зөлфәт беренчелекне бирмәде. Төшкә таба төнлә яуган кар эреде, аяк астын пычратып жибәрде. Йөрү бермә-бер кыенлашты. Ләкин Зөлфәт барыбер куалады. Әнә шулай ул әкренләп машина йөртү серләренә төшенә башлады. Зур тизлек белән барган машина аз сикертә, мотор да ул тикле кызмый икән.

Ашап утырганда экскаваторчы егет мыек астыннан гына бер Зөлфәткә, бер Исламга карап елмаеп алды да:

— Хәлләр!..— дип, мәгънәле генә сызгырып куйды.

Эшнең уеннан узуын башкалар да аңлаганнар иде инде. Алар чышын-пышын шул турыда сөйләштеләр. Ислам ашады да машинасы янына китеп барды. Зөлфәт тә кабинасына кереп утырды. Экскаватор чүмече астында гадәттәгечә Ислам машинасы түгел, аның үзбушаткычы тора, шуңа бераз күңеле тынычлана төшкән иде.

Кабинага кергәч, ул тәрәзәгә карады.

Кар ява башлады. Кар бөртекләре тәрәзә пыяласына төшәләр дә

шундук су тамчысына әверелеп, юл ясап, борыла-сырыла түбән тәгәриләр. Кабинада буяу исе, соляр исе килә, шуңамы, бераз баш шаулый.

Зөлфәт Чаллыга килүен хәтерләде, машинага утыруын, нигәдер эшләп китә алмыйча җәфалануын исенә төшерде.

Әйе, бүгенге көнгә кадәр аңа күп оялырга туры килде. Иң әүвәл ул Мәснәвиядән ояла иде. Ул уйлый иде: Ислам өенә кайтадыр да бригадада Зөлфәтнең иң артта сөйрәлүе турында сөйлидер, ә үзе шәп эшләве белән мактанадыр. Мәснәвия аның өчен горурланадыр һәм кочагына сыенадыр... Аннары Дианадан да оят. Диана алар бригадасы эше белән кызыксынадыр һәм ул да Зөлфәтнең начар эшләвен беләдер кебек иде.

Аның уйларын бүлеп, кемдер машина ишеген шакыды.

— Ач әле ишегең?

Бу — Ислам иде. Зөлфәт ишекне ачты.

— Ни йомыш?

Ислам бу сорауны көтмәгән иде, гаҗәпләнүдән кашларын җыерды, ачуы кабарудан җете кара күзләрендә гүя очкыннар күренде.

— Ни пычагыма шул тиклем куалыйсың?

— Син кушмаганга! — диде Зөлфәт.

Ислам нидер әйтергә дип ымсынып алгандай итте, әмма ачкан авызыннан сүз чыгып өлгермәде — Зөлфәт үкертеп моторын кабызды да шапылдатып ишеген япты.

Ул арада кузовка беренче чүмеч балчык коелды. Ислам, биш-алты адым читкәрәк китеп, бу хәлгә карап-карап торды да аяк астындагы балчык кисәген тибеп җибәрде. Балчык төере кабина ишегенә килеп бәрелде.

## 10

Сәгъди Низамовның Чаллыга килүе болай булды.

Бер көнне аны трест начальнигы үзе янына чакырды. Сәгъди «нигә? ни өчен?» дип сорап тормады, гадәттәгечә, дәшү белән килеп тә житте. Икенче катка теләмичә генә күтәрелде. Күңеле нидер тоя, сизенә иде. Валентинасы үлгәннән соң Сәгъди еш кына нервылана, юкбарга йөрәге кагып китә, сабырсызлана төшә иде. Бигрәк вакытсыз китте шул. Ичмасам, тагын биш-алты ел гына яшәсен иде, пенсиягә дә чыга алмый калды. Ул, ичмасам, аны тынычландыра, киңәш бирә, үгетли, юата белә иде.

Сәгъди трест начальнигының ни өчен чакыруын белмәсә дә, бераз шәйли иде. Кичәгенәк аның бер шоферы Оренбург тракты үрен төшкәндә, машинасын тыя алмыйча, милиция посты будкасы өстенә килеп менгән, житмәсә, үзе имгәнгән. Ярый әле будкада кеше булмый, ул чакта бәладән баш китәрдәй хәл туасы иде. «Шуның өчен чакыруымы әллә бу Гавриловичның?» — дип уйлады Сәгъди.

— Үзендәме? — диде ул секретарьга, алгы якка керү белән.

Секретарь Мәрьям аны үз итә, якын итә, «син» дип дәшә иде, ишектә Сәгъди күренүгә, ул аңа урын тәкъдим итте.

— Каядыр чыкты гына. Хәзер керер. Утырып тор, Сәгъди, хәлләреңне сөйләп җибәр...

— Рәхмәт.

Сәгъди түргә үтеп, креслога утырды.

— Ни өчен чакырды икән, Мәрьям?

— Белмим шул. Белсәм, сиңа әйтми калмас идем. Миңа да әйтмәде, үзе чакырды. Димәк, сере бар...

— Нинди сере булсын аның миңа. Кичәгенәк бер шоферым милиция будкасын җимергән, шуның өчендер әле...

— Аның өчен түгел бугай. Мин белгәнчә, Иван Гаврилович сине Чаллыга кодаламакчы. Яңа автохуҗалык башы итеп...

— Нигә икән мине? Сәер!

— Син бит революция елында туган кеше, Сәгъди... Син дә бармагач, кем генә барсын соң анда...

Сәгъди еш кына: «Мин, Мәрьям, үзгә кеше, революция елында туган кеше»,— дип шаяртырга ярата иде, секретарь хатынның шул турыда төрттереп әйтүе иде, күрәсең.

— Анысы, кушсалар бармый булмас. Ләкин, Мәрьям, без бит инде олыгаеп киләбез. Әле кайчан гына син дә Нуриең артыннан чаба идең... Хәзер әнә ике бала үстердегез, чәчләргә кырау төште. Картаеп барабыз...

— Минекеләр хет үз янымда. Син, әнә, бер ялгызың калдың...

— Нишлисең, кем әйтмешли, язмыштан узмыш юк.

— Малайларың хат язамы? Әллә әниләрен җирләгәч тә гел онытылармы үзеңне?

— Язгалыйлар. Сашасы гел язып тора. Ленинградта бит. Капитан. Хәрби кеше. Дисциплина үзгә...

— Тәки кеше иттен үзләрен, Сәгъди. Николаең Себердәме әле?

— Әйе. Академшәһәрдә. Анысы ике-өч айга бер генә яза. Вакыт җитми, ди.

— Өйләндеме соң әле? — дип сорады Мәрьям.

— Юк шул. Бозылды хәзерге яшьләр. Буйдак тормыш яраталар.

— Яшьлекнең кадерен беләләр. Ике килми, диләр ич аны... Хәзерге балалар үз аталарын да бик искә алмыйлар, Сәгъди, алай язып торгач ярый инде.

Бу сүзне ишетүгә, Сәгъдинең йөзенә караңгы сарды. Моны Мәрьям дә сизми калмады, әлбәттә.

— Гафу ит, Сәгъди, кәефеңне кырдым, ахры. Хатын-кыз шулайрак инде ул...

— Зыян юк. Син, кем әйтмешли, Валя белән бергә эшләгән кеше, үз кеше. Читләр әйткәндә кыен була торган иде,— диде Сәгъди һәм, торып, ишектән кереп килүче трест начальнигына таба китте.

Әнә шулай, Сәгъди, Казанда җитәкчелек иткән автохуҗалыгын калдырып, Чаллыга килде. Урта буйлы, чаларган чәчле, беренче карашка шактый кырыс чырайлы булып күренгән Сәгъди Низамов яшәп-яшәп тә гаилә җылылыгын тоймаган, күрмәгән кешегәрәк охшый. Һәрхәлдә, дуслары аның турында шулай дип уйлыйлар иде. Аннары ул үз эшләре җыелганда еш кына семья турында бәхәс кузгата. Һәм бу хакта аның үз фәлсәфәсе бар. Анынча фикер йөртсәк: семья ул — кечкенә дәүләт, семья ул — дәүләтнең асылы.

Сәгъди үзе семья ямен татыганмы-юкмы, анысын дуслары тәгаен генә белмиләр, әмма аның кайчандыр хатыны, баласы булуын беләләр. Хатыны сугышка кадәр үк, берәүгә ияреп, аны ташлап китә. Әмма семья корырга омтылган Сәгъди гаиләсез, баласыз озак яши алмый, сугыш бетүгә, Казанга кайта һәм үзеннән дүрт-биш яшькә олырак өч балалы хатынга йортка керә. Өчесе дә малай булган бу хатынның балаларын үстерә, укыта, кеше итә. Ләкин тегеләр кайсы кая очып таралып беткәч, кинәт кенә әниләре Валентина үлеп китә. Сәгъди янә бер ялгызы кала. Авыр кичерә ул Валентинаның үлемен. Ләкин кайгы-хәсрәт адәм баласына килә дә, китә дә, диләр. Тора-бара Сәгъди дә тынычлана төшә, мәгәр күңел түрендәге Валясын юксыну һәрчак үзен сиздереп тора. Соңгы вакытта Сәгъдинең каңгырыбрак йөрүен трест начальнигы да күреп ала һәм иң әйбәте — китеп эшләү дигән фикергә килә.

Казандагы автохуҗалык начальниклары арасында ул алдынгылардан булды. Шофер халкы да ярата иде үзен. Сәгъди белән бергә эшләгән

кешеләр аны, әйбәт житәкче иде, диләр. Сәгъди үзе чәчрәп торган шофер егетләрне ярата. Бу сәер ярату аңа сугыш елларында танкистлар хәзерләгәндә үк кереп кала, күрәсең. Аның үзе яраткан гына шоферлары булыр, ул аларны тиешле оешмаларга гына эшкә җибәрер иде. Яратмаганы — сабыр-салмак, эленке-салынкы йөргән шоферлар. Андый машина йөртүче ул җитәкчелек иткән хуҗалыкта озак эшли алмый. Чөнки тегене Сәгъди җыелыш саен кызарта, кабинетына чакырып сөйләшә.

— Кешене кеше итүче — хезмәт,— ди ул еш кына.— Димәк, кеше исемен алгансың икән, дускай, чын-чынлап, көчеңне кызганмыйча эшләргә кирәк.

— Менә син аның белән сөйләш,— дип җилкә җыерып чыгалар аның кабинетыннан кайбер ялкаурак шоферлар.— Я һәр көн норманы үтисең, я слесарь булып күчәсең,— дип әйтә, диләр. Әнә шулай нык коллектив туплаган иде ул Казанда чакта.

Чаллыда аңа эшне өр-яңадан башларга туры килде. Биредә акчаны күрәп алырга килүчеләр дә байтак. Әнә шулардан, гади таш арасында яткан энҗе-гәүһәрләрне тапкандай, тырыш, хезмәт сөючән шофер егетләрне сайлап алырга, Казандагы кебек үк нык, бердәм коллектив тупларга кирәк иде. Чаллыга килгәч, Сәгъди иң әүвәл әнә шуннан башлады.

Әлбәттә, бу мәсьәләдә аның ялгышып киткән чаклары да булды. Ләкин эшләгән кадәре дә аз түгел иде. Әгәр дә мәгәр шофер тырыш, эш өчен җанын бирергә тора икән, ул аны төшемле урынга җибәрде һәм тегеңә, күрәп үк булмаса да, кушуч тутырып акча алырга ярдәм итте.

Биредә аңа бер үзенә бер бүлмәле квартир бирделәр. Сәгъди онытылып эшли башлады. Эштән бик соң кайткан чаклары ешаеп китте. Көннәрдән бер көнне Иске Чаллы буйлап кайтып килгәндә берәүнең ишегалдында әрнүле хатын-кыз тавышы ишетте. Түзмәде, борылып керде.

— Гафу итегез, ни бар? Ни булды?

— Әнә, улым эчеп кайткан. Эшли башлавына өч ай булмады, эшеннән куганнар. Шул кайгыдан айлык акчасын туздырып бетергән...

Кечкенә капкалы, такта койма белән уратып алынган һәм урам яктан ямьле генә күренгән бу өйдә шундый хәсрәт күреп, Сәгъди борчылып куйды. Нинди кайгылар гына китерми бу аракы кешегә.

— Кайда эшли иде?

— Икеенче автохуҗалыкта шофер иде...

Сәгъди хуҗалыгыннан түгел икән.

Ул өй бусагасына яны белән төшкән егет янына килде. Егетнең кыяфәте җирәнгеч иде: чәче-башы тузган, бер яңагы сыдырылган, иреннәре күм-күк, аның саен укшып, тешен шыгырдатып куя, кемнедер орыша, сүгә...

— Суыгыз бармы, әни кеше? Бер чиләк су китерегез.

Сәгъди шәлперәйгән исерек гәүдәне көч-хәл белән сөйрәп өйгә кертте, өстен-башын чишендерде, ишек янындагы караватка салды. Аннары ул әни кешегә таз һәм су китерергә кушты.

— Кой, әйдә!

Ана курка калды.

— Суык су бит, салкын тимәгәе...

— Кой диләр сезгә!

Сәгъди шунда хатынның йөзенә ачулы караш ташлады. Һәм аның күзләрендә яшь күреп, кызганып куйды. Ләкин моңа карап кына егеткә күнеле йомшармады.

— Коегыз, берни дә булмас! — диде ул боерган тавыш белән.

Хатын чиләктән улы башына салкын су коя башлады.

— Кой, кой, кызганма! Сез кызганганга күрә шул көнгә калган да ул... Хәзер сөлге бирегез...

Сәгъди бит-башына салкын су койганнан соң, өшеп калтырый башлаган егетнең өстенә юрган япты да үзенә гаҗәпләнеп карап торган анадан:

— Малаеңның исеме ничек? — дип сорады.

— Әнәс.

— Әнәс!..— дип кайтарып сорады Сәгъди һәм күңел күгендә әллә кайчан булып үткән хатирәләр пәйда булды. Бу исемнән ул квартирына кайткач та арына алмады. Ә инде урынына ятуга, зиһене ачылып китте, иске хәлләр бәйнә-бәйнә исенә төшә башлады.

## 11

Кайчандыр аның да үз баласы, хатыны бар иде. Дөрес, беренче хатыны Сараны югалтканнан соң тапкан Валяның улларын да ул үз итте. Күңелен ялгызлык талкымады, әрнүле-үкенүле хисләр кичермәде. Ләкин барыбер вакыт-вакыт йөрәкне нидер тырнап куйгалый иде. Үткән өчен үкенү идеме бу, малайларның үги аталарына карата кайчак гадел булмаганнан туган әрнүле хис идеме? Сәгъдинең моны әлегә кадәр аңлый алганы юк. Ләкин бер нәрсәне яхшы белә иде ул: чын мәгънәсендә беренче мәхәббәте булган Сарасын әле дә булса оныта алмый, вакыт-вакыт ул искә төшә, күңел төпкелегендәге хатирәләрне кузгатып, уйланырга мәҗбүр итә. Валентина, уллары Коля, Саша, Сергей белән исән-сау, таза-тигез яшәгәндә бу хатирәләр ул кадәр аны борчымый иде. Валясы аны ярата белде. Ул һәрвакыт аның турында кайгырта, борчыла торган иде. Кешелеге зур иде. Шуңа яшәде ул аның белән, шуңа яратты. Тора-бара Валяның кайгыртучанлыгы Сәгъдигә дә күчте. Шул кешелеклелек Сараны исенә төшерергә мәҗбүр итте, кайчандыр үзен ташлап киткәне өчен аны гафу иткән чаклары да булгалады.

Ни булды? Кем комачаулады аңа Сара белән торып китәргә? Кем күпсенде аларның тату яшәүләрен?

Кем?

Барысына да бер әнисе гаеплеме? Әллә тагын үзләрендә дә гаеп булдымы? Дөрес, әнисе Сарага көн күрсәтмәде, һәрвакыт тавыш-буза чыгарып торды. Ләкин Сара аны бер шуның өчен генә ташлап киттеме?.. Юк бит, юк!

Әнисе Сәгъдигә еш кына:

— Сараң кая китте? Тагын үзең генә йокладыңмы? Төн юк, көн юк — шул булнисында югала,— ди торган иде.

— Эше шундый ич аның. Ул бит — хирургия сестрасы. Ә аларны кирәк булганда төнлә дә чакыралар. Нигә алай тузынасың әле, әни?

— Әллә син аны гел эшендә югала дип беләсеңме? Бераз күз-колак була аласыңмы үзенә, юкмы? Ирме соң син? Хатының шул булнистагы Әнәс атлы хирур белән гыйшык-мыйшык тота ди...

— Кем шулай ди?..

— Кем, кем... Кем сөйләсә дә барыбер түгелмени? Үз хатынының зина кылуын иң соңыннан ире белер диләр, хак икән...

Сәгъди башта моңа чынлап та ышанып җитмәде. «Әни Сараны күрәлмый, шуңа нахакка рәнҗетә, бер дә бүтән түгел, Сара белән минем араны бозмакчы», дип йөрде. «Юк, әнкәй, безнең арага чөй керәчәк түгел. Сараны мин яратам, балабыз бар»... диде.

Шулай дип барса да, көн саен шул турыда уйлана, сөйләшә торгач, коткы дигәнең үзенекен итте: Сәгъди чын-чынлап Сарадан шикл-

нә башлады. Бакса, соңгы вакытта Сара аңа сулыгып киткән кебек күренде. Ни булды? Сәгъдигә карата ул ничектер суына башлаган сыман иде. Хатыны еш кына бер ноктага карап уйга чума, сәер итеп һич юктан үзалдына уфтанып куя. Күзләреннән дым кипми. Аеруча әнисе белән Сара икәүдән-икәү калганда хатынының күзләре елаудан кызарган була иде.

Күңел сизә, күңел тоя, диләр, дөрес икән. Сәгъди, Сараны күзәтә башлауга, хатынында чынлап та үзгәреш күреп таң калды. Сарасы гел аңыкы түгел ич хәзер! Ул күптән инде үзалдына йомылып, үз дөньясы белән яши. Кем өчен көя, кем өчен көн-төн уфтана бу Сара? Әллә соң чынлап та берәрсе белән йөриме?

Аерылышулары тиз булды. Беркөнне ул соңгы вакытта еш кына әниләренә китеп югала башлаган Сарасы артыннан китте. Бәлкем, Сара моны бианасы җәбереннән котылу өчен эшләгәндер? Әмма бу хәл Сәгъдине барыбер шиккә калдырды. Ул ашыкты, суга батудан саламга тотынып котылырга теләгән кеше сыман, тизрәк чын хакыйкатьне белергә теләде. Ул бетереште, аяк астында ныклык тоймый башлады, йокыдан калды, күзен йомса, Сарасы белән Әнәсне күрде. Әнәс Сәгъдинең бабалары белән бер йортта тора иде, Сара белән алар бергә үскәннәр иде. Сәгъди моны белә, шуңа шиге тагы да арта бара иде. Ниһаять, моңа бер чик куярга, Сара белән ачыктан-ачык сөйләшергә, аңлашырга кирәк иде.

Ләкин моны әнисе янында, өйдә эшлисе килми иде аның. Чөнки күңел түрендә вакыт-вакыт бу хәлнең юк сүз икәненә өмет чаткысы кабынгалап китә иде әле.

Көнчелек ул математик алдындагы чишелмәгән мәсьәлә кебек. Математик мәсьәләне никадәр тизрәк чишәргә тырышса, көнче кеше дә көнләштерүчесен тизрәк фаш итәргә омтыла.

Сәгъдинең дә Сараны тизрәк фаш итәсе килде. Шуңа ул әбиләренә ашыкты.

Күңелгә килгән — алга килә ди. Сәгъди әбиләренә килеп кергәч, әбисе:

— Сара яңа гына баланы алып ишегалдына чыккание, кияү, бар, чакыр әле үзләрен. Мактап кына йөрисең икән әле, минә коймагым да өлгергәние,— диде.

Сәгъди ишегалдына чыкты, беренче каттагы ачык тәрәзәгә күз ташлады һәм акылын җуярлык бер хәл күрде.

Диванда Әнәс белән Сара утыра. Сара аның күкрәгенә башын салган, тегесе нидер сөйли, чәчләреннән үбә, аркасыннан сөя, нәрсәдер әйтә иде.

Ни әйтте ул? Сәгъди ишетте дә, ишетмәде дә. Колаклары чыңлап китте, күз алды томанланды. Идәндә йөргән бала, әтисен күреп:

— Әттә!..— дип эндәште.

Сара сискәнеп китте, диваннан сикереп торды һәм идәндәге баланы элеп алды да ишегалдына чыкты. Тәрәзәдәге Сәгъдине ул әллә күрде, әллә күрмәде, әмма Әнәс дигәне аны аермачык күрде. Күрде һәм йөзенә зәһәр бер елмаю билгеләре чыкты. Аның әнә шул карашын Сәгъди гомер буена оныта алмады.

Сәгъди Сарага бу көнне бер сүз әйтмәде. Гаҗәп, мәсьәлә чишелгәннән соң, аңа кинәт рәхәт булып китте. Хак, әнисе дөрес әйткән. Ул хәтта, берни булмагандай, үчтекиләп баланы сөйде, әбисе белән ачылып сөйләште, сөмсере коелган Сараның күңелен ачарга теләп, мәзәкләр сөйләде.

Чын мәгънәсендәге көнчелек тойгысы аңа соңрак килде: шул хәлдән соң хатынының, берни булмагандай, гамьсез йөрүеннән башланды. Бу тойгы аңарда көннән-көн көчәя барды һәм ахырда Сәгъдине авыруга сабыштырды.

Сәгъди көнләшүнең кеше өчен бик яман чир булуын белә иде. Әмма аның бу чирне үзе кичергәне юк иде әле. Гашыйк булмыйча, мәхәббәт ләззәтен тоймаган егет кебек, ул да, көнчелек килмичә, аның никадәр авыр фаҗига икәнен белми йөрде.

Хәзер ул аны белә. Бу яман авыруны ул йөрәге белән кичерә. Сәгъди күзгә күренеп ябыкты, суырылды, яңаклары эчкә батты. Күзендә яшәү дәрте сүнде. Әнәс кочагында яткан Сараны күз алдыннан җибәрә алмыйча җәфа чикте. Еш кына берни күрмәс күзләре белән бер төбәккә карап, уйга чумды.

Сәгъди өчен бер бәхеткә килгән ике бәхетсезлек иде бу. Ирлек. Ирлек нидә сынала соң? Әллә тагын ул зина кылган хатынына дәшмәүдәме? Юк, юк, ул аңа бу турыда әйтергә, алар аңлашырга тиешләр.

Сәгъди хатыны янында күпме генә сабыр, тыныч булырга теләмәсен, Сара белә иде: бүгенме, иртәгәме, берсекөнгәме — сөйләшү булачак. Ләкин ул аны үзе башламаячак. Шуңа Сара көтәргә, сабыр итәргә булды. Ул аңлый иде: әгәр дә мәгәр бу сөйләшү була кала икән, моннан соң инде алар бергә тора алмаячаклар. Шул ук вакытта ул бу сөйләшүнең тизрәк булуын да тели иде. Чөнки кылыч өстенә баскандай яшәү аны тәмам талкыган, авыру бер хәлгә китергән иде.

Кайчак ул бу сөйләшүгә сылтау да эзләде. Эштән соңга калыбрак кайтты, кырысланды.

Сәгъди түзмәде, көннәрдән бер көнне җыелып килгән бөтен ачузәһәрен бер минутта түкте дә салды. Имеш, Сара сөйрәлчек, Әнәс белән йөри, ә бу инде җинаять, фахишәлек, бозыклык бу.

Мондый сүзләрне ире Сәгъдидән ишетергә өйрәнмәгән Сара әүвәл, битенә кайнар су сибүдән котылырга теләгән кеше шикелле, ике кулы белән йөзен каплады, башын чайкый-чайкый аһылдап торды, ахырда түзә алмады, йокы бүлмәсенә кереп, караватка капланды һәм илерепүртәлеп еларга тотынды.

Яшәү гомерләрендә беренче тапкыр Сәгъди курка калды һәм чынчынлап икеләнеп китте.

— Мин гаепле түгел, гаепле түгел, Сәгъди! — дип такмаклап-такмаклап елады Сара.

Сәгъди аны тыңламады, йөрәге кукрәгеннән чыгардай булып тибә. Аның бер Сара алдына тезләнеп гафу үтенәсе, бер аны битенә төкереп куып чыгарасы килә иде. Ләкин ул тегесен дә, монысын да эшләмәде. Киенде дә дәшми-тынмый өйдән чыгып китте. Һәм таң алдыннан гына кайтып керде.

Ул кайтканда Сара өйдә юк иде инде. Баланы алып әниләренә киткән иде.

Бу хәлгә шаккатып торган Сәгъдигә әнисе:

— Иләсләнеп йөрмә, ир бул! Китсә китәр. Хатын бетмәс әле. Башың исән-сау булсын,— дип кенә әйтә алды.

Сәгъди, әнисенең үгетенә ышанып, Сара артыннан бармады. Алар шулай аерылышып тора башладылар. Нәкъ шул көннәрдә кинәт Сәгъдинең әнисе авырып китте. Әле иллесен дә тутырып житкермәгән Гөлҗәннәтнең чире көткәннән хәтәррәк булып чыкты. Аңардан рак таптылар һәм, үләргә күп калмаган, дип, өенә җибәрделәр. Сәгъди өчен авыр көннәр башланды. Эше дә җаваплы иде: начармы-яхшымы — автохуҗалык инженеры, үлем көтеп яткан әнисен дә карыйсы бар иде.

Беркөнне шулай Сәгъдине әнисе үз янына дәште. Сәгъди, урындык алып, хаста әнисе янына килеп утыргач, Гөлҗәннәт буыннары төерләнеп беткән кулын улының тезенә салды да текәлеп күзләренә карады. Әнисенә аның ни белән авыруы турында әйткәне юк, шуны беләсе килә, дип уйлады Сәгъди. Ләкин ана үзендә нинди сырхау икәнлеген

белә иде булса кирәк. Сәгъди моны энисенең матур зәңгәр күзләрендә нур сүрелүеннән үк сизеп алды.

Менә шул күзләр яшь белән мөлдерәп тулды.

— Балам, бәгырем! — дип, беравык сүз эзләгәндәй, яшенә тыгылып торды ана.— Мине җырләгәч, киленне алып кайтырсың. Мин аны хакка да, нахакка да рәнжеттем бугай. Әҗәле килер алдыннан әнкәй бәхиллегең сорады, диген үзенә...— Күз яшен яулык очы белән сөртеп алды.— Инде килешә алмасагыз, баланы, Вәлиемне үзеңә ал, аңарда калдырма... Без, балам, аксөякләр нәселеннән. Атаң мәрхүмнең Мәкәрҗәдә генә бишләп кибете бар иде. Нишлисең, аллаһы тәгалә насыйп итмәгән, күрәсең, күпсенгән,— диде Гөлҗәннәт һәм бер тын уйланып ятты.

Әлегә кадәр йөрәк түрендә сер итеп саклаган иң кадерле, шул ук вакытта иң фаҗигале сүзләрен улына әйтергәме? Әллә, югыйсә, үзе белән гүргә алып китсенме?.. Юк, юк, ул аңа әйтергә тиеш, аның Сәгъдие үзенең кем канынннан икәнен белергә тиеш...

— Син туганда, улым, атаңны атканнар иде инде. Онытма, васыять итеп әйтәм: без — аксөяк нәселеннән. Әлегә кадәр әйтми йөрүемнең сәбәбе бар, улым. Сине укытыр өчен, сине кеше итәр өчен дәшмәдем, үземне сиңа да, башкаларга да бай тегүчесе дип кенә бардым. Мин, улым, Казанда бер диярлек байбичә идем. Мин урамга чыкканда барча Казан мине күрергә чыгар иде... Революциядән соң, әйдә, укысын, кеше булсын дип, егерме ел тегү тектем. Күзләрем күрмәс булды, кулбуыннарым кимерчәкләнеп катты. Менә бу кулларым чынаяктан ак, сөттән пакь иде. Әтиең кулларымны учына алыр иде дә: «Мамыктыр, Гөлҗәннәт, синең кулларың»,— дияр иде.

Ана буын-буын бөҗраланып, шәмәхә кан тамырлары беленеп торган кулларын улының күзенә таба китерде.

— Менә кара, тегү тегә-тегә нишләде анаң куллары!.. Сине кеше итү өчен, халык арасында ким-хур булмасын дип эшли-эшли шулай катты бу бармакларым...

— Инәй...

— Тукта, тыңлап бетер... Сарага өйләнергә ниятеңне белгәч, кайгырдым, гел йокыдан калдым. Ризалыгым бирмәвем дә шуннан иде. Барыбер өйләндең, барыбер анаң киңәшен тотмадың!.. Әниең йөрәге парә-парә килгәнне белмәдең шул син, белмәдең... Сараны алып килгәч, гомер үзеңә җаным эремәс дип уйлаган идем, аллаһы тәгаләнең мәрхәмәте киң икән: әҗәл түшәгенә яткач булса да, күңелемне йомшартты...

Гөлҗәннәт сулыгып елап җибәрде. Яшь бөртекләре йөзе буйлап йөгерешә-йөгерешә мендәргә төшеп тамды. Сәгъдигә ул яшьләр мендәргә түгел, аның йөрәгенә тамалар кебек иде.

Гөлҗәннәт улының иелгән башын күкрәгенә кысты, сөяктәй каткан кулы белән чәченнән сыйпый-сыйпый сөя башлады. Улына аның сүзе бетмәгән иде әле. Хәле генә бетеп киткән кебек булды. Хәзер, хәзер ул аңа барысын да сөйләр. Кодасы, кодагые турында да, әлегә кадәр оныта алмаган Вәлие турында да әйтер. Шунсыз аңа үлем үлем булмаячак. Кодасын күз алдына китерү белән, Гөлҗәннәт, бер мәлгә акылын җуйган кешедәй, күзләрен акайтып, түшәмгә карап ятты.

— Улым, бәбкәчем, балам! — дип, юаш һәм күндәм тавыш белән, үтенгән сыман, сүзендә дәвам итте.— Әйтми гүргә керә алмыйм... Тәкъдирем тәкъдир булмас дип куркам. Йа аллам, кичер мин колыңны, кичер!..

Сәгъди башын күтәреп әнисенең күзләренә карады.

— Улым, балам,— дип кабатлады ана янә, Сәгъдинең кулларын эзләп.— Атаңны үтерүче — Сараның әтисе Гомәр бабаң... Кодага кансыравымның сәбәбе дә шул. Үз күз алдымда атты бәгыремне!.. Ул

мине дә теге дөньяга җибәрә иде. Мине байбичә тегүчесе дип белде. Сиңа ыштан-күлмәк тегеп утыра идем... Соңыннан ул исемне мин үзем дә бик теләп алдым. Чөнки карынымда син бар идең, синең гомереңне кызгандым, сине исән калдыру өчен шулай эшләдем, улым... Югыйсә, мин атаң белән янәшә ятып та үлә ала идем,— диде ана һәм тагын бер хәл тын алып ятты.— Йа ходаем, күз алдыма килсә, әле булса тәнем калтырый... Килеп керде. Өстендә күн тужурка, ике кулында ике наган... Ай, шул минутлардагы бәгырем өзгәләнүләре!.. Әтиең идәндә кан эчендә ята... Йа аллам, ниләр генә күрсәтмәдең мин колыңа!.. Соңыннан ул минем кем икәнемне белде, ләкин һичкемгә әйтмәде, тегүче дип документ бирде. Мин, улым, атаң нәселен калдырыр өчен шул мәкергә барырга мәҗбүр булдым... Исеңдәме, бабаң, аз гына кәефләнеп алса, ни дип күкрәк кага иде: «Дөнья безнеке хәзер. Без аны кан түгеп яуладык. Бу хөррият — мәңгелек!» — дип әтәчләнер иде. Күп күкрәк кага торгач, әнә былтыр, бахырны, үзен дәябып куйдылар. Бәла ул, улым, агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри... Бәлкем, бахырга, минем каргыш та төшкәндер, үзе бер кызыл авызга өйләнде, миңа өйләнергә гарьләнде, үзе син Сарага өйләнгәнче диярлек минем янга йөрде. Куркытып, сине институттан кудыртам, кем булуыңны фаш итәм дип йөрде. Йа аллам, ниләр генә күрми бу дөньяда адәм баласы. Ярый әле, аллага шөкер кылам, син боларны күрмәдең дә, белмәдең дә... Хәзер инде белсәң дә үкенмим. Мин сине кеше иттем... үзең ничек телисең, шулай яшә. Миңа рәнҗемә, төрле чаклары булгандыр... Бәхиллә, бәхиллә...

Сәгъди, бөтен тәнендә кургаш авырлыгы тоеп, кинәт калтырап китте. Гүя аның җилкәсенә авыр йөк салганнар иде. Һәм ул аңардан арынырга тели, әмма көче җитми, ә йөк аны һаман баса, җиргә сеңдерә иде. Әнисенең һәр сүзе Сәгъди йөрәгенә шырпы булып кадала барды. Ул, ни кылырга, ни эшләргә белмичә, көч-хәл белән урыныннан кузгалды да, читлеккә япкан арыслан кебек, ишекле-түрле йөри башлады. Татлы хыяллар аның күңеленнән җуела бара, аның урынын тормыш чынбарлыгы, әнисе сөйләгән, тетрәтердәй гыйбрәтле хәлләр тәэсире били бара иде. Ә ул тәэсир, йөрәгенә төшә барып, кемнәндер үч алу тойгысын кузгата, гасабиландыра иде.

Әйе, әйе, ул бүгенгә кадәр канатлы кош иде. Бүген аның ул канатларын кисеп аттылар. Хәзер ул оча алмас. Хәзер ул, елан кебек, җирдән шуышыр. Аның зәһәр, үткен угында һәрчак агу булыр. Ул хәзер белә, аңа бер нәрсә мәгълүм: ул — бай малае, Сәгъди — аксөяк нәселеннән, аның әтисе Вәли Казан байларының берсе булган. Аны Сараның әтисе (бабай диярга теле бармады) атып үтергән. Атып! Нигә? Ни өчен?! Әтинең политик кыйбласы? Бәлкем, ул Совет яклы булгандыр? Сараның әтисе аны бай булуы өчен генә атканмы? Бәлкем, ул моны әнисен сөяркәсе итү өчен эшләгәндер? Нигә бу турыда әнисе бер сүз дә әйтми?..

Гөлҗәннәт, күзләрен зур ачып, түшәмгә текәлде.

— Улым,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә.— Мин бүген үләрмен, ахрысы. Ясин чыгарга мулла чакырсаң ие... Бу минем соңгы үтенечем, балам...

— Инәй...

— Мулла чакыр...

Сәгъди мулла алып килде дә, аны әнисе янында калдырып, урамга, каршыдагы бакчага чыкты.

Сәгъди малай чагын күз алдына китерергә тырышты, үзләренә килеп йөргән юантык гәүдәле Гомәр бабасын хәтерләде.

Шул кеше Сараның әтисе булды микәнни? Ул Сәгъдинең әтисен — Вәлине аткан! Юк, юк, һич дөрес түгел. Авыру саташуы гына бу!

Сәгъди йөгереп өйгә керде. Булган хәлне энисеннән тагын бер тапкыр әйттерергә дип керде. Әмма соңга калган булып чыкты. Ул чыгып китүгә күп тә үтми, энисе җан биргән иде.

— Нигә чакырмадыгыз? — диде ул энисенең баш очында утырган муллага.

Мулла дәшмәде.

Сәгъди, энисе үлеменә ышанмагандай, аның кулына кагылды, пульсын тотып карады. Кул салкын, җансыз, кургашындай авыраеп калган иде.

— Үлгән!

Сәгъди энисе күкрәгенә капланып күз яше белән елап җибәрде. Аның катып киткән, буынланып беткән бармакларыннан үпте, куллары белән аның вакытсыз чаларган чәчләренә кагылды... Ул гүя энисенең үзенә кем булуын менә хәзер генә аңлады. Шушы минуттан ул бу дөньяга бөтенләй икенче күзлектән карый башлады.

...Энисен җирләгәч, Сәгъди өен юдыртты, мәрхүмәнең өчесен үткәрде. Дөрес, боларны ул үзе генә эшләмәде — күрше-күлән булышты. Шул мәшәкатьләрдән соң, ул Сараны алып кайтырга дигән нияткә килде.

Транспорт туктаган, урамнарда хәрәкәт сүрелгән иде — тротуарны бер итеп җәяү китте. Сара белән йөргән урам-тыкрыклар буйлап атлаганда, шунда икәү бергә таң аттырган чакларны хәтерләп, Сәгъдинең йөрәге талпынып тибәргә тотынды.

Кешеләр энә тавышланып, тәпәләшеп тә алалар, хәтта аерылышып та торалар, әмма барыбер килешәләр, яңадан кавышалар һәм «никах яңарту» сылтавы белән мәҗлесләр җыялар. Ә ул, Сара, ике сүз әйткәнгә чыкты да китте. Кайбер ирләр үз хатыннарын куа алмый җәфа чигәләр: ире ишектән куса, тегесе тәрәзәдән керә, дигәндәй. Нигә соң мин аны гафу итмәскә тиеш?! Бала хакына. Бәлкем, Әнәс белән әллә нәрсәсе дә булмагандыр?..

Әнә шундый уйлар белән әбиләренә ашкынып килсә дә, ишегалларына керү белән, икеләнә калды. Әллә соң бер киселгән икмәкне ябыштырып та маташмаскамы? Әни әйтмешли, «хатын бетәрме».

Ләкин Сара белән әүвәл башта пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп тату-матур торулары күз алдына килүе булды, йөрәге тарсылдап кага башлады. Юк, ул биредән китә алмый. Ул аны, һич югы, күрергә тиеш.

Әбисе элекке татар баеның яшь хатыны өчен салдырган, сырлап-франтунлап ясаган өйнең икенче катында тора иде, тар баскычтан шунда күтәрелә башлады.

Менә ишек. Сәгъди таныш звонок төймәсенә басты. Кемдер келәне ычкындырып җибәрде, шагырдап эчке ишек ачылды, ут кабынды.

— Кем ул?

— Бу — мин, әбкәй, ач әле!

— Ай аллам, кияү...

Сәгъдине бусагада күрүгә, әбисенең кинәт төсе-бите агарынып китте. Сәгъди аңа гел игътибар итмәде. Бусаганы атлап алгы бүлмәгә керде, залга күз ташлады, йокы бүлмәсенә үтте.

— Әби, Сара кая?

Әбисе аһ итте, авызын яулык почмагы белән каплап, башын иде.

— Кияү, Сара Әнәс белән китте. Зинһар, кичер син аны... Анаң бик җәберләгән бит. Синең атаң да уйнашчы иде, син дә шуның сыңары, дип көн-төн битәрләгән...

Сәгъди белән әбисе күзгә-күз карашып алдылар. Әбисе, ниндидер уңайсызлану хис итеп, күрше бүлмәгә чыга башлады.

— Әйдә кер, хәзер чәй куям...

— Рәхмәт...

Сәгъди иләс-миләс хәлдә баскычтан төште, урамга чыкты. Күңелен сагыш биләп алды. Ул гүя тирән чоңгылда бутала. Менә аннан ургылып-айкалып чыга. Чыга да Сәгъдинең болай да нечкәреп киткән күңелен жилкендерә иде. Ул, гажиз калып, зират ягына таба китте. Ул анда бармаска да тели, ләкин үз-үзе белән берни эшли алмый, аяклары аны шул якка, әнисе каберенә таба сөйри иде.

Казан! Сәгъди туган һәм Сәгъди үскән мәшһүр шәһәр! Ул төнозын шәһәр урамнарында йөреп чыкты. Тик таң беленеп, кояш нурлары Кремль манараларына кунгач кына эшли торган гаражына таба баруын шәйләде.

Гаражга килгәч, кабинетына керде һәм бөтен тәнендә хәлсезлек тоеп, диванга ятты. Һәм шунда ук йокыга да китте.

Ул илереп елаган хатын-кыз тавышына сискәнеп уянды. Начальникның секретаре еш кына елаштыра, ире белән тату тормый дип сөйләүчеләр бар иде. Тегенең елавына түзмәде, янына чыкты.

— Ни булды тагын, Кадрия? Нигә елыйсың?

Секретарь хатын, елаудан кызарынып беткән күзләрен күтәреп, баш инженерга карады.

— Сугыш башланган!

— Сугыш?!

Сәгъди кабаланып кабинетына үтте, радионы жибәрде.

Дөрес! Фашистик Германия бүген төнлә чикне бозып кергән һәм Украина шәһәрләрен бомбага тота...

Бер атнадан соң аны да сугышка алдылар. 1941 елның июнендә Сәгъди Низамов берьюлы ике фажига кичерде: семьясыз калды һәм сугышка китте.

## 12

Сугышның беренче көненнән үк аны танк училищесына укытучы итеп жибәрделәр. Ул фронтка танкистлар хәзерләде. Аннан, сугыш беткәч кенә, майор дәрәжәсендә Казанга кайтты.

1946 ел сугыштан соң килгән иң авыр ачлык елы булды. Сәгъдине автохужалыкка начальник итеп билгеләделәр. Шунда ул Валясын тапты.

Валя диспетчер булып эшли, бик авыр, бик интегеп яши иде. Сәгъди аңа һәр атна саен бер бөтен ипи, бераз шикәр, ярты кило чамасы ярма биреп жибәрде. Азык-төлекне ул авылларга йөргән шоферлардан кайтарта иде.

Беркөнне Валя аны үзенә чакырды. Сәгъди балаларга күчтәнәч китергән иде. Берсеннән-берсе кечкенә Коля, Саша, Сергей аны шунда ук үз иттеләр. Хәтерендә: бераз кәефләнеп алгач, ул аларны берәмберәм жилкәсенә атландырып йөртте. Киткәндә Валя аны озата чыкты, капка төбендә саубуллашырга дип туктагач, хатын кинәт Сәгъди күкрәгенә сыенды, жылы, йомшак, кайнар иреннәре белән ирне үзе үк үбә башлады.

— Тагын кил,— дип пышылдады хатын, назга сусаганын сиздереп.

— Дмитрий...

— Ул кырык икенче елда ук Калинин фронтында һәлак булды. Бүтән сорама аның турында, Сәгъди,— диде хатын.

...Сәгъди бу семьяга шулай килә-китә ике-өч ай йөрде дә бер килүендә китмәде, бөтенләй калды. Валя аны баласы кебек карады, бик яратты. Ул сөя дә, назлый да, назлана да белә иде. Сәгъди ансыз тора алмаслыгына тәгаен ышангач, аларны үз квартирына алып килде. Аның өч бүлмәле квартирында су да, пар да бар иде, Валя исә баракта бер бүлмәдә яши иде. Яңа квартирга күчеп килгәч, малайлар-

ның түбәләре күккә тиде, ә Валяның икенче сулышы ачылды. Ул, гел унсигез яшьлек кызлар кебек, Сәгъдине ярата, сөя башлады һәм аңа гомере буе саф йөрәкле, намуслы хатын булды.

Әнә шулай алар малайларны үстереп «очырдылар», икәү генә калдылар. Ләкин Валяга нигәдер гомер кыска бирелгән булып чыкты.

Чаллы. Биредә дөньяда тиңе булмаган автогигант салына. Төзелмәгән объектларның әле исәбе-саны юк. Автохуҗалыкка үткән елда ук бокс салып бирергә ышандырган төзүчеләр һаман суза киләләр. Стенасын өеп куйдылар да китеп бардылар. Имеш, балкалар юк. Табыгыз, кайтарыгыз, безгә аны ябып кую озак түгел.

Хуҗалык үсте. Әле килгән елны гына нибарысы илле-алтмыш машина иде, хәзер әнә биш йөздән артып бара. Ике ел үтте. Ике ел җәфалана, ике ел инде җитәкчелек итә бу хуҗалык белән Сәгъди. Мәгәр әле һаман тынычланып эшләп киткәне юк. Бокс юклык та җанга тия. Машиналар ачык һавада торалар, кабызулары кыен. Кыш көннәрендә шул сәбәп белән линиягә чыкмый калучылар да була. Я ягулык багына су эләккән, я насосы суырмый.

Балкалар, балкалар кирәк! Казанда бар, ләкин ни белән алып кайтасың! Паром-поездлар завод өчен төзү материалларын ташудан арынмыйлар, Низамов хуҗалыгынамы чират!..

Сәгъди, бирегә килгәч, күзгә күренеп ябыкты. Аны ялгызлык талкый башлады. Ул еш кына ком сахрасына эләккән кешедәй тилмереп йөри. Малайлар, әниләре үлгәннән соң, хатны сирәк язалар. Хәер, аларны гаепләми дә ул, һәрберсенең үз мәшәкате, үз дөньясы дигәндәй. Ул үзе дә андый чорны кичергән кеше.

Шуңа күрә Сәгъди күп вакытын эштә үткәрә. Анда ул кешеләр белән аралаша, алар белән шатлана, алар белән бергә хафалана. Аннары биредәге бер егетне — Исламны ярата ул. Яхшы шофер булуы өчен генә түгел, үзе кебек япа-ялгыз, ярым-ятим булганы өчен ярата ул аны.

Исламны ул эшкә алганда ук ошатты. Аны иң яхшы дигән өйгә урнаштырды. Инде тулай торакта урын табылгач, егетне шунда күчерде.

Иң әүвәл Исламны ул эше өчен яратты. Дөрес, ул аны башкалардан аермады. Ислам үзе алардан аерылды. Сәгъди моны тоя һәм күрә генә белде.

Сәгъди Исламны төрле коллективта, төрле идарәләрдә, төрле участокларда эшләтеп карады, хәтта тегеләрдән:

— Егет ничегрәк, ялкау түгелме? — дип аталарча кайгыртып сораштыргалый торды.

— Ислам Байтимеровмы? Әйбәт эшли. Дөрес, егет бераз дуамалрак...

Исламны төшемле урыннарга гына җибәргәне өчен диспетчерлар бераз начальникка үпкәлиләр. Ләкин авыз күтәреп дәгъва итәргә кыймыйлар иде. Комсомол секретаре Анатолий гына:

— Сәгъди Вәлиевич, нигә алай кайбер шоферларны төшемле урыннарга гына җибәрергә кушасыз? Сукранучылар бар,— дип әйткән булды. Ләкин Бабай аңа:

— Толя, юк сүз сөйләмә! Син Исламны менә комсомолга өндә,— диде.

— Нигә ул безгә?!.. Исерек баш Әнәсне кеше итә алмый да чиләндек. Әле анысы яңа рәтләнеп килә, тагын берәүне димлисез...

— Рәтләнәме Әнәс? Рәтләнер. Ә бит мин аны ләх исерек чагында таптым. Өенә сөйрәп керттем, юындырдым, йокларга салдым... Кешелеге бетмәгән икән әле алайса...

— Кичә энисе килде. Миңа рәхмәт укый. Рәхмәт инде Сәгъди Вәлиевичка, сиңа, Толя, юлдан язган улымны комсомолга алдыгыз, кеше иттегез, ди...

— Шулай ук диме?..

— Чыны шулай, Сәгъди Вәлиевич...

— Я, ярый. Шул темпта эшли бирегез. Ә Исламны комсомолга алмый булмас... Начар егет түгел ул...

— Тик аны бик кызу диләр.

— Бар кызу кеше дә лихач шофер түгел, Толя... Ал син аны комсомолга. Идарә буенча гына түгел, трест алдында беренче урынга чыгу турында хыял тотыгыз әле, егетләр...

— Анысы шулай...

— Шулай булгач, әйдә тырышып карагыз...

Ислам, комсомолга керергә гариза биргәч, Сәгъди янына килде. Кич иде, Сәгъди китап укып ята иде. Ислам килеп кергәч, аны көтеп торган кебек, өстәл хәзерләде, бер шешә болгар виносы куйды.

— Котлыйм, туган... Әллә кайчан кирәк иде дә сиңа, моңа кадәр очрашмаганбыз... Мин үзем унҗиденче елда — революция елында туган кеше, уналты яшемдә комсомолга кергән идем... Аннары сугыштан соң партия сафына бастым... Үз тормышың дөньядагы иң гадел, иң алдынгы идеяне яклаучы партия белән бәйләгән адәм — буш кеше түгел ул. Җаваплылык сизеп тору ул һәркемгә кирәк нәрсә. Мин аны гомерем буе тоеп торам... һәм үкенмим... Партия миңа яшәргә өмет нуры өсти. Ә бит, туган, бу дөньяда өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелгәннәр дә тулып ята... Урамда исереп аунап ятучыларны күргәнең бармы? Бар, дисеңме?.. Менә шул... Алар, туган, барысы да өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелгән халык. Мин тик шуңа гына шаккатам. Алар бездә елдан-ел күбәя бара, һәм мине гаҗәпләндергәне шул: андыйларга карата берниндн чара күреп булмый. Исеңдә тот, Ислам, артык эчүгә башын салган кеше бик тә тиз рюмкага батып үлә. Васыять итеп әйтәм, кирәксә-кирәкмәсә, юк сылтауны бар итеп, һичкайчан эчмә! Эчсәң эч мәҗлесләрдә, күңел ач, җырла, бие, ә тиктомалга эчмә! Эчә башладыңмы, югалдым дигән сүз... Аннары инде яңадан кеше булам димә.

Сәгъди Исламның чибәр йөзенә бер тын карап торды. Ярата иде ул бу егетне һәм яратуын яшерми дә иде.

— Карале, Ислам, син таза егет, зуррак машинага утырасың килмиме?

— Хезмәтең шул ук руль тотып бару, акчасы бер чама төшә. Минем машина начар түгел, кирәкмәс, Сәгъди абый,— диде Ислам һәм алдындагы рюмканы читкәрәк этеп, түше белән өстәлгә ятты.— Менә үзеңә бер «Жигули» алсаң иде икән ул, Сәгъди абый...

— Җиңел машина! Нигә кирәк ул сиңа? Артың болай да утыргычтан төшкәне юк. Кызлар ташыргамы? Юк инде, ул ниятең бар икән, башта өйлән...— Сәгъди беравык яңагын ышкып утырды.— Акчаң бармы соң? Җиңел машинаның бәһасе, мин белгәнчә, шактый бит?..

— Машинасы булса, акчасы табылыр иде әле,— диде Ислам һәм эчке кесәсеннән саклык кассасы кенәгәсен алып күрсәтте.— Менә акча, әти мәрхүм калдырды. Шахтер иде ул...

Сәгъди, кенәгәдәге сумманы күреп, күзләрен түгәрәкләндерде.

— Ун мең сум?! — диде ул гаҗәпләнеп.

— Әнә астагы соңгы нке меңе үземнеке...

— Бай егет икәнсең,— диде Сәгъди, кенәгәсен кире сузып.— Сиңа, туган, теләсә нинди сылу чыгачак... Кенәгәңне генә күрсәт... ha-ha-ha!.. Шулаймы?..

Күзгә-күз карашып, рәхәтләнеп көлешеп алдылар. Сәгъди торып телевизорны кабызды.

— Сәгъди абый,— диде Ислам, аның янына килеп.— Беләсезме, ни, мин нәкъ шул турыда сезгә киңәшкә дип килгән идем...

— Бу турыда нинди бәхәс булырга мөмкин... Әллә соң теге француз кызымы? Кем әле?.. Инга түгелдер бит?..

— Юк.

Ислам күзен идәнгә төбәп беравык сүзсез торды.

— Я, я, кем соң?

— Аның баласы бар... Кияүдә булган...

— Соң, булсын... Бала... Тора-бара барыбер синеке була ул. Ата була гына бел... Я, кем?.. Әйт. Үзең дә яраткач...

— Диана...

— Диана?.. Теге үзең квартирда торган врач хатынмы?

— Әйе...

Сәгъди, беравык дәшмичә, экранда күренгән диктор хатынга карап торды да:

— Димәк, Диана,— дип, телевизорны сүндереп, диванга барып утырды.

Ул Исламның Диана атлы бер балалы хатынга өйләнүенә каршы түгел иде. Баласы булган хатын, икенче тапкыр кияүгә чыккач, ир кадерен белә төшә, моны ул үз тәҗрибәсендә сынады. Аның эчен пошыручы нәрсә башка иде: Дианаgreны ире ташлап киткән ич. Ә яхшы хатынны ире ташламый. Я йөргән, я усал... Аннары тагы бер сәбәбе бар иде: Сәгъди Харис исемле бер врач белән таныш иде. Харисның аңа Диана турында саксызрак сүзләр ычкындырганы булды, хәтта бер тапкыр әллә көлеп, әллә шаярып: «Өйләнегез шуңа, Сәгъди абый, Диана сезгә чыгачак, ирсез тора алмый ул, аңа, үзеннән олырак булса да, ир кирәк, ә минем семьям бар»,— дигән иде. Бу хәтлесе дә мәгълүм иде Сәгъдигә. Ә монда аның улы кебек егет шул хатынга өйләнергә тора. Кимендә өч-дүрт яшькә кече бит бу Ислам аңардан. Юк, юк, мин аны ул хатыннан биздерергә тиеш. Беткәнме бездә кызлар... Туктале, мин аны бер атнага авылга эшкә җибәрим булмаса. Фәрештәләрнең амин дигәненә туры килеп, үзе кебек бер чәчбине табып куймасмы!

— Ярар, Ислам. Ул турыда соңыннан... Әйтик, бераз тернәкләнгәч, күзгә таба... Яисә җиденче ноябрьга, ризамы?.. Иртәгә авылга китәсең. «Кызыл юл» колхозына тирес чыгарырга ун машина билгеләдек, мин сине дә керттем...

Сәгъди Исламны билгеләмәгән иде, юри әйтте, егет риза булгач, ул аны иртәгә иртән дә хәл итә алачак иде.

— Ярый соң, мин риза,— диде Ислам елмаеп.

— Ну, алай булгач, әйдә бу рюмкаларны тотып куйыйк... Аннары хоккей карарбыз. Швеция белән безнекеләр уйный бүген...

Хоккей беткәч, Ислам йокларга ятты, Сәгъди тәмәке көйрәтергә дип балконга чыкты, балыкчы урындыгына утырды да төпсез һавага карап уйга чумды.

«Их, гомер, гомер! Үтеп тә барасың бугай инде. Ә бит, Сәгъди, синең дә кайчандыр үз семьяң бар иде, үз хатының, үз балаң, Сараң!»

Сарасы аның зәп-зәңгәр күзле, чак кына чөенкерәк борынлы, ахактай ак йөзле, озын, калын толымлы бер сылу иде. Чәчләрен таратып йоклаганда Сәгъдигә караватта урын да калмый иде. Ләкин Сәгъди аны барыбер уятмый иде, шул таралган толымга борынын төртер иде дә йоклап китәр иде.

Нигә ул аны оныта алмый? Нигә, менә әйтик, Ислам ярата һәм шундук оныта ала, ә ул — юк? Әллә соң Сәгъди башка тукымадан эшләнгәнме?..

Сәгъди Ислам белән француз кызы Инга арасында булган мәхәббәт мажарасын бәйнә-бәйнә хәтере аша үткәрә.

Бөтен Кама буйлары, тугайлары, болыннары шау чәчәккә күмелгән июль ае иде. Идел буендагы Халыкара дуслык лагереннан төзелеп килгән заводка француз яшьләре килеп төште. Чит ил кунаклары үзләрен әрсез тоталар һәм, Сәгъди уенча, бераз оятсызрак кыланалар иде. «Кунак булгач, тыйнак булырга кирәк иде бит. Юк, башка күәстән ясалганнар, чытлыкланалар»,— дип уйлап торды Сәгъди, автохужалыкка килеп төшкән яшьләрнең әрсезләнеп китүләрен ошатмыйча.

Төзелеп яткан шәһәрдә кунаклар озак тормады, завод салынасы төшкә ашыктылар. Сәгъди шәһәр комитетыннан җибәрелгән яшьләр белән аларны озата китте. Биредә француз яшьләре эшчеләр белән таныштылар, бер-берсенә значоклар бирештеләр, хәтта татар егетләре белән күлмәк алыштыручылар да булды. Француз кызлары, төскә-биткә бик әллә ни булмасалар да, чуар киенгәннәр. Берсе чалбар, берсе мини, берсе миди юбка кигән, ә кайберләрендә Казан кибетләреннән алган күлмәкләр, күбесенең аякларында чиккән татар чүәкләре иде.

Әбәт вакыты җитте. Эшчеләр ялга туктадылар. Шунда кунак кызның берсе нигәдер Сәгъди янында бөтерелә башлады. Ярты-йорты русча-французча сорашкан була, ләкин Сәгъди җилкә генә сикерткәч, кыз гидны чакырып китерде.

— Татарларда кияүгә чыгу йолалары ничек? — дип тәрҗемә итте гид кызның соравын.

Сәгъди беравыкка аптырашта калды.

— Ни бит инде ул, яратып, сөеп чыгалар. Теләсә кемгә... Ул яктан бездә полный демократия,— диде Сәгъди, үз җавабыннан канәгатьсезлек белдереп йөзен чытты.

— Ә женси мәсьәләдә?

Бу сүзләрне ишетүгә, Сәгъдинең күзләре түгәрәкләнеп китте. Ул бу кунак кыздан теләсә нинди сорау көткән иде, әмма күрер күзгә әллә ни сылу, чибәр булмаган, мәгәр буй-сыны су камышыдай гүзәл күренгән француз кызын нәкъ менә шушындый сорау кызыксындырыр дип башына да китермәгән иде. Аннары ул мондый сорауга җавап бирергә әзер дә түгел иде. Бу фәрештәдәй кыз илледән өстәге Сәгъдигә шундый сорау бирер дип кем уйлар!

— Әйдә, әйдә, Сәгъди Вәлиевич, әйтегез, ничегрәк беләсез?..

— Ни бит инде ул,— Сәгъди гидка күз төшереп алды. Янәсе: «Ничек соң, турыдан-туры ярыймы?» Гид аны тынычландырып елмаеп алды һәм бу «ярый» кебегрәк чыкты.— Кем, ни бит, мадмуазель, бездә теләгән кешең белән очрашырга була. Дөрес, бездә бу турыда күзгә бәреп әйтү әдәпсезлеккә керә кебегрәк тоела миңа. Яшьләр, әйтик, хәзер бездә дә бер дә сездән калышмыйлар кебек...

«Ни сөйлим мин? Кемне кем белән чагыштырам?» — дип шомланды Сәгъди. Ләкин башлаган сүзен әйтеп бетерергә булды.

— Сез теләгән мәсьәлә бездә дә бик җиңел хәл ителә дияр идем мин. ЗАГС дигән урынга барасың да шул кеше белән чәчең бәйләү теләгеңне әйтеп гариза язып бирәсең... һәм...

Башта гид көлеп җибәрде, кызга аңлатып биргәч, кыз елмая башлады. Аңлашкач, кыз гидка рәхмәт әйтте һәм Сәгъдине үзе үк култыклап, табын хәзерләгән өстәлгә таба әйдәде.

Кыз ни арададыр Исламны күреп алды. Төз борынлы, сызылып киткән нечкә кара мыеклы, кара күзле егет аңа шунда ук тәэсир итте. Ул башын иеп Сәгъдидән гафу үтенде дә туп-туры Ислам янына барып утырды.

Шау-шу килеп ашап-эчкәннән соң (кунакларга ике өчпочмак, шулпа, бер стакан компот, катык бик ошады), төркем-төркем, пар-пар

таралыша башладылар. Кыз, Исламга ияреп, аның машинасы янына китте һәм, күп сорамыйча, кабинасына кереп тә утырды. Боларның барысын да каш астыннан гына күзәтеп утырган Сәгъди шомлана, борчыла калды: «Алып китә күрмәсен тагын дуамал баш?»

Һәм шик-шөбһәсе юкка булмады. Экскаватор әрҗәсен тутыруга, Ислам машинасын кабызды.

— Һәй, Ислам!..

— Йөри бирсен,— диде аның янәшәсендә басып торган гид.

Бер рейс әйләнеп килгәч, француз егетләренең берсе кызның машинадан төшүен сорады, хәтта орышты да бугай. Ләкин кыз аяк терәп карышты, төшмәде, башын чайкап, көлемсерәп тик утырды.

Ахырда гид та, француз егете дә кызга кул селтәп китеп бардылар.

«Менә шулай ул дөнья,— дип уйлады Сәгъди, автобуска утыруга.— Карасана син аны, салам сыйракны, ни белән кызыксына! Имеш, татарлар женси мәсьәләгә ничегрәк карыйлар? Ничек, ничек? Сез ничек карасагыз, без дә шулай карыйбыз, яратып-сөешеп өйләнешәбез. Хәзер бездә дә ир хатынны түгел, хатын ирне ташлап китү модага кереп бара инде. Әйтик, менә...»

Сәгъди үзе турында телдән әйтергә түгел, уйларга да оялды. Ә бит аны да хатыны ташлап китте. Мопассан романнарындагы мәхәббәт мажараларыннан ким хәлмени? Һай, француз халкында да һәм татарларда да шул бер үк мәхәббәт инде ул. Тик аны һәркем үзенчә кичерә генә.

Сәгъди, үз фәлсәфәсеннән үзе канәгать калып, уйнап-көлешеп кайткан яшьләрне күзәтә башлады.

«Их-ма, замана диген син! Урысы-татары, французы гөр килеп сөйләшеп кайталар. Дуслыкның теле бер генә шул — ышану. Без дә үстек, без дә яшәдек... Тик болай булмады. Шулай да мин үткән гомерем өчен үкенмим. Минем өчен мәңге үлмәс тәгълимат бар иде һәм ул минем өчен бүген дә шул ук. Ә менә болар, француз яшьләре, киләчәккә нинди хыяллар белән яшиләр икән? Бабалары башлап җибәргән революциягә ничек карыйлар икән? Буржуазия белән көрәш дәверендә Париж урамнарында өелгән баррикадаларда йөзәрләп, меңәрләп һәлак булган, якты тормыш өчен гомерләрен корбан иткән ата-бабалары турында ни уйлыйлар икән?»

Сәгъди тәрәзәгә карады. Нарат урманы буенда ике кыз гөмбә җыя, кәрзин тотканнар, алардан кала ике егет атлый.

«Юкка, юкка калдырды бу гид дигәннәре кызны Ислам белән. Иленә кайтып, татарлар турында тузга язмаганны сөйләп йөрсә? Кем белә, бәлкем, ул салам сыйрак нинди дә булса берәр яман ният белән калгандыр? Ислам, беткән баш, бер-бер юләрлек эшләп ташламасын тагын! Их, юкка калдырды бу гидлары кызны...» — дип үкенеп алды ул.

Яңа шәһәр борылмасына җитәрәк, юл аркылы эленгән комачлар күренде. Ике-өч сәгать элек кенә биредән үткәндә бу лозунглар юк иде. Моны күрүгә, яшьләр дәртләнеп киттеләр һәм комачка язылган сүзләрне хор белән кабатлый башладылар:

— Рәхим итегез! Добро пожаловать!..

Сәгъдинең шунда ниндидер үзе дә аңламаган рәхәттән йөрәге кысылып куйды һәм, яшьләргә теләктәшлек белдереп, алар артыннан кабатлый башлады.

Кичке якта яшьләр ашханәсендә кунаклар белән очрашу кичәсе оештырылуы турында ишеткәч, Сәгъди шәһәр комитеты секретарена шалтыратты һәм кичәдә кемнәр булуы белән кызыксынды. Секретарь: «Сезнең коллективтан яшьләр чакырылмады бугай», дигәч, Сәгъди:

— Хезмәттә үңган эшче егетләрнең берсен дә чакырмагач, кемне

генә жыясыз соң анда? — дип тузынып алды. Секретарь аны яхшы белә иде, күрәсең, чакыру билетлары жибәрергә вәгъдә итте.

...Ислам кичәгә яшькелт галстук тагып, ак күлмәк, чем-кара костюм, ялтырап торган туфли киеп килде. Бу сурәттә ул тагы да матураеп, чибәрләнеп киткән иде. Сәгъди аңа сокланып карап торды.

Алар ашханәгә килеп кергәч, кыз, аларга каршы килеп, чытлыкланып күрешкәндәй итте.

«Мутлык үзендә»,— дип уйлап алды Сәгъди, кызның кыюлыгын ошатмыйча.

— Инга! — диде кыз аңа һәм нигәдер Сәгъдигә күрешергә биргән кулын алмый торды.

— Я — Ингә... Яраттэм,— диде Инга Исламга елыша төшеп.

— Син өйрәттеңме? — дип сорады Исламнан Сәгъди.

— Әйе,— диде Ислам елмаеп.

Инга аларның икесен дә култыклап табынга таба алып китте.

— Һәй, бу француз кызларын, Мопассан токымнарын,— диде Сәгъди.

— Мопассан — нэт...

— Сәгъди абый,— диде Ислам.— Мин бу кызны урлыйм бүген...

— Син нәрсә?!. Тилердеңме әллә?! Башың ике булса, урла,— диде Сәгъди егет сүзенә ышана калып.

Ашап-эчкәч, бию башланды. Сәгъди һава алыштырырга дип, гид белән тышка чыкты. Гид аны култыклап алды һәм зур сер әйткәндәй:

— Сәгъди Вәлиевич, егетегез кунак кызын аздыра күрмәсен тагын,— диде.

— Юк, ул болай гына. Сөйләшә белмиләр ич... Ни кырсыннар,— дигән булды Сәгъди.

— Ярый. Күңел ачсыннар, мин каршы түгел болай,— диде гид, шаяртып әйтүен аңлатырга теләгәндәй, елмаеп куйды.

Бүгенге кеше үзе яшәгән җәмгыятькә бәйле. Ислам белән Инганы бергә итү ике яшьнең үз теләкләреннән генә торса да, аларны, әйтик, өйләнештерү шактый четерекле мәсьәлә. Дөрес, мәхәббәтнең үз законы, үз теләге, моңы-хисе, тойгысы-теле, сагышы, уе-хыялы бар һәм, ниһаять, үз азатлыгы, ирке бар. Кем әйтмешли, мәхәббәт иреге — мәңгелек. Мәхәббәт үлгән хәлдә дә җиңеп, тантана итеп үлә, чөнки аны кылыч белән генә буйсындырып булмый. Шулай да, шулай да... Сәгъди Ислам белән Инганы урам чатындагы эскәмиядә калдырып киткәч, шундыйрак фәлсәфәгә бирелеп, уйланып йөрде.

Әле дә хәтерендә: саубуллашканда Инга егетнең муенына сарылды һәм оялмыйча-тартынмыйча тегене үбеп алды. Шунда Сәгъди кызның күзләрендә яшь күргәндәй булган иде. Ул хәтта ваемсызрак кыяфәттә кыз белән саубуллашкан Исламга бераз рәнҗегән дә иде. «Нигә назиркәгә үзе үк өмсенеп торган кызны кыю гына кочып сөйми, нигә оялып тора, нигә әшендәге сыман тәвәккәл кыланмый?»

Картаю күңелне нечкәртә икән. Сәгъди шул мәлдә Сарасын исенә төшергән иде.

...Сәгъди балконны ябып бүлмәгә керде һәм бер тын идән уртасында басып торды. Аннары торшерны сүндерде. Кинәт стеналарга караңгы иңде, түр почмакта урам як фонарьдан төшкән кулъяулык кадәр генә яктылык кунып калды. Ислам йокламый икән әле, әйләнеп ятты.

— Сәер, кинәт кенә Инга искә төште,— диде ул Сәгъдигә.

— Яраттыңмы син аны, Ислам?

— Чат дөресен әйтимме?

— Мин дә шул турыда уйлый идем бит. Әллә соң чынлап та биотоклар тәэсир иттеме?..

— Ул биредә калса, мин аңа өйләнә идем... Телефонистка иде бит ул...

— Калмадымы?

Сәгъди юри киная белән сорады. Ислам, ахры, моны сизде, беравык дәшми торды.

— Кайтам да әти-әнидән рөхсәт алып киләм дигән иде...

— Килмәдеме? — диде Сәгъди мыскыл иткәндәй.

Ислам дәшмәде. «Үпкәләде»,— дип уйлады Сәгъди.

— Ул нәрсә, Ислам туган, алай, син әйткәнчә, орды-бәрде генә эшләнми. Бик мәшәкатьле эш ул француз кызын бирегә китерү. Дөрес, космос чорында андый әкәмәтләр дә буладыр инде ул. Әгәр дә мәгәр чын була калса, илчелектәге дипломатия мәшәкатьләрен үз өстемә алам... Тик нигәдер моның буласына күңел ышанмый...

— Мин аңа ике хат яздым инде...

— Нинди телдә?

— Русча.

Сәгъди егеткә ни әйтергә белми чарасыз калып торды.

— Ә соң Диана?

— Диана...— диде Ислам нигәдер каушый калып.— Мин аңа Ингадан хат килмәгән хәлдә генә өйләнәчәкмен...

— Киресенчә, ул сиңа өйләнәчәк... Миңа мәрхүмә Валентина апаң өйләнгән кебек.

Сәгъди Исламга Валентина турында күп сөйләгән иде, егет ул апаны белә иде, дәшмәде.

Шул сөйләшүдән соң ун көн үтмәде, Сәгъди кабинетына, яңа чыккан кояштай балкып, Ислам килеп керде.

— Сәгъди абый, өйләнәм. Тәбрикләгез. Менә дигән кыз! Вәгъдәсен дә алып кайттым инде...

Сәгъди туйны тиз тотарга булды. Ул Исламга бер атна ял рөхсәт итеп, үз машинасын бирде дә кызны алырга җибәрде. Үзе шунда ук, вәгъдә иткәнчә, квартир хәстәрен күрә башлады. Алай итте, болай итте, әмма квартир ала алмады. Ахырда үзе тулай торакка күчеп, яшь киленне үз квартирына төшерергә мәҗбүр булды. Моны белгән Исламның түбәсе күккә тиде.

## 13

Көзге ай сентябрь җитте. Кама өстендәге пароход-баржалар, кыш якынлашуны сизенгәндәй, гудокларын сузыбрак кычкырта башладылар. Гүя алар йөзү сезоны бетеп баруын тоялар һәм зур төзелешкә китергән йөкләрне бушатып, кайтып китәргә ашыгалар иде. Һәм шулай иде дә ул. КамАЗга су юлы белән дә, тимер юл белән дә меңәрләгән машина, җиһаз, краннар, төзү материаллары, вагон-өйләр килеп тора. Аларны тиз арада бушатырга, склад, предприятиеләргә, төзелеш идарәләренә озатырга кирәк иде.

Сәгъди елга портындагы кысанлыкны белә, әмма барыбер балкалар килеп җитәр дип өмет итә иде әле. Ул менә җәйдән бирле инде боксларның түбәләрен ябарга балкалар көтә. Кичә генә трестка барды, аннан тәэминатчылар белән низаглашып кайтты. Низаглашмыйча да мөмкин түгел. Балкалар бер хәл, житмәсә, июнь аенда кайтасы ун махсус прицепны ноябрьга калдырганнар. Ул гынамы!

Быел кыш салкын булачак дип сөйлиләр. Боксларның түбәләре ябылмаса, дизель машиналарын кабызу мәхшәргә әвереләчәк. Балкаларны Казаннан кайтартырга була. Ләкин ни белән? Һәр төзелеш идарәсенең үз планы, үз кайгысы бар. Елга транспортына май аенда ук

балкалар китерергә заявка бирелсә дә, алар завод җиһазлары ташудан арынмыйлар. Кыскасы, чират житми, чират!..

Бүген порт янына килгәндә бередә аеруча жанлылык күрде Сәгъди. Кояш яңа күтәрелә генә башлауга карамастан, порт гөж килә: төзү материаллары китергәннәр.

Сәгъди УАЗын бер читкәрәк туктатты да өлкән диспетчер янына керде, балкаларны белеште.

— Сез генә борчымагыз, ичмасам, заводка дигәннәрен дә китереп бетерә алган юк,— диде аңа диспетчер.

Сәгъди йөрәкләнеп чыгып китте һәм кайтышлый шәһәр комитетына сугылды.

— Иң яхшысы — үзегезгә барып алу, Сәгъди Вәлиевич,— диде аңа промышленность бүлегендә утыручы иптәш.

— Рәхмәт, куандырдың! — дип чыгып китте Сәгъди аның яныннан. «Һич мөмкин булмаган нәрсә турында сөйли»,— дип сукрана-сукрана кайтырга чыкты Сәгъди. Ләкин кайнарлыгы басыла төшкәч, бу хәлнең мөмкинлегенә ышанычы ныгый төште. Әмма моның өчен Камаҗың туңганын көтәргә туры киләчәк иде. Аннары кышкы салкыннар башлана. Димәк, бокслар тагын бер елга кичегәчәк дигән сүз. Һич югы, быел кайтарасы иде. Ичмасам, киләсе елга әзер булыр иде. Әнә шул фикерендә бераз реальлек күреп, ул кайта-кайта тынычлана төште.

Менә Сәгъди иске шәһәргә керде һәм таныш урамга житүгә, машинасын шунда таба борды. Ул бер уңайдан Исламның элекке квартирына кереп чыгарга булды. Бирегә берәр эшче урнаштыру нияте бар иде аның.

Капка каршына килеп туктауга, ул ишегалдында йөрүче хужа хатынны күрде. Сәгъди аны шундук таныды. Бу — Ислам өйләнергә теләгән Диана иде. Хатын өстенә кыска пальто кигән, башына йомшак шәл бәйләгән, ишек тирәсен себереп маташа иде. Сәгъди аңа чаларган башын түбән иеп сәлам бирде.

— Хәерле иртә, Диана Галимовна.

— Исәнмесез, Сәгъди... абый.

Хатын аның әтисе исемен онытты мы, белмәве идеме, комачтай кызарынып чыкты.

— Ничего, анысы вак мәсьәлә,— диде Сәгъди.— Мин сезгә, Диана Галимовна, бүлмә мәсьәләсе белән кагылган идем...

— Без ул бүлмәгә кеше кертмәскә булган идек инде, Сәгъди абый... Авыру әнием бар... Аңа да кыен, торган кешегә дә дигәндәй...

— Һы, алай дисез. Бик кысанга килмәсә, без сезне борчымаска тырышырбыз, әлбәттә... Бездә торак ягы хәрт бит. Эшче кирәк, эшкә алабыз, ә торыр урын бирә алмыйбыз... Я, ярый, хушыгыз...

— Хушыгыз, Сәгъди абый...

Тәрәзәдә бер чырай чалынып китте. Сәгъди машинасына таба атлаганда тәрәзәдә күренеп киткән әлеге йөз таныш кебек тоелды, кем дип юрарга, таныш-белешләреннән кемгә охшатырга зиһене житмәде.

Сәгъди кулына эләккән бүлмәне тиз генә ычкындыра торганнардан түгел иде. Кайта-кайта: «Бүген үк булмаса да, иртәгә берәрсен жибәрергә кирәк, юкса, киреләнеп куюлары бар», дигән фикергә килде.

Һәм икенче көнне анда яңа гына эшкә кергән Зөлфәтне жибәрде.

## 14

Махсус прицеплар тик декабрь аенда, аның да икенче яртысында гына кайтып життеләр. Прицеплар барысы да балка ташырга жайланган иде. Сәгъди иртән эшкә килү белән яңа кайткан прицепларны карап йөрде.

— Җиңелрәк машиналар тапмадылар микәнни? Төзелеш участокларында шушы бегемотлар белән борылып буламы соң?! — диде ул, КрАЗ автомобильләренә көйләнгән прицепларны ошатмыйча.

— Җиңелләрне 1974 елда, менә үзебездә, Чаллыда, ясый башлыйбыз,— диде аның янәшәсендә басып торган Петрович.— Безнең КамАЗлардагы маневр искитмәле булачак. Ә шуна кадәр, кадерле Сәгъди Вәлиевич, шул прицеплар белән эшләп торырга туры килер...

— Анысы шулай, безнең КамАЗда бүгенге чор автомобиль техникасының иң яхшы сыйфатлары булачак,— диде Сәгъди һәм, өлкән механикны үз кабинетына сәгать тугызга киңәшмәгә дәшеп, китеп барды.

«КамАЗ, КамАЗ,— дип уйлады Сәгъди.— Син үзеңә бик күп милләт кешеләрен, бик күп язмышлар җыйдың. Әйе, җиңел дә түгел кебек, эшләп карагач, әллә ни авыр да түгел кебек. Монда әле кайчан гына бүлмә-вагоннар гына иде, хәзер әнә бишәр-тугызар катлы дистәләгән өйләр калкып чыкты. Өйләр салына, завод корпуслары калкып чыга, ә менә автохуҗалык бокслары һаман сөрәеп тора бирә. Дөрес, Чаллыдагы иң мөһим эш — КамАЗ һәм торак йортлар. Ләкин транспорт биналары төзергә дә вакыттыр инде. Бүген — җомга. Бүген үк машиналарны Казанга балкалар алырга җибәрсәк?»

Кабинетына кереп утыруы булды — телефон шалтырады.

— Сәгъди Вәлиевич, исәнмесез? Бу — мин, Петр Ильич...

Петр Ильич генераль директорның баш инженеры иде, Сәгъди, турыдан-туры булмаса да, аңа буйсына иде.

— Сезгә кайткан прицеплар дүшәмбе көнгә линиядә булсыннар. Станциягә дүрт эшелон төзү материалы кайтты. Ишеттегезме, дүшәмбегә! — диде боерган тавыш белән Петр Ильич.

— Машиналар линиядә булыр, Петр Ильич...

Сәгъди телефон трубкасын куйгач, беравык аннан кулын алмыйча торды...

«Менә ничек! Ә бит мин дүшәмбе көнне аларны Казанга үзебезгә балкалар алырга җибәрмәкче идем,— дип уйлады Сәгъди.— Әллә соң бүген үк җибәрергәме? Сәгать икеләрдә кузгалсалар, төнгә анда булачаклар. Иртән алсалар, өйләдән соң кайтыр юлга чыга алалар. Тик әүвәл Казан тимер-бетон җайланмалары заводы директоры белән сөйләшергә кирәк... Шимбә көн эшлиләр микән?

...Казаннан ышанычлы хәбәр килгәч, Сәгъди кабинетына хуҗалык активын җыеп, сөйләшеп-киңәшеп алырга булды.

Секретарен чакыртып, унбиш минуттан автохуҗалык активын бергә җыярга кушты. Ул арада кабинетка Петрович килеп керде. Сәгъди аңа үз фикерен әйтте. Карт кашларын сыпыра-сыпыра беркавым уйланып торды.

— Резонно, сүз дә юк. Яңа машиналарны тетеп кайтмасалар, бик хуш та бит...

Актив җыела башлады.

— Прицепларга тәҗрибәле егетләрне утыртырга кирәк.

— Каян алырга соң аларны?

— Минемчә, комсомол-яшьләр бригадасы шоферларын җибәрергә кирәк булыр...

Керүчеләргә Сәгъди түргә узып утырырга дип ияк какты. Барысы да җыелгач, ул баш инженерга карап сүзен башлады.

— Артем Борисович, без монда бер фикергә килдек әле. Прицепларны Казанга балкалар алырга җибәрергә. Бүген үк... Минемчә, исәнсау йөргән хәлдә иртәгә кичкә, һич югы, якшәмбегә кайтып җитәчәкләр... Бу безгә бердәнбер җайлы момент. Прицепларны чыгардыкмы, алар безнеке түгел инде...

— Ай-һай,— диде инженер,— яңа машиналарга яшь шоферлар утыртып җибәрсәң... тетеп кайтулары бар...

— Машиналарга тәҗрибәле шоферларны утыртачакбыз. Комсомол-яшьләр бригадасы шоферларын...

— Ә аларның машиналары тик торырмы? — диде өлкән диспетчер.

— Шимбә, якшәмбе — ял көннәре.

— Ярый ла кайтып җитешсәләр,— диде моңа кадәр сүзсез утырган Анатолий.— Бураннар башлана дип хәбәр итәләр.

— Анатолий Иванович, сезнең үзегезгә дә барырга туры килмәгәе эле,— диде Сәгъди.— Гатифә урынына, ә? Анда сезнең булуыгыз кирәк, минемчә. Петрович, сез ничек уйлыйсыз?..

— Мин дә шулай уйлыйм, Сәгъди Вәлиевич. Аннары миңа да бармыйча булмас. Казан юлын миннән дә әйбәт белүче юк... Күз-колак та булыр идем...

Сәгъди партоешма секретаре тәкъдимен хуп күрде. Гомумән, ул карт механикны хөрмәт итә, аның шулай эшкә омтылып торуын ярата, күп вакытта үзе дә аңарга охшарга тырыша иде. Хәтта ул сүз башлар алдыннан уч төбенә тамак кырып кую гадәтенә дә аңардан өйрәнеп киткән иде...

— Анатолий баргач җитмәсме соң? — диде Сәгъди.

— Юк, мин аларның үзләрен генә җибәрә алмыйм, Сәгъди Вәлиевич. Барысы да яшьләр, кайнарлар.

— Ярый, килештек, чакырыгыз яшьләр бригадасын... Ә алар урынына гараждагы бөтен слесарьны китерегез... Кичкә чаклы Бакый да йөреп торыр...

Комсомол-яшьләр бригадасы шоферлары гаражга төш вакытына таба гына кайтып җиттеләр. Алар машиналарын башкаларга бирүгә аптырап калганнар, ачулары кабарган, усалланулары йөзләренә үк бәреп чыккан иде.

Сәгъди аларның кабинетка кереп утырышуларын сабыр гына көтеп торды да куш йодрыгын өстәлгә салып:

— Тынычландыкмы? — дип сорады.— Күрдегезме ул «поезд» кайтты?

Шоферлар нидер сизенеп шаулаша башладылар. Сәгъди кулын күтәрде.

— Сабыр, иптәшләр! Әүвәл башта мин сөйлим. Менә нәрсә, егетләр. Сез хәзер кабинеттан шау-шусыз гына чыгасыз да яңа кайткан прицепларны кабул итеп аласыз. Исемлек Петровичта. Номерлар алынган. Куярсыз. Хәзерләнергә ярты сәгать. Май, ягулык салырга. Һәм бүген үк Казанга барып җитәргә. Балкалар алып кайтасыз. Үзегез өчен. Боксларны ябарга... Казаннан кайткач, кире үз машиналарыгызга утырасыз. Рейс гаять җаваплы, егетләр, балкаларны бу елда алмасак, башка предприятиеләргә бирәчәкләр. Хәзер һәр тимер-бетон балкасы, плитасы исәптә. Сораулар бармы?

— Командировка буламы?

— Бухгалтериягә кереп алыгыз, анда бар да әзер.

— Тәэминатчы барамы?

— Петрович белән Анатолий бара.

Шоферлар кузгала башладылар.

— Сабыр! — Сәгъди кулын күтәрде.— Өйләрегезгә кайтып килергә ярый, җылырак киенеп алыгыз. Минем машина ишек төбендә. Аңлашылдымы?..

Шоферлар чыга башлагач, Сәгъди Гатифәгә калырга кушты.

— Сезгә, Гатифә, калырга булыр. Аннары,— Сәгъди нигәдер, урынсызга оялып киткәндәй, түбән карады.— Бәлкем, сезне, Гатифә, дис-

петчерлыкка эшкә күчерергәдер, ә? Тиздән ана буласы кешегә шофер эше... Мин аны яхшы аңлыйм, һәм син дә аңлыйсыңдыр дип уйлыйм...

Гатифәнең бит алмалары алсуланып китте, яшь хатын начальникның бу турыда сүз кузгатуын көтмәгән иде, күрәсең, калкыбрак торган эчен җыя төшкәндәй итте.

— Толик та шулай дип теңкәмә тиеп бетте инде. Тик, ни бит, Сәгъди абый, иптәшләрдән яхшы түгел... Ирегез начальник булгач та дип әйтүләре бар...

— Кем әйтер икән? Исламмы? Гатамы? Зөлфәтме, Әнәсме?..

— Алар үзләре машинадан китәргә вакыт дип йөриләр...

— Менә нәрсә, Гатифә сеңел, сез дүшәмбедән диспетчерлыкка эшкә чыгасыз. Ә сезнең машинага шофер табылыр, кайгырмагыз. Сөйләштекме?

— Рәхмәт, Сәгъди абый.

Гатифә чыгып киткәч, Сәгъди кабинет буйлап йөреп китте. Аннары тәрәзә каршына килеп басты. Яна кайткан прицеплар янында шоферлар мәш килә: кайсы номер куя, кайсы ачкычлар барлый. Һава бераз томаланып, кар явып тора. Җепшек кар. Тәрәзәгә куну белән эреп, тамчыга әверелә. Күк йөзендә болытлар куерганнан-куера бара. Болай машиналарны чыгармастай куркыныч түгел-түгелен. Шулай да соңгы минутта Сәгъди шомланып куйды.

«Буран чыкса, хәтәр булачак... Әллә соң җибәрмәскәме?»

Әмма туктарга дип әмер бирергә кодрәте җитмәде. Мәгәр эче дөрес сизгән икән. Җомга көн кичкә таба башланган буран төнгә таба бер тын гына басылып торгандай итте дә, шимбә иртәсе җитүгә, аеруча өйләдән соң, карлы яңгыр явып китте, ә кичке якта, җил юнәлеше алышынып, суытып җибәрде, аның артыннан аяктан егардай көчле җил чыкты, ул да түгел, котырынып буранлый да башлады.

## 15

Ислам Чаллыдан юлга чыкканда да, Казаннан кайтырга борылгач та, колонна башында булды. Тиз йөрергә, МАЗын куаларга өйрәнгән Ислам КрАЗның илле-алтмыш километр тизлегенә гасабиланып, ташбака дип орышып кайтты. Аның кабинасында утыручы Петрович моны ошатмый, тамак кырып, җитәр, дип куя иде.

— Двигательне көчләмә, иплә6рәк, яңа бит,— ди ул тыенкы-салмак кына.

Ислам, механикка карамый гына, өченче тизлеккә күчә, әкренрәк кайта башлый.

Сәгать дүрт. Әңгер иңеп килә. Тагын шулай ике сәгать тирәсе кайтсалар, Алабуга шәһәренә житәчәкләр. Аннан инде ерак калмый. Ислам көзгегә күз ташлап алды, ишек пыяласын төшерә төште. Кабина эче эссе була башлады. Шуңамы, Петрович та мәлҗерәп йокымсырап китте. Ислам борын астыннан гына көйләп җибәрде.

Алда озын үр күренде. Үр уртасында ниндидер машина туктаган. Ислам үз машинасына тагылып диярлек килгән Зөлфәткә туктарга дип сигнал бирде һәм КрАЗын юл читенәрәк алды.

Машина туктауга, Петрович күзләрен ачты.

— Ни булды?

— Гарәфи үренә җиттек...

— Әллә үрдә машина туктаганмы?

— Әйе... Нишлибез?

— Нинди машина? — дип сорады Петрович һәм нигәдер кесәсен капшап алды.— ЗИЛга охшый. Прицеп...

— Кузгалдыкмы, Петрович?
— Сабыр ит. Беребезгә, үрне менеп, юлны япмыйча булмас.
— Нигә, каршы килүче машиналар күренми ич...
— Ә килеп чыкса? Башың икеме әллә синең, Байтимеров?!
Петрович Исламга биргән фонарьны сорап алды. Юлга фонарьсыз чыкмый инде ул. Бу — шахтер лампасы сыман, өч төсле пыялага көйләнгән шактый зур фонарь иде.
Арттагы машиналар сузып-сузып сигнал бирә башладылар.
— Мин үргә менеп каршы юлны ябам, ә син сигнал булганчы көтеп тор,— диде Петрович һәм көч белән ишекне ачып төште дә буран эченә кереп югалды.
Петрович китүгә ун минут үтте, егерме... Ниһаять, Ислам тау түбәсендә диярлек яшел ут күрде. Ул газга басып алды да кузгалып китте.
Тизлек арткаyнан-арта барды, спидометр угы алтмышка якынлашты. Яңа двигатель көчәнми, җиңел тарта кебек иде, әмма үр башлануга, спидометр теле күренеп сулга авыша башлады. Тизлек кырыкка, утызга төште. Үр башланды. Алда үр уртасында туктап калган «ЗИЛ-130» аңа өзеп-өзеп сигнал бирә иде.
«Чәпәлермен дип курка», дигән шиккә килде Ислам, рульне кыса төшеп. Ит-колбаса ташый торган ябык прицеп иде бу. Ислам, аңа җитәрәк, аягын газ педаленнән ала төште һәм моторның әйләнеше аз гына кимүгә, кул тормозын тартыбрак куйды. Хикмәт шунда: бозлавык үрне менгәндә мотор һәм тәгәрмәчләр әйләнеше бар чамага көйләнергә тиеш. Югыйсә, көпчәкләр секунды белән буксовать итә башлаячак. Моны тою тәҗрибәсе шоферга еллар буе эшли-эшли генә бирелә.
Ислам ЗИЛны әйбәт үтте. Тизлек угы егерме биш-утыз тирәсендә селкенә, димәк, йөреш дөрес сайланган иде...
Үрне менеп җиткәч, ул машинасын алгарак туктатты да, двигательне сүндереп, Петрович янына ашыкты. «Петрович кабинага кереп утырсын, егетләр менеп беткәнче фонарьны үзем тотып торырмын»,— дип уйлады Ислам. Ләкин Петрович янына килгәндә кювет кырыенда торган УАЗны күреп туктады һәм аның кабинасын ачып шоферга сәлам бирде.
— Кая таба сәфәрең, картлач!
— Казанга...
— Хуҗаң кая?
— Әнә теге кеше янына китте.
Ислам, алда торган кешенең Петровичка кул селти-селти нидер кычкыруын күрүгә, шунда ашыкты...
— Нигә юлны яптыгыз?
— Гражданин, гражданин, зинһар өчен, комачауламагыз,— диде ят кешегә Петрович.
Ят кеше Исламга бөтенләй игътибар итми, Петрович тирәсендә урала иде. Ислам аның капрон пальто җиңеннән тотып алды.
— Нигә тузынасыз әле, гражданин?
— Сезгә ни кирәк?
— Гафу итегез, сез кем? — диде Ислам, аның терсәгеннән кыса төшеп.
— Җибәрегез җиңне?.. Ишетәсезме, җибәрегез!
— Шауламагыз әле. Бу буранда сезне кем ишетә... Без КамАЗга төзү материаллары алып кайтабыз.
— Миңа димәгәе алтын алып кайтыгыз!
— Үр уртасында машина туктап калган... Ун минут көтәргә мөмкинме?
— Юк. Без ашыгабыз...
— Әйдәгез әле кабинагызга, күзне ачып булмый...

Капрон пальто җиңен йолкып алмакчы итте, әмма Байтимеров тиз генә җибәрә торганнардан түгел иде.

— Әйдәгез машинагызга,— диде ул, теш арасыннан ысылдап.

— Нахал, хулиган!..

— Я, я, гражданин, шауламагыз!

Кабинага капрон пальтоны утырткач, Ислам УАЗ алдына чыкты һәм, аркасын радиаторга терәп, басып тора башлады.

Шофер моторын кабызды, әмма кузгалырга кодрәте җитмәде, аның каравы, сигналын бик каты кычкырта башлады. Ислам башта берни ишетмәгәндәй басып торуын белде, ахырда тәкате бетте, капотны тиз генә ачты да быргы чыбыкларын тартып өзде.

Ул арада калган машиналар менеп җитте. Петрович та УАЗ янына килде.

— Юл ачык, китәргә була, Вәли Сәгъдиевич,— диде Петрович янында буталган кешегә. Капрон пальто аны таныды, күрәсең, нишләргә белмичә, әле Исламга, әле карт механикка карап-карап алды.

— Менә, ни, Чаллыга әнинең хәлен белергә дип кайткан идем... Буран чыкты, ә иртәгә эшкә...

— Алай,— диде Петрович.— Ярый, китегез, Вәли Сәгъдиевич, юл ачык.

Алар янына Зөлфәт, Гата, Анатолий, Энәс килделәр.

— Туктагыз әле! — диде капрон пальтога Ислам.— Сез кем?

— Врач ул,— диде Петрович.— Бездә Чаллыда эшләгән иде...

— Бар китегез, Вәли Сәгъдиевич... Югыйсә, шоферыгызның правасын алам. Штаттан тыш автоинспектор бит мин... Нигә болай больница машинасын Чаллы кадәр Чаллыга куасыз... Рөхсәтегез бармы? Ярыймы?..

— Гафу итегез, Петрович, мин сезне танымадым. Буран-җил...

— Китегез! — диде Петрович, ачулануын сиздереп.

УАЗ кузгалып киткәч, Петрович:

— Хашәп, кәефне бозды! — дип, мыегына каткан бозны йолкып юлга ташлады.

— Петрович, ЗИЛны ничек менгерәбез?

— Ялгагыз тросларыгызны!..

...ЗИЛны тартып менгергәч, Петрович кузгалырга әмер бирде. Ислам, беркадәр юл китүгә, янә йокымсырап киткән Петровичны уятыр өчен (чөнки кабинада кеше йоклаганда аны да йокы баса иде), сораштыра башлады:

— Петрович, кем ул Вәли Сәгъдиевич?

— Ә-ә? Ул безнең санэпидстанция врачы иде. Хатыны белән баласын ташлап Казанга китте. Әнисе хәзер монын беренче хатынында тора, ә үзе яшь хатын белән Казанда.

— Менә нинди эшәке адәмнәр бар бу дөньяда!..

— Әйе, алама кеше... Бик куалама, юлны күздән яздырып, кюветка төшмик, балкаларыңны җыеп та ала алмассың...

Ислам дәшмәде. Аның бөтен дикъкате юлда иде. Буран көчәйгәннән-көчәя бара, сыртлап юлны каплап киткән төшләр ешрак очрый башлады. Кайту бермә-бер кыенлашты.

— Петрович, өйгә кайтып житеп булырмы икән бүген?..

— Шулай кайтсак, төнге уникеләргә Камага җитәрбез дип уйлыйм.

Петрович тамак кырып, җылыда җебеп киткән мыекларын сыпырып алды, кашларына кагылды. Сул кулында аның ике бармагы юк, фронтта калдырып кайткан, чак кына мактана башласа, шул ике бармаксыз кулы белән як-якка мыек-кашларын сыпыра иде.

— Карчыгын көтә бугай үзенне, Петрович? — диде Ислам, картның кәефе рәтләнүгә таба китүен сизеп.

— Гомер буе шулай көтә инде ул җанкисәк мине. Сугышка киттем, анда дүрт ел көтте, аннан кайттым, унбиш ел шофер булып эшләдем, юлдан, ерак рейслардан баш кайтмады — анда көтте. Хәзер дә көтә. Кhм... Сагынып кайтулары рәхәт була торган иде. Кайтуга, өстәлдә бер ярты булыр, эчәк пирогы... Шул эчәк пирогын яратам... Минә хатын сагына иде. Кайтып керүгә, әй, йөри синең янында!.. Тегеме, бумы дигән була, сораша, күңелне эретә прямо...

— Әле дә сагынып кайтасызмы, Петрович?

— Ничек диген әле! Үзем картаям, ә үземнең елдан-ел яратуым арта... Кешегә әйтсәм, кеше ышанмас, эштән сагынып кайтам үзен, эштән...

— Ә мин менә алай түгел, Петрович...

Петрович Исламга күз төшереп алды һәм шофер сүзендә бераз дөреслек күреп, беравык дәшми барды.

— Минемчә, бала кирәк сезгә, Ислам. Бала ул ике йөрәк кушылудан туа. Шуңа кадерле, шуңа үзгә. Хәзер шул сез хатыннарыгыздан бала таптырмыйсыз. Кан коялар, сәламәтлек югалталар... Их, яшьләр, яшьләр... Әллә нишләдегез сез... Күзең акайтма, мин синең турыда гына әйтмим. Минем үземнекеләр дә шулай. Сашаны беләсең бит. Былтыр институтны тәмамлады. Икенче курста ук өйләнешкәннәр иде Надясы белән. Әле булса балалары юк. Тоталар да тегендә чабалар, монда йөриләр, дөнья күреп калыйк, диләр. Быел әнә Болгариягә бармакчылар... Бала булмагач, кайчак эт белән мәче кебек талашып та алалар... Монысы инде эч пошудан... Әллә хатыны теләми, әллә Сашасы... Тегесеннән сорыйм, киленнән... Ни, ди, Саша кушмый, ди. Сашадан сорыйм, Надя теләми, ди... Имеш, итәк тотырып бала үстерергә, әллә без урта гасыр кешеләреме! Нәрсә ул урта гасыр! Әнә Урта Азиядә һәр семьяда җиде-сигез бала хәзер. Кырык җиде процентка үсеш, ди. Ә бездә икеме, өч кенә процент диме шунда... Менә сез дә икәүдәнникәү генә яшисез бит әле. Һәй соң, карчык әйтмешли, курчаклар өйләнешеп бала була димени!.. Мәңге буласы юк ул. Сез дә шул минем Саша белән Надя килен тиңнәре булдыгыз... Семья күрке — балада, Ислам улым...

«Ә бит Петрович дөрес әйтә. Бала кирәк. Семья күрке — балада. Нишләдең теге көнне — Мәснәвия балага уздым дигәч? Шашынып сөеп яратырга тотынмадыңмы?» — дип уйлады Ислам, Мәснәвиянең «балага уздым» дип әйткәнен исенә төшереп.

Ничек булды әле ул? Алар җәй көне гөмбәгә бардылар. Бик күп йөреп-йөреп тә гөмбә тапмагач, Кама буена төшеп, су коенып алдылар. Аннары куе үлән эченә ятып ял иттеләр. Бераз өшегәннәр иде, Мәснәвия Исламның гел кочагына ук кереп инде. Үзе еш-еш сулый, үзе калтырый, үзе һаман елыша, сыена... Йөрәге кайнарланып китеп, Ислам аны шундый итеп назлаган-сөйгән иде, әле булса күз алдына килеп, күңеленә рәхәт коелуын тоя.

Менә нәкъ шул көннән Мәснәвия аңа тагын бер ягы белән ачылган иде. Ул сөю-назлауны ярата. Ләкин Исламга андый нәрсә ятрак кебек тоела иде. Шуңа бераз саранрак кылана, йөрәк җылысын бирел бетерми, горурлыгы кушмый идеме, нигәдер, үзе моны теләмәсә дә, корырак тора иде.

Ләкин Мәснәвия аның бу холкын да йомшарта алды. Ул Исламны күз алдында яратырга тартына, ояла төшә. Әмма Ислам йокыга китсә, Мәснәвия аңа гүя бөтен хис ташкынын бирә: Исламның кашларына кагылып ала, мыекларына тиеп-тиеп куя, чәчләрен сыпыра, ахырда гаҗиз калып, бите белән күкрәгенә сыена һәм беравыкка тынып тора. Ислам күреп түгел, тоеп белә аның яратуын. Андый минут-

ларда ул чиксез бер рәхәтлек тоя, хатыны сөю-назлаудан туктар дип, чын-чынлап йоклагандай булып кылана, селкенергә куркып, тирәнтирән сулыш алып ята. Мәснәвия аның уяу икәнен сизәр дә һичкайчан да аны шулай сөймәс, иркәләмәс, назламас дип курка иде ул.

Юк, юк, ул Мәснәвияне яратты. Ул хәтта аңа бер күрүдә гашыйк булды. Дөрес, аның күңеле чуарланып киткән чаклар да булды. Үзенең тәкәбберлеген, горурлыгын җиңә алмый җәфаланган минутларны онытып буламы соң! Петрович хатыны турында сөйләгәч, Исламның Мәснәвиягә карата булган горурлык, тәкәбберлек тозы кинәт эреп киткәндәй булды.

Казанга китәр алдыннан бер көн элек Мәснәвия аны янә шулай яратты, сөйде. Ислам, гадәттәгечә, йокыга сабышып ятты. Мәснәвия бик озак аның чәчләрен сыйпады, ахырда күз-кашларына, битләренә кагыла-сыена торгач, тәэсирләнеп китеп, Исламны кысып кочып алды һәм пышылдап кына:

— Ислам, Ислам бәгырем, мин балага уздым,— диде. Мәснәвиянең кайнар сулышы аның колагын пешергәндәй булды, Ислам да түземен җуйды — хатынын кочагына кысып алды да күзен ачып:

— Чынлапмы, Мәснәвия? — дип сорады.

Мәснәвия җавап бирмәде, керфек очларына кунган яшьле күзләре белән аның битенә сыенды.

— Мин сиңа нәкъ үзеңә охшаган малай табып бирермен, Ислам җаным. Ул ике тамчы судай син булыр: күзләре дә, борыны да, кашы да, йөзе дә, иреннәре дә, хәтта мыегы да...

...Алабуга шәһәреннән чыгуга, буран тагы да көчәйде. Петрович, алдагы машинада бик бәргәли дип, икенче машинага күчеп утырырга булды.

— Юл бирсдә таныш, иплс кайт, куалама,— диде ул һәм, кабина ишеген ачып, кар-буран эченә кереп югалды.

Бер ара баргач, алда гадәттән тыш биек булып сырган көрт күренде. Ислам өченче тизлеккә күчте һәм моторны бар куәтенә үкертеп көрткә якынлашты. Мотор капот астыннан очып чыгардай булып улый, үзенең тавышы белән гүя көртне куркытырга тели иде.

Менә алгы көпчәкләр көрт эченә кереп чумды. Капот-кабина өстенә кар бөркелде. Ислам һични күрмәс булды. Нәкъ шул мизгелдә машинаның туктап калуын сизде. Сизде һәм, кинәт арткы тизлеккә күчереп, чыкмакчы булды, әмма куәтле КрАЗ селкенмәде дә.

«Утырдым»,— дигән уй үтте Исламның зиһене аша.

Ислам моторны сүндерде дә кабина ишеген ачмакчы булды. Әмма ишек ачылмады.

«Ни булды?»

Ишек янында көрәк тоткан берәү күренде. Ислам аны ишекне кыскан карны көрәп бетергәч кенә таныды. Зөлфәт иде бу.

Ниһаять, ишек ачылды. Алар янына Петрович килде, бөтен сакалмыегын кар сырган карт механик гел кыш бабайга охшап калган иде.

— Мәхшәрдер бу, егетләр... Тросың бармы, Ислам?..

— Бар.

— Бир Зөлфәткә. Тартып карыйк.

Тросны ыргакларга эләктергәч, Петрович Зөлфәткә кузгалырга дип команда бирде, Ислам да моторын кабызды.

— Әйдә, кузгал! Давай, давай!..

Корыч канат кылдай тартылды.

— Әйдә, кыюрак!..

Тартыша торгач, корыч канатның бер сеңере өзелеп китте һәм суырылып сүтелә башлады.

Икенче трос китерделәр. Петрович ике машина белән тартырга әмер бирде. Ике КрАЗ жигелгәч, көрт эченә кереп утырган Ислам машинасы да чыкты. Ислам тросны җыеп алды да, йөз метрлар артка чигеп, моторны бар куәтенә үкертеп, көрт эченә ташланды. Юлга аркылы төшкән көрт, кисеп ташлаган еландай, кинәт икегә аерылып калды.

— Молодец,— диде Анатолий белән янәшә басып торган Петрович, Исламның тәвәккәллегенә сокланып.— Мондый егетләр булганда бүген үк өйгә кайтып җитәбез, Толя, менә мин әйтте диярсең...

— Бирсен ходай,— диде Анатолий.

Петрович аңа карап алды да, кар-җилдән битен каплап, Зөлфәт машинасына таба китте.

...Мең бәла белән тик сәгать төнге икеләрдә генә колонна Камага җитә алды. Алдан барган Ислам Кама яры кырындагы будкага барып килде.

— Биредә адәм заты юк,— диде ул, уфылдап килеп җиткән көйгә.

— Кайда икән соң алар? Чыгарга ярамыймы әллә?

— Нигә ярамасын,— диде Ислам.

— Әйдә, утыр...

Кабинага кергәч, Ислам, бүреген салып, карын каккалады.

— Ахырзамандыр, шул киләдер, юкса, бу тамаша котырмас иде,— диде Петрович.

— Нишлибез, Петрович, керәбезме?

— Шаштыңмы әллә? Рөхсәтсез!..

Ислам түше белән рулена ятты да уйга чумды. Нигәдер бүген аның тизрәк өйгә кайтып җитәсе, Мәснәвияне күрәсе килә иде. Нигә болай кисәк кенә күңеле талпына башлады соң әле?

— Ислам, кереп китә күрмә,— диде Петрович.— Мин Анатолий белән киңәшеп киләм.

— Ярый.

Ислам, бер мәлдә ниндидер битарафлык тойса да, йөрәгендә кайнаган ашкынуына әле булса төшенеп бетә алмый тора иде.

— Чыкмасак, җәяү китәбезме, Петрович?

— Җәяүме булыр анда, килепме алырлар... Я, мин киттем.

Петрович китеп баргач, Исламның кабина ишегенә Зөлфәт килеп кагылды. Ачты, керде, утырды.

— Ай-һай, гел күз ачмаслык итте бит бу... Шул кадәр дуламаса.

— Минемчә, бераз басыла төште кебек,— диде Ислам, аңа карамыйча гына.

— Кабинада утырганда — әйе,— диде Зөлфәт, кинаяле елмаеп.— Алдан китәсеңме?

— Петрович алдан ЗИЛны җибәрәм, ди... Без юкармадыммы икән?..— диде Зөлфәт.

— Күпмегә юкарса да, сиңа алдан чыгасы түгел, борчылма...

— Син чыкмасаң, үзем керәм, машинаңны читкәрәк ал,— диде Зөлфәт, ачуы кабаруын яшермичә.

— Син, нәмәрсә, әллә минем чыдамлыкны сынарга телисеңме? — дип тавышын күтәрә төште Ислам.

— Дулама, Ислам. Кузгалсаң, әйдә, кузгал, кузгалмасаң, миңа юл бир!..

Ислам аңа күзен акайтып карап алды. Ул бу кешене яратмый иде. Ул белә иде: Зөлфәт аның кебек дуамал түгел, шактый сабыр холыклы, мәгәр эчле — бар ачуын үзенә җыя торган кеше. Ислам исә алай итә алмый, аныкы эчендәге тышында. Ислам, бер кабындымы, пыскып кына калмый, шундук дөрләп янып китә.

— Төш машинадан, Зөлфәт!
— Төшмәсәм, нишләр идең?
— Төш яхшы чакта! Мин бозга керәм.
— Кермисең! Петрович килмичә беркая да кузгалмыйсың! — диде Зөлфәт тыенкы, әмма боерулы тавыш белән. Бәлки, алай ук та булмагандыр, әмма йөрәге кабарган Исламга бу шулай тоелды.
— Төш диләр сиңа!..
Зөлфәт ишекне ачты, аягын баскычка куйды.
— Псих! Керә бир!..— диде һәм шапылдатып ишекне япты.
Ислам бер тын, тик бер тын гына икеләнеп торды. Аның йөрәге ярсып кага, күңеле каядыр ярамастай җиргә әйди иде.
Ачуы кабарудан идеме бу, Зөлфәтне күралмаудан идеме, ни генә булмасын, Ислам катгый карарга килде. Ул моторны үкертеп алды да әкрен генә боз өстенә кереп китте.
Арттан кемдер кычкыртты бугай, әллә инде колакка гына шулай ишетелде, шуңа аягын газдан алмакчы, тормозга басмакчы итте, әмма нигәдер моны эшләмәде.
Тизрәк, тизрәк чыгарга да өйгә кайтырга.
Ул арада машина биш метр тирәсе юл үтте, нәкъ менә шунда, Исламның өнен алып, боз чатнап китте. Ислам тәне буйлап, ток шикелле, салкын йөгерүен тойды, ә инде машина кинәт алды белән елгага чума башлагач, тирләп чыкты һәм ике куллап рульгә ябышты. Соңгы уе, соңгы сүзе «батам!» булды.
Ике якка аерылып киткән боз гүя машинаның алгы яртысын йотып алды: кабина секунд эчендә яртылаш суга чумды. Кайнар мотордан бөркеп пар чыкты, каяндыр су астыннан ярдәмгә чакырып, машина сигналы ишетелгәндәй булды.
Машина чумган төшкә беренче булып Зөлфәт килеп җитте һәм шунда ук машинасына кире йөгерде.
Ул кабинасыннан бау алып килүгә, бирегә Петрович, Анатолий, Гата һәм калган шоферлар җыелганнар иде инде. Зөлфәт тиз генә бауның бер очы белән билен уратып бәйләде дә икенче очын Анатолийга тоттырды. Хәзер генә Зөлфәтнең ни эшләргә теләвен аңлап алган Анатолий:
— Нык бәйлә, чишелерлек булмасын! — диде.
— Нишлисез, егетләр? — дип сорады, сулышына кабып, Петрович.
Ләкин кайтарып сорамады. Ул тораташтай катып калды. Аның зиһенен әллә ниләр: үлем, афәт, күз яше, җаваплылык тойгылары көйдерә башлады.
— Кабина ишеген ача алса, алып чыга ул аны, су тулып җитмәгән булырга тиеш,— диде Анатолий, кабина буйлап төшеп маташкан Зөлфәткә бауны җибәрә-җибәрә.
Бер минут.
Шушы бер минут өстә калган унөч кеше өчен үзе бер гомер булып тоелды.
Шушы алтмыш секунд Петрович өчен моңа кадәр яшәгән гомереннән күп озын күренде!
Ул арада Зөлфәт, муен тиңентен суда торып, кабина ишеген ачты, Ислам гәүдәсен эләктереп, «бауны тартыгыз!» — дип кычкырды. Анатолий һәм башкалар бауга ябыштылар.
— Егетләр, читкәрәк китегез, боз җимерелмәсен! — дип кычкырды кинәт һушына килгән Петрович.
Уннарча кул Зөлфәт белән Исламны тартып алды.
— Исламны беренче машинага, Зөлфәтне икенчегә! — дип боерды Петрович.
Берничә кеше Исламны күтәреп алды һәм беренче машинага йөгерде. Петрович, Зөлфәт янына килеп:

— Тизрәк, тиз икенче машинага йөгер! — дип әмер бирде.
Үзе Зөлфәт артыннан йөгергәндә, ЗИЛ шоферын күреп алды.
— Мөгаен, синең аракың бардыр?
— Бар.
— Ал да беренче машинага оч! Тиз! Баткан егетнең авызына коегыз!..
ЗИЛ шоферын әйтерсең җил алды.
Петрович барып житкәндә Исламны урындыкка сузып салганнар һәм ике кеше: Анатолий белән Әнәс шофер авызына аракы коярга маташалар иде инде. Петрович кабинага керергә теләп карады, сыймады, Әнәсне төшереп, үзе менде. Карт механик Бөек Ватан сугышында разведчик булган, суга баткан кешеләрне беренче коткаруы гына түгел иде, күрәсең: керә-керү белән, Исламның күкрәген ачып, чак кына аракы койды, аннары бер-ике йотым эчерергә кушты. Аннары Ислам гәүдәсен каплап салды, һәм кулларын аллы-артлы йөртергә тотынды.
— Хәзер борынын кысып тот,— дип боерды ул Анатолийга.— Кыюрак кылан! Я, хәзер авызына өр! Авызынны авызына куеп өр! Капла!..
Шулай берничә тапкыр хәрәкәт ясауга, Ислам укшып куйды һәм кинәт ухылдап косып җибәрде.
Петрович, бөтен әгъза-буыннары сынсыз калуын тоеп, идәнгә иелде.
— Ни булды сезгә, Петрович? — дип сорады Анатолий курка калып.
— Берни юк. Әллә нигә йөрәк хәлсезләнеп китте, үтәр,— диде карт механик.
Ислам косудан туктауга, Петрович аны чишендерергә, тәненә аракы коеп уарга һәм Анатолийга тунын салырга кушты.
— Эчке киемнәреңне салып киендер. Үзең менә минем тунга төренерсең. Мин Зөлфәт янына киттем.
Зөлфәт, Гатаның кием-салымын киеп алгач, җылынып өлгергән иде инде, Петрович кереп аңа аракы салып сузса да, ул эчмәде, башын чайкады.
— Карышып торма, җәйге Камага төшмәдең, эч! — диде аңа Петрович.
Шулай кеше гомерен бизмәнгә салып үлчәп торганда, шәһәр ягындагы ярда машина уты күренде.
— Петрович, күрегезче, берәү боз аша чыкмакчы!..
— Беткән баш, кем булыр икән... Гатаулла, йөгер каршы, кертмә боз өстенә! — диде Петрович.
Ләкин соң иде инде — машина зур тизлек белән баткан прицепка таба килә иде. Ут көлтәсе кабинасы белән суга чумган КрАЗны яктыртуга, ул туктады, артка чикте һәм уратыбрак бу ярга таба килә башлады.
— Йөрмә,— диде Петрович, кабинадан чыгып йөгерергә торган Әнәснең җиңеннән тотып.— Соң инде...
Ислам яткан кабинага килеп керү белән, аны Анатолий куандырды.
— Сөйләшә егет, җан керде,— диде.
— Йа хода, бар икән әле кодрәтең,— диде Петрович.— Шайтан алган нәмәстә, кем кушты?! — дип әйтеп ташлады ул күзләрен шардай ачып кабина түшәменә карап яткан Исламга.
— Гафу итегез, Петрович,— диде Ислам хәлсез генә һәм укшый башлады.
— Гафу ит, гафу ит,— дип кат-кат кабатлады Петрович, Исламга һичнинди ачу тотмыйча. Бу минутта ул шат иде, егетнең исән калуына, афәтнең үтүенә шат иде, шул ук вакытта ул тыштан моны берәү-





5*

гэ дэ белдерергэ дэ телэми, шуңа бераз дорфарак кыланмакчы иде, лэкин ахыргача булдыра алмады, Исламның кулын тотуга, тегенең салкын бармакларында хэрэкэт тоеп, егетнең бит-йөзенэ аталарча кагылып алды, юеш чэчен сыйпады.

— Куркыныч узды инде, Ислам улым, котылдың хэзер,— диде.

Ул арада алар янына УАЗ килеп туктады. Петровичның эче дөрес сизгэн икэн: машинадан өстенэ ак тун кигэн Бабай төште. Петрович та, аны күрүгэ, кабина ишеген ачып, кар өстенэ сикерде.

— Я, Петрович, исэн-сау кайтып житүме? — диде начальник коры гына.

— Менэ...

— Күрдем...

— Егетлэр исэннэрме, үлем-хэтэр юкмы?..

— Ислам чумып алды, аны алырга Зөлфэте төште...

— Тиз генэ икесен дэ минем машинага күчерегез... Тизрэк! Кая егетлэрен, Петрович?..

Ислам белэн Зөлфэтне УАЗга күчергэч, Сэгъди, өстеннэн туның салып, Исламга каплады да, һични сорашмыйча, больницага ашыкты.

— Петрович, мин килгэнче көтегез,— диде ул машинага утырыр алдыннан...

Больницадан ул ярты сэгатьлэр чамасы узганнан соң гына килде, туктауга, шоферларны жыйды да:

— Машиналарны сүндерергэ, суны агызырга, ишеклэрне биклэргэ һэм биш минуттан минем янга! — дип боерды. ЗИЛ шоферы Сэгъди артыннан чыгарга телэвен белдергэч, ул: — Мин синең начальнигыңны белмим, эмма минем боерыкка буйсынмасаң, кем генэ булуыңа карамастан, бүгеннэн шофер түгел дип исэплэ үзеңне,— диде. Шоферга бу кешегэ буйсынудан башка эмэл калмады.

Сэгъди башта, ике рейс ясап, бар шоферны боз аша чыгарды, аннары уникe кешене сигез урынлы УАЗ кабинасына «тутырды» да, һэрберсен өенэ илтеп, таратып йөрде.

...Иртэн иртүк начальник һэм инженер аръякта калган машиналар янына килеп киттелэр. Озак кына киңэшкэч, ике бульдозер, кран алып, баткан машинаны бүген үк чыгарырга дигэн фикергэ килделэр.

Һэлакэткэ очраган машинаны бары тик кичке якта гына гаражга алып кайта алдылар. Машинага эллэ ни булмаган, капоты изелеп, фаралары гына ватылган иде.

Шул эшлэрне башкаргач, Сэгъди, кабинетына кереп больницага шалтыратты.

— Бер егетегезгэ бераз ятырга туры килмэгэе, Зөлфэт атлысын бүген үк чыгара алабыз,— диде аңа дежур врач.

Сэгъди башын кулы белэн учлап тотты да уйга калды. Кисэк кенэ аңа Ислам тагы да үз һэм якын кеше булып китте.

Сэгъдигэ врачлар Зөлфэтне поликлиникадан үк өенэ кайтарып жибэрергэ була дисэлэр дэ, егетнең суга төшүен белгэч, нидэндер шиклэнеп, аны да больницага салырга дигэн фикергэ килделэр.

Икенче көнне үк Зөлфэт янына иптэшлэре килде, Анатолий белэн Бабай кереп хэлен белеп чыктылар. Алар инде Ислам янында булганнар, эмма булсалар да, аның хэле белэн кызыксынган Зөлфэткэ өзеп кенэ бер сүз дэ эйтэ алмадылар. Кичке якта аның янына Диана керде, хэлен сорашкач, ул кинэт кенэ:

— Ә Исламның хэле авыр, инсульт булмагае,— дип чыгып китте.

Зөлфэт инсультның ни икэнен белмэсэ дэ, Дианаңы туктатып, кайтарып сорарга яхшысынмады, бар сагышын эченэ йотты. Ахырда түзмэде, аңа чыгып йөрергэ кушмасалар да, Ислам яткан палатаны эзлэп китте. Палатаны ул тиз тапты, лэкин аны Ислам янына кертмэделэр. Ишек янында торучы няня:

— ...Консилиум бара, һичкемне кертергә кушмадылар. Казаннан профессор килде,— диде.

Больницада ятып, таң атуны көтеп алу зарыктыргыч бер нәрсә икән ул. Бәлкем, бу авыру Зөлфәткә генә шулай озак тоелгандыр. Зөлфәт үзен яхшы сизсә дә, тәнендә ниндидер ою тоя.

Кичә кичке якта Исламның үлү хәбәрен ишеткәч, ул туп-туры аның палатасына барып керде. Ислам тагы да озаеп китеп, бер үзе бер палатада ята, аның караваты кырыендагы урындыкка Мәснәвия утырган. Ул иренең кулын тоткан да үксеп-үксеп елый. Мәснәвия Зөлфәткә күтәрелеп тә карамады. Бу яшь ана өчен дөнья кинәт тараеп киткән, яшәү мәгънәсез бер төс алган, алсу йөзе сулып калган иде.

Зөлфәт агарынып, җүдә яфрагы төсенә кереп калган Исламның йөзенә карап торды. Йөрәге күкрәгеи ташлап китәрдәй ярсынып тибә башлады. Шунда ук Ислам белән кичәге низагы күз алдына килде.

— Гафу ит, дускай... кичер мине,— диде ул пышылдап һәм иләсмиләс килеп үз палатасына таба китте. Палатага керү белән, ул читлеккә эләккән кош кебек бәргәләнергә, үзалдына сөйләнә-сөйләнә идән буйлап йөрергә тотынды. Аның янына дәвалаучы врачны чакырдылар. Врач Зөлфәтне тынычландырырга теләде, ахырда укол кадарга кушты. Аны караватка яткырдылар. Укол кадаганнан соң, Зөлфәт тынычлана төште һәм изрәп, хәлсезләнеп калды. Күз кабаклары кургашындай авырайдылар, әгъза-буыннарын кузгатмас булды.

Күпмедер йоклаганнан соң, ул сискәнеп уянып китте. Уянды һәм зиһенен телеп үткән беренче уй Ислам булды.

Палатадагылар йоклыйлар иде әле. Зөлфәт әкрен генә торды да тәрәзәгә килеп сөялде. Аның сызып кына йөрәге әрни, күңеле рәнҗи иде. Менә тәрәзәгә беренче таң нурлары кунды, Зөлфәт, күзе талганчы, чыгып килгән кояшка карап торды.

Аның кисәк кенә боегып, ямансулап калуын иртән обходка кергән врач та сизеп алды. Ул аның йөрәген тыңлап карады да:

— Йөрәгең сикергәләнә синең, егет. Нигә бик борчыласың, нигә кайгырасың? — дип сорады.

— Әйтегез әле, Гали абый, инсульт нәрсә ул? — диде Зөлфәт, врачны аптырашка калдырып.

— Инсультмы? — врач беравык уйланып торды.— Инсульт ул мигә кан саву очрагы...

— Ә... Байтимеровның миенә нидән кан сауды икән?

Врач җыерчыклар ермачлаган маңгаен имән бармагы белән ышкып алды, ул Ислам Байтимеровның ни сәбәптән кинәт авыраеп китүен һәм йөрәге туктавын хәтеренә китерергә тырышты бугай.

— Аның баш сөяге яньчелгән иде бераз. Минемчә, шул биргәндер. Консилиум шундый нәтиҗәгә килде,— диде.

## 16

Кыш гадәттән тыш йомшак килде. Чатнама суыклары, төкрек җиргә төшмәстәй үзәк өзгеч салкыннары белән Кама елгасы буенда яшәүчеләрне җәфа чиктергән сыкылы декабрь ае да бу елда юмартланып киткән иде — салкынлык ай буе унбиш-егерме градустан артмады. Гомумән, соңгы елларда салкыннар сүрелә башлауны галим агайлар һава өлешендә углеводород матдәсенең артып китүеннән күрәләр. Сәгъди исә, моңа бик үк ышанып җитмәсә дә, җир шарында һәр көн сафка кергән завод-фабрикаларны, конвейердан коелып торган машиналарны күз алдына китерә иде дә, галимнәр фикерендә дә аз-

маз хаклык күреп, шул турыда чыккан мәкаләләрне еш кына укыштыра тора иде. «Менә кара әле тагын бер могҗиза,— дип кемгә дә булса яңа гына укыган мәкаләсен күрсәтә иде ул.— Унсигезенче гасыр башында Мәскәү шәһәрендә март аенда ук агачлар яфрак яра һәм апрель башында сабанга төшәләр. Димәк, биредә бер дә һава өлешендә арткан машина газына сылтыйсы түгел».

Бу — мәсьәләнең фәлсәфи ягы иде. Кышның йомшак килүе нәтиҗәсендә автопредприятие бокслapсыз да җиңел яши. Машиналар чыгышы әйбәт, план айдан-айга арттырып үтәлә. Трест каршындагы автопредприятиеләр арасындагы социалистик ярышта Сәгъди җитәкчелек иткән коллектив беренче урынны алуга иреште. Яңа елга күчмә Кызыл байракны коллективка тапшырырга трест начальнигы Чаллыга үзе килде. Күп кенә шоферларга «Машина йөртү отличнигы» значоклары, акчалата бүләкләр бирделәр. Комсомол-яшьләр бригадасы республикада алдынгылар рәтенә чыгып «Мактаулы бригада» исемен алуга лаек булды.

Бу яктан Сәгъдинең күңеле тыныч иде. Тик үткән айда булган фаҗигале хәл — Исламның үлеме генә йөрәкне сыздырып-сыздырып әрнетеп куя. Шул турыда уйлана торгач, ул төннәр буе саташып, хәтәр төшләр күреп чыга, аннары көнозын кәефе кырылып, башы авыртып йөри.

Яңа елга бер көн калгач, Сәгъди, Зөлфәтне шаккатырып, ул торган бүлмәгә килеп керде. Һәм кергән шәптән үк бер шешә коньякны өстәлгә чыгарып куйды да рюмкалар сорады.

Зөлфәт түбән төште, ояла-тартына булса да, Дианадан ике-өч рюмка, кабарга ризык сорап алды. Ул әйләнеп менгәндә Бабай чишенгән, җайлап торып Зөлфәтнең караватына утырган иде инде.

— Әллә миңа китәбезме? — диде ул, Зөлфәт рюмка-тарелкаларны, чәнечке-калакларны өстәлгә тезеп куйгач.— Эч поша минем, Зөлфәт туган,— һәм кисәк кенә сорап куйды: — Ә синең эч пошкан минутларың буламы? Ну, әйтик, үз-үзеңә урын табалмаган чакларың?..

Зөлфәт килешсез генә елмаеп куйды һәм ни әйтергә белми аптырап калды.

— Ярый,— диде Бабай.— Әйдә сал әле берәрне. Моңа кадәр рәтләп эчкән дә юк иде, бу көннәрдә салмый булмас, ахрысы. Яңа ел, җиңү, аннары...

Сәгъди тәрәзә янындагы Диана рәсемен күреп тынып калды. Ул, бераз һаваланып китүенә уңайсызлангандай, тавышын түбәнәйтә төшеп:

— Өйдәме? — дип рәсем ягына ияк кагып сорады.

— Өйдә,— диде Зөлфәт Бабайның соравына гаҗәпләнә калып.

Берәр рюмка салып куйгач, Бабай беравыкка уйга чумды. Аннары бер-бер артлы тагын ике рюмка салды да, караватка кырын төшеп, авызына капкан кыяр турамын чәйни-чәйни, бер ноктага карап тынып калды. Бу — Зөлфәт беренче күргәндәге Бабай түгел инде инде. Аның иңбашлары калка төшкән, бетерешкән гәүдәсе бөкерәебрәк калган, ә чал чәче тоташ кылган төсенә кергән иде.

— Әйе, шактый гыйбрәтле хәлләр булып алды быел,— диде Бабай Диана рәсеме аша каядыр еракка, күңел күзе генә күргән төбәккә карап.— Зөлфәт, әйт әле, син Исламны дус итә идеңме?..

Шул сүзне әйтүгә, Бабай йөзенә кызыксыну, сабырсызлану билгеләре йөгерде. Моны Зөлфәт тә сизми калмады. Ул гасабилана, дулкынлана иде. Бабай аның ягына карамый, сабырсызлануын белдермәс өчен, үрелеп кыяр капты һәм теләр-теләмәс кенә ашый башлады. Ләкин аның эчке кичерешләре гаять киеренке бер хәлдә иде. Зөлфәт,

бу кешенең үзеннән ни теләвен белмәвенә гаҗиз калып, өстәлдәге шешәгә карады.

«Әллә Исламны бозга керергә мин мәҗбүр итте дип шикләнәме бу?» — дигән шомлы уй үтте аның зиһене аша. Һәм ул бар булган хәлне түкми-чәчми, барысын да сөйләп бирергә булды. Хикәясен ул үзенең хезмәттән кайту көненнән башлады. Мәснәвиягә булган мәхәббәте, аның белән булган хәлне дә яшермәде. Дианага булган үз мөнәсәбәтен дә, Исламга тоткан дәгъвасын да әйтте, хәтта кабинадагы соңгы бәрелешүләрен дә сүзгә-сүз бәян итте.

Зөлфәт туктагач, Бабай тәрәзәдән күренеп торган айга карап торды, аннары кисәк кенә ишекле-түрле йөреп китте. Ул бер йөнтәс кулын аркасына куеп атлады, бер, теше сызлаган кеше сыман, уң кулын яңагына кысып йөренде. Ниһаять, ул Зөлфәт каршына туктады.

— Әйт әле, Зөлфәт, сезгә ул көнне УАЗ очрадымы?

— УАЗ? Больница машинасымы? Очрады...

— Шул машинадагы кеше сезгә берәр сүз әйттеме? Әйтик, бульдозер турында?

— Нинди бульдозер?

— Нинди бульдозер,— дип кабатлады Сәгъди һәм янә йөреп китте.— Мин бит ул кешене боз аша чыгарып җибәрдем. Котлары алынып, каян чыгарга белми куркып торалар иде. Мин аңа: «Безнең машиналарны очратсагыз, минсез елга бозы аша чыкмасыннар дип әйтегез»,— дип кат-кат әйттем.

— Кем иде соң ул?

— Шайтан белгән аны. Казанга кайтучы иде бугай. Ул сезгә бер сүз дә әйтмәдемени?

— Юк кебек. Ислам аның белән ни өчендер әйтешеп тә алды кебек. Мин алар янына килгәндә, ул кеше китәргә җыена иде инде. Мин ул кешедән андый сүзләр ишетмәдем. Исламга әйткән булса гына...

— Берсе өстенә берсе килеп кенә тора. Сезгә каршы киткән бульдозер, юлдан язып, таш карьерына төшеп баткан, теге адәмнәр, имеш, йомышны әйтмәгәннәр...

Кемдер ишек шакыды.

— Керегез!

Бүлмәгә баласын нәртеп Диана килеп керде. Бала, уенчыкларын күтәргән килеш, үзалдына бытбылдый-бытбылдый, түргә узды, Диана Сәгъдине күрү белән уңайсызланып китте.

— Гафу итегез, Диана Галимовна, минә шоферымның хәлен белергә дип кергән идем,— диде Сәгъди, түбәнчелек белән чал башын иде.

— Бер дә борчылмагыз, Сәгъди...

Диана тагын аның атасының исемен онытты һәм шуңа комачтай кызарынып чыкты, ләкин Сәгъди аны бу юлы үзе коткарырга булды.

— Сәгъди Вәлиевич,— диде ул бөтен йөзенә елмаеп.

— Гафу итегез, Сәгъди Вәлиевич, хәтернең чуалган чагы. Зөлфәткә бер-ике сүзем бар иде.

Сәгъди Зөлфәткә чыгарга кушып ым какты. Ләкин башта бер рюмка салып сузды.

— Бәлкем, безнең белән...

— Юк, юк, Сәгъди Вәлиевич... Рәхмәт, анда мине көтәләр.

— Ярый соң,— диде Сәгъди аның белән килешеп.

Зөлфәт кергәч, ул аңа сораулы караш ташлады, янәсе, ни?

— Юлда безгә очраган кеше килгән. Ул аның ире икән. Әнисен алып китәргә килгән диме. Ә Сара апа якын да килми, ди. Вәли дигәне яшь хатын белән килгән...

Сәгъдине ниндидер коточкыч дулкын аягыннан еккандай итте.

— Кем?! Сара?! — Сәгъди агарынып китте һәм караватка утырды.

— Бабакай, бабакай, сиңа ни булды, башың авырта, да? Хәзер әни укол кадый,— диде аңа бала, Бабайның хәлсезләнеп калуына аптырап.

— Кызым, кечкенәм минем, балакаем!..

Язилә курка калды һәм чырыйлап елап җибәрде, яшьле күзләре белән Зөлфәт абыйсына карады. Зөлфәт аны кулына алды да, җилкәсенә атландырып, идән буйлап чабып китте. Хәзер генә күз яше белән елаган бала шырык-шырык көлә дә башлады.

— Зөлфәт,— диде Сәгъди, түргә карап.— Мин хәзер анда төшәм. Мин аларны күрергә тиеш...

— Кемнәрне?..

— Соңыннан,— диде Сәгъди һәм бетерешкән гәүдәсен турайта төшеп, ишеккә таба китте.

Каян килгәндер аңа бу тамаша тәвәккәллек, ул хәтта, керергә рөхсәт сорап, ишек кагып та тормады: ишекне киң ачып, бусаганы атлап бүлмәгә узды. Керә-керешли үк күзенә чалынган беренче күренеш шул булды: түр креслода Сара утыра, аның янәшәсендә Вәли, Сараның икенче ягында яшь хатын,— Сәгъди аны күрү белән шулай дип юрады,— һәм бер читтәрәк, йокы бүлмәсенең ишеге янында, кимсенгән кыяфәттә Диана басып тора иде.

Бүлмәдәгеләр башта аны шәйләми калдылар, алар дикъкать белән Сараны тыңлыйлар иде.

Иң әүвәл аны яшь хатын күрде. Сәгъдинең аңында беренче чагылган уй: «Курчак!» — булды. Шуннан аңа Вәли күтәрелеп карады. Бу — Сәгъдигә төс-йөзе белән тартым, әмма шактый юантык гәүдәле кеше иде. Тик Вәли тураеп баса төшкәч кенә Сәгъдине Сара күрде. Күрде һәм аның йөзе шул тиклем куркыныч бер сурәткә керде ки, хәтта Сәгъди: «Исәнмесез»,— дип әйтергә ачкан авызын яба алмый калды...

Сара тавышы аңа соңрак ишетелде, торырга дип күтәрелә башлаган, әмма баса алмыйча йөзтүбән идәнгә капланган гәүдәсен күргәч кенә ишетте ул аны.

Сәгъди тәүге тәвәккәл халәтеннән нәкъ менә шунда айнып китте. Сара йөзтүбән капланган килеш идәндә ята, ә бүлмәдәге өч кеше Сәгъдине танымыйлар, танысалар да, аның бирегә нигә килеп йөрүен белмиләр иде; алар аңа бер мизгелгә аптырашып карап тордылар. Ике-өч секунд эчендә булып алган бу хәлдән башта Вәли исенә килде һәм каударланып, идәндә яткан әнисен күтәрергә ташланды. Ул арада Сараны күтәрергә яшь килен килеп тотынды, җаны әрнүдән гаҗиз калып торган Диана да әнисенә торырга ярдәм итте. Сәгъди шунда гына үзенең биредә бөтенләй чит-ят кеше булуын һәм рөхсәтсез-нисез килеп керүенең биредә никадәр оят булуын күз алдына китерде. Шул ояттан ул бүлмәдән чыгып китте. Йөгерә-атлый өске катка менде. Тизтиз киенде дә, шулай ук кабаланып, ишегалдына чыкты. Артыннан чыккан Зөлфәткә ул:

— Кирәкми, озатып маташма! — дип кенә әйтте.

Күк йөзе чалт аяз, тулы ай йөзә, ай тирәсендә сүнәр-сүнмәс йолдызлар җемелди. Сәгъди ашыга-кабалана өенә таба атлады. Бу минутта аның тизрәк өенә кайтасы һәм иске мотордай дылбыр-дылбыр типкән йөрәген валидол кабып тыя төшәсе килә иде. Югыйсә, кем белә, искереп, тузып-таушалып, сыны-куәте бетеп барган гомер моторының кинәт кенә туктап куюы да бар. Ә бүген ул, исән калса, бәлкем, тагын яшәү өчен көрәшә башлар иде.

## 17

Ул аны көтмәде, Сәгъди үз язмышы белән килешкән иде инде. Сараны очрату, улы Вәлине күрү Сәгъдигә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Башта ул ни эшләргә белмичә аптырашта калды. Аларны яңадан күрергә теләү, яңабаштан нидер корырга омтылу ахмаклык булыр иде. Шул ук вакытта ул аларны күрергә тели һәм, моны эшләмәсә, үз гомеренә үкенәсен дә белә иде. Әйе, әйе, Сәгъди аларны күрергә һәм хәл-әхвәлләрен белергә тиеш. Ләкин бу теләгенең тормышка ашуына ул ышанып бетми, чөнки күңел түрендә нииндидер ятсыну, гарьләнү, шул ук вакытта горурлыкка охшаш бер тәкәбберлек чаткысы кабынып-кабынып китә иде.

Икенче көнне кичке якта аңа Зөлфәт килеп керде.

— Сезнең арттан килдем. Сара апа чакырды. Зинһар, килсен, күрәсем килә дип әйтте,— диде.

Бу хәбәрне ишетүгә: «Әллә соң барып сөйләшеп утырыргамы? Яңа ел!» — дигән уй зиһенендә кайнаша башлады Сәгъдинең һәм ахыр килеп, түзмәде, кырынды, киенде дә җавап көтеп торган Зөлфәткә барырга ризалыгы турында әйтте.

«Ул мине онытмаган, Сара мине күрергә тели,— дип уйлап барды Сәгъди Зөлфәт белән янәшә атлаганда.— Нигә? Ни өчен?»

Бу соравына ул җавап таба алмады. Ул хәлләрдән соң бик күп сулар акты, күп еллар узды бит инде. Ихлас күңелдән генә әйткәндә, ул аны гәрчә исенә төшергәләсә дә, Сарага булган мәхәббәте кайчак аңа инде сүнгән-сүрелгән кебек тоела иде.

Сәгъди, истәлеккә бирелеп, Сара белән торган соңгы елларын исенә төшерергә тырышты.

Сара малай тапкач, Сәгъди: «Балага Вахит дип исем кушыйк», диде. Шунда әнисе бу исемгә аяк терәп каршы төште. Имеш, таптың исем, беткәнмени безнең татарда башка исем.

Сәгъди Зөлфәт белән янәшә атлаганда әнә шундый хатирәләргә бирелеп барды. Һәм үзенә каршы килүче берәүнең чыршы күтәреп үтеп баруын күрүгә, кылт итеп, бүген Яңа ел булуы, Зөлфәтнең аны Яңа елны каршыларга чакыруы исенә төште. Анда, Сара янында, аның килене Диана, улы Вәли, оныгы булачагы, бүләксез барып керсә, үзенең оятка калачагы күз алдына килде. Һәм ул Зөлфәтне әүвәл магазинга әйдәргә булды.

— Син дә әйтмисең, минем дә гел истән чыгып киткән... Яңа ел ич бүген!..

— Яңа ел шул. Күрмисезмени тәрәзәләрне! Ә үтү-сүтүчеләргә күз салыгыз әле, Сәгъди абый...

— Менә нәрсә, Зөлфәт, әүвәл универмагка сугылыйк әле.

Тик сәгать кичке уннарда гына өй янына килеп җиттеләр алар. Зал тәрәзәләрендә балкып ут яна, түр яктан төрле төстәге лампочкалар белән бизәлгән чыршы күренә иде.

Чыршыны Зөлфәт алып кайтты, янында бытбылдап йөргән Язилә белән үзе бизәде. Диана кухня ягында кайнашты. Бала белән Зөлфәтнең мәш килеп чыршы бизәүләрен, Сараның аларга уенчыклар биреп торуын чыгып-чыгып карады. Һәм нәкъ менә шул чакта аның күңелен нидер айкап-болгатып алды. Кинәт аңа нәкъ менә шунда, үз өендә, баласы-анасы янында Зөлфәтне дә күрәсе килде. Һәм квартирант итеп кенә түгел, ә...

Ләкин күңеленә алай дип өмет чаткысы салырга ул курка иде. Нигә? Ни өчен? Үзе дә белми, әмма шомлана, курка иде.

Ишектән ирләр килеп керүгә, иң әүвәл аларга каршы бала йөгерде.

— Зөлпәт абый, бабакай! — диде ул, тегеләрнең кулларында дөнья кадәр уенчык, кучтәнәч күреп.

«Сара өйрәткән»,— дип уйлады Сәгъди, тиз генә балага йөри торган курчак тоттырды, курчагы белән бергә баланы күтәреп үчтекиләп сөеп алды. Аннары ул кухнядан чыгып килгән Диана белән күреште, аны Яна ел белән котлады.

— Иртә бит әле, Сәгъди абый, тагын ике сәгать көтәсе бар,— дигән булды Диана көлә-көлә...

Шуннан соң гына Сәгъдинең карашы Сарага төште. Ул аңа таба бер адым ясады да бер мизгелгә генә туктап калды. Сара сабырсызланып, стенага тотынып тора һәм, ахры, бик нык дулкынлана, гасабилана иде.

Сәгъдинең кинәт туктап калуыннанмы, өйдәгеләрнең үзенә игътибар итүләреннәнме, Сара кинәт кенә аркасы белән стенага сөялде һәм, ике кулы белән йөзен каплап, елап җибәрде. Сәгъди кабаланып аның янына килде, хатынны култыклап алды, саклык белән генә янәшәсендәге креслога утыртты.

— Зинһар, борчылмагыз, Сара!..

— Сәгъди, синме бу!..— диде Сара үксеп.

Диана Сарага ниндидер дару бирде. Дару төймәсен тел астына салгач, Сара тынычлангандай булды.

— Гафу ит, Сәгъди, мин, күрәсең, менә шушы көнгә калдым инде,— диде беравык тын утыргач.— Тау белән тау очрашмаса да, кеше кеше белән очраша, диләр, дөрес икән,— диде ул.

— Язмыштан узмыш юк, Сара,— диде Сәгъди һәм нигәдер шулай әйтүенә үкенеп, уңайсызланып китте.

Сара аңа яшьле күзләре белән күтәрелеп карады. Сәгъди аның күзләрендә ягымлылык, йөзендә моңсулык күрде. Сара нидер әйтергә дип авызын ачкан иде, әйтмәде, нигәдер тыелып, туктап калды.

«Вәли турында әйтмәкче иде»,— дип уйлады Сәгъди һәм аның күңелендә авыру хатынга карата кызгану хисе уянып китте.

— Кирәкми, Сара. Куй...

— Ул китте, ул бик ашыкты,— диде Сара һәм аның аксыл-сары йөзенә кызыллык йөгерде.

Сара гомере буе улы Вәлигә атасын хурлап, яманлап, аерылышуларында аны гаепләп сөйләде, кечкенәдән үк бала күңеленә әтисенә карата нәфрәт хисе сала килде. Вәлинең атасы Сәгъдине күрергә теләмичә китүе шул тәрбиянең нәтиҗәсе иде. Сара моңа менә хәзер генә, Сәгъди килгәч кенә төшенде. Ләкин берни кыла алмады. Хәзер ул моңа үкенә, үртәлә, кайчандыр, ачу хисенә бирелеп, Сәгъдигә карата кылган явызлыкларыннан гаҗиз калып, йөрәге әрни, күңеле рәнҗи иде.

Соңгы минутларда гына Сәгъди Сара күзләрендә әнә шуны күргәндәй булды. Шуны сизгәч, аның күңеле җәберләнде. Ул бер даим почмакка, Сара белән улы Вәли рәсемнәре эленгән рамга карап торды һәм, уйга чумып, кулын кушырды, тәрәзә каршына барып басты.

«Мин аны Әнәс турында әйтергә уйлый дип торам. Ә ул мина Вәли турында сөйли. Аның мине күрергә теләмәвенә кем гаепле соң? Кем!?» — дип үзалдына уйланды Сәгъди һәм эчтән генә Сара белән бәхәскә керде.

«Син тәрбияләдең аны шулай, син, Сара!»

«Мин гүгел, мин түгел, Сәгъди!»

«Ә кем соң?»

«Белмим».

«Әнәсме?»

«Юк, юк. Ул түгел, Әнәс тә түгел, Сәгъди. Ул аны тәрбияләмәде дә диярлек. Әнәс сугыштан кайтмады».

«Кем соң? Дәшмисең? Димәк, син, син, Сара?!»

«Гафу ит, кичер мине, Сәгъди. Әйе, миндә гаеп, миндә. Мин тәрбияләдем аны, мин салдым аның күңеленә сиңа карата усал оеткы. Хәзер мин аңладым, мин ялгышканмын, булдыра алсаң, кичер мине?!.»

Сәгъди, борылып, Сарага карады. Хатын аптыраган кыяфәттә креслода утыра һәм гасабиланып терсәк тәрәгән ышкый, калтыранган бармаклары белән нидер чүпләгәндәй итә иде.

— Бәлкем, Вәли хаклыдыр,— диде Сәгъди, күрмәс күзе белән бер ноктага текәлеп.— Тапкан түгел, баккан ата-ана балага якын була диләр бит.

— Әнәс 1941 елда ук сугышка китте һәм әйләнеп кайтмады. Мин аны үзем тәрбияләдем, үзем кеше иттем,— диде Сара калтыравык тавыш белән. Сәгъдигә ул менә-менә елап җибәрер кебек тоела иде.

— Әбекәй, әбекәй, калале-кала, бәбәй тәпиен болай-болай йөлтә,— дип, бала Сара алдына килеп басты һәм аны җиңеннән йолыккалый башлады.

Аннары Язилә Сәгъдигә сорау бирде:

— Бабакай, бәбәйнең исеме ничек?

— Нинди исем кушарга икән соң? — диде Сәгъди бала йөзендә ниндидер таныш чалымнар күреп.

— Наилә булсын,— диде бала.

— Бик матур исем, әйдә Наилә кушыйк,— диде Сәгъди һәм бала белән чыршы янына китте.

Зөлфәт Дианага табын әзерләшеп йөрде. Инде барысы да әзер булгач, Диана аларны табынга чакырды. Язилә башта әбисенең тез өстенә менеп кунаклаган иде, ләкин әбисенең уңайсызланып, борсаланып утыруын тоеп, аннан төште дә Зөлфәт абыйсы алдына менеп утырды.

— Зөлфәт абыйсы, узындырма әле син ул хәтле бу кычыткан чыпчыгын, хәзер тезеңә, аннан башыңа менәм дия башлый ул, ирәюе ашып житте,— диде Диана. Ул, алъяпкычын салып, җемелдәп торган ука җеп белән тукылган карасу төстәге затлы, матур күлмәк киеп алган, шуңамы, йөзе бераз кырыслана, моңсулана төшкән кебек иде.

— Ә мин Зөлпәт абыйның башына менмим дә, әнием, җилкәсенә атланам. На-а, китәбез аннары,— диде бала, ике кулы белән Зөлфәтнең муеныннан кочаклап.

Ул арада Диана Сәгъдигә табынны алып баруны тапшырды. Сәгъди, шампан шешәсен ачып, бокалларга күбекләнеп-күпереп торган ширбәт салып чыкты, кечкенә рюмкаларга коньяк койды. Һәм барысына да күз йөртеп алды да:

— Ягез, дуслар, Яңа ел белән! Әнә Мәскәү уникене суга, Яңа ел, яңа бәхетләр белән! Дөньялар имин булсын, барча халык тату яшәсен. Һәммәгезгә бәхет алып килсен Яңа ел! — дип тост әйтте.

— Сезгә дә бәхет алып килсен Яңа ел, Сәгъди абый! — диде Диана.

Сәгъди, аяк өсте басып, барысы белән дә чәкәшеп чыкты, бокаллар чынлап куйды. Сара да басмак иткән иде, Диана аңа күтәрелергә рөхсәт итмәде, Сәгъди иң соңыннан аның белән чәкәште. Сараның күләгәдә үскән гөмбә кебек саргылт йөзенә алсулык йөгерде һәм бит очлары кызарып китте.

Керфек астыннан гына моны күзәтеп, күреп торган Диана, теләсәтеләмәсә дә, алдында бала утырган Зөлфәткә карады. Күзгә-күз ка-

рашып алуга, ул егет иреннәрендә елмаю хасил булуын күрде. Күрде һәм күңеленә тагын нииндидер шом иңде. «Нигә тартылам мин аңа? Нишләвем бу!» — дип куркуга калды ул.

Нәкъ менә үз-үзенә шулай диюендә кычкырып әйтергә түгел, уйларга да курыккан сәбәп ята иде.

Кичәге мәхшәрдән соң аның күңеле һаман исә тынычланып җитми, юк-барга чарпалып китәргә генә тора.

Кичәгенәк Вәли әнисен үзе белән алып китәргә теләп тә, Сараның риза булмавы, аны тегеләрнең икәүләп үгетләүләре, кыланчык, чытлыкай яшь хатынның Дианага әрсез һәм төксе төстә күз төшергәләп алуы Диананы гел акылдан шашарлык халәткә җиткергән иде.

Яңа елга табын хәзерләве дә Зөлфәт дәртенә генә ияргүеннән һәм тыштан елмая-көлә табында утыруы да эчке халәтен биредәгеләргә белдерергә теләмәвеннән генә иде.

Ләкин Яңа елга санаулы минутлар калгач һәм Сәгъди дулкынлана-дулкынлана табындагыларны Яңа ел белән котлап тост әйткәч, күңеле бераз йомшара төште. Моңа Зөлфәтнең кыланышы да ниндидер этәргеч булды.

Егет аны үзе дә Яңа ел белән тәбрикләде һәм мәгънәле итеп, һич тә моңа кадәр карамагандай текәлеп, күз төшереп алды. Әнә шулай, инде янында күрергә күңеле гадәтләнеп барган егетнең үзенә елмаеп куюы, әйләнгән саен чәкәшергә рюмка сузып торуы, эчеп алган бер рюмка коньяктан соң Сәгъди белән Сараның авызны авызга терәп дигәндәй сөйләшеп китүләре, күрәсең, үз тәэсирен итте, Диана: «Ичмасам, Яңа елда гына онытылып торсын әле бу Вәли!» — дип тагын бер рюмка коньяк эчеп җибәрде, ә сәгать уникене сукканда аңа янә бер бокал шампан ширбәте өстәлде.

«Шушындый ярсулы вакытта янында син якын иткән, үз иткән кешең була икән, моңа битараф калып буламы? Нигә кирәк, кемгә кирәк минем кайгым?» — дип уйлады Диана.

Зөлфәт аңа чәнечкегә элеп тозлы гөмбә, бер телем лимон сузып тора. Менә нәкъ шунда инде ул егетне беренче тапкыр күргәндәй булды. Диана күрде, Диана сизде: Зөлфәт аңа хөрмәт һәм ихтирам йөзеннән генә күзләрен елтыратып карамый. Ул аңа элек тә хөрмәт йөзеннән генә карамаган. Егет, мөгаен, аны сөя. Әйе, әйе, Диана бик яхшы күрә. Егетнең күзләренә текәлеп карамыйча да тоя: ул аны күз карашы белән назлый, күз карашы белән сөя-ярата.

Егет Диана өстендәге карасу нәфис күлмәккә, аның күпереп торган чәчләренә, чак кына чөенке борынына, аксыл йөзенә сокланып карый.

Әгәр дә мәгәр, хатын-кыз үз буй-сыныннан, зифалыгыннан, гүзәллегеннән үзе канәгать икән һәм ул бу минутта кемнеңдер назлы карашын үзендә тоя икән, бу хәл аңа бихисап ләззәт бирә, күңелендә урынлы-урынсыз горурлык хисе уята.

Ә бит Диана — хатын-кыз. Ул кайбер нәрсәләрне, әйтик, әнә шушындый ягымлы-назлы карашларны тансыклый башлады түгелме инде?

«Юк, юк, миңа ялгыз яшәве кыен. Бик кыен. Минем янымда мине яратучы, мине үз итүче, минем белән бу тормышта бергә атларга гәләүче кеше булырга тиеш... Зөлфәт мине чынлап торып яратса, мин аңа «өйләнер» идем. Ике дә уйламый «өйләнер» идем».

Һәм шунда ук Диана үз фикереннән үзе үк оялып китә.

«Ул миннән дүрт-биш яшькә кече түгелме соң? Килешеп бетәрме? Җитмәсә, балам бар. Юк, юк, мин бу җүләр хискә бирелмәскә тиеш. Мин аның бәхетен урларга теләмим. Яшьлеккә бер генә бәхет бирелә. Ә ул аны татып та карамагандыр әле?»

Шулай дип уйлап утырса да, инде күнеле бер талпынып, җилпенеп алгач, Диана үз дәрт-хисен үзе тыя алудан гаҗиз калды.

Яңа ел туганда ул башта Сараны барып үпте, аннары, ояла-тартына булса да, Сәгъдине, тик шуннан соң гына аның үбүен зарыгып көтеп торган Зөлфәт янына килде. Һәм гаҗәп бу хәлдә ул Сәгъдине үпкәндәге кебек һичнинди оялу да, тартыну да тоймады...

Бераздан музыка да табылды, яңадан-яңа пластинкалар уйнатылды. Зөлфәт Диананы биергә чакырды.

Егет белән биегәндә Диана аның муенны пешереп торган кайнар сулышын тойды. Шунда аның егеткә елышасы, көчсезләнеп аңа буйсынып каласы килеп китте.

Баланы йоклаткач, тагын табын янына җыелдылар. Сәгъди сузып кына «Тәфтиләү» көен башлады. Аннары Зөлфәт «Туган тел»не җырлады, сүзләрен белмәсә дә, Диана да кушылгандай итте.

Сара да дәртләнеп китте. Хәтта ниндидер бер кыска гына көйгә җырлап, торып биемәкче итте. Шунда Диана:

— Әни, болай булгач, ике-өч атнадан син дә биисең,— диде.

Сара бөтен йөзе белән көлә-елмая кызарынып:

— Бирсен ходай,— дип, нигәдер тагы елмаеп җибәрде.

Барысы да уңайсызланып тынып калдылар. Сәгъди, урыныннан кузгалып, кайтырга теләве турында әйтте.

— Соң инде, кайтыйм мин,— диде ул үзен бераз утырырга кыстый башлаган Дианага.

Сара кисәк кенә торып басты һәм күз яшен сөртә-сөртә, стенага тотына-тотына, Сәгъдине коридорга озатырга чыкты.

— Гаеплэп китмә, Сәгъди, күңелем чарпылырга гына тора шул хәзер минем...

— Хушыгыз, рәхмәт сезгә, тыныч йокы...

Зөлфәт аны киенеп озата барырга булды. Аларга ияреп, җилкәсенә пальтосын салып кына Диана да ишегалдына чыкты. Капка янына җиткәч, Сәгъди кинәт туктады да, Диананың кулыннан алып:

— Мин, аңа путевка табып, санаториягә җибәрергә ярдәм итәрмен,— диде.

— Гаеплэп китмәгез, Сәгъди абый...

— Гаеп итсәм, үзем чакырырмын,— диде Сәгъди.— Нинди гаеп ди ул. Рәхмәт сезгә... Я, хушыгыз, Диана Галимовна...

— Хушыгыз, Сәгъди абый. Тагын килегез... үз итеп килегез,— диде Диана һәм капка келәсен ачып маташкан Зөлфәткә карап: — Син анда озак йөрмә, кара аны, тиз кайт,— дип куйды.

Ярым шаярып, ярым чын әйтелгән бу сүз төбендә нинди мәгънә ятуына игътибар иткәч, өчесе дә көлешеп алдылар.

## Гәрәй Рәхим

# Көтмәгәндә

Көтмәгәндә генә киләләр дә
Җылы ләйсән тулы болытлар —
Сусап беткән чәчәк күзләренә
Тезеп калдыралар ал чыклар.

Сөрсеп барган чакта тып-тын күңел,
Сүнеп барган чакта калтырап —
Көтмәгәндә килә зур мәхәббәт,
Яшен яктысыдай ялтырап.

Көтмәгәндә давыл дулап ала,
Көтмәгәндә куба зилзилә.
Көтмәгәндә асты-өскә килеп,
Меңгә түнеп бетә зур илләр.

Көтмәгәндә Җирнең баш очында
Эленеп кала хәвеф кылычы.
Эшен ташлап шул чак бөтен дөнья
Дәррәү оран сала:
— Ты-ныч-лык!

Без гомергә күз дә сирпемәгән,
Кыргый як дип йөргән урында
Көтмәгәндә гап-гади бер халык
Җир язмышын ала кулына.

Көтмәгәндә зур ачышлар ясый
Легендалар имеш-мимеше.
Кешелеккә агу була башлый
Цивилизация җимеше.

Көтмәгәндә яңа Гитлер туа —
Куркып кала асыл зат ирләр.
Шунда кинәт дөнья мәйданына
Калкып чыга яшь-яшь шагыйрьләр.

Көтмәгәндә генә киләләр дә
Җылы ләйсән тулы болытлар —
Сусап беткән чәчәк күзләренә
Тезеп калдыралар ал чыклар.

●

Җир яңара, җир яшәрә,
Җирдә иске эзләр бетә.
Күпләр килә, күпләр китә —
Җир өр-яңа эзләр көтә.

Җирдә иске эзләр бетә,
Моңлы бер өн тирә-юньдә.
Гөрләвекләр юып утә
Эзләрнең иң тирәнен дә.

Җир яшәрә, җир яңара,
Онытыла күпме җаннар.
Бөеклекне раслар өчен
Кирәк икән яңа каннар.

Җир өр-яңа эзләр көтә.

## Учак янында

Без бүген дә менә өч яшь шофер
Ерак юлда арып туктадык.
Кайнар шулпа белән сыйланыйк дип
Дала уртасына ут салдык.

Очкыннары чәчрәп-чәчрәп китә,
Очып-очып төшә шулпага.
Кара төндә якты утрау булып
Дала уртасында ут яна.

Учак яна...
Коры усак яна,
Яна каен, яна имәннәр.
Искә төшә утта янмас өчен
Илен сатып башын игәннәр.

Ә күбәүләр янган! Дахауларда,
Шәп машина — төрмә мичендә.
Кеше янган күп сөйләгән өчен,
Янган эндәшмәгән өчен дә.

Яна кеше, зур-зур мәйданнарда
Бензин сибеп яна үзенә.
Ялгыз учак булып яна шулай
Тугры калып хаклык сүзенә.

Иминлеген саклап туган җирнең,
Яуда яна зур-зур халыклар.
Ил бурычын үтәп, кинәт Җиргә
Янып төшә космонавтлар.

Һәм кайгыдан яна ил йөрәге,
Дөрләп яна утсыз, төтенсез.
Илдәшләрем, тоям, шулар кебек
Янар идегез бит ил өчен сез!

Ә без менә тагын, өч яшь шофер
Ерак юлда арып туктадык.
Кайнар шулпа белән сыйланыйк дип
Дала уртасына ут салдык.

Очкыннары чәчрәп-чәчрәп китә
Очып-очып төшә шулпага.
Искә төшә денья, планета
Һәм еракта калган кыз бала.

•

Урта Азиядә туңып йөрим,
Шундый салкын быел март башы.
Һәм җылынып китәм, түбәтәйлештә
Очратам да берәр якташны.

Түбәтәйлеш күп монда. Димәк, шик юк;
Түбәтәйлеш бар җирдә — татар бар.
Бөтен илгә сибелеп ил түзиләр
Якташларым минем, татарлар.

Ә татар бар җирдә — хәтәр бар, дип
Әйтмәгәннәр, ахры, белмичә —
Хәтәр эшли татар, рәсемнәре
Кызыл почмак саен берничә.

Урта Азиядә туңып йөрдем,
Тиргәп йөрдем салкын март башын.
Тик җылытты мине рәсемнәрдән
Карап торган һәрбер якташым.

Ташкент — Алмалык.

•

*(Кайбер киңәшчеләргә)*

Сызланма дип, сыкранма дип
Өйрәттегез.
Сызланмыйм да, сыкранмыйм да —
Нишләттегез?!

Тавышланма, сагышланма
Дип әйттегез.
Дулау да юк, сагыш та юк —
Нишләттегез?!

Гел бер тонга, гел бер моңга
Сөйләттегез.
Көем дә юк, моңым да юк —
Нишләттегез?!

Бик узынма, бик зур булма
Дип һәр мәлдә,
Нишләттегез?! Бу дөньяда
Мин — бер кәрлә.

## Әни кирәк

Бишек тирбәтергә әни кирәк,
Яңа сүзләр өйрәтергә әни кирәк.
Кулына алып чәбәкләргә әни кирәк,
Усал малайларны әләкләргә әни кирәк.
Ятлар ятим димәсенгә әни кирәк,
Өйләнгәндә киңәшергә әни кирәк.
Дөнья артка типкәләсә дә әни кирәк,
Хатын сиңа үпкәләсә дә әни кирәк.

Суыткычта ит бетсә дә әни кирәк,
Йөрәгендә ут бетсә дә әни кирәк.
Ә әнигәниләр кирәк —
Уйлыйбыз без моны сирәк.

●

Бер сихерсез сихерләдең,
Әйтерсең әфсун өрдең —
Гап-гади бер кызый инде,
Сөйдергечсез сөйдердең.

Сырхаулаттың авырусыз,
Бер дарусыз терелттең.
Бер бизәксез тормышыма
Алтын суы йөгерттең.

Җаныма син бер шырпысыз
Дөрләтеп ут кабыздың —
Үзең бары болын буйлап
Тын гына җырлап уздың.

Бер сихерсез сихерләдең,
Әйтмәдең бер ырым да.
Тып-тын кызый, давыл кебек
Килеп кердең җырыма.

●

Дөньям тәмам ямьсезләнеп беткәч
Син киләсең миңа елмаеп.
Шунда гына тоям, бу дөньяда
Мине елмайтырлык көч барын.
Дөньям кинәт матурланып киткәч,
Син киләсең миңа моңаеп.
Шунда гына тоям, бу дөньяда
Адәм күтәралмас моң барын.

Әнә шулай, миңа үзгәрешләр,
Яңарышлар алып киләсең.
Тик битараф чакта да бу дөньям,
Юк, битараф булып килмә син.

## Таралыгыз, томаннар

Юлларыма ак томаннар
Ак пәрдәләр корганнар.
Сөйгәнемне эзләп киләм,
Таралыгыз, томаннар!

Бүген кич тә ак томаннар
Юлны каплап куйганнар.
Ул да мине эзләгәндер,
Таралыгыз, томаннар!

Без бит җиргә мәңге бергә
Булу өчен туганнар.
Мәхәббәткә юл бирегез,
Таралыгыз, томаннар!

1972

## Резеда Вәлиева

### Толымнарың...

*Апам Рәүзиягә.*

Хәтеремдә, мин төшемдә сине
Югалттым дип куркып уяндым.
Күзем ачсам,
тып-тын якты иртә,
Син янымда.
Шундый куандым.
Баскансың да көзге каршысына,
Озын толымнарың сүткәнсең.
Тезләреңә төшкән дулкыннардан
Нәкъ су кызы булып киткәнсең.
Ә күзләрең шундый-шундый уйчан,
Әллә ничек моңсу карыйсың.
Сөеп-назлап ефәк чәчләреңне
Тарыйсың да һаман тарыйсың...
Мин сокланып сиңа карап ятам,
Куанычым сыймый эчемә,
Һәм кулыңда кинәт
кайчы күреп,
Сикереп торам...
Әйе, исемдә,
Илгә килгән бәла
минем өчен
Синең чәчләреңнән башланды:
Күз алдымда
куе көлтә кебек
Толымнарың
кисеп ташладың...
— Апам!
— Мин фронтка, сеңелем...
Әйтерсең лә җир убылды кинәт,
Утлар сирпеп, туплар күкрәде.
Әйтерсең лә
сугыш өйгә керде —
Сабый күңелем шундый тетрәде!
Аңладыңмы йөрәк хисләремне,
Битләремнән шашып үптең син:
— Я, елама, мин бит үзем теләп...—
Яшьләремне минем сөрттең син.

Тын бакчада аннан
таңга кадәр
Тальян гармун түкте моңнарын,
Аһ, мин беләм, ул кич
тальян синең
Толымнарың сагынып елады...
Озатырга диеп,
таң атуга
Бөтен авыл килде җыелып.
Соңгы сүзләреңне әйткән чакта
Көчкә генә тордым тыелып:
— ...Җиңү өчен!
Шул җиңүгә илткән ут эчендә
Эзләреңне ничә җуйдык без.
Ничә тапкыр
салкын толымнарың
Кайнар яшьләр белән юдык без...
Әле дә булса,
сөйләсәләр әгәр
Сагышларын сугыш елының,
Күз алдыма килә
көлтә кебек
Киселеп төшкән ике толымың.

## Әхәт Гаффаров

# ИКЕ ХИКӘЯ

## ӘҖӘТ



Мәрьям әби төн буе йөрәге сызланып, әллә нинди кеше чырайлы козгын белән саташып чыкты. Таланып беткән козгын, каралтыдан каралтыга, баганадан баганага, тупылдан тупылга күчә-күчә, корымлы морҗага килеп кунаклады да, кан сауган тонык күзләре белән ялварып, ишек алдында тавык-чебеш ашатып йөргән карчыктан ашарга сорады. Кара ипи кисәге ыргыткач, алмады, агы кирәк, диде. Аннары тавыш-тынсыз гына күтәрелде дә төпсез караңгылыкка китеп югалды. Иләмсез зур козгынның сызгырып көлүе генә ишетелеп калган кебек булды.

Мәрьям әби исенә килеп уянганда өй эченә таң шәүләсе төшкән иде инде. Ул беравык айный алмый ятты. Яңа гына күргәннәренең өн түгеллегенә ышангач, кысылган йөрәге киңәеп, җиңеләеп китте. Берәздән ул торып, ашыкмый гына киенде дә, яулык өстеннән башына җылы шәлен бөркәнеп, тышка чыкты.

Иртән җылы яңгыр явып үткән икән. Ярылырга җитешкән сусыл бөреле каеннар яшәреп, сафланып калганнар. Болдырга чыгып баскач та, Мәрьям әби әлеге төше хакында уйланды: «Ни булыр икән соң бу, рәхмәт төшкере? Әллә ходай тәгалә алдында берәр гаебем, гөнаһым бармы?» Үзалдына шулай сөйләнә-сөйләнә, ул имче Галимәләр урамына таба атлады.

Урам буп-буш иде. Бөтен дөнья, нидер көткән төсле, тирән тынлыкка чумган. Бары тик тау астында каралып күренгән тар инеш кенә тигез шаулап үзен сиздереп тора. Карчык аны иртәнге томан эчендә йөзеп барган кара еланга охшатты. Мондый охшатудан күңеле чирканып, йөрәге тагын сулкылдап куйды.

Имче Галимә төшне бик тиз юрады:

— Түлисе әҗәтең бар, ахирәт,— диде.

Карчык озак баш ватты. Нинди әҗәт булыр икән ул? Бу арада һичкемгә йомышы төшмәгән иде, югыйсә. Киресенчә, һинд чәе, мәтрүшкә, миләш-балан, вак-төяк йомыш юллап күрше-күлән кайчак аның үзенә керә. Юк, якын арада карчыкның кешегә бурычка

кергәне булмады бугай. Шулай да күңел төбен нидер хафалап, тынгы бирми борчый да борчый.

Өенә кайткач, Мәрьям әби ике өрек җимеше салып чәй эчте. Эчеп туйгач, шик-борчуларын әзрәк булса да басарга теләп, капка төбенә чыгып басты.

Дөньяда яз исе аңкый. Йомшак һавалы яз иртәсе шул кадәр саф, анда-санда ишетелгәләгән авазлар шул кадәр аһәңле иде, карчыкның кайчандыр коңгырт-кара булган, хәзер инде төссезләнеп калган күзләреннән ике тамчы яшь, җыерчыклы битендә юеш эз калдырып, түбән тәгәрәде.

Тыкрык борылышыннан зифа буйлы, битләре алсуланып торган бер кыз килеп чыкты.

— Исәнме, әби!

— Аллага шөкер, кызым! Үзең саумы?

— Сау булмаган кая, әби, җир җимертеп йөрибез!

Кыз тип-тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды да калын толымнарын кояш нурларында уйната-елкылдата китеп барды.

«Җир җимертеп йөрибез...» Карчык, күзләрен кыса төшеп, кыз артыннан карап калды. Мәрьям әбинең дә күпләрне иләсләндереп, күпләрне көнләштереп җир җимертеп йөргән яшь чаклары бар иде!.. Сагындыра шул узган гомеркәйләр, әй, сагындыра!.. Хәзер менә теге каз өмәләренә, шаплы сабан туйларына, дәртләнеп печәнгә төшүләргә, Садретдине белән болын кочагында таң каршылаган чакларга, кышкы аулак өйләрнең караңгы почмакларына кире кайтсаң икән?! Юк шул, юк, гомер су кебек, гел түбәнгә таба ага...

Мәрьям әби күргән төшен, Галимә ахирәтенең иртәнге сүзләрен яңадан исенә төшерде. Һәм аның уйлары, үзе дә сизмәстән, сугышта хәбәрсез югалган улы Нәкыйпкә барып тоташты.

Сугышның беренче язында яраланып, Нәкыйп авылга кайтып торган иде. Беркавым дәваланып сихәтләнгәч, такталары гаралган өй түбәсен кадаклап бетергәнен дә көтмәстән:

— Китәм, әнкәй, без өйдә ятсак, фашист козгынны кем куар? — дигән иде.

Мәрьям әби ары сугылып, бире кагылып аһ орса да, җилпучында сыңар уч та он калмаган йортта сугышчы улына юл күчтәнәче хәстәрли алмады. Күрше Гөләндәмнән әҗәткә бер бөтен кара ипи алып чыкты. Нәкыйп ипине кадерләп кисеп, яртысын капчыгына салды, калган яртысын өстәлгә куйды. «Гөләндәмгә әйт, әнкәй, үз бурычымны кайткач үзем түләрмен, дип әйтте, диген. Ә иртәгә председательгә бар. Өч пот арыш вәгъдә иткән иде», — диде.

Нәкыйп кайтмады... Ә әҗәт тора да тора бирде. Мәрьям карчык, исендә тотса да, баштагы елларда ипине кертмәгән иде. «Ашыйсы ризыгы бетмәгән булса, Нәкыйбем кайтыр, үзе түләр», — дип өметләнде. Күрәсең, онытылган... Галимә әйткән әҗәт шул булгандыр инде. Тәкъдир козгыны да шуны сорамады микән?

«Тукта әле, күәсемә баш ясап ипи салыйм да шул әҗәтне кертим әле Гөләндәмгә. Үзе оныткандыр инде. Биргән онытыла, алган онытылмый ич. Кайтыр тәкъдирдә Нәкыйбемә эш кими торыр, ичмасам».

Карчык, шундый карарга килеп, кече капкадан эчкә атлады.

Кояшның туры нурлары бөреләрдә елтырашкан яңгыр тамчыларын минут эчендә кипшетеп алды. Тәрәзә каршында моңаеп утырган миләш ботагына чуар күбәләк килеп кунды. Әйтерсең лә кемнеңдер тылсымлы кулы табигать белән шаярып миләш өлгертте...

Икенче көнне фермага ашыгучы кыз-кыркын башын җиргә иеп читән буендагы каен бүрәнәдә утырган Мәрьям әбигә узышлый көләшаяра сүз катты:

— Саумы, әбекәй!

Җавап булмагач, берсе, якын ук килеп, кулы белән аның иңбашына төшкән йомшак шәленә кагылды.

— Галәмәт, йокыга киткән ул, кызлар!

— Егетләр белән озаграк утыргандыр...

— Кунарга да кереп тормаган...

Карчык, чая кызның тагын бер орынуыннан уянып киткәндәй, авырмыйм дигән төсле, сак кына янтаеп, чалкан авып төште. Кыз, корт чаккандай, үрсәләнеп, читкә сикерде.

— Әни-и-и!..

— Үлгән ич ул, кызлар!

— Үлгән?! Кит әле! Бүрәнәгә утырып үләләрмени?..

— Яз көне...

Халык җыелды. Карчык, яшь баланы кочкан кебек, сөякчел бармаклары белән күкрәгенә кызарып пешкән ак бодай ипие кыскан. Мәрьям әби аны кая, кемгә илтергә җыенган — илтифат итүче, кызыксынучы булмады. Барысы да сәерсенү катыш курку һәм кызгану белән карчыкның җыерчыклы йөзенә, кысылган иреннәренә, төссезләнгән тоныйк күзләренә карадылар. Ә бу күзләр төбәлгән зәңгәр күк гөмбәзен туган як болыннарына ашкынучы бер көтү кыр казының сагынулы сәлам авазлары яңгырата иде.

# СОҢГЫ СҮЗ



Казыгыз! Тизрәк! — диде офицер, эт өргән кебек итеп, һәм аларның аяк астына шапылдап ике көрәк килеп төште.

Мәһабәт гәүдәле, һәр нәрсәгә боз салкынлыгы белән карарга күнеккән зәңгәр күзле чибәр немец офицеры баскан урынында сүлпән генә борылды да өйрәтелгән симез этләрдәй һәр хәрәкәтенә буйсынырга хәзер торган солдатларына үзенчә нидер сөйләнеп куйды. Тегеләре ясалма бер ялагайлык белән көлешеп алдылар һәм автоматларын әле чыклары да кибеп җитмәгән ак ромашкалар арасына куеп, фляжкаларын ачтылар.

Рахман әсәсчыларның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды. Ул чәчәкләр өстендә тәртипсез яткан автоматларны кояш җылысына шуышып чыккан кара еланнарга охшатты. Күңелендә туган бу тойгысы шул кадәр көчле һәм яшен чаткысыдай кискен иде — ул бер мизгелгә генә кайчандыр авыл малайлары белән урманга җиләккә баруын, юл кырыендагы черек төп өстендә бөгәрләнеп яткан нечкә кара еланны кемдер төшереп калдырган каеш чыбыркы дип белеп әләктереп алуын һәм «камчы»ның аерылы нәзек телен чыгарып сызгыруын ишеткәч, корт чаккандай кабаланып, кире йөгерүен күз алдына китерде һәм еланның юеш салкынлыгын үз тәнендә тойгандай булды. Шул чактагы кебек, чирканудан тәне чымырдап китте.

«Үлем белән күзгә-күз очрашу шушы микәнни?»

Юк, үлем аны куркытмый иде. Киресенчә, гитлерчылар бүген иртән салкын таш подвалдан чыгарып тузанлы кыр юлы буйлап алып киткәч, ул җиңел сулап куйды. «Ниһаять, газаплардан коты-

лам» дип шатланды ул. Ахмак немецлар!.. Рахманның үлемне ике атна буе көткәнен бәләләр микән алар?

Рахман беркайчан да үлемне шулай җиңел каршылармын дип уйламый иде. Аны бердәнбер куркыткан нәрсә — башкарасы эшне үтәмичә юкка чыгу, бердәнбер кызгандырган нәрсә — Җир шарының инде ансыз әйләнәчәген, тормышның инде аңардан башка дәвам итәчәген, табигатьнең аңардан башка җырлаячагын аңлау тойгысы иде. Ул үз гомерендә күп явызлыкка каршы чыкты, димәк, ул башкарасы эшләрнең көче килгән кадәресен түгәрәкли, тәгәлли алган. Чын ир өчен шуннан да газиз, рәхәт кичереш бармы? Ә тормыш... җырлый бирсен!! Аның үлеме галәм чиксезлеге алдында тузан бөртегедәй кечкенә булып, тормыш хаклыгына һәм киләчәк агышына зыян китерер дәрәҗәдәге көч түгел икән, бу фашист үрмәкүчләренең корган җәтмәләренә эләккән корбаннарына әллә ни кырган шикелле ахмакларча үҗәтләнеп карап торулары көлке бер комедия генә ич!.. Шуңа күрә аның ромашка аклыгына төренгән саф, иркен аланда, башын горур төстә артка чөйгән килеш, эсэсчылардан һәм үлемнән көләсе, фашистларны, җирдә аунаган автоматларны кара еланны изгәндәй аяусыз таптыйсы, сытасы килде. Тик бу мөмкин булмастай эш иде. Кычкырып көләсе урында аның иреннәрен чак кыйшайтып елмаерга гына хәленнән килде.

— Алар казымыйлар, обер-лейтенант әфәнде!..

Офицер, гаҗәпләнгән төсле, әсирләргә әйләнеп карады. Озын аяклары белән дөп-дөп атлап килде дә, кулларын артка куеп, саф рус телендә:

— Нәрсә, үзегезгә кабер казырга теләмисезмени? Снаряд чокырында уңай булмас бит, ә? Казыгыз! — диде һәм итеге белән көрәкләрне аларга табарак этеп җибәрде.

Юк, бу аның партизаннар өчен ләхет кайгыртуы түгел иде. Күрәсең, кешенең үз-үзенә кабер казуын карап тору аңа ләззәт бирә иде. Әйе, бу фашист үлем алдыннан совет разведчикларының калтырануларын күрергә тели. Ә Рахманга хәзер дошман алдында кабер казу да батырлыкка таба бер адым атлау булыр кебек тоела. Снаряд чокырында эт үләксәсе шикелле аунаганчы шушы имән төбендә үзең хәстәрләгән җир куенына күмелү,- һәрхәлдә, мәслихәтрәктер. Рахман шуны уйлап кулына көрәк алды да күршесенә эндәште:

— Әйдә, Вася, керешик булмаса... Мин үзебезчә, кыйблага карап ятар идем.

— Барыбер түгелмени, туган?..

Разведчиклар икесе ике баштан көрәкләрен коры туфракка батырдылар.

Күк йөзе зәп-зәңгәр иде. Баш очыннан пырылдап кошлар очып үтә. Кайдадыр сандугач сайрый. Туп көпшәсен җиргә кадап тынып калган тәреле танк өстенә ике козгын кунаклаган да нәрсәдер көтәләр.

— Безне озаталар, туган,— диде Вася, иптәшенең уйларын төшенгәндәй.

Рахман үзенә әллә кайдан көч кергән кебек хис итте. Дошманнары алдында сынатмаска теләпме, аның эшкә күнеккән куллары туфракны каерып-каерып ала. Әйтерсең лә алар кабер түгел, бәлки бәрәңге базы казыйлар иде.

— Кара әле, туган,— диде Вася шыпырт кына.

— Кычкырып сөйләш, Вася! Урланган алтын казымыйбыз ич...

Рахманның урманны яңгыраткан авазына гитлерчылар борылып карады. Офицер авызын күтәреп шаркылдап көлә иде.

— Рус дуңгызлары тирес актарамы?

— Руслар кабер казый, фашист! — диде Рахман, тешләрен кысып. Көчәнүдән анык яңагындагы тирән ярасы ачылган һәм аннан кан саркып муенына, күкрәгенә агып төшкән иде.

— Шым бул, туган. Монда кара,— диде Вася һәм аяк астына ымлады. Туфрак астыннан яртылаш калкып, шартламый калган мина күренеп тора иде.

— Әҗәл аяк астында йөри,— диде Вася,— фашистлар әҗәле.

Разведчиклар, карашып, бер мәлгә туктап калдылар. Күзләренең ни әйткәнен алар сүзсез дә аңлыйлар иде.

— Казымыйлар, обер-лейтенант әфәнде...

— Хәл җыябыз,— дияргә ашыкты Вася.

— Ә бәлки, калтырый башлагансыздыр? — диде офицер.— Партизаннарның кайдалыгын әйтергә җыенмагансыздыр ич? Җыенсагыз, рәхим итегез, ашыктырмыйбыз. Уйлашыгыз. Әйтсәгез, оберст әфәнде сезгә җаныгызны саклап калырга вәгъдә итте. Әйтмәсәгез — үлем!..

Үлем... Ул разведчикларның аяк астында күгәрә башлаган мина кыяфәтендә ята иде. Рахманны әнә шул үлемнең үз кулларында булуы шатландырып җибәрде. Үлемеңне сайлау ирке давыллы көндә кояш чыгу түгелмени? Ач бүреләр ботарлаганчы упкынга ташлануың артыграк ич!

— Ну, туган, хуш...

— Бәхил бул, Вася...

Алар астан гына кулларын кысыштылар. Рахман мина янына басты. Хәзер аңа бер орыну җитә иде.

— Офицер әфәнде!..

— Тагын нәрсә?

— Без монда уйлашып тордык та...

— Әйтергә булдыгыз?

— Әйе, офицер әфәнде. Бер сүзебез бар.

— Гут, гут,— диде эсэсчы һәм аларга таба атлады.— Миңа әйтәсезме, әллә кире оберст әфәнде янына кайтыйкмы?

— Сиңа...

Ул солдатларны чакырып кул изәде. Алары да казыла башлаган чокыр тирәсенә килделәр.

— Я, партизаннар кайда, лагерь кайда?..

— Монда, этләр, сезнең алда...

Ромашкалы аланны каты гөрселдәү авазы яңгыратты. Ул кайтаваз булып урман өстеннән шаулап узды да ерак тауларга җәелеп әкренләп сүнә, сүрелә барды...

## А. Твардовский

### Ленин һәм мич чыгаручы

Кем белмәс аны Горкида:
Картлар җыенга дәшә,
Тын кала бала-чагалар,
Бабай барса янәшә.

Сырхау иде, һәр көн саен
Чыкты һава суларга,
Кемне курсә, чын куңелдән
Сәлам бирде шуларга.

Ерактан ук таныдылар,
Җәяулэп килсә әгәр,
Бик гаҗәп хәлгә юлыкты,
Әкәмәт хәлгә, мәгәр.

Бабай — мич остасы — карый,
Күрә: таптап болынны,
Таныш түгел кеше килә,
Санламый да юлыңны.

Билгә таянып дәште карт,
Куанды ул, сөенде:
Иске чорда шулай басып
Тора алыр идеңме?

Бакчаңда суган түтәлең,
Бер атлам җир урамда —
Шуннан гайре ниең булсын
Элеккечә торганда?..

— Әй, син, кем йөри болында,
Кем таптый покосларны? —
Тетте тегене мичче карт,
Турыдан ярып салды.

Кызып китте. Теге кеше
Тукталып калды, көлде,
Кепкасын салды: — Бабакай,
Шәп сүгенәсең! — диде.

Тагын бераз басып торды,
Янәсе, кичер, бабай,
Бүтән юл белән китәрмен,
Болын таптамам алай.

Андый-мондый бабай түгел,
Мичченең яна йөрәк:
— Исемең әйтеп сөйләш! — ди,
Шомландырырга теләп.

Уртача буйлы пеләш ир
Авыр сулап эндәште,
Шаккатты бабай, әйтте ир:
— Мин... Ленин дигән кеше...

Көннәр үтте, көзләр җитте,
Көзләр үтте — алмалы!
Мичче карт шул вакыйганы
Һич оныта алмады.

Мичченең капка төбенә
Яңа кар төшкән чакта
Ике хәрби тукталдылар,
Икесе — ике атта.

Гаилә купты, тәрәзгә
Сыенды алар, сеңде.
Кунаклар:
— Сез кем? — диделәр.
Әйтте хуҗа:
— Мин..— диде.

— Җыеныгыз! —
Бабай тапмый
Тунның ни тышын, эчен.
Карчык:
— Китәсең,— ди,— сүзләрең,
Шул тупаслыгың өчен...

Елады карчык, башкаен
Салды тун изүенә.
— Эш коралын,— диде хәрби,—
Алырга үзең белән.

Чыжлый чана, туган йортлар
Калды карлы үрендә.
Борылыш, Горки тирәсе,
Ак йорт — бакча түрендә.

Буш йорт, беркем дә юк, ахры,
Юк песи баласы да.
Салкын, сөрем. Гүя хәлләр
Әвендә бара сыман.

Кунак бүлмәсенә бабай
Утырды гына кереп —
Берәү килә! Буп-буш йортка
Кинәт җан керде кебек.

Шул, әйе, нәкъ теге кеше.
Танып алды миччене,
Сәлам бирде һәм:— Бабакай,
Шәп сүгенәсең! — диде.

Гүя берни булмагандай,
Сүз озайтмады бүтән:
— Мич суырмый, суык,— диде,—
Ярдәм итмәссең микән?

Тамак кырып куйды оста,
Кызарды, ул оялды:
— Ничек ярдәм итмәскә ди?
Булдырабыз без аны!

Иңнән селтәп атты тунын,
Коралын алды: Я-ле...
Голланд мичен, доктор сыман,
Шакып чыкты тирәли.

Белеп алды хикмәтен,
Эшне бик кызу тотты,
Әзер булды измәсе,
Суы да кайнап чыкты.

Ком, кирпеч тә табылды,
Ярыш сыман кызды эш:
Монда — мичче, ян бүлмәдә
Язуын яза Ильич.

Мичченең кулларында
Ут уйнап тора,
Бөтен маһирлыгын ул
Күрсәтмәк була.
Исән-сау гына бул син,
Кадерле Ильич,
Нинди утын яксаң да
Дөрләп торыр мич.
Язуыңны җылыда
Син язсаң иде,
Суырыр мич, морҗада
Җырлатып җилне.

Начар суырса, җәһәт
Җайларбыз аны,
Сөекле иптәшебез,
Илебез даны...

Уйлана шулай, тезә
Тигез итеп кирпечне,
Җыр җырлаган күк эшли
Яратып эшли мичче.

Мич төзәлде. Дөрләп утын
Кабынды кичке якта.
Шулчак Ленин чыкты бирө
һәм әйтте шушы хакта —

Мичче андый кадерле сүз
Юк, ишетмәгән иде,
Әйтте: — Бабакай, син бик шәп
Эшли беләсең,— диде.

Нидер булды, әллә инде
Тузан керде күзләргә,
Сөртеп тә булмый, куллары
Буялганнар измәгә.

Тибрәнде теле, чыкмады
Җавапка әйтер сүзе,
Күзләре яшьтән арынгач
Караса — ул берүзе...

Чәй янында утырдылар,
Җай гына гәпләштеләр,
Эш хакында, мич хакында
Иркенләп сөйләштеләр.

Инде бераз тынычлангач,
Чәй җылыткач тәннәрне,
Бабай курка-курка гына
Үзгәртте әңгәмәне.

Әйтмичә булмый, янәсе,
Әйтим ризык янында,
Кичерә күр, берүк, Ильич,
Хаталандым болында.

Хаталык миндә, мең гафу...
Ленин сүзне бүлдерде,
Елмайды: — Бакчы, мин күптән
Онытканидем,— диде.

Тышта суык, чыкты оста,
Борылып бакты артка.
Күккә ургып менә төтен,
Мич тарта, җырлап тарта.

Түбәң күккә тиярлек шул.—
Бабай бик кыска тотты:
Иске бакча, ак кыр аша
Авылына сыпыртты...

Карчыгы көтә — йокысыз:
— Саумы син? — ди.— Ни булды?
— Ленин белән,— ди карт,— чәйләп
Шактый ук утырылды.

*

## Н. Стрижевская

●

Үткәннәргә тимә. Газаплама.
Шундый авыр синең бу караш.
Минеке дә түгел, синеке дә —
Үткәннәр, аһ, нинди битараф!

Йолкый алмый җаннан үткәннәрне
Җәһәннәм дә, җен дә, алла да.
Кирәк түгел — авыр таш күк алар,
Үткәннәрне миннән даулама.

Ни даулыйсың, зинһар, уйлап кара.
Язмышыма сеңгән ул минем.
Мәңге җанда калыр, үткәнемә
Теше үтмәс хәтта үлемнең.

Тынычлыкта калдыр үткәннәрне,
Үткәннәргә җирдә юк хаким.
Яхшы, яманмы ул — мөһим түгел,
Тимә ләкин, тимә, юк хакың...

●

Иреннәр сүзгә күнекте,
Бигрәк җиңел бу сүзләр,
Күнеккән кул юл арты юл —
Кабергәчә сүз тезәр.

Тик могҗиза гына мәрхүм,
Сокланырга юк вакыт:
Таныш сүзләр — тәндә инә,
Әрнетә кыймылдашып.

*Русчадан Зөлфәт тәрҗемәләре.*

## Шөһрәт,

үзбәк шагыйре

### Кеше һәм туфрак

Кешене туфрактан яралган дигәннәр...
Йөрәк соң нәрсәдән яралган?
Туфракта шундый хис, шундый дәрт буламы? —
Аптырыйм, аңлатып бир алдан.

Минемчә, йөрәкне башка бер галәмнән
Китереп туфракка күмгәннәр.
Һәм аны туфрактан яралган дигәннәр.
Әгәр дә нәкъ шулай булмаса, янарга
Кайдан соң ут килсен аңарга?!

Туфракка да хаят бирүчә бит кеше!
Бу йөрәк, бу кайнар кичерешләр
Һәм кеше булмаса — туфрак та бер җансыз
Төшенчә, ялгызы ул нишләр?

Әй, Кеше, хәятның башы бит син үзең,
Туфрак та кадерле син барда.
Җирдә зур, мәңгелек ихтирам кешегә.
Икегез — пар кояш җиһанда.

Мин сине кешечә олылыйм, кадерлем,
Әй, изге, рәхимле туфрагым!
Балкысын куеныңда югалмас сәгадәт,
Хәсрәттән сулмасын яфрагың.

## Бу—минем сукмагым

Бу — минем сукмагым, аңа мин эз салдым,
Иң якты уйларым, хисләрем бар шунда,
Рухланып үткәндә шушы тар сукмактан,
Кояшым нур чәчеп елмая каршымда.

Шушыннан юл алам мин иркен урамга,
Ышанам, бер көнне сукмагым юл булыр.
Айлары балкыган шатлыклы кичләрдә
Кешеләр кулга-кул тотынып омтылыр.

Хәзергә бу — сукмак. Мин анда ялгызым
Дәртләнеп, рухланып барамын эземнән,
Киләчәк көннәргә ышанып карыймын,
Офыклар зәңгәре югалмый күземнән.

Без үткән бүгенге юлны да кайчандыр,
Башлангыч эз салып, бер кеше ачкандыр.

## Галәм бик иске ул

Бу юллардан күпләр үткән инде...
Ә күпмеләр тагын үтәчәк!
Гел яңарып торыр иске галәм,
Һәм дәверләр килеп китәчәк.

Бу юллардан кыю үткән генә
Ирешә алган өмет, хыялга.
Батыр аучы юлбарыслар аткан,
Ә куркаклар йөргән куянга.

Юлбарыска ташлан! Аның белән
Сугышып үлде, дигән калыр дан!
Күпме хәлләр күргән бу җиһанда
Куркаклардан бер эз калмаган.

●

Бер секунд гөлт иткән атом зәррәсе
Галәмне яндырып көл итә ала.
Сабыйның шәфкатьле, көләч әнкәсе,
Елмаеп, җиһанны гөл итә ала.

Шул көләч елмаю сүнмәсә — ил тыныч.
Тик аны саклаучы без булу кирәк!
Сафларда нык торып, үзара дус булсак,
Ут капмас дөньяга,
Көл булмас йөрәк!

Үзбәкчәдән **Мостафа Ногман** тәрҗемәләре.

## Василе Александри

### Родика

Алсу йөзле бер кыз ашыгып кайта,
Чүлмәгенә салкын су алып...
Яшь егетләр чыга нәкъ шул чакта
Каршысына аның елмаеп.

Юлга җәйгән чыклы итәген җәй...
Берсе дәшә кызны туктатып:
«Тулы булсын бәхетең чүлмәгеңдәй,
Теләгеңә иреш һәрвакыт!

Матурлыкта юк, Родика, тиңең,
Яз чәчәкләр сипсен юлыңа.
Учак сыман җылы булсын өең,
Елмайсын яшь сабый кулыңда!»

Кыз башына сибеп алтын бодай,
Су эчәргә егет иелә...
Ә Родика көлеп оча коштай,
Толымыннан бодай сибелә!

## Михаил Еминеску

### Ник син, урман, чайкаласың?..

— Ник, урман, җиргә тикле
Чайкаласың иелеп?
Яңгыр да инде бетте,
Җил дә исми илереп...
— Чайкалам, чөнки минем
Сүнә бара гомерем.
Кыскара бара көннәр,
Озая бара төннәр.
Җилләр киптерә чыкны,
Куа барлык кошчыкны,
Куптара өй түбәсен,
Кыш якынлый, күрәсең...
Чайкалам моңсу чакта —
Кошлар китә көньякка.
Оча алар тезелеп...
Бәгырь кала өзелеп.
Кыш салкынын сизәмен...
Бәхтемнең бер кисәген
Алып китә бит алар.
Минем уйлар-хыяллар
Гизәләр кошлар белән
Зәңгәр юллардан, беләм.

Алга күзгә кич баса.
Шундый вакыт, ичмаса,
Күренми һичбер бәндә,
Бушлык кына тирәмдә.
Һәм төнен, һәм көндезен —
Ялгызым мин, берүзем.
Ни кош юк, ни җил-гәптәш...
Тик сагыш — әңгәмәдәш.

## Андрей Лупан

### Пахом коесы

Сөйли картлар: «Ярлы килеш,— диеп,—
Читтә узган ярты гомере.
Туган якка кайткач, янып-көеп,
Кое казыган ул бер көнне».
Шул вакытлар кабат искә төште:
...Дала суы тирән урында
Бөкерәйгән,
җир казыган кеше
Көч җитәрлек булган кулында.
Таш катламнар куптарылып торган,
Янып-пешкән кояш нурына.
Төшермәгән күрәген ул кулдан,
Җитми торып чишмә суына,
Кое ачкан шулай карт көнендә...
Кая киткән аннан — белмиләр.
Ә су чыккан төшне ил телендә
Пахом коесы дип йөриләр.
Белсәң иде,
кое туган көннән
Бүгенгәчә вакыт эчендә
Бөкре карт үз хезмәте белән
Сусын биргән күпме кешегә?!
Калмаса да исеме язуларда,
Күңелләрдә калган сеңеп ул —
Корылыктан корган басуларга
Җан иңдергән яңгыр кебек ул.

## Николай Костенко

### Бөтен шәһәр кызыл бүген

Бөтен шәһәр кызыл бүген... бөтен мәйдан...
Бу кызыллык күзгә алсу кич түгелме?
Күренә ал булып шәүлә әллә кайдан —
Бу — кирпечләр киптерүче мич түгелме?
Бу — молдаван партизаны каны мәллә?
Я пионер галстугы алы мәллә?..
Бу — молдаван базарлары уртасында
Тау-тау үскән помидорлар алсуыдыр?

Яисә бу — Кишиневның урамына
Нур сибүче карбызларның ал суыдыр?..

Бөтен шәһәр кызыл бүген... Бар тирә-як...
Ал яулыклы молдаван кыз килә атлап:
Кәрзин тулы ал георгин — аркасында,
Кызыл кояш яна алтын алкасында,
Толымында ал тасмалар җилфердәшә,
Иренендә мәк таҗлары лепердәшә.
Сәфәр чыккан ерак-ерак төбәктән ул —
Җилләр исә ал муенса белән уйнап...
Ялан аяк килеш, ситсы күлмәктән ул
Горур атлый туган Молдавасы буйлап!

Мәхмүт Хөсәен тәрҗемәләре.

## Дора Лалева,

болгар шагыйрәсе

### Карт ана

Җыерчыклы йөзенә бал кортлары
Кунгалыйлар, ул тын утыра.
Ботакларын җәеп иске имән
Башын игән аның йортына.

Монда һәр көн саен ишек алды
Сары яфрак белән каплана.
Һәр яз саен яшел ялкын булып
Балкып тора таллар бакчада.

Шаулап ага чишмә,
таудан түбән
Ул котырган аттай очына,
Күз яшьләрен —
бәллүр тамчыларын
Ташлый чәчрәп ана учына...

### Туган җирем

Кызгылт-сары җылы җәй көннәре...
Мин шигырьләр язам төнката.
Яратам шул болгар урманнарын,
Шул хисләргә бирелеп таң ата.

Кайнар җилләр исә серле чыңлап,
Мин тауларга менәм җилләрдә,
Тыңлар өчен кыңгыраулар тавышын.
Әллә кайсы ерак илләрдән

Болыт кәрваннары агыла, гүя
Тылсымлы йөк төяп илемә:
Гасырлардан килгән хикмәт серен
Яшәтергә туган җиремдә.

**Минко Лалев,**
болгар шагыйре

## Тынгы бармы

Утырабыз яшел чирәмдә
Дуслар белән, зәңгәр бер төндә.
Тирәбездә яна фонарьлар,
Алар бии шаян җилләрдә,
Штраус вальсы көенә.

Кәстәнәләр тора чайкалып,
Яфракларын җәеп юлларга.
Кинәт радио,
чит-ят бер телдә,
Бар дөньяга сөйли яр салып [1],
Күңелләрне тутырып шомнарга...

Әйтерсең лә безгә ташланды
Кыргый яулар, уттан-сөремнән...
Кайсы төштә тагын шартлады
Артериясы бу җир шарының?!!
Нинди өн бу тагын үлемнән?!

Тирәбездә бии фонарьлар,
Вальс көенә, шаян җилләрдә,
Ә кайдадыр тәтри шартлаулар,
Үлем нуры сибеп капшый җирне
Прожекторлар кара төннәрдә...

## Совет солдаты кабере янында

Мин җырламыйм каберең ташы турында,—
Җырлыйм яшәү моңын.
Вакыт үткән белән бозылмый бер дә
Синең елмаюың.
Ташың тора,— зыян юк аның һич.—
Ул гаепле түгел...
Кара күзле болгар хатын-кызларын
Үзеңә тартасың гел.

Тын, чал аналар да, гитаралар да
Моңлы, сабыр-салмак:
Сөйләмиләр синең үлемең турында,—
Мәңге янар якты көнең турында
Яд итәләр, солдат!

**Нури Арсланов** тәрҗемәләре.

---

[1] Яр салып — оран салып, бу урында: шом хәбәр итеп.

**Мәрди Рафиков,**
**Рәшит Зәкиев**

# БАТЫРЛЫК КАЛАСЫ

## БЕЗ ЮЛГА ЧЫКТЫК



Самолет аэровокзал каршына ук туктый. Аквариум кебек үтә күренмәле вокзалның түбәсенә алыптай хәрефләр белән язылган «Магнитогорск» сүзләрен укыйсың. Монысы — Магниткаsuccessive ның һава капкасы. Ә кала үзе Урал буенда, елганың ике ярына сузылган. Шунда юнәләбез.

Магнитогорскины кара металлургия башкаласы дип әйтәләр. Ватанның корыч йөрәге дигән исеме дә бар. Барысы да уйланып һәм урынлы әйтелгән. Магнитка илгә иң күп, иң арзан металл бирә. Монда корычның иң әйбәтен коялар. Илнең бөтен металлурглары Магнитка эшчеләренә охшап, рухланып эшләргә тырышалар. Магнитка совет индустриясенең янар йолдызы, аның исемен совет эшчесенең хәйран калырлык батырлыклары бизи.

Корыч коючылар каласындагы киң проспектлар, скверлар, күп катлы йортлар, гаҗәп матур проект белән эшләнгән драма театры һәм кино-театрлар — барысы да сокландыра. Һәйкәлләргә күз төшү белән, беренче төзүчеләрнең, беренче корыч коючыларның батырлыгын тоясың. Ут чәчеп эшләүче гигант комбинат — үзе бер һәйкәл, дуслык һәйкәле. Магнитогорскины күп халык вәкилләре корган, хәзер шәһәрдә 80 милләт кешеләре яши, аның мәшһүр комбинатында, совет эшчесенең корыч семьясын тәшкил итеп, дистәләгән милләт кешеләре эшли, иҗат итә.

Шәһәрне төзү Ленин исеме, Ильичның илне индустрияләштерү планы белән аерылгысыз бәйләнгән.

В. И. Ленин, Совет властеның беренче елында ук, илнең табигый байлыкларын киң файдаланып, житештерүче көчләрне моңарчы булмаган дәрәҗәдә үстерүне бурыч итеп куйган иде. 1918 елда Ленин күрсәтмәсе белән Халык Хуҗалыгы Югары Советы инженерларның Себер җәмгыятенә Урал тау-металлургия промышленносте һәм Кузнецк ташкүмер бассейны, иң беренче чиратта, Магнит тавындагы гаять зур руда байлыклары буенча бердәм хуҗалык оешмасы булдыру мәсьәлә-

сен эшләргә тәкъдим итә. ГОЭЛРО планында Уралда металлургия промышленносте булдыруның зарурилыгы аерым атап күрсәтелә.

1929 елның 15 январенда СССР Халык Комиссарлары Советы, Хезмәт һәм Оборона Советы Магнитогорск металлургия комбинатының беренче проектын раслыйлар. Илдә авыр промышленностьны кызу темплар белән үстерү бурычы проектка төзәтмәләр кертергә мәҗбүр итә. 1930 елда партия Үзәк Комитеты комбинатның проект куәтен 2,5 миллион тонна продукция бирерлек итәргә, алга таба бу санны 4 миллионга җиткерергә карар чыгара. Шулай итеп, борынгы магнит тавы итәгендә Европада иң эре металлургия предприятиесе төзү өчен тиңдәшсез көрәш башлана.

# ТАТАР ЕГЕТЕ ОРДЕН АЛА

Тау итәкләрендәге урман-әрәмәләрне аралап юл салган елга, таш араларыннан ургылып торган чишмәләрнең терекөмештәй саф суларын җыя-җыя, түбән таба йөгерә. Бер мәлгә ул сылу каеннар арасында утырган Березовка янына ук килеп чыга. Елдамлыгын киметмичә, аны әйләнебрәк үтә дә, Магнитная станцасын уң кулда калдырып, дала ягына борыла. Кайчагында аның ярларына җайдаклар килеп чыгалар. Тугаенда кымыз атлары утлый. Югарыда, таулар өстендәге зәңгәр бушлыкта, канат җилпемичә генә бөркетләр йөзә. Гүя гасырлар тынлыгын алар да бозарга теләмиләр...

Бу күренешне Урал рәссамнарының полотнолары аша гына күз алдына китерәсең. Утызынчы еллар бусагасында менә шул Магнит-тау итәгендәге гигант төзелеш бөтен киңлегенә җәелә. Илебезнең төрле почмакларыннан кемнәр генә юл тотмый бирегә! Байтагын яшьлек дәрте кузгаткан, хезмәткә сусау китергән.

Урта Россиядән килүчеләр арасында мыек та төртмәгән егет бар. Өстендә кырык ямаулы бишмәт, аягында киндерәләре тезгә кадәр уралган чабата. Картуз кигән. Аркада капчык, кулда бәләкәй генә тимер сандык. Ул — авыл егете, комсомолец Виктор Калмыков.

Группаны плотина төзелешенә начальник итеп җибәрелгән Мәскәү инженеры Михаил Степанов каршылады.

— Хуш киләсез, бөркетләр,— диде Михаил Николаевич.

— Минем янга плотинага барасызмы? Беләсезме, ул ни өчен кирәк? Аңлатам...

Виктор төзелеш начальнигын шаккатып тыңлады. Булачак могҗиза — завод тәүлеккә 70 миллион чиләк су «эчәргә» тиеш икән. Шул кадәр суны Урал елгасын бумыйча таба алмыйсың икән. Ул су шәһәргә дә кирәк булачак, ди.

— Аңлыйсыздыр, плотина бүген иң әһәмиятле участок,— ди Степанов, басым ясап. Завод дигәнең шуннан башлана икән.

Плотинада 40 ка якын бригадага берләшкән бер мең ике йөздән артык төзүче эшли. Буаны ике ярдан торып коралар. Виктор сулъяк ярдагы җир казучылар бригадасына эләкте. Эшкә кулы ята, җир эшен ярата иде, көрәкне уйнатып кына торды. Тырышлыгын күреп бетончылар бригадасына күчерделәр.

Бу вакытта инде уңъяк ярдагы төзүчеләр арасында шактый танылып өлгергән татар егете Нурулла Шәйхетдинов та җир казучылар бригадасына җитәкчелек итә иде. Базык гәүдәле, какча битле, таза мускуллы егет ут чәчеп эшли. Ә язмышы Виктор Калмыков белән уртак: икесе дә авыл малайлары, бирегә икесен дә яшьлек дәрте, комсомол ялкыны китергән.

Тиздән рус һәм татар егетенең исемнәре бөтен төзелешкә танылды. Чуваш авылыннан килгән Евгений Майковның штурм отряды, Соколовның балта osталары, Соловьевның җир казучылары, Розановның арматурачылары, Сәгъдиев бетончылары һәм башкалар ярыш байрагын яулап алу өчен көрәш башладылар. Сентябрьнең икенче атнасында күчмә Кызыл байракны Калмыков егетләре алды. Ләкин озакка түгел.

— Байрак бездә булыр! — диделәр каршы ярда эшләүчеләр һәм сүзләрендә тордылар. Тиздән байрак Шәйхетдинов бригадасына күчте.

Шәйхетдинов җитәкләгән бригадага бетон салу өчен котлован казырга кушылды. Җаваплы бурыч. Тиз һәм сыйфатлы башкарырга кирәк. Сузсаң, арматурачы һәм бетончыларның эшен тоткарлыйсың. Бригада зур дәрт белән эшкә керешге.

Менә смена төгәлләнер вакыт житте. Әмма шәйхетдиновчыларның берсе дә төзү участогыннан китмәде. Эш кызганнан-кыза барды. Таң атты. Ә егетләр һаман ару-талуны белмиләр. Алар туктаусыз 34 сәгать эшләделәр һәм котлованны сроктан элек өлгерттеләр. Бик күп төзүчеләр өчен хезмәт батырлыгы үрнәге иде ул. Бригаданың эш мәйданында, җир казучыларның зур җиңүен күрсәтеп, Кызыл байрак җилфердәде.

Бу батырлык Магнитка төзелеше тарихына җуелмас сәхифә булып керде.

Ул елны Уралга көз иртә килде. Сентябрьдә үк кар төште. Елга өсте боз белән томаланды. Ләкин төзүчеләр, бер нәрсәгә дә карамыйча, эшләрен дәвам иттеләр. Бу көннәрдә Кызыл байраклы Шәйхетдинов бригадасы бетончылар өчен яңа мәйдан әзерли иде.

Җил сызгыра. Биткә кар бөртекләре бәрә. Куллар туңган, бармаклар бөгелмәс булганнар. Нурулла иң кыен урында, дамба кырыена яткан хәлдә, лом белән туңган җирне чокый. Ә җил көчәйгәннән-көчәя, ә Нурулла да башын күтәрмичә эшли.

Көтмәгәндә кулыннан ломы ычкынды да суга чумды. Нишләргә? Төзелештә лом кадерле, исәпле корал, туң җирдә ансыз берни эшли алмыйсың. Ә бетончылар эш мәйданы көтәләр. Аларның инде измәләре дә өлгерәдер, аны кая салырлар? Бетон туңар, төзелеш тоткарланыр. Нишләдең, Нурулла?

Кешеләр ни булганын да абайламыйча калдылар, Нурулла өс киемен салып суга чумган иде инде.

Башкалар «әһ» дияргә дә өлгермәделәр, ул бозлы судан калкып чыкты. Кулында — лом. Ярга күтәрелде дә, берни булмаган кебек, туң җирне тагын чокый башлады. Бригада кешеләре канатланып киттеләр һәм бетончыларга эш мәйданын срогыннан элек бирделәр. Шәйхетдиновчылар бу көнне ике норма үтәделәр.

Татар егетенең үз-үзен аямавы электр станциясе, домна миче һәм башка төзелешләргә шул ук сәгатьтә ишетелде. Үн меңнәрчә эшчеләр аны батырлык дип кабул иттеләр, аңа сокландылар.

Магнитка төзелешендә һәм комбинатның 40 еллык тарихында төзүчеләрнең һәм корыч коючыларның геройлыгы, шәхси батырлыклары күп булды, ләкин Урал плотинасында татар егете күрсәткән батырлыкның үз урыны бар. Ул — авылдан чыгып эшчеләр сафына баскан совет кешесенең рухи күтәрелүе, аның Ватан һәм коллектив алдында җаваплылыгы үсүе, иркле совет кешесенең характеры чыныгу иде. Ул — совет индустриясенең флагманын корганда башкаларның йөрәгендә ут кабызган шәхси батырлык иде. Ул — героизм үрнәге булды һәм илнең олы төзелешен тизләтүгә булышты. Урал елгасы аша бер километрга сузылган тимер-бетон плотина 74 көндә — срогыннан ай ярым элек өлгерде. Ә икенче чиратын — флютбетлар коруны, Урал кышының кырыслыгына карамастан, язгы ташкынга хәтле — 1931 елның 5 апре-

ленә тапшырдылар. Шпунтлар арасына соңгы кубометр бетон салу хокукын яулаган Виктор Калмыков бригадасын яр буенда бетон коючылар каршылады. Калмыковчылар янына Шәйхетдинов егетләре, социалистик ярышта җиңүче башка бригадалар басты.

Ә Нурулла Шәйхетдинов өчен плотина төзелеше тагын да истәлеклерәк булды. Совет хөкүмәте аны монда күрсәткән батырлыклары өчен 1931 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде. Бу — Магниткада беренче орден, ә Шәйхетдинов аңа лаек беренче эшче иде...

Күп милләтле төзүчеләр семьясында татар егете һәм аның бригадасы кешеләре күрсәткән батырлыкка инде кырык елдан артык. Аны Магнит каласындагылар бүген дә онытмыйлар. Чөнки Магнит-тауны урап аккан Урал елгасы утызынчы еллар батырларының ихтыяр көче белән бу урында диңгезгә әверелгән.

Без аның ярында йөрибез. Анда берничә километрга сузылып, Ленин исемендәге өч орденлы металлургия комбинаты утыра. Диңгез өстендә йөгерек дулкыннар уйныйлар, әйтерсең лә алар бүгенге буын кешеләренә төзүчеләрнең фидакарь эшләре турында сөйлиләр.

## ДӨНЬЯ РЕКОРДЫ

Магнитогорск ике материкка утырган. Урал елгасының сул ягы — Азия, уң ягы — Европа. Әмма климат бер: «дуслык климаты». Магнитка кешеләре моны шәһәрдәге 80 милләт вәкилләрен күз алдында тотып әйтәләр.

Шәһәрнең Европа өлешен Бөек Ватан сугышыннан соң кора башлаганнар. Ул һаман үсә, колач җәя. Без яңа микрорайон белән танышабыз. Матур проект белән эшләнгән биек торак йортлар. Күл астында гына кибетләр, балалар бакчалары. Урамның берсенә Сталевар исеме биргәннәр. Икенчесе Магнитостройга һәм комбинатка озак еллар җитәкчелек иткән «авыр индустрия командармы» А. П. Завенягин исемен йөртә. Бара торгач, Галиуллин урамына килеп чыгабыз. Ул яңа шәһәрнең берничә микрорайоны буйлап сузыла һәм Магнитка төзелешендә зур ихтыяр көчен күрсәткән кешегә мәңгелек һәйкәл булып тора. Зур каланың горурлыгы булырдай бу кеше совет металлургларының олы хөрмәтен батыр хезмәте белән яулаган.

...Уралның индустриаль үзәге булачак Магнитканың контурлары топограф карталарына һәм чертежларга төшерелгәндә Хәбибулла Галиуллин Мәскәү төзелешендә, атаклы совет инженеры Михаил Николаевич Степанов кул астында эшли иде әле. Инженер һәм җир казучы-бетончы шунда дуслашалар. Степанов Магниткага күчкәндә, артеле белән бергә Галиуллинны шунда чакыра.

...Коксохимкомбинат төзелеше. Галиуллиннар эшне шуннан башлый. Плотина корганда танылган Виктор Калмыков, Нурулла Шәйхетдинов, Арча егете Зариф Сәгъдиев, Егор Смертин, Петр Ульфский һәм башка бригадалар да бирегә күчкәннәр. Америка белгечләре, консультантлары коксохимкомбинат төзүгә ике ел бирәләр, ә совет эшчеләре бу срокны икеләтә кыскартырга сүз куялар.

Атаклы «бетон спартакиадасы» башлана. Сәгъдиев җитәкчелегендәге бригаданың яшьләр сменасы 375 литр күләмле «Егерь» машинасында 8 сәгатькә 429 измә бирә һәм харьковлылар рекордын яңарта. «Бәхәскә» Смертин һәм Калмыковлар кушыла. Әмма яңа хәбәр: Мәскәүнең шарикоподшипник заводын салучылар сменага — 600, ә Харьков трактор заводы төзелешендә 800 измә биргәннәр. Коксохимда бу рекорд та яңара, Сәгъдиев һәм Галиуллин бригадалары шаккатырып эшлиләр, бетончыларның Бөтенсоюз ярышына тон бирәләр. Ниһаять, 1931 елның 27 июне. Бригада яңа рекорд куярга чыга. Көн

эссе, Казагыстан далаларыннан коры жил исә. Ул төзелеш мәйданында тузан күтәрә, күзләргә ком тутыра. Татарстаннан эшчеләр алып килергә киткән абыйсын алыштырган 18 яшьлек Хәмидулла Галиуллин бригада кешеләрен эш урыннарына куя һәм команда бирә:

— Башладык!

Өч коммунист һәм егерме ике комсомолец дәррәү эшкә керешәләр. Мөхәммәт Зиннуров, Гариф Миңнуллин, Хәмит Мәҗитов, Сафа Борһанов, бертуган Мәннан һәм Малик Кадыйровлар, Юныс һәм Муса Сиражетдиновлар, Нургали һәм Абдулла Әхмәтгалиевләр һәм башкалар тачкалар белән цемент, ком һәм чуерташны өзлексез китереп торалар, «Егерь» барабаны туктаусыз әйләнә, ул 25 секунд саен измә бирә. «Егерь» машинисты, украин егете Вася Сиренкога торна шикелле бер аякта гына торырга туры килә. Икенчесе тормоздан бушамый. Васяга ике сәгать саен бияләй китерәләр, чөнки тишелеп эштән чыга бара.

Алдынгы бригадалар куйган рекордны өч сәгать дигәндә узалар. Әмма төзелеш мәйданына китерелгән ком бетә, эшнең туктап калу куркынычы туа. Моны сменаларын тәгәлләгән Артемкин бригадасы комсомоллары ишетәләр һәм алар галиуллинчылар участогына өч платформа ком китерәләр.

«Егерь» барабаны зырылдый, кешеләр ут чәчеп эшлиләр, сигез сәгать киеренке хезмәт һәм... дөнья рекорды! Бригада сменага 1.196 измә бирә. Галиуллинчылар Бөтенсоюз социалистик ярышында күчмә Кызыл байрак яулап алалар. Татарстанның Апас районы егетләре Магниткада шулай яңа удар темп тәкъдим итәләр. Төзелештәге иҗади киеренкелекнең менә дигән үрнәге була ул.

Ә америкалылар моны башларына да китерә алмыйлар. Америка «Мак-ки» фирмасының бетон эшләре һәм механикалаштыру буенча баш инженеры — 1931 елның җәендә Советлар Союзына килгән Дәвис — үзенә аңлаешлы булмаган иҗади күтәренкелек турында сөйли һәм, нинди татар эшчеләре бетон салуда, америкалыларны уздырып, бөтендөнья рекордлары куялар дип, аптыравын белдерә. Әмма ул совет кешесенең патриотизмын, аның эчке халәтен күрми, «нинди татарларның» Магнитка төзелешенә килгән күп милләт вәкилләре белән кулга-кул тотынып, дус коллективтан рух алып эшләүләрен тоймый, аңламый. Галиуллинчылар күп дуслары белән бергә иҗат итәләр. Эшче шагыйрь Александр Ворошилов бригада коллективының эшен сурәтләп, «Дөнья рекорды турында җыр» исемле поэмасын яза. Валентин Катаев Магнитка төзелешендә «Время, вперед!» исемле роман иҗат итә, анда бергә эшләп дуслашкан Егор Смертин белән Хәбибулла Галиуллин бригадаларының эшен сурәтли. Без Магниткаының халыклар дуслыгы ялкынында туууын бу әсәрдә ачык күрәбез.

Шул хакта башка күп документларда да басым ясап әйтелә. Магнитка гиганты сафка баскан көнне үзәк газеталар да, шулай ук «Уральский рабочий», «Магнитогорский рабочий», «Роте фане», «Дейли уоркер» газеталарында Магнитостройда эшләүче 21 милләт вәкилләренең Советлар Союзының эшчеләр сыйныфына, дөнья пролетариатының алдынгы отрядына язган коллектив хаты басылып чыга. Бу хатта дөньякүләм тарихи җиңү яулауда катнашкан күп милләт вәкилләренең зур иҗади хезмәт фидакарьлеге тасвирлана. «Бетон салу буенча дөнья рекорды куйган Галиуллин, Сәгъдиевләрнең удар бригадаларын бөтен Советлар Союзы белә,— диелә анда.— Ударник Буховцев, Шәйхетдинов, Прокопенко, Богатырев, Слуцкий, Козлов, Женабаев, Калье, Ульфский, Поух һәм социалистик төзелешнең башка ун меңнәрчә геройларын бөтендөнья пролетариаты белергә тиеш. Без монда, Магнитостройда, грандиоз төзелеш казанында кайныйбыз. Магнитостройда шушы зур эшләрдә СССРны тагын да индустрияләштерү өчен көрәшкә чыккан кадрлар чыныга». Бу сүзләрне СССРдагы күп милләт вәкилләре

һәм, Советлар Союзын икенче Ватаннары дип танып, Магнитка төзелешендә катнашучы чит ил пролетарийлары да әйткән. Хатка Магнитостройда эшләүче татарлар исеменнән электросварщик-ударник Сабитов та кул куйган...

Галиуллин бригадасының бетон салу буенча дөнья рекорды турында чит ил матбугаты да яза. Аның төзелештә зур яналык булган хезмәт батырлыгы турында XVII Бәтенсоюз партия конференциясендә сөйлиләр.

Бригадир һәм аның хезмәттәш дуслары үз традицияләренә тугрылыклы булып калалар, башка күп батырлыклар күрсәтәләр. Галиуллин үзе Магнитка төзелешендә һәм металлургия комбинаты цехларында Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнарына, «СССРның иң яхшы төзүчесе», «Отличник» исемнәренә лаек булган. Монда ул, белемен үстереп, бетонит заводына, аннары алдынгы эш методларын пропагандалаучы инструкторлар группасына җитәкчелек иткән, үзе кебек үк атаклы бик күп металлурглар тәрбияләгән.

## МУСА БАТЫР

Урал иртәсе.

Металлургларның күбесе домналарга, мартеннарга, станнарга ашыгалар. Аларның бер төркемен КПССның Магнитогорск шәһәр комитетында да очратабыз: шәһәрнең танылган кешеләре, Магнитканың беренче төзүчеләре, исемнәре бөтен дөньяга билгеле булган корыч коючылар, әтиләре эшен горурлык белән дәвам иттерүче алдынгы яшьләр. Алар бергә Кама автомобиль комплексын төзүчеләргә хат язу өчен килгәннәр, барлык кыенлыкларны җингән һәм ил кушканны гел намус белән үтәгән эшче сүзен тугызынчы бишьеллыкның гигант төзелешендә катнашучыларга җиткерергә телиләр.

«Кадерле иптәшләр!

Магниткада илнең күп миллә һәм халык вәкилләре кулга-кул тотынып эшләде,— диләр алар.— Аңа бөтен ил ярдәм итте.

Бездә гадәт шундый: бөек эшләрне ил өмәсе итеп бергә башкарабыз, бергә күтәрәбез. Социалистик индустрияләштерү башлангычлары Днепрогэс, Магнитка, Турксиб һәм башка төзелешләрнең эстафетасын КамАЗ үзенә алды. Бүген КамАЗны да күп милләтле илебез төзи. Советлар Союзының биш мең заводы һәм фабрикасы Кама автомобиль заводы заказларын үти. Бу бөек төзелеш — сезнең дә, безнең дә горурлыгыбыз. Ул — экономик куәтебезнең монарчы булмаган дәрәҗәдә үсүен, илебез халыкларының туганнарча семьясы көчен күрсәтә торган олы дәлил...

Без сезне, КамАЗ төзүчеләрен, объектларны тизрәк сафка кертү, югары житештерүчәнлек һәм бик яхшы сыйфат өчен көрәшкә чакырабыз. Без КамАЗны металл белән тәэмин итәбез. Үзебезнең объектларны тизләтелгән срокларда төзү буенча 40 елдан артык вакыт эчендә тупланган тәҗрибәбез белән уртаклашырга әзер — безгә кунакка килегез, эшләребез белән танышыгыз».

Хатта башка бик күп теләкләр дә бар. Иң беренче булып аңа якташыбыз Мөхәммәт Зиннуров кул куя. Аның инде Магниткадан Татарстанга җибәрелгән икенче хатка кул куюы иде. Хатның беренчесе моннан күп еллар элек, беренче бишьеллыкның беренче рекордлары шаулаган вакытта була.

Архив материаллары белән танышканда кызыклы документка очрадык. 1932 елның маенда дөнья рекорды куючы Галиуллин бригадасы

«Красная Татария» газетасы аша Татарстанның яңа төзелешләрендә эшләүчеләргә хат язган.

«Нәкъ ел ярым элек, без, илле колхозчы Апас районының Кормаш авылыннан Магнитостройга киттек. Барыбыз да бөек ышанычны аклау, үсә барган төзелешкә ныклы ярдәм итү теләге белән килдек».— диләр Галиуллин егетләре. Аннары Магнитка төзелеше, эшчеләрнең андагы героизмы, төрмышлары турында язалар һәм Татарстандагы яңа төзелешләргә шефлык итү теләген белдерәләр, бригаданың иң яхшы ударникларын Татарстанда эшләүче бетончылар, ташчылар, балта осталары, җир казучылар бригадаларына житәкче итеп җибәрергә вәгъдә бирәләр. Бу хатка Галиуллин бригадасының актив члены комсомолец Мөхәммәт Зиннуров та кул куйган.

Бүген Магнитка КамАЗга кул бирә. Хатка тагын беренче булып Зиннуров имза сала. Әмма ул инде гади бетончы түгел, хәзер ул Дәүләт премиясе лауреаты, новатор, «Почетлы металлург», күп орденнар кавалеры, ул «Магнитка йолдызы» һәм... «Муса батыр».

Шушы кадәр хөрмәтле исемнәр аның данлы хезмәт юлы турында сөйли.

Зөя буеннан Уралга килгән егет авылдашлары, бертуган Галиуллиннар бригадасында бетон салу буенча дөнья рекорды куюда катнаша. Алар кокс батареялары, домналар, мартен мичләре коралар. Аннары Мөхәммәт Зиннуров, башка бик күп иптәшләре белән бергә, шул агрегатлар янына баса.

Мартен миче әкияттәгедәй үкереп, ут чәчеп тора. Бит алмаларын яндыра. Шул ут давылын буйсындырырга, аңардан корыч алырга кирәк. Зур осталык таләп итә бу эш. Ә Зиннуровның бик әйбәт укытучысы бар, ул — тәҗрибәле металлург, украин егете Иван Дьяченко. Бертугандай яшиләр. Мөхәммәткә корыч кою серен ул өйрәтә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Магнитогорск металлургия комбинаты хөкүмәт заданиесен ала: броня әзерләргә! Ул чагында яшь комбинатта броня һәм махсус снаряд корычы кою өчен корылган мичләр дә, слябинг та булмый. Ләкин ил язмышы моның белән исәпләшми, дошман техникасына каршы торырлык ныклы калкан кирәк аңар. Магнитка металлурглары хөкүмәт заданиесен үтәргә керешәләр. Июль ахырында калкан өчен яраклы корыч иҗат итела. Ләкин слябинг юк. Тагын кыю карар: табакларны блюмингта җәяргә! Соңгы сүз полигонда әйтелә, анда броняга пушкадан атып карыйлар. Сынау уңышлы уза. Урал бронясына танкларны киендерәләр, Магнитка корычыннан снарядлар ясыйлар.

Урал бронясын иҗат итүчеләр арасында бу вакытта инде корыч коюда шактый остарган һәм мөстәкыйль рәвештә эшләүче Мөхәммәт Зиннуров та була. Ул көннәрдә Мөхәммәтнең бик кайгылы вакыты була. Дусты һәм өйрәтүчесе Иван Дьяченко нәкъ сугыш башланыр алдыннан гына, сәламәтлеге какшау булганга, туган якларына кайтып совхоз директоры булып эшли башлаган иде. Менә шул дустын фашистлар җәзалап үтерүе турында ишетә ул. Мөхәммәт аның өчен дә эшли, фашистларны тизрәк дөмектерү өчен, хезмәттәшләре белән бергә, фронтка металлны күбрәк бирергә омтыла.

Бөек Ватан сугышыннан соң якташыбызның исеме бөтен илгә танылды. Ул, Мариуполь металлургы Василий Кучерин белән бергә, тизләтелгән методлар белән корыч кою инициативасын күтәрде. Шушы хәрәкәт илебезнең бөтен металлургия заводларына күчте. Зиннуров үзе Кучерин белән ярышта җиңеп чыкты. Ул еллык планын 19 ноябрьдә үк үтәде һәм сугыш яраларын төзәтүгә керешкән Ватаныбызга планнан тыш шактый корыч бирде. Бу 1946 елда иде.

Мөхәммәт Зиннуров, хезмәттәге дуслары Владимир Захаров һәм Иван Семенов белән бергә, яңа Бөтенсоюз ярышын башлап җибәрде.

Өченче мартен мичењең шушы өч новаторы хезмәтне оешдыруның деталенә кадәр җентекләп тикшереп, елга 1 миллион сум акчаны янга калдырырга, планнан тыш 12 мең тонна корыч бирү өчен көрәш башладылар. Алар инициативасын комбинат парткомы, шәһәр һәм өлкә комитетлары, СССР Кара металлургия министрлыгы, Металлурглар профсоюзы Үзәк Комитеты яклап чыкты.

Магнитогорскида туган бу инициативаны бөтен ил белде, аңа меңнәрчә металлурглар кушылдылар. Магнитканың үзендә югары экономия белән эшләү, продукциянең үзкыйммәтен киметү өчен көрәш аеруча киң җәелдерелде. Ярышта комбинатның 29 цехы һәм 50 агрегаты, участок, бригада коллективлары катнашты. Алар планнан тыш 15 миллион сум экономия бирделәр.

Ә корыч коючы Зиннуров, Захаров һәм Семенов йөкләмәләрен 28 ноябрьга үтәделәр, планнан тыш 16 мең тонна корыч койдылар һәм дәүләткә миллион сумнан артык экономия бирделәр. Шушы хезмәтләре өчен бу өч новаторга 1951 елда Дәүләт премиясе лауреаты исеме бирелде. Металлурглар якташыбыз Зиннуровны «Магнитка йолдызы» дип атадылар.

Күренекле язучы Александр Фадеев шул елларда совет эшчеләр сыйныфы турында эпопея иҗат итәргә тели һәм Магнитогорскига килә. Даны бөтен илгә таралган өченче мартен миче коллективының эшен, тормышын өйрәнә. Язучы Владимир Захаровның семьясында торып эшли. Ул «Кара металлургия» исемле романын яза башлый. Без ул әсәрдә Павел Кузнецов, Коля Красовский, Муса Нургалиев һәм Иннокентий Сомов образлары белән танышабыз. Шушы әсәрнең геройларында (романның сигез бүлеге дөнья күрде) өченче мартен миче корыч коючылары Владимир Захаров, Иван Семенов, Мөхәммәт Зиннуров һәм ул чагындагы комбинат директоры, Дәүләт премиясе лауреаты Георгий Носовны тануы кыен түгел. Шулай итеп, безнең Мөхәммәт әсәргә Муса исеме белән керде. Кызганычка каршы, язучы үзенең романын тәгәлли алмады. А. Фадеев дөнья куймаса, без эшче металлургларның, шул исәптән «Муса батырның» тулы образын, аның аша якташыбызның да менә диган портретын күз алдына китерер идек.

Авыл малае эшчеләр коллективында, Магнитогорскидагы күп милләтле зур семьяда менә шулай күтәрелде. Ул мартен цехында өзлексез 26 ел эшләде. Һәм батыр хезмәте өчен ике мәртәбә Ленин ордены, Хезмәт Кызыл байрагы ордены, медальләр белән бүләкләнде. Соңыннан новатор Мөхәммәт Зиннуров мәктәбен күп металлурглар үттеләр. Алар арасында хатын-кызлардан беренче корыч коючы Татьяна Ипполитова да бар иде. Бүген дә өченче мартенның 18 һәм 19 мичләрендә Мөхәммәт аганың авылдашлары, шәкертләре — аталы-уллы Якуб белән Юныс Биккининнар һәм Шәяз Гафиятуллин корыч коялар. Почетлы металлург М. Зиннуров, пенсиядә булса да, дусларының эше белән якыннан кызыксына һәм аларга булыша.

Галиуллин бригадасы членнары Сафа Борһанов һәм Мәннан Кадыйров та нигезен үзләре салган Магниткада илнең танылган корыч коючылары булып үстеләр, бүгенге буын сокланырлык матур юл үттеләр.

Зиннуров һәм аның хезмәт дуслары турында сөйләгәндә, Америкадан Магнитка төзелешенә киңәшче булып килгән Смит әфәнденең сүзләре искә төшә. «Бу кешеләр бритва тота белмиләр, ә домналар турында хыялланалар. Көлке!» — дигән иде ул. Техниканы көрәктән башлаган саф табигатьле кешеләр бүген гигант домналар, мартеннар, станнар белән бик яхшы идарә итәләр, дөньяда иң арзан металл бирәләр. «Ватанның корыч йөрәге» тулы пульс белән тибә. Аның цехларында беренче төзүчеләр һәм корыч коючылар кабызган хезмәт ялкыны дөрли.

# УРАЛНЫҢ ӘДӘБИ ЦЕХЫ



«Безнең өчен вакыт бик кадерле, аның бер минутын да бушка әрәм итәргә ярамый, без хәл итәсе бурычлар — искиткеч зур. Советлар Союзы эшчеләр сыйныфы үзалдына куйган һәм хәл итә торган шундый авыр максатны һәм бурычларны әле моңарчы беркайчан да, беркем дә, дөньядагы бер халык та куеп һәм хәл итәргә омтылып караганы юк иде».

Бу юлларны без М. Горькийның 1931 елның августында Магнитострой эшчеләренә язган хатыннан алдык. Әйе, эшчеләр гигант предприятиеләр кордылар, аны тизрәк сафка бастыру өчен көрәштеләр. Бер үк вакытта алар илһамлана да белделәр, әдәбият белән кызыксындылар, белемгә омтылдылар. «Безнең бригадада 26 кеше: шуларның 3 се коммунист, 22 се комсомолец,— дип яздылар галиуллинчылар 1932 елда Татарстан эшчеләренә җибәргән хатларында.— Алар барысы да татар телендә өстәмә эшче белеме мәктәбендә укыйлар, политик һәм техник белемнәрен үзләштерәләр. Икебез әдәби түгәрәккә йөри һәм үз бригадабыз һәм бригадир Хәбибулла Галиуллин турында китап яза».

Моңа ничек сокланмыйсың: кешеләр төзелештә дөнья рекордлары куйдылар, палаткаларда яшәп укырга-язарга (бригадада андыйлар да бар иде) өйрәнделәр, шул ук вакытта иҗат ялкыны белән яндылар. Төзелеш җитәкчеләре, партия, совет органнары төзүчеләрнең иҗат эше белән шөгыльләнүләрен хуплыйлар һәм ярдәм күрсәтәләр иде.

Магнитогорск металлургия комбинаты буенча 1934 елның 31 гыйнварында комбинат директоры А. П. Завенягин тарафыннан язылган приказ сакланган. Анда болай диелә:

«Магнитогорск әдәби оешмасына 3 ел тулды. 1930 елда оештырылган һәм 24 кешесе булган «Буксир» әдәби группасы хәзер Уралда йөзгә якын кешене берләштергән эре әдәби оешма булып әверелде. Аларның күбесе Магнитогорск комбинаты цехларында эшче-ударниклар булып эшлиләр.

Өч елда Магнитогорск әдәби оешмасы Уралда гына түгел, ә бөтен Союз җәмәгатьчелегенә билгеле язучылар тәрбияләп үстерде.

Магнитогорск язучылары повестьлар, шигырь китаплары, пьесалар яздылар. Машинист А. Авдеенконың «Мин сөям» исемле повесте Мәскәүдә басылды, немец һәм француз телләренә тәрҗемә ителде. Мәскәүдә В. Ручьевның «Икенче ватан» исемле шигырьләр китабы басылды. В. Макаров «Ярыш утлары» дигән шигырьләр җыентыгы бирде.

Магнитогорск әдәби оешмасының үсүе пролетар культура үсешенең, Магнитострой һәм аның кешеләре үсешенең ачык чагылышы булып тора. Магнитогорск комбинатының күпчелек язучылары бүген дә әле монда эшлиләр».

Комбинат директоры бу приказында, әдәби оешма членнарының зур хезмәтен билгеләп һәм аларның комбинат коллективы тормышыннан яхшы әсәрләр иҗат итүләренә ышанып, журнал чыгару, язучылар йорты, китапханә ачу өчен средстволар җибәрелүе, оешманың язу машинасы белән бүләкләнүе, бер төркем актив язучыларга персональ бүләкләр (кыйммәтле әйберләр, иҗат командировкалары) бирелү турында әйтә.

Иҗат ялкынын менә шулай кабызганнар. Ул корыч каласында хәзер дә дөрли. 1970 елда комбинат буенча язылган 282 нче приказ белән танышсаң, моны ачык күрәсең. Комбинат директоры А. Д. Филатов кул куйган бу документта мондый юллар бар:

«Кырык ел элек, 1930 елның октябрендә, Магнитогорскида әдәби түгәрәкләр туды. Алар соңрак «Буксир» әдәби группасына берләштеләр. Группага яшь эшчеләр һәм белгечләр керделәр. Алар үз иҗатларында Ватаныбызда кара металлургиянең беренче гиганты булган Магнитогорск металлургия комбинатының гуу һәм үсү тарихын чагылдырдылар.

30 елларда ук инде Магнитканың беренче эшчеләреннән чыккан шагыйрь һәм язучылары танылды. Алар Борис Ручьев, Александр Макаров, Александр Ворошилов, Александр Авдеенко, Владимир Хабаров, Михаил Люгарин һәм башкалар. Аннан соңгы елларда да Магнитка Уралның эре әдәби цехы, яхшы мәктәп, күп шагыйрьләр һәм язучылар өчен иҗат чишмәсе булып торды. Магнитогорск әдәби оешмасыннан А. М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Борис Ручьев, РСФСР язучылар союзы правлениесе секретаре Людмила Татьяничева, Александр Лозневой, Марк Гроссман, Александр Авдеенко, Михаил Люгарин, Николай Воронов, Станислав Мелешин кебек киң танылган шагыйрьләр һәм язучылар чыкты. Үзәк электр станциясенең турбина машинисты Владилен Машковцев та шагыйрь, СССР Язучылар союзы члены булды.

Бүген комбинат цехларында буш вакытларын иҗат эшенә багышлаучы күп кенә яшь эшчеләр һәм белгечләр хезмәт итәләр. Алар шигырьләрендә, хикәя һәм повестьларында Магнитогорск металлургларының олы хезмәтен, хезмәт батырлыкларын һәм героизмын җырлыйлар». Приказда яшь эшче әдипләргә хезмәт иялəренә коммунистик тәрбия бирүдәге эшләре өчен рәхмәт әйтелә һәм аларны бүләкләү турында хәбәр ителә.

Магнитканың беренче көннәрендә каләм осталары иң кайнар йөрәкле төзүчеләр булалар һәм зур батырлыклар күрсәтәләр. Александр Ворошилов Урал плотинасы төзелешендә үз-үзен аямыйча эшли. Иң авыр участокларда аны күрәләр. Ул күрәгеп куйгач, каләмен ала, шигырьләр, поэмалар иҗат итә. Аның геройлары да, беренче укучылары да төзүчеләр булалар. Ләкин талантлы шагыйрьнең язмышы фаҗигале була, ул төзелештә салкын тиеп үлә. Аның җырын бетончы шагыйрь Борис Ручьев һәм башкалар дәвам иттерә. Бүген А. М. Горький исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Б. Ручьевның күкрәген ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бизи. Туган шәһәре аны менә шулай күтәргән. Магнитканың домна һәм мартеннарыннан укучыга билгеле булган башка әдипләр чыккан, йөзләрчә яшьләр анда иҗат чыныгуы алганнар.

Андагы беренче төзүчеләр белән Максим Горький тыгыз элемтәдә торган. Ул эшчеләргә берничә хат җибәргән. Магнитканың яшь әдипләренә Валентин Катаев, Демьян Бедный, Эммануил Казакевич, Александр Малышкин, Ярослав Смеляков, Вячислав Погонский, Исидор Шток, Николай Богданов, Лидия Сейфуллиналар күп булышты. Бер ук вакытта алар социалистик шәһәр төзүчеләр турында китаплар язалар. А. Малышкинның «Люди из захолустья», В. Катаевның «Время, вперед!», Н. Богдановның «Пленум друзей», Е. Воробьевның «Высота» әсәрләре данлы Магнитка җирендә туган. Әйткәнебезчә, Мәскәү һәм Магнитогорск язучылары Магнитканың күп милләтле эшчеләр коллективында (металлурглар шәһәрендә 370 меңгә якын кеше, шул исәптән 25 меңнән артык татар яши) хезмәт батырлыклары күрсәтүче татар эшчеләренә дә мөрәҗәгать иткәннәр. Илебезнең күп милләт халыклары белән бергә, Ватанның корыч йөрәген тигез эшләтүче татар эшчеләрен һәм аларның хезмәттәш дусларын татар совет язучылары әсәрләрендә күрсәк, тагын да олырак куаныч тояр идек.

Галиуллин бригадасы члениарының 1932 елда матбугат аша язган мәгълүм хатларында мондый юлларны укырга мөмкин:

«Магниткада яңа кеше туа. Меңнәрчә колхозчы татарлар сыйнфый-аңлы пролетарийлар булып үзгәрәләр, металлист, химик квалификациясе алалар. Бу — зур әсәр өчен тема түгелмени? Без ТАППтан дөньякүләм төзелештә булган татар эшчеләренең тормышын һәм көрәшен озак өйрәнү өчен язучы җибәрүне сорыйбыз.

Монысы — безнең үтенеч».

Кайвакыт матбугатта дистәләрчә ел югалып йөргән хатларның адресатына тапшырылуын укып елмаябыз. Бу хатны да шулай 40 ел буе югалып йөргән дип күз алдына китерсәк?..

Ә әдәби әсәрләр иҗат итү өчен никадәр чыганак, никадәр байлык бар анда! Дөрес, бертуган Хәбибулла һәм Хәмидулла Галиуллиннар, Сафа Борһанов, төзелештә һәм комбинатта танылган кайбер башка эшчеләр вакытсыз вафат булганнар, Нурулла Шәйхетдиновның соңгы еллардагы язмышы билгеле түгел. Әмма ветераннарның күбесе корыч калада яши, аларның уллары, оныклары — меңнәрчә татар эшчеләре, башка милләт эшчеләре белән бергә, хезмәт могҗизалары тудыралар. Хәбибулла Галиуллин гаиләсе — чын металлурглар семьясы. Аның дүрт улы, дүрт кызы, бер оныгы, ике кияве, бер килене Ленин исемендәге Магнитогорск металлургия комбинатында эшли. Семьяда рус, украин, белорус һәм башка милләт кешеләре бар. Оныклар тау-металлургия, медицина институтларында, музыка училищесында укыйлар. Хәмидулла Хәбибуллин, Мөхәммәт Зиннуров һәм башка металлургларыбызның балалары әтиләре традицияләрен дәвам иттерәләр. Алар укучыларга үрнәк булырдай геройлар булып романнарга һәм повестьларга, драма әсәрләренә һәм поэмаларга керергә лаек булсалар да, татар язучылары өчен әлегә кадәр һаман да күтәрелмәгән чирәм булып кала бирәләр...

Марсель Зарипов

# САРАН КАТЛАМНАР ХӘЗИНӘСЕ

*Узган бишьеллыкта Татарстан нефтьчеләре илгә 463 миллион тонна, ягъни үзе бер диңгез булырлык нефть бирделәр. Шуның 176 миллион тоннасы нефть чыгаруны тизләштерү, нефтьне аз бирә торган авыр катламнар белән эш итү нәтиҗәсендә алынган. Моннан әле берничә ел элек кенә мондый нефтьне бөтенләйгә җир астында калачак, югалачак нефтькә санып йөрүчеләр иде. Тугызынчы бишьеллыкта илнең төп нефть цехы эшчеләре Ватанга ярты миллиард тоннадан артык ягулык, ягъни бөтен Союз күләмендә табыла торган нефтьнең өчтән бер өлешен бирәчәкләр.*

*Нефтьчеләр алдында торган проблемалар турында Марсель Зариповның «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры, техника фәннәре кандидаты В. И. Грайфер белән әңгәмәсен тәкъдим итәбез.*



Валерий Исаакович, 463 һәм 500 миллион дигән саннарның төбендә ниләр ятканлыгын сөйләп бирмәссезме?

— Бу саннарның төбендә, билгеле, гаять зур хезмәт, тырышлык, осталык һәм тәвәккәллек ята. Бу хакта без алдарак сөйләшербез әле, ә хәзергә бөтенләй чыкмаслык дип исәпләнгән нефтьне дә җир астыннан чыгарырга өйрәнгән нефтьчеләребезнең иҗади тәҗрибәсе укучыларга аңлашыла төшсен өчен кызыклы бер тарихи фактны әйтеп китим. Революциягә кадәрге йөз илле ел вакыт эчендә Идел буе җирләрендәге байлыкны күрәп алырга чамалап йөрүче эшкуарлар арасында иң уңганы Бөгелмә алпавыты Малакиенко була. Грозный, Баку промыселларын талап баеган бертуган Нобельләр дә мондагы нефтькә күз аталар, ләкин әллә ни эш майтара алмыйлар. Инглизләр дә Казан губернасына килеп, «Казан ойл филд», икенче төрле әйтсәк, «Харам булса да алам» дигән фирма оештырып карыйлар, тик алар да бушка гына тырышалар. Шандор исемле бер американ да инглизләрдән калышмый, безнең якларга килеп, шурф казып карый — торба эчендә гүләп яткан фонтаннар арасында аның шурфлары әле хәзер дә очраштыргалый — шурфлар коп-коры. Малакиенко туганда ук бәхетле булып тугандырмы, әллә берәр тылсымын тапкандырмы — сиксән сажин тирәнлегендә кое казып, җир мае таба.

Алпавытның сөенечтән башы күккә тия. Шул җир мае белән ул тарантасын майлый, кунактан кунакка йөреп, булачак байлыгы бе-

лән мактана. Әмма «уңган» алпавытның да хыялы чынга ашмый. Сиксән чиләк чыгарганнан соң нефть бетә, кое кибә, Малакиенконың байлык күрәү өмете дә буш өмет булып кына кала.

Узган язда без Татарстан промыселларында бер миллиард тонна кара алтын чыгаруны бәйрәм иттек. «Җир маен» Бөгелмә астыннан да чыгаралар; ихтимал, хәзер нефть биргән меңләгән скважинаның берәрсе Малакиенконың теге коесына да, аннан йөз чакрым арырак, Шандор станоклары эшләгән төшкә дә, бертуган Нобельләрнең һәм инглиз эшкуарларының кара алтын эзләүчеләре йөргән җирләргә дә туры килгәндер.

Аннары, миңа мондый саннарны искә алып китү дә кызыклы булыр: илдәге барлык промыселлар беренче миллиард тонна нефтьне, узган гасырда беренче скважина эшли башлаганнан алып, туксан ел дәвамында чыгаралар. Татарстан нефтьчеләре исә бу санны егерме биш ел эчендә узып киттеләр.

— Хәзер без елына бер миллион тонна нефть чыгарабыз. Димәк, икенче миллиард тонна кара алтынны республикабыз промыселчылары беренчесенә караганда ике ярым мәртәбә тизрәк алачаклар.

— Безнең экономик күрсәткечләр промыселларның бик тиз үсүеннән, җир асты байлыкларын кызу темп белән чыгарудан, эшне вакытыннан алда эшләп барудан туа. Менә ничә ел инде Татарстан нефте илдә иң арзан нефть саналып килә, чөнки безнең нефтькә башка районнар белән чагыштырганда иң аз чыгым тотыла. Республика промыселларындагы хезмәт җитештерүчәнлеге бик югары. Былтыр җан башына бүлеп караганда һәр кешегә алты мең тоннадан артык нефть туры килде — Америка Кушма Штатлары промыселларындагыдан күп өлеш артык бу.

Татарстан промыселчылары тәҗрибәсенең иң әһәмиятле, иң кызыклы ягы шул — аларның эше сан ягыннан гына түгел, сыйфаты ягыннан да, үзенчә эшләү ысуллары, җир асты катламнарыннан иң күп файда алулары, бөтенләй өмет юк дип санаган участоклардан да нефть чыгара белүләре белән дә аерылып тора.

— Өметсез участоклар да буламыни?

— Җир асты катламнарының геологик үзенчәлеген исәпкә алмыйча, промыселга ерактан караганда гына шулай уйларга мөмкин. Ә чынлыкта исә янәшә торган ике скважина да, нефть запаслары бер чамада булуга да карамастан, продукцияне төрлечә бирәләр. Насослар бер скважинадан нефтьне чыгарып өлгерә алмый, ә икенчесендә торбалар коп-коры.

Татарстан нефтьчеләре, әлбәттә, миллиард тонна дигән чиккә быел булмаса, киләсе елга, яки биш елдан соң да һичшиксез җиткән булырлар иде. Ул чикне тугызынчы бишьеллыкның беренче елында узуга скважиналарны югары темп белән бораулау, яңадан-яңа нефть ятмаларын эшкә кертү ярдәм итте.

«Йортта иң зур байлык — булганны файдалана белү» дигән бер әйтем бар. Бу яктан караганда, нефтьчеләр иң бәрәкәтсез халык. Уйлап карагыз: берәү байлык таба, ул шуның яртысын ала, яртысын калдырып китә. Анысы — артыгы, янәсе.

Чыннан да шулай бит. Җир кешегә үз байлыгының яртыдан артыгын гына бирә, шуннан башкасы бөтенләйгә җир астында кала. Аны берни эшләтеп тә булмый. Промыселларның, бөтен бер нефть провинцияләренең билгеле бер чиккә җиткәч бик тиз кибеп, сүнеп калу фактлары тарихта байтак. Татарстан промыселчылары исә, нефтьне һаман бик югары темп белән чыгаруларына карамастан, егерме биш ел буена табышны арттыра килделәр һәм бу дәрәҗәне иң элек нефть ятмаларын эшкәртүне тизләштерү, нефть аз бирә

торган катламнардан табышны арттыру, запаслардан яхшы файдалану исәбенә — шушы бишьеллык дәвамында да киметмәячәкләр.

Татарстан нефьчеләренең кыю тәҗрибәсе хәзер илдәге барлык промыселларда да яхшы дип табылып, эштә кулланыла башлады. Бу тәҗрибәнең асылы шуннан гыйбарәт: нефтьле мәйдан үзәктән һәм тышкы яктан ике рәт скважина белән уратып алына, скважиналар җир астына су куа, шул рәвешчә «җир маен» ике яктан да су китереп кыса. Җир астындагы уннарча, йөзләрчә квадрат километр мәйданны су басымы әкренләп кыса килеп, нефтьне җир өстенә куып чыгара.

Алдан уйланган схема буенча эш әнә шул рәвешчә күз алдына китерелгән иде. Әмма җир асты катламнары, ватман кәгазендәге схема кебек, уч төбендәгедәй күренеп тормый. Табигать фәнгә «төзәтмә» кертте, практикларга сабак бирде. Хикмәт шунда: нефть ятмасы ул — бишәр, хәтта унар катлам булып аслы-өсле яткан җир асты хәзинәсе икән. Аларның беришесе сыеклыкны үткәрә торган комсу катлам, икенчеләре — энә очы кадәр дә тишеге булмаган балчыклы зона, өченчеләре исә — алмаз шикелле каты, «үле» алевролитлар. Физика законы буенча, җир астына җибәрелгән су сыеклык үткәрә торган катламнардагы нефтьне куып чыгара, ә башка горизонтларга бернинди тәэсир ясый алмый. Җир астындагы су басымы контурларын бик җентекләп язып барганда да проекттагы шикелле анык итеп билгеләп чыгып булмас иде...

— Димәк, нефтьчеләр чыгарган кара алтын юмарт катламнардан гына алынган? Калган запаска кеше кулы тимәгән?

— Әйе, нәкъ шулай! Гадирәк итеп әйткәндә, без җир астындагы байлыкның каймагын гына сөзеп алдык.

Практикада «дельта-ПЭ» дигән бер термин бар. Аңлаешлырак итеп әйтсәк, скважина забоендагы басымның җир астындагы басымнан аермасы дигән сүз ул. Бу аерма зуррак булган саен нефтьне җир өстенә куа торган көч тә зуррак була. Шуннан соң без җир астына кудыра торган суның басымын иң каты катламны да җиңәрлек итеп арттырырга булдык. Алтмыш атмосферадан башлап ике йөзгә чаклы җиткердек. Мәсәлән, Габдрахман авылы янындагы егерме беренче станция зонасында басымны 155 атмосферага хәтле күтәрдек. Аңарчы һәр скважина тәүлегенә 173 кубометр су «йота», нефтьле унөч катламның җидесе нефть бирә, тулаем 46 метр калынлыгындагы катламның нефть бирә торган өлеше 13,5 метр гына иде. Хәзер инде забойлар суны өчләтә күбрәк «йота», катламның нефть бирү көче бермә-бер артты. Шул участокта ук тагын бер кызыклы тәҗрибә ясалды: дүрт урынга АН-500 агрегатлары куеп, басымны 500 атмосферага хәтле арттырдык. Мондый басым бетонны да көл итеп очырта. Скважиналарның су йотуы җиде мәртәбә артты, су нефтьне бөтен катлам буенча куа башлады. Нәтиҗәдә бу участокның нефть бирүе тәүлегенә 633 тоннага артты. Исәп буенча, җир астыннан өстәмә рәвештә 8 миллион тонна нефть чыгарылган.

Әмма физика законнарының көче җирнең астында да, өстендә дә бер үк төрле. Басымны әнә шул дәрәҗәгә җиткергәндә дә су нефтьне җиңелрәк катламнардан тизрәк, күбрәк куып чыгара, авыррак катламнардан озаграк чыгара, аннары шунысы да бар: су куа торган мең ноктаның һәр өчтән бере «коры» участокларга туры килде. Яхшы участокларда скважина икешәр мең кубометр су йота, начарларында эшсез тик утыра. Тәүлегенә илле кубометр су җибәрү — эшмени ул? Хикмәт акча, материал, кешеләрнең хезмәте әрәм булуда гына түгел — гадәттә су кую объектларын ясауга китә торган чыгым барлык чыгымның чирек өлешен тәшкил итә — җир астында кала торган байлык кызганыч! Промыселларда җиргә бер генә

килограмм нефть түгелсә дә — ЧП, ә бу очракта миллионлаган тонна нефть әрәм була бит!

Нефть табу эшендә шундый бер тәртип бар: промыселларны салырга керешкәнче, иң элек нефть ятмасын эшкәртү проектларын төзиләр, ягъни алдан ук скважиналар челтәрен билгеләп чыгалар, кайсы ноктадан су куасын, кайсы ноктадан нефть аласын ачыклыйлар. Ләкин иң төгәл дигән исәп тә җир астында эш ничек буласын якынча да чамалап җиткерә алмый. Бу хәлнең нәтиҗәсе ничек булганын әйтеп киттем инде. Шуннан соң без нокталарны су куа торган һәм нефть чыгара торган дип алдан ук билгеләп куймаска булдык. Иң элек скважиналарны куябыз, моның өстенә, бораулау вакытында, нефтьне чыгара башлаган беренче көннәрдә, җир астын җентекләп «күрү» өчен, җитәрлек тикшерү эшләре башкарабыз һәм иң яхшы участокларны су кудыруга билгелибез, суландыру системасын инде сукыр рәвештә түгел, бәлки төгәл белеп, сайлап эшлибез. Аңарчы без суны бер насос станциясеннән бөтен бер скважиналар «куст»ына җибәргән булсак, хәзер һәр ноктада суны персональ режим буенча куабыз.

Нефть ятмаларын эшкәртүнең сайлаулы системасы практикада әнә шул рәвешчәрәк эшкә ашырыла. Бу система — күпьеллык практика, галимнәрнең тикшеренүләре, производство башлыкларының эзләнүләре, белгечләрнең сәләте һәм осталыгы нәтиҗәсе. Шушы уңай белән кайбер саннар китереп китү дә урынсыз булмас. Геологик шартлары белән катлаулы һәм кыен участок саналган Яңа Елхово мәйданында башта суны элек кабул ителгән схема буенча — ике яклап кудырып, нефтьне биш рәт скважинадан чыгарырга уйланылган иде. Аннары мәйданның көнбатыш өлешен сайлап су җибәрү ысулына күчердек. Барлык шартлар: материаль һәм техник чыгымнар, эшчеләр саны, катламнарның нефть бирү чамасы бертигез булуга карамастан, мәйданның көнбатыш өлешендә нефть чыгару темпы, көнчыгыш өлеше белән чагыштырганда, ел саен артык булып килә. Мәйданның көнбатыш өлешен көнчыгыш өлешеннән өч ел соңрак эшкәртә башласак та, монда нефтьне бер миллион тонна артыграк алдык инде.

Эшнең иң әһәмиятле ягы хәзерге көндә күпме нефть чыгарылуында түгел, бәлки җир астындагы кара алтын запасларын мөмкин кадәр күбрәк файдалануда, иң авыр катламнардан да нефть алуда. Ромашкино нефть ятмасында беренче проектлар буенча ел саен 54 миллион тонна нефть чыгару күздә тотылган иде, хәзер анда 80 миллион тонна нефть алына. Сүз уңаеннан әйткәндә, Татарстан промыселларында беренче миллиард тонна нефтьне ни өчен партиянең егерме дүртенче съезды булган елда чыгарып өлгерделәр, ни өчен соңрак түгел? дигән сорауга да төп җавап шушы.

— Егерме дүртенче съезд Директиваларында: «планлаштыру һәм идарә итү эшендә автоматлаштырылган системалар төзү һәм аларны гамәлгә кертү эшләрен җәелдерергә» диелгән. Татарстан промыселларында бу бурыч ни дәрәҗәдә эшкә ашырыла? Һәм, гомумән, электронлы хисап машинасы нефтьчеләргә нинди ярдәм, файда бирә алыр?

— Иң элек ул промыселның бөтен исәп-хисап эшен эшли ала. Электронлы хисап машинасы турында хәзер бик күп сөйлиләр. «Бу акыллы математика машинасы ниләр эшли ала?» дигән сорауга һәрбер мәктәп баласы: «Бик тиз һәм бик дөрес итеп исәпләп чыгара ала»,— дип җавап бирә. Мин моңа өстәп: «Нефть тә чыгара ала», дияр идем. «Чыгарырга ярдәм итә» генә түгел,— аңысы һәркемгә билгеле,— нефтьне үзе чыгара ул, чөнки электронлы хисап машинасы тиз исәпли торган арифмометр гына түгел,— бүгенге заман

производствосының бик катлаулы проблемаларын бөтенләй яңача куеп эшкә ашырырга шарт тудыра торган бер корал ул.

Башта берничә сан китереп китик. Безнең оешманың иң түбән баскычы саналган нефть-газ чыгару идарәсендә елына 58 миллион геологик, техник, технологик, экономик һәм хуҗалык мәгълүматы файдаланыла. Идарәнең шуннан чак кына югарырак баскычында — производство берләшмәсендә инде — билгеле бер хәлләрдә дөрес чарасын табу, дөрес карар кабул итү өчен кирәкле була торган һәртөрле белешмә мәгълүматларының саны бермә-бер арта — 116 миллионга җитә.

Югары квалификацияле меңнәрчә белгеч иң гади эш белән шөгыльләнә: башта мәгълүматлар җыя, аннары аларны чагыштырып, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгара. Еш кына мондый гаять зур эшнең файдасы легендар Сизиф тырышлыгы шикелле генә булып чыга, чөнки кеше исәп-хисап иткәндә ялгышлар да җибәрә.

— Сизиф эше белән чагыштыру артык түгелме? Белүебезчә, Сизиф тау башына таш ташыган, ә ташы кире тәгәрәп төшә торган.

— Юк, артык түгел. Кайвакыт шундый хәлләр килеп туа — электронлы хисап машинасыннан башка эш итү тау башына таш тәгәрәтеп менгерү шикелле үк була.

Бер мисал китерим. Моннан ике-өч ел элек «Татнефть» берләшмәсендә электронлы хисап үзәге төзеделәр. «Акыллы» машинага беренче эш итеп километр ярым тирәнлеккә төшерелгән насосларны никадәр күп чыгара алуларын тикшерергә куштылар. Электронлы җайланмалар, кешеләр файдалана торган шул ук мәгълүматларга нигезләнеп, ике мең ноктадан торып җир астын карадылар һәм скважиналарның яртысы дөрес җиһазланмаган булуын әйтеп бирделәр. Нефть аз катламнарда моторлар бушка әйләнә, нефть күп катламнарда — көчәнеп эшли, нефтьне өскә чыгарып өлгерә алмый. Ә бит насосларны тәҗрибәле яхшы белгечләр: геологлар, инженерлар, практиклар сайлап куйганнар. Шулай да ул электронлы хисап машинасы кушканча эшләп карарга булдык,— ике йөз ноктада ул «әйткәнчә» эшләдек һәм беренче елында ук ике йөз мең тонна өстәмә нефть алдык.

Бу — кешенең акылы һәм тәҗрибәсе хисап машиналарының тиз һәм төгәл эшләве белән кушылганда электронлы хисап техникасының мөмкинлеге никадәр зур булуын күрсәтә торган бер мисал гына әле. Хәзер республикабыз промыселларында автоматлаштырылган идарә системасының беренче чираты эшкә ашырыла. Бу система — нефть һәм газ табу участокларыннан башлап, промыселларның эшче штабы — берләшмәгә хәтле — бөтен производство тармагына керешәчәк.

— Гади бер арба йөртү өчен дә искиткеч яхшы идарә системасы эшләп була бит. Һәм, киресенчә, тоташтан конвейер линияләре куелган, билгеле бер программалы станоклары булган искиткеч яхшы производствоны да кустарьларча примитив ысуллар белән идарә итәргә мөмкин.

— Промыселларда төзелә торган идарә системасы,— аның илдә беренчеләрдән икәнен дә әйтеп китик,— Татарстан нефтьчеләре объектларны автоматлаштыру, идарәнең төзелеш структурасын яхшырту буенча инде күп еллар дәвамында эшләп килгән зур хезмәтнең соңгы бер этабы. Бүгенге көндә барлык скважиналарның җитмеш биш проценты диспетчер пунктларына тоташтырылган, насос станцияләре «бикләнгән хәлдә», приборлар контролендә эшли, механикалаштырылган исәпләү фабрикалары төзелде, һәр промыселда «Наири», «Минск-22» маркалы электронлы хисап машиналары белән җиһазланган үз хисап үзәкләре эшли. Арттырып әйтү түгел —

промыселларда гаять зур фәнни-тикшеренү комплексы эшли, кеше көче җитмәслек бик зур күләмле эшне хисап машиналары башкара. Сайлап эшкәртү системасын исәпләп чыгару, югары басым зоналарын ачыклау, скважиналарга иң оптималь эш режимы билгеләү һәм башка шундый файдалы хезмәт күрсәтү — болар барысы да акыллы хисап машиналарының эше. Башка фәннәр кебек, нефть фәне дә коры ышануга нигезләнеп кенә эш итми. Эшкә керешкәнче иң әлек фикереңнең дөреслегенә ышанырга кирәк. Электронлы хисап машинасы туктаусыз килеп торган мәгълүматларны бик тиз һәм дөрес бәяләргә, перспективаны күрергә ярдәм итә, сайлау өчен унлаган вариант тәкъдим итә ала.

«Татнефть» берләшмәсе хәзер производство фирмасы дип йөртелә, аны «фәнни производство фирмасы» дип атау дөресрәк булыр иде, югыйсә. Хәер, хикмәт исемдә түгел. Иң әһәмиятлесе — Татарстан нефте өчен турыдан-туры утыз фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык институты эшли. Нефтьчеләр, галимнәр һәм конструкторларның теләсә нинди яхшы, файдалы идеяләрен кабул итәргә, беренче тәҗрибәләрдән башлап, ул файдалы идеяне производствога кертеп таратып җибәргәнче алар белән бергә бөтен тикшеренү эшләрен башкарып чыгарга әзерләр. Чөнки хәзерге заман фәненең чыннан да җитештерүче бер көч икәнлегенә, бүгенге халык хуҗалыгының иң рентабельле бер тармагы булуына практикада ышандык инде.

— Валерий Исаакович, былтыр мин нефтьчеләрнең бөтен Союз киңәшмәсендә булган идем. Ул киңәшмәдә промыселларда автоматлаштырылган идарә системасы төзү мәсьәләсен тикшергәннәр иде. Шунда Казан университеты профессоры, күп еллар буена нефть мәсьәләләре белән шөгыльләнеп килгән физика фәннәре докторы Н. Н. Непримеров та чыгып сөйләде. Николай Николаевичның шунда практикларга әйткән бер фикере истә калган. Ул эшне югарыдан, хисаплау үзәгеннән башларга кирәкми, бәлки скважина, буровойлар, компрессорлар станцияләреннән керешергә, иң әлек аларны төгәл приборлар белән җитәрлек итеп җиһазларга кирәк. Шул приборлар идарә системасын җентекле мәгълүматлар белән тәэмин итеп торырга тиеш... Мәгълүматлар ялгыш булса, нәтиҗә дә ялгыш килеп чыга, дигән иде. Хәтеремдә, башкаладан килгән кунакларның берсе шунда Непримеровны пессимист дип атаган иде... Кем хаклы?

— Беләсезме, мин алай өзеп әйтергә ашыкмас идем. «Тизрәк ЭВМ[1] бирегез безгә!» дип бүрек чөю дә начар, уңайлы объектив шарт туганны көтеп яту да әйбәт түгел. Минем үземә калса, Непримеров фикере игътибарга лаеклы. Мәсәлән, безнең объектлардагы барлык приборларның паспортында төгәллекләре плюс-минус ике процент дип язылган. Кибернетик машиналардагы плюс-минус ике процент төгәлсезлек — акылга сыймаслык нәрсә бит ул. Татарстан масштабында ни дигән сүз андый төгәлсезлек? Миллионлаган сум акча, миллионлаган тонна торба, цемент, балчык дигән сүз... Ә чынлыкта безнең приборлар, беренчедән, ун процентка алдашалар, икенчедән, аларның күбесен яңадан эшләргә, өр-яңадан төзергә кирәк. Анысы прибор ясаучыларның бурычы. Автоматик система, производство белән идарә итүнең иң югары формасы буларак, кешеләргә практик эштә ярдәм итеп кенә калмый, аларның эшенә сыйфат ягыннан бөтенләй икенче таләпләр, тагы да зуррак таләпләр куя.

— Газета-журналларда әледән-әле нефтьчеләр тормышы турындагы фотографияләр басылып тора. Әйтик, менә мондый бер фото: вышка тора, вышка әстеннән фонтан ата, тирә-якта кешеләр шат-

[1] Электронлы хисап машинасы.

ланышып кул болгыйлар, бүрек чөялэр. Э минэ Татарстан промыселларында төшереп алган андый рэсемнэрне күргэнем юк минем.

— Минемчэ, бу сорауга репортерлар үзлэре җавап бирсеннэр. Минем үземнең андый фонтанны күргэнем юк. Фонтан — гадэттэ булмаган хэл, брак дигэн сүз ул, аңа сөенергэ түгел, еларга кирэк. Язучылар үзлэре дэ китапларының соңгы бүлеген китапның уртасында, башын ахырында күрсэлэр, сөенмэслэрдер, шэт. Нефтьчелэрнең шундый бер сүзе бар: «Скважина кую — бер эш булса, аннан нефть чыгарту — ике эш»,— дилэр. Корыч торбалар эченэ кертелгэн нефтьне моторларның каны, зур химиянең азыгы дип атыйлар. Аңарчы нефть беркемгэ дэ буйсынмаган дуамал бер көч эле ул. Кеше аның хуҗасы булырга да, чарасыз бер колы булып калырга да мөмкин. Эллэ кайда җир астында кешегэ күренмэгэн зур бер эш эшлэнэ, һэм нефть ташкыны арматураларны ватып-җимереп тышка бэреп чыга, бөтен тирэ-юньне басып китэ, яисэ эйбэт кенэ эшлэп утырган скважина кинэт тыгылып, тынып кала, бернинди тылсым да аңа җан кертэ алмас шикелле тоела.

Вышка өстеннэн бэреп чыккан нефть ташкынын туктату җиңел эш түгел, эмма иң кыены — башкасы. Татарстан промыселларының егерме биш еллык гомерлэре бар инде, республикада зур нефть эшен башлаган яшь эшчелэр ветераннар булдылар, лэкин аларның күбесенең фонтан күргэннэре юк, чөнки нефтькэ җир өстенэ бэреп чыгарга юл куймыйлар. Иң зур кыенлык — сүнеп барган скважиналарның гомерен озынайту.

Промыселлар озаграк эшлэгэн саен нефтьне азрак бирэ баралар, еш кына тынып та калалар. Кайбер промыселларда нефть чыгаручылар һэм сүнгэн скважиналарны терелтүчелэр бергэлэп эшлилэр. Моның сэбэбе шул — һэр мэйдан, һэр участок өчен аерым промыселлар төзелэ. Болай итү — эшне оештыру ягыннан уңайлырак, җиңелрэк. Җирнең эчке катламнары кешегэ буйсынмый, анда аның үз законнары хэрэкэт итэ һэм бердэм геологик структура үзара бик аз бэйлэнгэн аерым-аерым өлешлэргэ бүлгэлэнгэн булып чыга. Татарстан промыселларында ремонт эшлэрен бик нык специальлэштерү юлына күчтелэр, скважиналарга капиталь ремонт ясау һэм катламнарның нефть бирүен арттыру буенча подразделениелэр төзелде, шуңа эшне бик яхшы белэ торган ике меңлэп кеше сайлап алынды. Һэм аңарга нибары бер эш — Ык елгасыннан алып Кама аръягына чаклы булган арадагы скважиналарны тергезү эше йөклэнде. Өстэвенэ, белгечлэрне сайлаганда күп белүлэренэ карап кына түгел, зур практик белеме өстенэ, иренмичэ, җентеклэп тикшеренэ белүенэ карап та алдык. Чөнки бер скважина икенчесенэ охшамаган, һэр очракта мэсьэлэне яңача, үзенчэ хэл итэргэ кирэк. Идарэнең башлыгы В. Каменев менэ унбиш ел инде сүнгэн скважиналарны терелтү эше белэн шөгыльлэнэ. Баш геолог А. Сафиуллин — оператор булып эшлэгэн кеше, кичке институтны тэмамлады; мастерлар Г. Хөсэенов, Р. Эхмэтҗанов һэм башка ремонтчылар да — бик яхшы белгечлэр, эштэге тэҗрибэлэре өстенэ, аларда зур инженерлык сэлэте дэ бар. Мондый исемнэрне байтак тезеп китэргэ булыр иде. Барыннан да бигрэк, бу зур тату коллективны берлэштерэ торган уртак сыйфатны эйтеп китэсе килэ. Ул сыйфат — үзеңнең зур бер мөһим эш башкарганыңны аңлау, һэркем үзлэреннэн соң инде эшне икенче бер кеше эшлэмэячэген, скважинаны тергезү дэ, сүндерү дэ үзлэре кулында икэнен аңлап эшлилэр.

— Эшне күпме эшлэнүенэ карап түгел, бэлки аннан нинди файда килүенэ карап бэялилэр. Ремонт эшлэрен алай оештырудан нинди файда бар?

— Мәсәлән, Миңлебай мәйданының иң уэзгендә 3484 нче точка бар. Бу участок — атаклы Ромашкиноның җәүһәре. Монда тәүлегенә 50 шәр-100 әр тонна нефть бирә торган скважиналар бар. Ә 3484 тә көн-төн насос эшләп тә нибары 5 тонна гына нефть чыга иде. Насосны алмаштыру да файда итмәде. Скважиналарны юып та, парлап та, перфозарядлар белән тиштереп тә, катламны ваттырып та карадылар — берниндн файда булмады. Шуннан соң мондый бер тәҗрибә ясап карадылар. Ремонтчылар бик четерекле, катлаулы бер эш эшләделәр: катламга кырык тонна күкерт кислотасы кудырдылар һәм скважина нефтьне бермә-бер артык бирә башлады.

Мондый мисалларны йөзләп, меңләп китерергә мөмкин. Ремонтчылар скважинадан скважинага күчеп, моторларны алмаштыралар, кайвакыт нефтьне бер-ике тоннага арттыру өчен генә дә әллә ничә төрле физик һәм химик чаралар кулланалар. Татарстан күләмендә караганда бер тонна әллә ни күп түгел, йөз миллионнан бер өлеш кенә. Ләкин, тамчы тама-тама күл җыела, диләр бит. Бу яшь коллектив тергезгән скважиналар бер елда гына да миллион ярым тонна чамасы кара алтын бирделәр, ремонт эшләренә тотылган бер сум акча 1 сум 73 тиенлек продукция бирде.

— Катламнарның нефть бирүен арттыру — хәзерге нефть фәненең һәм нефть чыгару эшенең иң катлаулы, иң кыен мәсьәләләреннән берсе. Нефтьчеләрнең былтыр Мәскәүдә булган сигезенче бөтендөнья конгрессында иң төп темаларның берсе итеп җир асты хәзинәсе запасларын мөмкин кадәр тулырак, әрәм итмичә файдалану мәсьәләсе каралды. Нефть ятмаларында бик күп төрле чаралар кулланырга: бик зур фәнни-тикшеренү эшләре башкарырга, идарә итү эшен автоматлаштырылган системалар белән җиһазландырырга, сүнгән скважиналарны тергезергә һәм башка бик күп эшләр эшләргә кирәк, диделәр. Мондый чаралардан файда килерме?

— Һичшиксез киләчәк. Мәсәлән, табигать моңарчы кешеләргә үзенең җир асты байлыгының яртысын гына биреп килгән булса, Татарстан нефтьчеләре аны тагы 10—15 процентка арттырып, өстәмә рәвештә 300—350 миллион тонна нефть алырга исәп тоталар. Бу хәл үзе генә дә яңа бер нефть провинциясе ачуга бәрабәр.

Совет нефть фәненең атасы академик Губкин:

«Кешеләр үзләре сынатмасалар, җир асты сынатмас»,— дигән. Аның бу сүзләре чынга ашып бара.

Рафаэль Мостафин

# ҖӘЛИЛНЕҢ РУХИ ТУГАННАРЫ

Донбасс җире... Туп-туры булып әллә кайларга сузылган асфальт һәм бетон магистральләр як-ягында җиләк-җимеш агачлары үсә. Шахталар, эшче поселоклары, Мисыр пирамидаларына охшашлы терриконнар... Бакча эчендә утырган украин авыллары һәм биек морҗаларыннан төтен бөркелеп торган металлургия заводлары. Уңдырышлы басулар һәм кояшның рәхимсез нурлары ялаган ташлы далалар. Бу тирәләрдә җир өстенә пулялар һәм снаряд, мина ярчыклары яңгырдан да күбрәк яуган.

Ворошиловград өлкәсе буйлап сәяхәт итү бездә бик күп тәэсирләр калдырды, аларны бер тәртипкә китерүе дә авыр. Бу сәяхәт кан белән ныгытылган дуслык, күп милләтле Ватаныбызның бик күп уллары һәм кызлары гомере бәрабәренә яулап алынган туганлык турында кабат уйланырга мәҗбүр итте.

1942 елның мартында Волхов фронтында сугышкан Муса Җәлил «Туганлык» исемле шигырен яза. Бу шигырь чын пролетар интернациональ бердәмлек үрнәге булырлык. Ул тугандаш Украинаның гитлер оккупациясенең дагалы олтаны астында сыкраган чорда язылган:

Украина,
Минем туган илем —
Татарстанның туган апасы!
Яраланган лачын кошы булып,
Кан эчендә аунап ятасың.
Вәхши немец үтте
синең келәч
Кырларыңны таптап, яндырып.
Хатын-кызларыңны мыскыл итеп,
Уллрыңны үксез калдырып.

Топольләрең немец балтасыннан
Яраланып җиргә аудылар.
Сокланырлык зифа шәһәрләрең
Кәберлеккә охшап калдылар.

Пычратырга халкың мәхәббәтен
Тартынмады кулы палачның:
Ул хурлады таптап Днепрда
Изге кәберен бөек Тарасның.

Бу юллар мәсхәрәләнгән Украина җире өчен тирән сызлану белән сугарылган. Юк, алардан көчсез кызгану түгел, ә көчле нәфрәт, дошманнан үч алу омтылышы бөркелә:

Татарстан — синең туган энең
Дуслык антын эштә ныгытты.
Йортсыз калган ятим улларыңны
Кайнар кочагында җылытты.

Ата булды үксез балаларга,
Кием бирде киемсезләргә.
Көн-төн койды корал заводында
Уртак дошман муенын өзәргә.

Ул чакырды батыр егетләрен
Синең кырлар буйлап үтәргә
Һәм дошманны куып Днепрдан,
Туганнарны азат итәргә.

**Украина җирен фашист илбасарларыннан азат итү көнен Җәлил күрә алмады. Украинаны азат итү өчен башларын салган Татарстан батырларының исемнәре мемориаль такталарга мәңгелеккә алтын хәрефләр белән язылуын да ул белмәде. Әмма Җәлил халыклар дуслыгының җиңелмәс көченә һәрвакыт ышанды һәм шуңа күрә җиңәчәгебезгә бер минут та шикләнмәде.**

Бер ананың туган балалары —
Ташкын булып бергә кузгалдык.
Һичкайчан да һичбер көч алдында
Җиңелмәс бу изге туганлык.

* * *

Ворошиловград өлкәсендә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгында катнашучы һәркемнең бу сәяхәттә туган үз хисләре, үз уйлары бардыр. Миңа калса, иң тирән хисләр тудырганы — Краснодон геройлары белән бәйле урыннар булды. Краснодон шәһәрендә кая гына карама, кайда гына булма — һәр җирдә сугышларда һәлак булган, фашистлар җәзалап үтергән геройларның исемнәренә тап буласың. Төрле җәзалау кораллары куелган казематлар гестапочы палачларның ерткычлыгын искә төшерде... Алар мин анда булган вакытымда күргән төрмәләрдән асылда берни белән дә аерылмый. Фашизмның чын йөзе кайда да бертөсле...

Безнең күбебез А. Фадеевның «Яшь гвардия» романын балачактан ук укып, Краснодон геройлары белән рухланып, алар кебек булырга хыялланып үскән кешеләр. Краснодонга баргач, шуңа ышандым: язучы аларны сурәтләгәндә берни дә арттырмаган икән. Хәтта киресенчә, чынбарлык язучы фантазиясенә караганда да катлаулырак, киңрәк, рәхимсезрәк булган икән.

Минем өчен, мәсәлән, Краснодонда яшерен оешмада катнашучылар арасында безнең якташларыбызның, Татарстаннан киткән кешеләрнең дә булуы яңалык иде.

1942 елның 20 июлендә немецлар Краснодон шәһәренә бәреп керәләр. Һәм берничә көннән соң ук инде, провокатор доносы буенча, үзәк мәйданда яшерен оешманың ике членын — ике бертуган геройны — Яков һәм Михаил Бикмеевләрне асып үтерәләр. Бу якларда гадәткә кергәнчә, исемнәрен алар, мөгаен, руслаштырганнардыр. Ә фамилияләре татарча. Кызганычка каршы, бертуган бу ике герой турында мин əстәмә документлар таба алмадым. Аларның фашистлар тылында яшерен эш алып бару өчен партия комитеты кушуы буенча калдырылган икәнлеген генә белә алдым. Шушы ук көннәрдә партия заданиесе белән калдырылган М. Б. Поляков, А. В. Әхмәтов, И. Г. Пархоменко, Ши-Та-фу һәм Е. Саранча да фашистлар тоткынлыгына эләгә һәм соңрак ерткычларча җәзаланып үтерелә. Күрәсезме, төрле милләт вәкилләре уртак Ватан өчен бергәләшеп көрәшәләр һәм бергәләп һәлак булалар.

1943 елның февралендә, Краснодон шәһәре азат ителгәннән соң, полиция идарәсе ишек алдында искиткеч күренеш безнең сугышчыларны гаҗәпкә калдыра. Анда

җәзаланып үтерелгән, йөзләрә танымаслык хәлгә китерелгән совет кешеләренең мәетләре әрдәнәләп өелгән була. Бары тик җидесеннән генә документлар чыга. Шулардан: Садыйков Форман, 1918 елда туган, Нурбаев, Юсупов. Алар да, мөгаен, безнең якташларыбыз — татарлар булгандыр. Әмма хәзергә әле безгә алар турында берни дә билгеле түгел, хәтта исемнәрен дә тогәл белмибез.

1942 елның 29 сентябрендә фашистлар Краснодонда тагын бер ерткычлык эшлиләр: үзләренә эшләмәгән өчен 32 шахтерны кулга алалар да, башкаларга сабак булсын дип, шәһәр бакчасында чокыр казып терелэй күмәләр... Бу урынга хәзер геройларга һәйкәл куелган. Алар арасында да татар фамилияләре бар. Үзеннән-үзе Сибгат Хәким шигырендәге түбәндәге юллар искә төшә:

Батырлар бар җирдә —
татарлар бар
Кимендә бер урын татарга...

Шуны да сүз уңаеннан әйтергә кирәк, нәкъ менә шушы коточкыч вакыйга «Яшь гвардия» оешмасы төзелүгә этәргеч бирә.

Шахтерларны җәзалаганнан соң икенче көндә, яшерен партия үзәге җитәкчеләре Ф. П. Лютиков һәм Н. П. Баранов заданиесе буенча, коммунист Евгений Мошков «Яшь гвардия»нең беренче оештыру утырышын үткәрә. Штаб булдырыла, аңа Иван Земнухов, Сергей Тюленин, Виктор Третьякевич һәм Василий Левашев кертелә. Аларга соңрак Любовь Шевцова һәм Ульяна Громова өстәлә. «Яшь гвардия»нең комиссары итеп Олег Кошевой, командиры итеп Иван Туркенич билгеләнә.

Яшьгвардиячеләрнең эш ысуллары җәлилчеләрнекенә бик охшаш. Һәр ике оешмада да яшерен рәвештә дә эш алып баралар, легаль мөмкинлекләрне дә киң файдаланалар. Алар, җәлилчеләр кебек үк, «артист»лар булып чыгышлар ясауны уңышлы кулланалар. Яшерен оешма членнары көннән-көн арта бара, ә квартираларга җыелышып, эшләнәсе эшләрне билгеләү куркыныч. Шуңа күрә җыелышу өчен Горький исемендәге клубны сайлыйлар. Н. П. Баранов рекомендациясе буенча Евгений Мошков клуб директоры булып, Иван Земнухов администратор, ә Виктор Третьякевич художество җитәкчесе булып урнаша. Яшерен оешманың бүтән членнары клубның үзешчән артистлары буларак җыелышалар.

Әмма яшьгвардиячеләр белән җәлилчеләрне берләштергән төп нәрсә боларда гына түгел, ул да булса — искиткеч рухи ныклык, коммунистик ышаныч һәм җан-тән белән Ватанга бирелгәнлек.

* * *

Өч ел элек Краснодон шәһәрендә «Яшь гвардия» музееның яңа бинасы салынып бетә. Пыяла һәм бетоннан эшләнгән тигез дүрт почмаклы бу бина төгәллеге, гадилеге белән ерактан ук игътибарны үзенә тарта. Музей бинасы эчендә яктылык һәм һава мул, кино күрсәтү, лекцияләр уку өчен махсус уңайлы заллар, китапханә бар. Әмма безнең күзебез иң беренче шуңа төште: бинаның фасадына «Яшь гвардия»нең фашистлар кулыннан һәлак булган барлык членнарының исем-фамилияләре эре хәрефләр белән язып куелган. Ә алар йөзгә якын бит... Бу гүзәл бинаны карап йөргәндә, безнең делегация составыннан кемдер әйтеп куйды:

— Казанда да берзаман Муса Җәлилгә багышланган шушындый ук музей ачылыр әле,— диде.— Ә фасадына, мондагы кебек үк, фашист балтасы астында һәлак булган җәлилчеләрнең исем-фамилияләре язылган булыр!..

Без музей залларын зур дулкынлану белән карап йөрдек. Дәфтәр битләренә ярым балаларча итеп, кул белән язылган листовкалар инде вакытлар үтүдән саргайган... Андагы нәфрәт сүзләре мәсхәрәләнгән туган җир өчен, ата-аналарның, туганнарның үлеме өчен үч алырга чакыра...

Соңрак оешма членнары шрифтлар да булдыралар һәм яшерен типография оештыралар. Оешма утызлап исемдәге листовка бастыра, аларның тиражы 5 мең данәдән артып китә.

Стендларның берсенә корыч аркан кисәге куелган. Сорокина № 1 шахтасында бу арканны, Н. П. Баранов заданиесе буенча, яшьгвардияче Ю. Вицековский игәүләп кискән. Фашистлар бу шахтаны көч-хәл белән торгызып, ходка җибәрергә әзерләнәләр. Ниһаять, ул эшли дә башлый. Әмма икенче көнне үк күтәргеч корыч аркан өзелә һәм шахта, коесы җимерелеп, ябыла. Шулай итеп, гитлерчылар Краснодон шахталарыннан бер вагон да күмер ала алмыйлар.

Ул вакытта «Кара биржа» дип даны чыккан хезмәт биржасына ясалган тәвәккәл һөҗүмне сурәтли торган документлар һәм фоторәсемнәр дә күп кенә. 1942 елның декабрендә гитлерчылар Краснодон районыннан ике меңгә якын егетләрне һәм кызларны Германиягә җибәрү өчен барлык документларны әзерләп бетерәләр. Аларның исем-фамилияләре, адреслары тутырылган анкеталары — хезмәт биржасында. Инде җибәреләсе көн дә билгеле. Менә 6 декабрьга каршы төндә кинәт биржа бинасы өстендә ялкын күтәрелә. Барлык кәгазьләр янып бетә. Ике меңгә якын совет яшьләре фашист коллыгыннан коткарыла. Ә бу операцияне Сергей Тюленин, Любовь Шевцова һәм Виктор Лукьянченко башкара.

Миндә иң зур тәэсир калдырганы бер кечкенә һәм гади генә әйбер — Ульяна Громованың куен дәфтәре булды. Ул бу кенәгәгә күңеленә якын цитаталарны, афоризмнарны, төрле язучыларның фикерләрен язып барган. Менә Джек Лондон сүзләре:

> *«Геройның үлемен карап тору нинди дә булса кызганыч куркакның рәхим-шәфкать сорап ялваруын тыңлап торуга караганда җиңелрәк».*

Гамлет монологыннан өзек:

> *«Мин яхшы күңелле булу өчен*
> *Рәхимсез булырга тиешмен».*

А. П. Чехов, Л. Н. Толстой, А. М. Горький, Николай Островский фикерләре...

Бу кенәгәне актарганда Ульянаның кеше булып җитлегүен, классик язучыларның әсәрләре йогынтысы астында дөньяга карашының кинәюен күрәсең. Ул төрле катлаулы тормыш мәсьәләләре турында күп уйлана, үзен борчыган төрле проблемаларга җавапларны китаплардан эзли.

> *«Кешенең ныклы ихтыяр көченә нәрсә каршы тора ала?*
> *Ихтыяр көче үз эченә бөтен рухи дөньяны ала, теләк — куралмау, ярату, кызгану, шатлану, яшәү дигән сүз, кыскасы, ихтыяр көче һәр җан иясенең әхлакый көче, нәрсәне дә булса төзүгә яки җимерүгә юнәлдерелгән ирекле омтылыш, юк нәрсәдән искиткеч нәрсәләр булдырырга сәләтле иҗади власть!*
>
> **М. ЛЕРМОНТОВ».**

> *«...Кешенең үз-үзеннән ризасызлыгы, аның хәзергә караганда яхшырак булырга омтылышы изге, аның үзе тарафыннан үк барлыкка китерелгән барлык чүп-чарларга карата яшәештәге нәфрәте изге, аның җир йөзеннән көнләшү, комсызлык, җинаять, авыру, сугыш һәм кешеләр арасындагы дошманлыкны бетерү теләге изге, аның хезмәте изге.*
>
> **М. ГОРЬКИЙ».**

Ульяна Громованы кызыксындырган һәм аның үз уй-хисләренә якын булган бу җитди фикерләрне укыганда, мин шул турыда уйладым: әйе, батырлык юктан гына

барлыкка килми. Шулай ук хыянәт тә. Хуш ис бөркеп торган гүзәл роза чәчәге үссен өчен, эшкәртелгән, уңдырышлы туфрак кирәк. Ә ташландык җирләрдә шайтан таягы үсә.

Уля бөтен эчке дөньясы белән батырлыкка әзер була. Башка яшьгвардиячеләр кебек үк, ул да аңлы рәвештә эш итүче көрәшче була һәм үз иманы, үзенең дөньяга карашы өчен гомерен бирә. Әмма яшьгвардиячеләрнең барысы да аның кебек булмый.

Оешмада Почепцев дигән кеше дә була. Аны мәктәп елларыннан ук яхшы беләләр. Тыйнак һәм астыртын бер малай була ул. Укытучылардан курка, көчле укучылар белән бәхәскә керми. «Кеше кая — мин шунда» дигән принцип белән яши. Әмма аның үз-үзен тотышына иптәшләре җитди игътибар бирмиләр. Ләкин Почепцевның нәкъ әнә шул сыйфаты «Яшь гвардия» оешмасын һәлакәткә китерә.

1942 елның 26 декабрендә «Яшь гвардия» штабында шәһәргә немец солдатлары өчен яңа ел бүләкләре төягән йөк машиналары туктаганын белеп алалар. Штаб бу машиналарны «бушатырга» карар кабул итә. Кыю операция уңышлы тәмамлана, бүләкләр төрле урынга яшерелә, бер өлешен Горький клубына китереп урнаштыралар.

Оешма членнары бу вакытта акчасызлыктан интегәләр. Ә акча полицайларны сатып алу, кызылармеец семьяларына ярдәм итү өчен кирәк. Шуңа күрә Евгений Мошков яңа ел бүләге итеп китерелгән сигаретларның бер өлешен базарга чыгарып сатарга карар кыла. Шул ук вакытта гестапо полиция начальнигы Соликовскийдан бүләкләрне урлаучыларны ничек кенә булмасын табуны таләп итә. Барлык полицайлар аякка бастырыла. Һәм менә базарда, сигарет сатып торганда, бер яшүсмер тотыла. Кыйнауларга түзә алмыйча, ул үзенә сигарет биргәннәрнең фамилияләрен әйтә.

Беренче январь көннең иртәсендә фашистлар Евгений Мошковны, Виктор Третьякевичны һәм Иван Земнуховны тотып алалар. Аларны бик каты кыйныйлар, әмма егетләр нык торалар, бер сүз дә әйтмиләр. Егетләрне бары вак-төяк урлашуда гаепилиләр, «Яшь гвардия» оешмасы турында башларына да китермиләр. Мөгаен, кулга алынган егетләрне ирекка чыгарган да булырлар иде. Полиция начальнигы аларны тагын бер кыйнап, куып чыгарырга да боерган булган. Әмма квартирларында соңгы тапкыр тентү ясарга алып барган вакытта тәрәзәдән аларны Почепцев күреп кала. Фашистлар «Яшь гвардия»нең эзенә төшкән дип белеп, үзенең тормышын саклап калу өчен, ул полициягә гариза яза. Анда яшерен оешма турында, аның җитәкчеләре һәм күп кенә членнарының исем-фамилияләрен дә әйтә. Шул ук көнне кулга алулар башлана...

Минем хәтергә җәлилчеләрне саткан хыянәтче Мәхмүт Ямалетдинов килде. Сугышка кадәр шулай ук аны да тыйнак, тәртипле егет буларак кына белгәннәр. Немецларга әсир төшкәннән соң, ул да бары тик бер нәрсә: исән калу турында гына уйлый. Һәм менә дигән кешеләрне харап итә. Ләкин мәртәтләр халык нәфрәтеннән котылып кала алмадылар, икесе дә хәрби трибунал алдына бастылар...

* * *

— Хәзер сезне, — диде партиянең Краснодон шәһәр комитеты секретаре Людмила Андреевна Ерохина, — яшерен оешманың партия җитәкчесе Филипп Петрович Лютиковның хатыны Евдокия Федотовна Лютикова белән таныштырам.

Сәхнә өстенә гади күлмәк кигән, башына зәңгәр яулык бәйләгән олы яшьтәге бер хатын чыгып басты. «Яшь гвардия» романының беренче редакциясенә карата партиянең әйдәүче роле тиешенчә яктыртылмавы турында әйтелгән тәнкыйть сүзләре хәтергә төште.

Никадәр дөрес булган ул тәнкыйть!

Лютиковага инде җитмеш тугыз яшь икән. Шулай да ул урындыкка утырмады. Акрын гына тавыш белән сөйләп китте:

— Бөек Ватан сугышы башланганда ук минем ирем шактый олы яшьтә иде инде. 1941 елның кышында без аңа илле яшь тулуны билгеләп үтәргә җыена идек.

1942 елның 12 июлендә Филипп Петрович мине, унеч яшьлек кызым Рая һәм аны карчык белән бергә, эвакуациягә озатты. Үзенең документларын: Хезмәт герое таныклыгын, партия һәм совет оешмаларыннан бирелгән рәхмәт кәгазьләрен, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены таныклыгын миңа тапшырды. Саубуллашканда болай диде: «Сезгә монда калырга ярамый, ә мин калырга тиеш. Илебез өстенә зур куркыныч килде — сез моны аңларга тиешсез...»

Бу вакытта әле Евдокия Федотовна, Краснодонга немецлар якынлашкач, Ленин чакыруы буенча партия сафына баскан саф йөрәкле коммунист Филипп Петрович Лютиковның дошман тылында яшерен оешма төзү буенча сөйләшү өчен беренчеләрдән партия райкомына чакырылуын белми. Гражданнар сугышы ветераны Филипп Петрович — царизмга һәм акгвардиячеләргә каршы көрәш чорында ук яшерен эш алып бару буенча зур тәҗрибә туплаган кеше.

Дөрес, электромеханика мастерскойлары начальнигы, революционер-коммунист шәһәрдә күпләргә таныш. Әмма оккупантларга да зур квалификацияле белгечләр кирәк. Лютиков гитлерчыларга эшләргә ризалык бирергә тиеш.

Оккупациянең беренче көннәрендә үк Ф. П. Лютиков 10 номерлы дирекцион канцеляриягә килә һәм механик булып эшләргә теләк белдерә. Әлбәттә, бу бик тәвәккәл адым була. Аның кебек күренекле коммунистларны немецлар, гадәттә, судсыз һәм тикшерүсез атып үтерәләр. Әмма Лютиков үзенең үткән тормышы турында «берни яшермичә» сөйләп бирә. Һәм аны мастерскойларның прорабы итеп билгелиләр. Беренче көннән үк Лютиков үз тирәсенә ышанычлы кешеләрне тупларга керешә, соңрак шәһәрдәге һәм якын-тирә поселокларлагы яшьләр, антифашистик төркемнәр белән бәйләнешкә керә. «Яшь гвардия» оешмасының турыдан-туры партия җитәкчесе нәкъ менә ул була.

...15 январь төнендә Краснодон батырларының беренче төркемен җәзалап үтерергә алып барганын күрүчеләр бар. Алар Лютиковның, комсомолецлар белән бергә, Ильич яраткан «Үч белән ярсыдык дошманга» җырын җырлаганын ишетәләр...

Лютиковның гәүдәсен шахта шурфы төбеннән иң соңыннан табып алалар. Димәк, ул үлемне беренчеләрдән булып каршы ала...

Бу турыда сөйләргә керешкәч, Евдокия Федотовна чайкалып китте, кемдер тиз генә китереп куйган урындыкка утырды. Стаканга су салып бирделәр. Нәрсәдер әйтергә ымсынды, ләкин авызыннан бер сүз дә чыкмады. Аннары яулык чите белән күзләрен сөртеп алды.

Соңрак фәнни хезмәткәрләр бүлмәсендә Краснодон яшерен оешмасындагы партия җитәкчелеген ачык расләп торган күп кенә материаллар белән таныштым.

Оккупациягә кадәр ике-өч ай элек Краснодонга берничә тапкыр партиянең Украина Үзәк Комитеты секретаре Д. С. Коротченко килә. Ул коммунистлар белән очрашулар, киңәшмәләр үткәрә. Очрашу урыннары, парольләр билгеләнә, азык-төлек һәм дарулар өчен базалар булдыру мәсьәләләре карала. Партизан отряды оештырыла. Яшерен оешма белән җитәкчелек итү чыныккан коммунист Ф. П. Лютиковка тапшырыла.

Әйе, «Яшь гвардия»не оештыруда һәм аның белән җитәкчелек итүдә Филипп Петровичның роле гаять зур. «Яшь гвардия» романының авторы әсәрен юкка гына кабат эшкәртмәгән һәм аңа юкка гына партия оешмасының ролен яктыртып торган яңа бүлекләр өстәмәгән.

* * *

Краснодон геройларының фоторәсемнәре... Барысы да яшьләр, ачык, саф йөзлеләр. Барысы да матурлар, аларның чырайларыннан яшьлек гүзәллеге генә түгел, рухи гүзәллек, рухи омтылыш, үз-үзләренә нык ышаныч балкып тора.

Каршы якка 5 номерлы шахта шурфыннан җитмеш бер мәетне чыгару күренеше эленгән. Һәрберсенең гәүдәсе танып булмаслык дәрәҗәдә имгәтелгән... Ә берничә дистә краснодончылар Ровеньки һәм башка урыннарда атып үтерелгән.

Советлар Союзы Геройлары Олег Кошевой, Иван Земнухов, Любовь Шевцованың әниләре, Ульяна Громованың әтисе хәзер дә Краснодонда яши. Без шуларның берсе — Анастасия Ивановна Земнухова белән генә очраша алдык.

Анастасия Ивановна инде сиксәннән узган, авыру аякларын көч-хәл белән генә хәрәкәтләндереп йөри. Кара яулык астыннан чал чәчләре күренеп тора. Әмма хәтере әле бик яхшы, аның сүзләре йөрәккә тирән үтеп керә, күңелдә онытылмаслык эз калдыра.

— Нәрсә сөйлим икән соң мин сезгә, күгәрченкәйләрем,— дип сөйләп китте ул, көйләп кенә.— Улым турында, Ванюша турында сөйлимме икән... Аларның эше турында мин ул вакытта берни дә белмәдем шул...

Шулай да аның сөйләгәннәреннән яшерен оешманың куркусыз члены Иван Земнуховның образы шактый тулы булып күз алдына килеп басты.

Ваня Земнухов яшьтәшләре арасында үзенең җитдилеге, пөхтәлеге белән аерылып тора. Тирән белемле, һәрвакыт җитди чырайлы булуы өчен сабакташлары аны «профессор» дип йөрткәннәр. Ул төрле юк-бар уеннарга катнашырга яратмаган, буш вакытның һәр минутын файдалы итеп үткәрергә тырышкан.

Партия сешмасы белән элемтә нәкъ менә Иван Земнухов аша алып барыла. Ваня «Яшь гвардия» оешмасына керергә теләк белдерүчеләрне тикшерә, листовка текстларын яза. Шифрлар һәм кодлар да аның кулында була.

— Оккупация елларында,— дип дәвам итте Анастасия Ивановна,— бик авыр яшәдек. Өйдә ашарга да, бер тиен акча да юк вакытлар еш була иде. Ачлыктан ирем, Ванякың әтисе, урыннан тора алмас хәлгә җитте. Туклыклы азык булса аякка басар иде. Әмма бер йотым сөт табарга да мөмкинлек юк иде. Мин вакыт-вакыт еларга керешәм. Ә Ваня, җилкәмнән кочаклый да: «Тынычлан, әнием, инде күп калмады, барысы да яхшыга бара»,— ди торган иде.

Мин аңа: «Эшкә урнашасыңмы әллә, Ванюша,— дим,— әз булса да өйдә ашарга ипи булыр иде. Ә ул: «Юк, әнием, немецларга эшли алмыйм. Тиздән безнекеләр килер, элеккечә яшәргә керешербез»,— диде.

Бик авыр булса да, түзә идем, ул белемле кеше, начарлыкка бармас, дип уйлый идем.

Ничектер беркөнне врач чакырдык. Аңа рецепт язарга кәгазь кирәк булды. Өстәл тартмасын ачып карасам, ни күзем белән күрим — акчалар, бик күп акча... Өстәлне тиз генә ябып куйдым. Бу турыда беркемгә дә бер сүз дә әйтмәдем. Әмма йөрәгем сыкрады: әтисе ачлыктан үләргә ята, ә аның өстәл тартмасында никадәр акча!..

Анастасия Ивановна кичен, улы өйгә кайткач, Ваняга үпкәсен белдерә. Ваняның йөзе караңгыланып китә, бөтенләй боегып кала. Әнисе янына килә дә кочаклап ала һәм: «Минем акчалар түгел алар, әнием,— ди.— Тиенenә дә кагылырга хакым юк».

Анастасия Ивановна улының чын күңелдән әйткән сүзләренә ышана, башка ул турыда сүз кузгатмый.

Әлбәттә, ана бу акчаларның «Яшь гвардия» штабыныкы икәнен белмәгән. Ул акчаларны оешма членнары листовкалар бастыру, кызылармеец семьяларына ярдәм итү өчен тотканнар. Люба Шевцова, мәсәлән, бервакыт, шул акчага немец каравылчысын сатып алып, ике хәрби әсирне азат итә. Ольга Иванцова полициягә эләккәч тә шул акчалар ярдәмендә азат ителә.

Ваня өендәге авыр хәл турында оешмада бер сүз дә чыгармый. Шулай да яшьгвардиячеләр бу турыда белеп алалар һәм Земнуховлар семьясына ярдәм оештыралар.

Мошков белән Третьякевичның кулга алынуын ишеткәч, Ваня Земнухов иптәшләрен коткару өчен үзе полициягә бара. Әмма аны бүтән чыгармыйлар. Сорау алган вакытта кыйныйлар, җәзалыйлар, төрлечә мәсхәрәлиләр. Фашист тикшерүчесе таяк белән бар көченә аның күзлегенә суга. Күзлек пыяласы челпәрәмә килә һәм күзләренә керә. Ваня сукырая. Җәзаларга аны күзләрен бәйләгән хәлдә алып баралар һәм шахтага тере килеш ташлыйлар. Өч көн буена шахтадан имгәнгән яшьгвардиячеләрнең ыңгырашулары ишетелеп тора. Ләкин немецлар шахта янына беркемне дә якын китермиләр. Аннан барысы да тына...

Хәзер бу урынга обелиск куелган, ә шахта шурфы патриотлар истәлегенә элекке хәлендә саклана...

* * *

Музей экспонатларын зур кызыксыну белән карап йөргәндә, кемдер иңемә төртеп болай диде:

— Карагыз әле, Радик Юркин!

Бер читтәрәк шактый тулы гәүдәле, урта яшьләрдәге бер ир утыра иде. Җилкәләре салынган, карашы каядыр билгесез бер ноктага текәлгән. Ул үзенә төбәлгән дистәләгән күзләргә бөтенләй игътибар итми.

— Сугыштан соң авиациядә хезмәт иткән,— диде миңа әлеге кеше.— Хәзер автоколоннада механик булып эшли.

Чигәләре чаларган... Күз яннарында һәм ирен тирәләрендә тирән җыерчыклар... Нечкә, балалар тавышы белән яшьгвардиячеләр анты биргәннән соң, Олег Кошевой кулыннан үзләре ясаган бланкка язылган вакытлы комсомол билетын алган кечкенә Радикка бернинди охшашлыгы юк кебек.

Соңыннан ачыкланды: Радий Петрович Юркинны да безнең белән очрашуга чакырган булганнар икән. Әмма ул чыгыш ясамады. Очрашуда да ахырына кадәр утырмады. Мин аны музейдан чыгып барганда куып җиттем.

— Радий Петрович, тыйнаксызлыгым өчен гафу итегез. «Казан утлары» журналы укучылары өчен берничә сүз әйтмәссезме икән!..

Юркин, туктапып тормастан, миңа карап куйды, иреннәренең бер кырые белән генә елмайгандай итте. Сорашулардан, сөйләшүләрдән туеп беткәнлеге сизелеп тора иде. Әйтергә генә җиңел: «Яшь гвардия» музееи ел саен йөзләрчә мең кеше карый. Быргылар кычкыртып, барабаннар кагып, колонналарга тезелгән пионер отрядлары килә, илебезнең төрле почмакларыннан комсомол-яшьләр делегацияләре агыла, стройга тезелеп тә, аерым-аерым да хәрбиләр килеп тора... Ә музейдагы әйберләр Юркин өчен гади экспонатлар гына түгел, алар аның үткәне белән бәйле, тормышының бер өлешен тәшкил итәләр. Бу гранит плиталәр астында аның сугышчан дуслары ята, анда Радикның сугышчан яшьлеге күмелгән...

Без Яшьгвардиячеләр мәйданын уздык, скверга җиттек. Мин тагын бер чараны кулланып карарга булдым. Портфелемнән «Герой-шагыйрь эзләре буйлап» дигән китабымны чыгардым да Радий Петровичка суздым.

— Беләсезме нәрсә, мин бит Муса Җәлил тормышын һәм иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнәм. Ә сезнең оешма белән Җәлил оешмасы арасында шактый уртаклыклар бар.

Радий Петрович адымнарын акрынайтты, аннары бөтенләй туктап калды һәм юл кырыендагы скамьяга утырды да китапны актарырга кереште. Мин шуннан файдаланып сорау бирергә ашыктым.

— Яшьгвардиячеләр антын ничек биргәнегез турында сөйләсәгез иде...

— Ноябрь башында «Яшь гвардия» штабы бер төркем яңа членнарга задание бирде: Ворошилов исемендәге мәктәп түбәсенә кызыл флаг кадарга! Без бу заданиене үтәдек. Үнике кеше идек. Кичке алтыда Яшерен квартирага җыелыштык. Олег берәмләп чакырды һәм без аның артыннан ант сүзләрен кабатладык: «Яшь гвардия»гә кергәндә коралдаш дусларым алдында, күп газаплар кичергән туган җир алдында, барлык халык алдында өлкән иптәшләрем тарафыннан бирелгән һәр заданиене бер сүзсез үтәргә тантаналы рәвештә ант итәм...»

Ант биргәннән соң, без яңа заданиене үтәргә киттек. Безне 22 нче шахтага җибәрделәр. Сугыш кирәк-яраклары, патроннар, гранаталар алып кайтырга тиеш идек. Анысын да үтәдек.

— Туктагыз әле, Радий Петрович,— дип бүлдердем мин аны.— Сез сөйләгәнчә бик җиңел килеп чыга. Задание бирделәр — үтәдегез. Чынбарлыкта алай җиңел генә булмагандыр...

— Анысы шулай, әлбәттә,— дип елмайды Юркин.— Башта шома гына барган кебек иде. Көн кичкә таба авышкач кына шахтага килеп җиттек. Шәһәрдән шактый ерак иде ул шахта. Тавыш-тынсыз гына полицейскийны юк иттек. Кесәләргә гранаталар, патроннар тутырдык. Кайтканда караңгы төшкән иде инде. Яңгыр катыш кар ява, каршыга көчле җил исә... Алдан барган Дадышев белән Тюленин күздән югалды. Без дүртәүләп — Степа Сафонов, Володя Куликов, Сеня Остапенко һәм мин —

артта калдык. Шактый вакыт адашып йөрдек. Таң атканда гына шахта № 1-бис янына килеп чыктык. Юл табылганга шатланырга өлгермәдек, ачулы тавыш ишетелде: «Тукта! Кем килә!» Патруль. Ә безнең кесәләрдә гранаталар, кайберләребез аны хәтта капчык белән аркаларына күтәргән. Полициягә алып киттеләр...

— Курыккансыздыр!..

— Беләсезме, яшьлек, балалык галәмәтедер инде, әллә ни курыкмадык. Ни буласын күз алдыбызга китереп бетермн идек әле. Үзебезчә, шыңшыган булабыз, янәсе, бәрәңге алырга авылга бардык... Полицейский күзләрен уа-уа безнең ялганны тыңлады да без әйткән фамилияләрне язып алды. Биштәр күтәреп йөрүчеләр белән эш итеп туйганы күренеп торэ иде. Тентеп тә тормадылар, бүтән бармаска кушып, чыгарып җибәрделәр.

— Александр Фадеев романында түбәгә куйган кызыл флагны полицайларның озак вакытлар алырга җөрьәт итмәүләре турында әйтелә. «Мина куелган» дип юри генә язу кадаклаган идегезме!

— Юк, юри генә түгел. Танкка каршы кулланыла торган миналар куйдык. Флагның сабын минаның запалына беркеттек. Тотынсалар, көл булып күккә очачаклар иде...

— Тормыш кыл өстендә торган вакытлар еш булгандыр!

— Булмады түгел...

— Соңгы сорау. Ничек исән кала алдыгыз!

— Массовый рәвештә кулга алулар башлангач, минем янга Степа Сафонов килде. «Бөтен җирдә безне эзлиләр,— диде ул.— Хәзер үк качарга кирәк». Сергей Тюленинны да әлегә таба алмаганнар икән, квартираларында көн-төн полицайлар саклап тора, ди. Ә Тюлениннар яши торган йортның чормасында автомат һәм корулы өч диск саклана иде. Сережа белән миннән башка беркем дә бу турыда белми иде. Әгәр полицайлар бу автоматны тапсалар — Тюлениннарның бөтен семьясын атачаклар. Юлда да автомат кирәк булачак иде. Базарда Сережаның сеңелесен очраттым да ярдәм итүен сорадым. Ул ризалык бирде. Сережа сеңелесе чормада автоматны таба да капчыкка салып сарайга алып чыга һәм печән арасына яшерә.

Бер полицай өйнең эчендә, икенчесе ишек алдында саклап тора иде. Ишек алдындагысы тәмәке тартырга өйгә кергән арада мин автоматны сарайдан алдым да йөгердем...

Ә аннан Степа белән Краснодоннан качтык. Ул Каменскига китте, ә мин Красный Лучка. Юлда ике полицайны дөмектердек. Фашистларның бер җиңел машинасын җимердек. Анда шофердан башка ике немец офицеры бар иде.

— Иптәшләрегез өчен үч алдыгыз, димәк!

— Без ул вакытта аларның язмышы турында берни дә белми идек әле... Краснодоннан киткәч, баштан күп нәрсәләр үтте. Барысын да сөйләп бетерүе дә мөмкин түгел...

— Ә Сафонов белән ни булды!

— Һәлак булды ул... Минем якын дустым, сугышчан иптәшем һәлак булды...

Радий Петрович тынып калды. Аның күзләре тагын кырысланды. Әмма купкә түгел. Ул яныбыздан узып барган пионерлар отрядына күтәрелеп карады, йөзе җанланып, күзләре нурланып китте. Мөгаен, бу вакытта ул илгә тагын авырлыклар килсә, әтиләренең батырлыгын кабатларга әзер булган яңа буын, алмаш турында уйлангандыр...

## Габдрахман Минский

# «КАЗАН КЫЗЫ» ЯФРАК ЯРГАН ЯКЛАРДА

Без барасы «Ново-Айдаркино» совхозы Ворошиловградтан алтмыш чакрым ары, Көньяк үзәнлегендә урнашкан. Юлы төзек. Тирә-як җанлы: яшел хәтфә басулар, ак чәчәкләргә күмелгән сәрби куаклары, тагын да арырак күкшел урманнар — болар барысы да күңелләрдә илһам уятырлык. Ямь өстенә ямь булып мәшһүр Донец елгасы ага... Елга аръягында — зәңгәр офыкта — борынгы Афины пирамидаларына охшаган, өчпочмаклы шлак таулары, шахтерлар телендә аларны терриконнар дип йөртәләр. «Донбассантрацит» комбинаты шахтасында тау инженеры булып эшләүче язучы Вениамин Мальцев аңлатканча: «...ташландык рудалар җир өстен чүплиләр чүпләвен, ә шулай да бу терриконнар Дон якларының байлыгын күрсәтүче бер билге ул!» Бу чыннан да шулай. Донбасс пейзажын терриконнарсыз күзаллау гомумән мөмкин булмаган хәл.

Донбасста мин үзем икенче кат. Беренче кат бик авыр көннәрдә, Ватан сугышының беренче айларында, өстә соры шинель, кулда автомат булган хәлдә, вакытлы чигенү сугышларында катнашырга туры килгән иде. Донбассның аякка сыланучан кара балчыклы даласы буйлап күзгә йолдызсыз төннәрдә, җәяүле маршларда җәфа чигүләр әле бүген дә, утыз елдан артык вакыт узуга да карамастан, кичәгедәй хәтердә саклана. Ул төннәр газабы һәм совет кешеләрендәге шул газапны җиңеләйткән бердәмлек, дуслык көче безне, иҗат кешеләрен, яңа әсәрләр тудыруга да илһамландырган иде. Минем дә, мәсәлән, «Тамань», «Өчәү», «Бәби туе» кебек хикәяләрем әнә шул моннан утыз ел артта калган Донбасс төннәрен сурәтләүгә багышланганнар.

Һәм менә бүген без тагын Донбасс җирендә, аның иң алдынгы индустриаль үзәкләреннән берсе булган Ворошиловград өлкәсендә, ә бу юлы инде без зур әдәбият бәйрәме кунагы сыйфатында катнашабыз.

Безне алда Ново-Айдаркино, Северо-Донец, Рубежное һәм Кременное кебек район үзәкләре, химиклар һәм шахтерлар шәһәрләре көтә. Бу — безнең маршрут...

Дөресен әйтергә кирәк, маршрутыбыз күрсәткән юл белән, Ворошиловград кунак йортыннан, машиналарга утырып кузгалып китүебезгә, минем күңелдә ниндидер бер шик кузгалып куйган иде: ничек ерып чыгарбыз икән мондый маршрутны!

Әнә, партиянең өлкә комитетында аңлатканча, без шушы өч көнлек юлда совхоз эшчеләре, кошчылар, химиклар, шахтерлар, ГЭС төзүчеләр һәм фәннең иң соңгы казанышларыннан электрик исәп машиналарын көйләүче инженер-техниклар белән очрашырга тиеш булачакбыз. Әнә ничаклы алар! Ә без!! Без дүртәү: Гариф Ахунов, Айрат Арсланов, Марзия Фәйзуллина һәм шушы юлларның авторы, ягъни без фәкыйрегез, күмәккә Ворошиловград шагыйре Степан Бугорков белән өлкә комитеты вәкиле Полуянов иптәшләр...

Әмма әлеге шик шул ук көннең беренче очрашуыннан соң, кем әйтмешли, юкка чыкты.

Беренче очрашу.

Район үзәге булса да, бәләкәй генә төзек шәһәрчеккә охшаган һәм күләгәле куе тирәкләргә күмелгән, урамнарына асфальт җәелгән Ново-Айдаркинога килеп керәбез. Райком бинасы алдында безне башларына аллы-гөлле тасмалар катыш кыр чәчәкләреннән үргән таҗлар, өсләренә украиннар орнаменты чигелгән ак бәз күлмәкләр кигән, көньяк кояшы көйдергән алсу-каракучкыл йөзле украин кызлары каршы алып, бизәкле сөлгегә куелган ипи-тоз сузалар. Мондый изге минутлар, әлбәттә, дулкынлан-

дырмыйча кала алмый һәм без, җир йөзендәге барлык сый-хөрмәттән дә өстен булган бу изге икмәкнең тәмен татып карагач та, районның партия, совет һәм комсомол активы белән бергә, күптәнге танышлар төсле, гөрләшеп сөйләшә-сөйләшә, райкомга, аның беренче секретаре Петля иптәшнең кабинетына кереп утырабыз. Без килү хөрмәтенәдер инде, райком җитәкчесенең кабинеты бу минутларда бөркадәр гайре табигыйрәк төстә: кая карама — чәчәкләр, чәчәкләр, чәчәкләр...

Гадәти әңгәмә башлана.

Петля иптәш безне районның экономикасы һәм культурасы белән таныштыра.

Сүз безнең якка, ягъни Татарстан кунакларына килеп җитә.

Сүзне Гарифка бирәбез, ә ул — Татарстан турында документаль әсәрләр язган автор 20—30 минут дигәндә донбасслы дусларга безнең якларның эшләрен, байлыкларын, кешеләрен хикәяләп бирә. Әлбәттә инде, бу хикәяләрнең төп лейтмотивы булып Татарстан нефтьчеләренең миллиард тонна нефтьләре белән КамАЗ төзүчеләренең фидакарь хезмәтләре тора...

Шуннан соң «эшкә» күчәбез: район Культура йортында безне очрашуга көтәләр икән. Бригада җитәкчесе буларак, очрашуны мин башлап җибәрәм һәм гадәти кереш сүз урынына кайчандыр, ягъни дүрт-биш ел элек язылган «Хикмәтле көч» исемле бер бәләкәй хикәямне укыйм. Бу хикәяне язарга Татарстанның Чирмешән районы, Тукай исемендәге колхозы белән Украинаның Корсун-Шевченко районы, Щорс исемендәге колхозы арасындагы социалистик ярыш илһамландырган иде. Еллар узуга карамастан, кечкенә генә бер парчамның мондый «премьера»сы өчен куанып бетә алмыйча укыдым. Марзия Фәйзуллина, Степан Бугорков шигырьләрен укыйлар. Менә бервакыт трибунага Айратыбыз чыгып басты. Нәкъ Чехов төсмерләгәнчә... тышкы һәм эчке ягы белән дә, кеме-салымы белән дә пөхтә, әдәпле бу сәнгать остасы рус, украин шагыйрьләрен, Тукаебызны, аеруча Муса Җәлил шигырьләрен татарча да, русча да бердәй оста укуы белән тыңлаучыларны чын мәгънәсендә таң калдырды.

Минем, мәсәлән, Айрат Арслановны сәхнәдә берничә тапкыр күргәнем һәм тыңлаганым бар иде, әмма Ворошиловград атналыгындагы очрашуларда бу сүз остасы Татарстан сәнгатенең күренекле вәкиле һәм ялкынлы пропагандисты булып гәүдәләнде дисәм, бер дә арттырган булмамын. Шуңа күрә без барыбыз берьюлы: «Айратны әле дә бәяли алмый килгәнбез, кайтуга, «Казан утлары» өчен әдәби портретын язып бастырырга кирәк»,— дигән фикергә килдек.

Кыскасы, бу очрашулар күңелле башланды. Алда да күңелле очрашулар көтә безне. Алары турында, әлбәттә, Гариф язачак, чөнки блокнот аның кулда, блокнотка теркәлгәннәрнең авторы да ул. Тик мин бу язманы гаять бер күңелле факт белән төгәлләмәкче булам.

Безне совхозның «Дуслык паркы»на илттеләр. Бу паркның гаять якты һәм шул ук вакытта символик тарихы бар: парк халыкларның күмәк көче белән салына, үсә, күерә бара икән. Бу совхозга чит илләрдән һәм үзебездән килгән кунакларны шушы паркка илтәләр һәм алар анда агач утыртып калдыралар икән. Безгә моны паркка килеп кергәч сөйләп аңлаттылар. Һәм безгә дә шундый әйбәт эшне тәкъдим иттеләр. Тәкъдим итүләре булды, кулларыбызга көрәкләр алып, болгарлы дуслар утыртып киткән яшь тирәк янәшәсенә сылу кыздай төз һәм яшь бер ак каенны утыртып, төбен йомшартып өеп, туфрагына чиләкләп су биреп, мондый әйбәт эшебезгә үзебез дә ничек кенә соенергә дә белмичә торганда, арабыздан кемдер, Айрат булса кирәк: «Иптәшләр, әйдәгез, бу сылуга «Казан кызы» дип исем бирәбез», диюе булды, барыбыз да, хәтта хуҗалар да, мондый исемне дәррәү хуплап каршы алдык.

Ә аннары...

Ә аннары Донец елгасы буендагы урманда аш-су, халыклар дуслыгына дулкынланып әйткән сүзләр, изге теләкләр һәм яңадан юлга, ә юлыбыз бай да, киң дә, якты да.

Кояш байый барып, Донец елгасының көзгедәй саф, тымызык суы өстендә алсуланып чагылганда, без, кунакчыл хуҗаларыбыз белән туганнарча хушлашып, алга карап юлга чыгабыз. Юлыбыз — химиклар шәһәре Северо-Донецкига. Ә Новоайдаркинода, аның бәрәкәтле, уңдырышлы туфрагында, татар әдәбиятының вәкилләре утырткан «Казан кызы» яфрак яра...

**Ирмәк Үтәбаев,**
филология фәннәре кандидаты, доцент.

# ИГЕЗӘК ХАЛЫКЛАРНЫҢ УРТАК УЛЫ

*(Казакъ совет язучысы Сабир Шәриповның тууына 90 ел)*

Язмышлары, культуралары уртак, телләре үзара аңлаешлы төрки халыклар арасында татарлар белән казакълар бигрәк тә якыннарыннан санала. Бу, чыннан да, шулай, чөнки борын-борыннан ук безнең халыклар тыгыз мөнәсәбәттә торып, кыз бирешеп, кан алмашып, кардәшлек җепләрен һаман да ныгыта килгәннәр.

Казакъ-татар әдәби бәйләнешләре да шулай ук бик борыннан, тарихның тирән катламнарыннан башлана. Мәсәлән, төрки халыкларның күпчелеге өчен уртак мирас булган Мәхмүд Кашгари әсәре «Диван лөгать ит-төрек»тә (XI йөз) тупланган фольклор әсәрләреннән алып, урта гасырларда нугайлар хөкем сөргән чорларда иҗат ителгән мәхәббәт җырлары, дастаннар һәм башка эпик әсәрләр дә безнең уртак хәзинәбезне тәшкил итәләр.

Җалаир исемле казакъ кабиләсеннән чыгып, XVI йөздә иҗат иткән Кадыйргали бәкнең «Җәмигъ әт-тәварих» дигән китабы[1], атаклы татар укымышлысы Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мостафад әл-әхбар» исемле гыйльми хезмәте, күренекле казакъ галиме Чокан Вәлихановның дусы, фикердәше татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезхановның бай гыйльми мирасы да халыкларыбызның уртак хәзинәсе дип карала ала.

Казагыстанда яисә аңа якынрак төбәкләрдә туып үскән татар әдипләренең кайберләре үз әсәрләрен һәр ике телдә дә язганнар. Моңа мисал итеп курганлы Әхмәт Уразаев-Курмаши, акмулалы Әкрәм Галимов иҗатларын күрсәтергә була. Ике телдә язган әдипләрнең кайберләре чыгышлары буенча да ике халыкка уртак угыл иделәр. Мәсәлән, атаклы Акмулла (Мифтахетдин Мөхәммәдьяров) әтисе буенча — казакъ, анасы ягыннан (Бибигөлсем) татар иде[2]. Ул казакъ, татар һәм башкорт телләрендә бердәй җиңел язган, өч халыкның әдәбиятына да бер дәрәҗәдә өлеш керткән шагыйрь. Беренче казакъ журналы «Айкап»ны (1911—1915) чыгаручы шагыйрь, прозаик, публицист Мөхәммәтҗан Сералин да татар халкының җияне иде[3].

Шулай ук казакълар арасында эшләп, аның әдәбиятын өйрәнүгә, милли интеллигенциясен тәрбияләүгә өлеш керткән, казакъ тормышы хакында күренекле әдәби әсәрләр язган Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимовлар каршында да

[1] 1902 елны Касыйм шәһәрендә иҗат ителгән тарих әсәре.— М. Г.
[2] Шагыйрьнең биографиясе ата-анасы хакында икенчерәк версияләр дә бар (карагыз: «Идел» альманахы. 1970 ел. Казан. 74—80 битләр).— М. Г.
[3] Җиян — озатылган кыздан туган ир кардәш, ягъни биредә автор М. Сералинның анасы татар кызы булуга ишарә ясый.

безнең халкыбыз һәрвакыт бурычлы. Күплəгəн элгəрге һəм хəзерге казакъ әдипләре Мәрҗани һәм Фәезхановны, Тукай һәм Ибраһимовны үзләренең остазлары дип таныдылар һәм таныйлар.

Казакъ халкын шулар кебек үк үзенә якын, хәтта бөтенләй үз иткән, аның бәхетле киләчәге өчен кулына каләм алып та, корал тотып та хезмәт күрсәткән татар улларының берсе Сабир Шәрипов иде.

* * *

Сабир (Мөхәммәтсабир) Шәрипов 1882 елның 7 июлендә хәзерге Татарстан республикасының Әгерҗе районындагы Барҗы авылында татар бурлагы Шәриф Дәүләтшин гаиләсендә дөньяга килә. Булачак язучыны балалык бәхете читләтеп уза: аңар унбер яшь тулмаган чакта ук анасы Мәрхәбҗамал вафат була, озакламый атасы да үлеп китә. Берсеннән-берсе кечкенә ике сеңелесе Шәрифә һәм Миңлеҗамал белән калган Сабир унбиш яшенә кадәр йорттан йортка күчеп, бусагадан бусагага барып, кеше күзенә тилмереп карап көн уздыра. Уналты яшь тулгач, ул казакъ сахраларына килеп чыга һәм, шуннан башлап, Казагыстан аның икенче ватанына әверелә.

1899 елда И. И. Ольшевский дигән бер чиновник ярдәмендә Сабир Павлодар шәһәрендә ачылган башлангыч авыл хуҗалыгы мәктәп-интернатына урнаша. 1903 елда исә авыл хуҗалыгы машиналары монтеры, балта остасы, китап төпләүче һөнәрләрен үзләштереп, әлеге мәктәпне тәмамлый. Шул елларны ул рус телен өйрәнә, классик әдәбият үрнәкләре белән таныша, татар язучыларының әсәрләрен укып, казакъ акыннарының җырларын тыңлый.

Сабир тормыштагы үз урынын эзләп, төрле җирләрдә эшләп карый: казакъ авылларында мөгаллимлек итә, авыл хуҗалыгы машиналары складында мөдир урынбасары булып тора, ә 1905—1907 елларда исә Атбасар һәм Күкчәтау өязләрендә волость идарәсенең эш башкаручысы булып эшли. Шушы елларда С. Шәриповның революцион эшчәнлеге дә башлана. Ул яшерен әдәбият белән таныша, большевистик прокламацияләрне һәм Выборг өндәмәсен казакъ теленә тәрҗемәләп, аларны гади халык арасына тарата. Шул эшләре өчен 1905—1907 елларда полициянең яшерен күзәтүе астында тора. Моннан соң Сабир империалистик дөнья сугышына каршы хәрәкәткә катнаша, ә 1916 елда казакъ егетләрен сугыш мәйданындагы кара хезмәткә алуга каршы башланган халык хәрәкәтен[1] яклап чыга.

Революцион күтәрелеш елларында Сабирның эшчәнлеге бигрәк тә активлаша. 1915 елның кышында ул Мәскәү, Казан, Пермь, Төмән, Омск шәһәрләрендә булып, андагы революционерлар белән элемтәгә керә. 1916 елда Күкчәтаудагы большевик И. М. Демецкий белән таныша һәм, Февраль революциясеннән соң үзе дә Күкчәтау шәһәренә күчеп, шунда большевиклар партиясе сафына керә. Күкчәтауда өяз депутатлар советы оештыруда, РСДРП(б)ның җирле оешмасын тудыруда ул якыннан катнаша, үзе шул оешманың җаваплы секретаре булып сайлана. Өяздә Совет власте урнаштыруда, бу эшкә казакъ хезмәт ияләренең, интеллигенциясенең вәкилләрен җәлеп итеп, милли кадрлар тәрбияләүдә дә Сабир зур эшләр башкара. «Берек» исемле газета чыгара, шәһәр халкы өчен казакъ һәм татар телләрендә әдәби кичәләр, концертлар оештыра.

С. Шәрипов «Өч йөз» дип аталган казакъ партиясенә, аның җитәкчеләренә дә күп ярдәм күрсәтә. Бу партиянең программасын яңабаштан карап чыгып, аны большевистик программага якынлаштыра. Сабир керткән төзәтмәләрне «өчйөзчеләр» теләп кабул итәләр.

Киләсе елны Сабир партиянең Күкчәтау оешмасы депутаты сыйфатында РСДРПның Омскида уздырылган Беренче Көнбатыш Себер съездына катнаша. Ләкин чехословак корпусы фетнәсе нәтиҗәсендә съезд эшен туктатырга мәҗбүр була,

---

[1] 1916 елга кадәр патша хөкүмәте, элегрәк казакълар Россиягә кушылган чакта ясалган килешү буенча, казакълардан солдат алмый иде. 1916 елны шарт бозылгач, казакъ халкы моңа зур восстание белән җавап бирә, һәм ул хәрәкәт «1916 елгы восстание» дигән исемдә тарихка керә.— М. Г.

Омск шәһәрендә Совет власте вакытлыча гамәлдән туктагач, башка коммунистлар белән бергә Сабир да яшерен хәрәкәткә — подпольега күчә. 1918 елның ноябрендә С. Шәрипов Совет власте хөкем сөргән Төркстан республикасы территориясенә чыга. Әмма республика партия-совет органнары аны яңадан Колчак тылына эшкә җибәрәләр. Иске-москы киенгән хәерче, яисә ил гизүче багучы-табип кыяфәтләренә кергән Сабир дошман тылындагы халык арасында колчакчылар белән буржуаз милләтче Алашурда хөкүмәтенә каршы пропаганда эше алып бара, хезмәт ияләрен алар белән кискен көрәшкә чакыра.

1919 елның октябрендә С. Шәрипов РСФСР Совнаркомы тарафыннан РКП(б)ның Төркстан эшләре буенча комиссиясе карамагына җибәрелә. Комиссия председателе Ш. Элиава һәм В. Куйбышев аңар колчакчылардан чистартылган Акмула губернасында Совет властен, партия оешмаларын аякка бастыру эшен тапшыралар. Шәрипов бу йөкләмәләрне җиренә җиткереп башкара.

С. Шәрипов Казагыстан советларының 1920 елның октябрендә Оренбургта үткәрелгән корылтаен оештыруга якыннан катнаша. Ул дүрт мәртәбә Казаткомга (КазЦИК) әгъза итеп сайлана.

Гражданнар сугышы тәмамлангач, Сабир барлык көч-куәтен илебездә социализм урнаштыру эшенә бирә. Башта Атбасар өязенең ревком председателе, аннары 1922 елда Акмула губернасының башкарма комитеты (губисполком) председателе итеп сайлана. Бу чорда Сабир җәмәгать тормышын яхшырту һәм какшаган халык хуҗалыгын аякка бастыру өлкәсендә җиң сызганып эшли, мәдәни-агарту эшләренә дә зур игътибар бирел, халыклар дуслыгын ленинчыл милли политика нигезендә үстерүгә, ныгытуга күп көч куя.

1924 елда РКП(б) Үзәк Комитеты һәм Бөтенсоюз Халык Хуҗалыгы Советы (ВСНХ), Казагыстанда нефть промышленностен ныгыту максаты белән, С. Шәриповны Эмбага эшкә җибәрә. Биредә ул, нефть промыселларын реконструкцияләү эше белән бергә, РКП(б)ның Доссор район комитетын оештыручыларның да берсе була.

Нефтьле Эмбада С. Шәрипов, кыска вакытлы китеп торуларын исәпкә алмаганда, гомеренең соңгы көннәренә хәтле эшли. 1925 елда Макат нефть промыселларының эксплуатациягә тапшырылуы, Доссор ятмаларының файдаланыла башлавы, соңрак Сагыз, Колсары, Чуаркодык, Искәнә һәм тагын башка бик күп ятмаларның ачылулары — барысы да Сабир Шәриповның исеменнән аерылгысыз вакыйгалар.

Илебездәге нефть промышленностеның күренекле оештыручыларыннан саналган С. Шәрипов 1933—1934 елларда Тәһранда «Кевир-Хуриан» («Совет-Иран») нефть акционерлык җәмгыятенең директоры булып эшли.

Сабир тирән белемле, югары культуралы, бай тәҗрибә туплаган эрудицияле кеше иде. Ул 1935—1936 елларда Казагыстан коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм институтында өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшли. Анда Сабир казакъ халкының 1916 елдагы милли-азатлык көрәшен тарихи планда тикшерә. Институт чыгарган «Восстание казахских трудящихся против царизма в 1916 году» (Алма-Ата, 1937) исемле китапның баш редакторы һәм авторларының берсе була.

1937—1941 елларда С. Шәрипов Эмбада геологик-тикшерену эшләрен башкара.

Сабир Шәрипов берничә мәртәбә җитәкче партия-совет органнарына — өяз, губерна һәм округ партия комитетларына әгъза итеп сайлана, партиянең республика конференцияләренә катнаша...

* * *

Сабир Шәрипов, киң колачлы дәүләт эшлеклесе булу белән бергә, югары культуралы язучы да иде. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында кулына каләм алып, туып килә торган казакъ совет әдәбиятының нигез ташларын салучыларның берсе булды ул.

Яшь әдәбиятның нигезен салучы язучылар арасында С. Шәрипов прозаик буларак таныла. Аның «Алтыбасар» исемле беренче очерк-повесте 1918—1919 елларда

язына. Ләкин әсәрне шул елларда ук бастырып чыгарырга мөмкинлек булмый. Чөнки, беренчедән, контрреволюция белән актив көрәшкә катнашкан әдип повестьны тәмам редакцияләп бетерә алмый, икенчедән, ул вакытны зур китаплар бастырырлык матбугат-нәшриятлар да булмый әле. Шулай итеп, язучының беренче әсәре үз укучысына тыныч социалистик төзелеш елларында гына барып ирешә.

1923—1924 елларда язучы әлеге повестена яңадан әйләнеп кайта, аны беркадәр тулыландырып, редакцияләп, әсәрнең беренче вариантын республика партия органы булган «Кызыл Казагыстан» журналының 1924 елгы 4—10 саннарында бастырып чыгара.

Әсәрнең журнал вариантын укучылар бик җылы каршылый, 1926 елда ул аерым китап булып чыга. Китапның редакторы һәм аңа кереш сүз язучы авторның каләмдәш дусы, көрәштәше, казакъ совет әдәбиятының классигы Сәкен Сәйфуллин була.

С. Сәйфуллин, повестька югары бәя биреп, болай ди: «Алтыбасар» — казакъ тормышын тасвирлаган әсәрләр арасында иң шәп китапларның берсе. Казакъ тормышын, казакъ крестьяннарының көнкүрешен сурәтләүдә ул үрнәк, мисал була ала. Әсәрнең теле саф, җиңел, сүз төзелеше матур. Картиналары ачык, төгәл, буяулары якты. Язучының **казакъ тормышын бик яхшы белүе күренеп тора** (курсив безнеке — И. Ү.).

«Алтыбасар»ның мактауга лаеклылыгын укучы үзе дә күрер. Моңарчы казакъ хуҗалыгын, аның көнкүрешен тасвирлаган китап бөтенләй юк иде. Бу юлда «Алтыбасар» беренче әсәр». (Сабир Шәрипов. Алтыбасар. Кызылурда. 1926. 3 бит.)

Алтыбасар — чирәм җирләргә күчеп килүче рус крестьяннары салган яңа поселок исеме. Менә шушы поселокның тормышын үзәккә куеп, аны башка авыллар белән чагыштырып тасвирлау аша автор казакъ тормышына Столыпин реформасы китергән үзгәрешләрне калку итеп чагылдыруга ирешә. Казакъ авылында хөкем сөргән патриархаль-феодаль гореф-гадәтләрне, ялкаулык һәм иренчәклекне, кәеф-сафага бирелүчәнлекне, шулай ук бездә элек киң җәелгән гайбәтчелек һәм хорафатны Сабир ачы тәнкыйть уты астына ала. Шул күрсәтелгән тискәре гадәтләрнең казакъларда экономик һәм мәдәни үсешкә киртә булып ятуларын ул бик ышандырып исбат итә. Шулай ук автор гади халык арасында көн саен үсә, ныгый барган сыйнфый конфликтны, казакълар арасында да йөз бирган революцион рухны калку итеп гәүдәләндерә.

Повесть символик картина белән тәмамлана:

«Таң атты. Арбаларга утырып, шәһәрдән әле генә чыгып бара идек, бер җайдак безнең яннан кычкыра-кычкыра узып китте:

— Унтугыз белән утыз бер яшь арасындагы казакълар сугышка алына!

Диңгез дулкынланырга тотынды...»

Моннан соң, чыннан да, 1916 ел килә, бу ел казакъ хезмәт ияләренең патша колонизаторларына каршы көчле протест ясавына, милли азатлык хәрәкәте белән сыйнфый көрәшнең үрелеп үсүенә китерә, ә аннан Октябрь революциясе таңы ата.

«Алтыбасар» асылда тәмамланмый калган әсәр, дөресрәге, С. Шәрипов язарга ниятләгән трилогиянең беренче өлеше генә [1]. Шулай да ул авторга шөһрәт һәм дан китерә. Әсәрнең төп идеясен — хезмәткә өндәүне, халыклар арасында дуслык хисен тәрбияләүне башка язучылар күтәреп алалар, алга таба үстереп җибәрәләр. Шулай ук әдәби сыйфаты ягыннан да «Алтыбасар» казакъ совет әдәбияты формалашкан чорның иң әйбәт әсәрләреннән исәпләнергә хаклы.

Сабир казакъ халкын җегәрле, сәләтле, азатлык өчен көрәшүче халык итеп күрсәтә. Аның характерындагы яңага омтылучанлык, гаделлек һәм тәвәккәллек кебек уңай сыйфатларын хөрмәт белән сурәтләп, хезмәт ияләренең сыйнфый аңы үсүен, ил бәхете өчен көрәшкән ирләрнең якты образларын гәүдәләндерүне үзенең төп бурычы итеп билгели. Һәм бу теләгенә ул тулысынча ирешә.

1923 елда «Кызыл Казагыстан» журналында С. Шәриповның «Баганалы иленең хәлләре» исемле әдәби-этнографик очеркы басылып чыга. Бу әсәрендә ул «баганалы» дип аталган казакъ ыруының узганы белән хәзергесен чагыштырып, күчмә казакъ тормышына совет строе китергән иҗтимагый үзгәрешләр, аларның тарихи әһәмияте хакында сөйли.

---

[1] Калган ике кисәкнең язмышы хәзергә мәгълүм түгел.

Егерменче еллар ахырында Сабир хикәяләр, әдәби очерклар яза. Алар арасында бер-бер артлы басылган «Ирдән батыр», «Закон җәбере», «Калага бару», «Сөлек» кебек хикәяләре аерата игътибарга лаек. Аларда язучы Октябрь революциясенә кадәрге казакъ тормышының төрле якларын тасвирлый. Мәсәлән, «Ирдән батыр» исемле әсәрендә халыкны алдау, патша властьларына ришвәт бирү юллары белән ил өстеннән билек итүгә ирешкән ялган батыр Ирдән Сандыбаевның тискәре образын тудырса, «Закон җәбере» дигән хикәясендә (автор аны 1935 елда яңадан повесть итеп эшли) патриархаль-феодаль авылда хөкем сөргән кыргый гореф-гадәтләрне сурәтли.

«Калага бару» исемле әдәби очеркында Сабир, беренчедән, иске казакъ тормышының кайбер этнографик якларын (азык-төлек һәм кием-салым өчен елына ике мәртәбә шәһәргә барып, мал сатып кайтуларны) тасвирлый, икенчедән, ялгыз-ярым маллары белән шәһәргә үзләре бара алмаганга, малларын байлар кәрванына кушып җибәрергә мәҗбүр булган ярлыларны тегеләрнең ничек итеп алдауларын сурәтли.

«Сөлек» хикәясендә язучы ярлыларга ярдәм йөзеннән сәвым сыеры биреп торган булып, әманәт маллары өчен гидайлардан үсем каерып алуга күнеккән сахра рибачысы (ростовщигы) Исхак хаҗиның образын тудыра.

* * *

Бу елларда С. Шәрипов рус телендә дә берничә әсәр яза. Шулардан иҗтимагый әһәмияте буенча «Җәза» («Возмездие»), «Караңгылык» («Темнота») исемле хикәяләре һәм ике бүлектән гыйбарәт «Сәлиа» (1929—1932) дигән зур күләмле романы аерата игътибарга лаек. Романда XX йөз башында, төгәлрәк әйткәндә, 1915—1921 елларда сахра тормышында йөз биргән үзгәрешләр, сыйнфый конфликтның кискенләшүе сурәтләнә. Ата-баба йоласы дип, иске гореф-гадәтләргә ябышып яткан байгуралар, биләр, руханилар казакъ дөньясына яңалык кертмәс өчен бөтен көч-куәтләрен эшкә җигәләр. Хезмәт ияләренең сыйнфый аңнары үсүдән аларның котлары алына. Искелеккә теш-тырнаклары белән ябышып яткан бу кара көчләргә яңа туып килгән милли буржуазия вәкилләре, аның авангарды булган «Алаш» партиясе дә якыннан ярдәм итәләр.

Билгеле булганча, күчмә патриархаль тормышта кызны калыммалга сатып, шул ысул белән кодалашу йоласы иске феодаль тәртипләрнең иң тотнаклы звеносыннан була. Шуңа күрә «калыммал», кыз сату йоласы тирәсендә барган көрәш үзенең табигате буенча искелек белән яңалык көрәшенә, ниһаять, кискен сыйнфый конфликтка кайтып кала. Романның үзәгендә нәкъ менә шундый тирән социаль бәрелеш ята, шуңа күрә сурәтләнгән вакыйгалар да трагик төс алалар.

Югарыда әйткәнебезчә, 1898—1924 елларны, ягъни егерме биш ел дәвамында, С. Шәрипов элгәрге Акмула губернасында яшәп, шунда төрле урыннарда эшли. Өстәвенә, ул Семипалат, Тургай, Сырдарья өлкәләрендә баргалый һәм үзе озак яшәгән, күзе белән күргән җирләрдәге тормыш, гореф-гадәт белән якыннан таныша, шуңа күрә казакълардагы «калыммал», тол хатын мәсьәләсе, җир давы, кон түләтү[1] кебек төрле традицион җәнҗалларны ул якыннан күзәтә, аларны нечкәлекләренә хәтле белә. Авторның шундый бай тәҗрибәсе, тирән белеме романны язар өчен зур мөмкинлек бирә. Коммунист язучы казакъ хатын-кызларына чын азатлыкны бары Октябрь революциясе генә китерүен оста итеп күрсәтә.

Сабир тарафыннан русча язылган әсәрләр арасында «1917 елгы Күкчәтау» («1917 год в Кокчетаве») исемле хикәясе үзенең әдәби сыйфаты белән аерата игътибарга лаек. Бу әсәр Бөек Октябрь революциясенең 20 еллыгына багышланып, 1937 елда иҗат ителә.

---

[1] Казакъларда ире үлгән тол хатын иректе булмаган, бәлки ыруының «милке» сыйфатында исәпләнгән, шуңа күрә яшьли тол калган хатынның кемгә чыгу, яисә үз ата-ларына кайту мәсьәләсе зур җәнҗалларга сәбәп булган. «Кон түләтү» — үтерелгән кеше өчен «кан бәһасе» түләтү.— М. Г.

* * *

Югарыда С. Шәриповның Иранда булып, анда җаваплы эшләрдә эшләп кайтуын әйткән идек. Бу сәфәреннән ул язучы буларак та файдалана: Тәһран, Пәһләви, Рәшд, Казвин һ. б. шәһәрләрдә, төрле өлкәләрдә булган чакта фарсы халкының бай тарихы, катлаулы тормышы, хуҗалыгы, олы мәдәнияте, музей-китапханәләре белән якыннан таныша; фарсы телен өйрәнеп, Иран тарихы буенча китаплар укый. Шулар нәтиҗәсендә 1935—1936 елларда «Рузи Иран» («Иран хәлләре»), «Иранга сәяхәт» исемле очерклар циклын һәм үзенчәлекле «Лэйла» романын яза.

«Рузи Иран» циклында утызынчы еллардагы буржуаз-феодаль Иран төрле яктан сурәтләнә. Хезмәт ияләренең авыр тормышын, аларның азатлык дип янып яшәүләрен күрсәтү белән бергә, автор шаһ, вәзирләр, генерал-губернаторлар, алпавытлар һәм милли буржуазия вәкилләре белән дә укучыны таныштырып, аларның чын социаль йөзләрен ачып бирә. Шулай ук «Иран — гөлләр иле, җәннәт» дип инанып, революция елларында туган илен ташлап китүче эмигрантларның да хәерчелек хәленә калулары сурәтләнә.

«Иранга сәяхәт» дигән очерклар циклында исә автор гади халыкның, хезмәт ияләренең хәлләренә киңрәк туктала. Язучы фарсы халкының якты киләчәгенә зур өмет баглый. «Лэйла» романында 1890—1907 елларда Иранда башланган революцион хәрәкәтләр сурәтләнә. Романның төп геройлары — Лэйла һәм аның сөйгәне Габдулла — хезмәт ияләренең типик вәкилләре. Башта аларның протестлары стихияле формада гына булса, соңрак, көрәштә чыныга-чыныга, алар сыйнфый аңнары өлгергән революционерлар сафына басалар. Мондый үзгәрүдә Беренче рус революциясе керткән өлеш тә нык сизелеп тора. Романны укыган кеше Иран революциясе әле бетмәгән, Лэйла-Габдуллалар башлаган эш һичшиксез җиңеп чыгачак, дигән фикер белән китапны ябачак.

С. Шәрипов үзенең бу әсәрләре белән казакъ совет әдәбиятында чит ил тематикасын башлап җибәрүче әдипләрнең беренчеләреннән һәм күренеклеләреннән булды дисәк, әллә ни ялгышмабыз. Бу әсәрләрен ул кайберәүләр кебек газета-журнал укып кына язмаган, бәлки үзе күреп-белү, хис итеп тою нәтиҗәсендә иҗат иткән. Соңрак дәвердә бездә иҗат ителгән китаплардан Мохтар Әуэзовның «Һиндстан күренешләре», «Америка тәэсирләре», Сабит Мокановның «Адәм ата тавы түбәсендә» дигән китабы, Габит Мөсрәповның «Япон балладасы», Һади Шәриповның «Ерак ярлары», Калмокан Исабаевның «Соңгы тәүлеге» һәм тагы башкалары чит ил тематикасын тагы да үстереп җибәрделәр.

* * *

Утызынчы елларның икенче яртысы С. Шәрипов иҗатында иң нәтиҗәле дәверләрнең берсе була. Шушы кыска гына вакыт эчендә ул егермедән артык хикәя, очерк һәм киң танылган «Бикбулат» исемле повестен яза.

Халкыбыз башыннан кичкән тарихи вакыйгаларны, киң колач җәйгән милли-азатлык хәрәкәтен тирәннән өйрәнеп, аны әтрафлап яктыртучы сүз осталарының беренчесе дә Сабир Шәрипов булды дисәк бер дә ялгышмабыз. Милли азатлык хәрәкәтен тасвирлауга багышлап язган документаль тугыз очеркын ул «1916 ел» дигән гомум бер баш астына җыя.

Очеркларда Актүбә-Тургай, Җидесу һәм Үзәк Казагыстандагы вакыйгалар тасвирлана. Вакыйгалар бер очерктан икенчесенә күчә, барган саен үсә, куера төшә.

1916 елгы хәлләр хакында Сабир рус телендә дә берничә әсәр яза. Мәсәлән, 1937 елда «Милысур үзәнендә дошманны ничек кыйнадылар», «Каработак восстаниесе», «Байларга сугыш игълан ителгән иде», «Бутабай», «Сахрада сугыш», «Кигән һәм Тикәс үзәннәрендә» исемле хезмәтләрен, шулай ук «Баян-авылда» дигән истәлеген бастырып чыгара. Ике телдә дә язылган бу әсәрләр С. Шәриповның исемен С. Сәйфуллин, Б. Майлин, М. Әуэзов, С. Моканов исемнәре белән янәшә куярга хокук бирә.

Әле генә күрсәтелгән әсәрләрендә автор, милли-азатлык көрәшенә җитәкчелек иткән, шул юлда газиз җаннарын фида кылган халык баһадирлары мәшһүр Аманкил-

де Иманов, Әделбәк Майкәтев, Бикбулат Әҗекәевлардан тыш, эшләгән эшләре тиешлечә тәкъдир ителмичә онытылып торган күп кенә батырларның исемнәрен тергезеп, аларның якты образларын гәүдәләндерә. Мәсәлән, 1916 елгы көрәш хәрәкәтенә зур өлеш керткән Тайшым Урыс улы, Мәрүа Сансызбаев, Иса Дәүләтбеков, Җөсеп Аҗагаев, Идрис Тайҗанов, Ирмөхәммәт Көзәмбаев, Мокаш Өдәрбаев, Түрәкилде Колҗанов, Эргәбай Далдабаев һәм башка бик күп каһарманнарның исемнәре әдәбиятыбызда бары Сабир Шәрипов әсәрләре аша гына үзләренең мактаулы урыннарын алдылар.

Көрәшче батырлар образы белән якыннан кызыксыну язучыны «Бикбулат» повестен язуга китерә.

«Бикбулат» — әдипнең иң соңгы зур күләмле әсәре. Ул үзенең идея-эчтәлек җәһәтеннән югары сыйфатлы, әдәби-сәнгатьчәлек ягыннан бик үзенчәлекле булуы белән казакъ совет әдәбиятында аерым урын биләп тора. 1937 елда аерым китап булып басылган повестьта гидайлар арасыннан чыккан казакъ революционерының тормыш юлы, аның рухан үсүе, героик язмышы күрсәтелә.

Бикбулат — үз кул көче белән көн күрүче авыл остасы. Аның сеңелесенә өйләнгән байдан «калым» өчен җир участогы кистереп ала. Бу — моңарчы казакълар арасында традициясе булмаган бер хәл. Ачыграк итеп әйткәндә, Бикбулатның гамәле феодаль-патриархаль мөнәсәбәтләр хөкем сөргән чорда хосусый җиргә ия булу аркасында аппавыт-байгураларның тәэсиреннән котылуга тырышуның бер чарасы була. Чыннан да, күп тә узмыйча, Бикбулат һәм аның тирәсендәге бер төркем ярлыябагайның шул кечкенә генә җирләре ярдәмендә байлар алдында бил бөгеп торудан котылуын күрәбез. Әмма мондый хәл байгураларга, би-булысларга ошап бетми, әлбәттә. Һәм алар, тегеләрнең хәлләнеп, бөтенләй мөстәкыйльлек юлына басуларыннан куркып, төрле киртәләр кора башлыйлар, байлар белән ярлылар арасында конфликт туа. Әлбәттә, бу бәрелеш югары катламнарның җиңүе белән тәмамлана — Бикбулат һәм аның якын шәрикләре илдән сөреләләр. Сөргендә чакта исә Бикбулат РСДРП(б) әгъзалары белән таныша, рус эшчеләренең яшерен җыеннарына катнаша, нәтиҗәдә ул дөньяга бөтенләй икенче күзләр белән карый башлый. Октябрь революциясе чорында без аны большевиклар партиясе сафында күрәбез, гражданнар сугышында исә чыныккан большевик буларак көрәшкә атлыга. Узак Казагыстанда Совет власте вакытлыча егылган чакта Бикбулат яшерен рәвештә дошман тылына уза, анда партизан отряды оештырып, Колчак һәм Алашурдаларга каршы хәрәкәткә җитәкчелек итә.

Повесть баш геройның һәлак булуы белән тәмамлана. Ләкин, моңа карап, әсәрнең рухы бер дә сүрелми, чөнки без батырның үлеме чын җиңүгә әверелүен күрәбез.

«Бикбулат» повесте казакъ революционерының образын тудыру юлындагы мөһим табышларның берсе. Әсәрнең гарбияви-эстетик әһәмияте дә зур. Революционер-герой образын тудыруда автор үзенең көрәш тәҗрибәсеннән нык файдалана, шуңа күрә бәхәссез уңышка ирешә. Повестьтагы башка геройларның — циркач Осип, авыл егете Кәребай, сөргендәге Рәхимҗан (прототибы — билгеле революционер Дәйсәнбаев), партизан отряды җитәкчесе Иса һәм тагы башкаларның образларын да автор бик яратып, илһамланып тудыра.

Язучы тискәре типларны гәүдәләндерүгә дә күп көч куя. Мәсәлән, найман-багаңалы ыруының малга да, җиргә дә иң бай, иң комсыз кешесе Дөрембай образы бары оста каләм иясе тарафыннан гына тудырыла ала. Җыеп әйткәндә, «Бикбулат» повесте бездәге сыйнфый көрәшнең кискенләшүен, казакъ җәмәгатьчелегенең иҗтимагый-политик яктан үсә баруын, хезмәт ияләренең Совет власте өчен актив көрәшен әтрафлап тасвирлаган зур күләмле һәм тәүге әсәрләрнең берсе. Мондый әсәрләрне иҗат итә алуы белән С. Шәрипов үзен социалистик реализм принципларын яхшы үзләштергән язучы итеп күрсәтте.

* * *

Сабир Шәрипов прозаның төрле өлкәләрендә эшләгән, үзе дә тормышны һәрьяклап өйрәнгән, аның яшерен серләрен белгән әдип. Ул язган очеркларда, хикәяләрдә, романнарда халык тормышы әтрафлы сурәтләнә, күбесенчә, башка каләм-

дәш дусларының кулы җитмәгән мәсьәләләр күтәрелә, шулар җентекләп, нечкәлекләренә кадәр ачылып тасвирлана. Язучы сайлаган төп объект — хезмәт ияләре, изелгән ярлы-ябагайлар, көрәшче халык, ил бәхете өчен көрәшкә бил баглаган азамат ирләр. Ул үз иҗатында тырышлыкны мактап, хәләл хезмәткә дан җырлый. Ләкин хезмәткә дә ул тарихилык күзлегеннән карый: әгәр элгәрге чорда хезмәт газап, җәфа булса, соңгы дәвердә мактау һәм дан эшенә әверелә.

С. Шәриповның әсәрләрендә вакыйга бик тыгыз, геройлар исә гел киеренке шартларда яшиләр. Сабит Моканов сүзләре белән әйткәндә, «Сабир Шәрипов романнарының сюжетын кызыклы итеп төзи торган язучы. Аның әсәрләрен кеше мавыгып укый». Күрәсез, С. Моканов хәтта язучының повестьларын да роман дип атый, һәм монда дәреслек юк түгел, чөнки аның кайбер повестьлары бай эчтәлекле, тыгыз вакыйгалы булулары ягыннан чын роман бурычын үтәделәр.

Сабир яше буенча да казакъ совет язучылары арасында иң олысы, шуңа күрә башкаларга караганда тәҗрибәлерәк тә, белемлерәге дә иде. Аның әдәбиятыбызга кайбер яңа темалар, яңа образлар алып килә алуы, димәк, очраклы түгел иде. Ул беренче булып күтәргән мәсьәләләр соңрак Мохтар Әүэзов, Сабит Моканов, Габит Мөсрәпов, Габидин Мостафин, Хәмзә Исәнҗанов һәм башкаларның әсәрләрендә дәвам иттеләр, гөрләп үстеләр.

Әлбәттә, хәзерге әдипләребезнең тәҗрибәләре тагы да баерак, белемнәре дә артып, каләмнәре дә сизелеп шомардылар. Шуңа күрә соңгы дәвер язучылары тарафыннан тудырылган әсәрләрнең, геройларның Сабир иҗат иткәннәргә караганда катлаулырак, камилрәк булулары бер дә гаҗәп түгел. Әдәби зәвыклары үскән культуралы укучыларның да язучы әсәрләрендә кайбер җитешсезлекләр табулары ихтимал. Ләкин Сабир калдырган әдәби мирасның гомуми кыйммәте, эстетик-тәрбияви әһәмиятләре моңа карап бер дә кимеми. Чөнки аның хикәя һәм очерклары, повесть һәм романнары казакъ совет әдәбиятының үсү юлында нигез ташлары хезмәтен үтәделәр. Бу бернинди бәхәс тудырмый.

Казагыстан тарихын өйрәнү буенча да С. Шәриповның сизелерлек өлеше бар. Мәсәлән, аның «Көнчыгыш Казагыстанда революцион хәрәкәт тарихына карата», «Алашурда тарихына карата» (ике әсәр дә рус телендә) дигән хезмәтләре, «Доссор һәм милли мәсьәлә» исемле зэлэнүе (1924), шулай ук 1916 ел вакыйгаларына багышланган күп кенә очерклары шуны раслый. Яшь республиканың аякка баса башлаган промышленностен, бигрәк тә нефть хуҗалыгын тикшерүгә багышланган гыйльми хезмәтләреннән «Нефть» исемле китабын күрсәтергә була. Бу әсәр 1929 һәм 1931 елларда ике мәртәбә басылып, шактый еллар дәвамында фабрика-завод училищелары укучылары һәм профессиональ нефтьчеләр өчен дәреслек хезмәтен үти.

Коммунист язучы Сабир Шәриповның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан туктап калды. Ул яла һәм нахак җәзаның корбаны булды. Халык бәхете өчен көрәшкән интернационалист-революционер, казакъ совет әдәбиятының нигез ташларын салышып, аның өметле киләчәген тәэмин итүгә зур өлеш керткән язучы-гражданин иң хәтәр дошманга каршы сугышта кешелек һәм прогрессның һичшиксез җиңеп чыгачагына ышанып китте. Игезәк халыкның уртак улы Сабир Шәриповның намуслы йөрәге 1942 елның 17 нче июлендә фаҗигале шартларда тибүдән туктады...

Язучының ана теле булган татар телендә төрле материаллар язылган егерме дүрт данә калын дәфтәре, шактый шигырьләре, җырлары, киносценарийлары, янә башка күп кенә язмалары, хосусый архив материаллары, тагы кайбер әсәрләренең төзәтелгән вариантлары һәм башкалар да шулай ук һәлак булалар...

Ләкин халкыбыз язучыны онытмый. Аның яхшы аты хәзер горурлык белән телгә алына. Әдипнең исемен йөрткән нефтепромысел, мәктәп, урам бар. Аның иҗаты Казагыстандагы барлык рус, казакъ урта мәктәпләрендә, шулай ук университетлар белән педагогик институтларда махсус өйрәнелә[1]. Аның гомере, әдәби мирасы коммунистик җәмгыять кешеләрен тәрбияләүгә туктаусыз хезмәт итә.

**Казакъ теленнән М. ГОСМАНОВ тәрҗемә итте.**

---

[1] Бу мәкаләнең авторы доцент Н. Үтәбаев хәзерге көндә язып яткан диссертациясендә С. Шәрипов иҗатына киң урын бирә — редакция.

Дания Гыйммранова

# ҮЗ МОҢЫ, ҮЗ ТАВЫШЫ БЕЛӘН

Наилә — минем иң яраткан артисткаларымның берсе. Миңа аның сәхнәдә тирә-юньне яңгыратып, матур итеп көлүе, көлүенең көмеш кайтавазы, уп-кә-сагышны бергә сыйдыра алган ягымлы күзләре, күңелдә ниндидер җылы тойгылар уята торган нәфис иңнәре ошый. Ә тормышта исә мин аның үзенчә фикер йөртүен һәм зирәклеген, тыйнаклыгын һәм горурлыгын, эчкерсезлеген һәм самимилеген, башкалар шатлыгы өчен чын күңелдән шатлануын, башкалар кайгысына беркайчан да битараф булмавын яратам. Таныш-белешләремнең, дус-ишләремнең берсенекенә дә охшамаган үзенчәлекле табигатен яратам.

Артистка Наилә Гәрәеваны минем кебек үз итүчеләр аз түгелдер, һәм шулай ук аны аңламаучы, аның рухи халәтен кабул итә алмаучылар да бардыр. Чөнки бу — һәрбер талантлы иҗат кешесе өчен табигый күренеш.

Наилә Гәрәева иҗатының төп темасы — кеше күңеле, заман баласының дөнья белән танышуы, аны танып белүе, аңлавы. Бүгенге тормыш, бүгенге матурлык актрисаның поэтик талантын тулысы белән ачыкларга мөмкинлек биргән мул җирлек булды.

Гәрәева тарафыннан гәүдәләндерелгән образлар төрле чор, төрле дәвер, төрле иҗтимагый җирлек, төрле милләт кешеләре. Ләкин аларны бер нәрсә берләштерә — алар яшьтәшләр. Шул сәбәпле, аларның тышкы кыяфәтләрендә әллә ни аерма юк сыман. Ләкин бөтерчектәй хәрәкәтчән Рәхиләне ялгыз торнадай моңсу Рапиах ролендә күз алдына китереп буламы соң! Шулай ук Шекспирның сылу, нәзакәтле Изабелласын Таҗи Гыйззәт комедиясендәге чая Бибкәй белән бер рәткә куеп булмый, әлбәттә. Очкындай чәчрәп торган Зөбәйдә белән салмак һәм сабыр табигатьле әзербәйҗан кызы Гөлтекин арасында да никадәр аерма бар.

Билгеле булганча, татар театры үзенең яшәү дәверендә ике юнәлештә үсеш алды. Аның беренчесенә табигыйлеккә, тормышчанлыкка, типиклаштыруга, реалистик дереслеккә омтылу хас булса, икенчесенә исә сәхнәдә ачыктан-ачык хисләр югарылыгына, югары пафослы романтизмга омтылу хас иде. Беренче юнәлешнең күренекле вәкилләре — Г. Кариев, З. Солтанов, Г. Болгарская, Н. Арапова, Н. Таҗдарова, Г. Камская, Ф. Камалова, Г. Нигъмәтуллина, И. Гафуров, В. Минкина, А. Хәйруллина кебек сәхнә осталары булса, икенче агымның үзәгендә М. Мутин, Ф. Ильская, Камал III, Г. Ибраһимова, С. Айдаровлар торды. Бу ике юнәлеш чор таләпләреннән һәм актерлар ансамбленең үзенчәлегеннән чыгып үзара якынлаштылар. Шуңа күрә реалистик plandагы артистлар иҗатында романтик яңгыраш алган рольләр дә бай-так булды. Ә Ш. Шамильский, Х. Әбҗәлилов, Г. Булатова, Х. Сәлимҗанов, Ш. Биктимиров, Ф. Кульбарисов, Ш. Әсфәндиярова һәм яшьрәк буын артистлар иҗатында исә бу уртаклык тагын да төгәлрәк, тагын да ачыграк чагылыш тапты. Бу уртаклыкны, бердәмлекне мин сәхнәнең поэтик реализмы дип атар идем.

Өлкән һәм урта буынга алмашка килгән яшьләр, мирас буларак, театрда менә шушы поэтик реализм стилен тулысы белән кабул иттеләр. Наилә Гәрәева иҗаты да менә шушы җирлектә бөреләнә башлады һәм унике ел сәхнәдә яшәү дәверендә татар театры сәнгатендә үзенчәлекле урын алырга өлгерде. Дөрес, Гәрәева бу өлкәдә ялгыз түгел. Щепкинлылар, бигрәк тә Р. Таҗетдинов, Р. Шәрәфиев, Н. Дунаев, Н. Ихсанова, Ә. Шакиров иҗатлары, минемчә, аңа якын һәм аваздаш.

1960 елның январь урталарында Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» спектакленең премьерасы булды. Әсәрнең героинясы Рәхилә ролендә В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры каршындагы студия студенткасы 19 яшьлек Наилә Гәрәева уйнады. «Беренче мәхәббәт» искиткеч зур уңыш белән барды. 10 спектакль, 50 спектакль, 100, 200, ниһаять, 300 нче спектакль дә тулы аншлаг белән узды.

Әйе, әсәрнең бүгенге көнебезгә багышлануы һәм, тәнкыйтьче Н. Юзиев сүзләре белән әйтсәк, «драмадагы образларның тормышчан булуы, сюжетының мавыктыргыч корылуы» аңа зур уңыш алып килде.



«Беренче мәхәббәт» спектакленнан бер күренеш.

Уңышның икенче сәбәбе режиссурада тәүге адымнарын атлаучы Р. Бикчәнтәевнең бүгенге көн ритмын, аның гүзәллеген һәм матурлыгын шигъриятькә бай сәхнә теле белән аңлата алуында иде.

Ниһаять, уңышның өченче сәбәбе, әйткәнебезчә, спектакльнең төп героинясы Рәхилә ролендә Наилә Гәрәеваның уйнавында булды.

Рәхилә — әле генә унынчы классны тәмамлаган, олы тормыш юлына яңа гына аяк баскан кыз, тату, матур гаиләнең бердәнбер иркә кызы. Балаларча самими, үткен телле Рәхиләне кешеләр шуклыгы, чаялыгы, кызларча назлана белүе өчен яраталар. Рәхилә үз гомерендә беренче тапкыр мәхәббәт хисе кичерә, ләкин аның саф һәм керсез мәхәббәте тормыш давылына очрый. Аның гашыйк булган кешесе бертуган абыйсы булып чыга.

Н. Гәрәева башкаруында Рәхилә образы тамашачы күз алдында тирә-юньгә үтә зирәк күзлектән караучы, кешеләргә ярдәмчел, тойгыларга бай кеше буларак сурәтләнде. Тынгысызлык, тормышта үз урыныңны эзләү һәм аны табу — Рәхилә-Гәрәева характерының төп үзенчәлеге.

Бу әсәрдә Гәрәева, Тинчуринча әйтсәк, «сәхнә белән тамаша залын тоташтыра торган җепләрне үзе, үз башыннануздыра» алды. Ул пьесадагы вакыйгаларга яктылык һәм җан өрде.

Вакытында кайберәүләр Наилә «үзен уйный», шуңа күрә дә ул уңышка иреште, дигән фикер әйттеләр. Миңа калса, артистканың «үзен уйнавы» аның файдасына сөйли торган бер факт кына. Әгәр артист үзенең уй-фикерләрен тамашачы белән уртаклашырга теләми икән, аның сәхнәгә чыгуы нигә кирәк? Наиләнең мәктәп укытучысы Нина Михайловна Малевецкая артистканың уңышы хакында болай дип язды: «Наиләнең сәхнәдәге уңышы очраклымы? Мин һич тә икеләнмичә әйтә алам: бу — киеренке иҗади эзләнүләр нәтиҗәсе. Гәрәева мәктәптә дә шул сыйфатлары белән аерылып тора иде».

Нил Юзиев спектакльгә язган рецензиясендә Рәхиләнең романтик табигатьле кеше булуына басым ясый. Нинди яклары белән романтик соң ул Гәрәеваның Рәхиләсе? Минемчә, хакыйкатькә туры күз белән карарга тырышуы, тормышта мөстәкыйль кеше булырга омтылуы, мәхәббәттә җитди һәм горур булуы белән. Үз-үзеңне хөрмәт итү кешеләрне, аларның хезмәтен хөрмәт итүдән башлана. Кеше-

ләр ихтирамын казану җиңел түгел. Моның өчен намуслы һәм тырыш булырга кирәк. Гәрәева иҗат иткән Рәхилә образында бу сыйфатлар барысы да тулы чагылыш тапты.

Әнә шулай итеп, актриса иҗатындагы беренче аккордлар аның өчен үзенчәлекле темага — яшүсмер кызның шәхес буларак җитлегүен күрсәтү темасына багышландылар. Бу тема аның алдагы рольләрендә тагын да киңрәк үсеш алды, төрле кырлыкта, төрле яктылыкта чагылды. Менә Индонезия язучысы Абдулла Муисның «Ялгыш тәрбия» исемле романы буенча эшләнелгән «Фаҗигале юлда» спектаклендәге Рапиах образы. Бу образ — актрисаның иҗат мөмкинлекләрен өр-яңа кырлыкта күрсәткән рольләреңнең берсе. Камыштай зифа буйлы, моңсу карашлы бу ханымның саф мәхәббәт өчен көрәштә искиткеч рухи ныклык күрсәтүенә сокланмый мөмкин түгел.

Менә Рапиахның Хәнәфи белән аңлашу сәхнәсе. Хәнәфине туганнары һәм якыннары укырга җибәрәләр. Индонезия егете Хәнәфи чит милләт кызы Коррига гашыйк була. Алар өйләнешеп бергә яши башлыйлар. Ләкин Хәнәфи шәхси тормышыннан никадәр генә канәгать булса да, үзен бәхетле хис итә алмый. Чөнки хезмәткәрләре, тирә-юньдәге халык аңа ят һәм чит итеп карый. Хәнәфи яңадан анасы, туганнары янына әйләнеп кайта һәм әнисе теләге белән күрше кызы Рапиахка өйләнә.

Моңа кадәр үзенең хисләрен бәрәүгә дә белдерергә кыймыйча йөргән яшүсмер кыз өчен Хәнәфигә кияүгә чыгу — иң якты хыялның тормышка ашуы булып тоела. Көтелмәгән зур бәхеттән Рапиах сүзсез һәм өнсез кала. Рапиах-Гәрәеваның шул моментта ниләр кичергәнен бары тик аның кыяфәте, барыннан бигрәк күзләре генә сөйли — ә аларда исә кояш нурларының чагылышы, мәхәббәт тантанасы.

Ләкин, асылда исә, Хәнәфигә иргә чыгу Рапиахка көткән бәхетен китерми. Иренең үз эченә бикләнеп сызлануы, әрнүе, үз хатынын күреп тә «күрмәве», тыңлап та «ишетмәве» Рапиах өчен тоташ газапка әверелә. Үзенең мәхәббәттәге ялгызлыгын, иренең иленнән, халкыннан аерылу фаҗигасен ул үзенеке итеп, ниндидер илаһи бер көч белән кичерә һәм безнең хәтеребезгә горур, олы җанлы кеше буларак кереп кала. Рапиах-Гәрәева бик аз сөйли, ул күбрәк тыңлый, күзәтә. Хәрәкәтләре дә күп түгел. Ләкин аның һәр сүзе, һәр карашы, һәр ымы безгә образның эчке халәте, аның кичерешләре һәм хисләре турында бик күпне аңлата. Һәм син аз сүзле, сабыр һәм мөлаем карашлы, йөрәк җәрәхәтен күңел түренә яшергән, гөлдәй нәфис һәм сөйкемле бу хатынның олы кайгысын уртаклашмыйча булдыра алмыйсың. Аның кичерешләре, хисләре синең күңелеңне биләгәнен сизми дә каласың.

Бу образ Гәрәеваның эчке потенциаль мөмкинлеген тулырак итеп ачты һәм киләчәктә «Гүзәлем Әсәл», «Чамасына күрә чарасы», «Айдын» спектакльләрендә аның иҗат перспективасын билгеләгән образ булды.

А. М. Горькийның «Дошманнар» спектаклендә Надя образы белән очрашу да артистка иҗатында матур эз калдырды. Кайчандыр тормышны алсу төсләрдә генә күз алдына китергән Надяның эчке драматизмын, аның ялганны, принципсызлыкны, явызлыкны ачыктан-ачык фаш итәрлек кеше булып җитлегүен Гәрәева ышандырырлык итеп уйнады һәм бу образның эчке кичерешләрен, эчке халәтен психологик нечкәлек белән ачты. Гәрәевага бу рольне хәзерләгәндә күп эзләнергә, күп уйларга, чын-чынлап иҗат газабы кичерергә туры килде.

Далаларның киңлеген һәм хозурлыгын тою, аның иркен һавасын сулау, чишмә тавышын тыңлау, күз нурың, җан дустың Акъегетне күрү, аңа елмаю, аңа дәшү, аның Зөһрәсе булу — нинди зур бәхет. Артистка башкорт шагыйре һәм драматургы М. Кәримнең «Ай тотылган төндә» спектаклендәге Зөбәрҗәт ролен башкарганда менә шул мәхәббәт ләззәтен, бәхет җырын тамашачыга бөтен хисияте белән җиткерергә омтылды. Акъегетка булган сөю хисе саф һәм көяшлы төсмерләрдә чагылды, назлы һәм гүзәл җыр булып яңгырады. Ләкин шуны да әйтергә кирәк, бу җыр бәхет һәм шатлык җырын гына хәтерләтте, әсәрнең трагедия тирәнлеге ачылмый калды. Ә мондый кимчелек исә әсәрнең конфликтын гадиләштерде, аның иҗтимагый һәм фәлсәфи яңгырашына җитди зыян китерде. Нәтиҗәдә Гәрәеваның Зөбәрҗәте күзләрне камаштырырдай гүзәл булса да, романтик югарылыкка күтәрелә алмады.

Сәхнәдә Зөбәрҗәт белән параллель рәвештә Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» спектакленнән Зөбәйдә образы яшәп килде. Наилә бүген Зөбәрҗәт булса,

иртәгесен Зөбәйдә иде. Гәрәеваның Зөбәйдәсенә әле мәхәббәт тойгысын татырга туры килмәгән. Ул, туганнарының ваемсыз, якыннарының гамьсез булулары аркасында, туганлык, дуслык хисләреннән дә мәхрүм.

Пәрдә ачылганда без ялгызлыктан иза чигүче, «яхшы» белән «начар» төшенчәләрен тәмам бутап бетергән, «олы юл чатында» аптырап калган яшүсмер кыз белән очрашабыз. Беренче карашка, ул шактый дорфа, тупас. Ләкин сәхнәдәге вакыйгалар тирәнәйгән саен, Зөбәйдәнең язмышы, характеры да ачыклана бара. Семьядагы рухи торгынлык атмосферасы, әтисенең, абыйсының икейөзлелеге Зөбәйдәнең күңелен кайтарган, аның тормышка ышанычын какшаткан икән.

Зөбәйдә-Гәрәева йөрәгендә әкренләп үзен уратып алган мещанлыкка, туң йөрәкле кешеләргә карата нәфрәт хисе туа. Ниһаять, ул «яхшы» белән «начар»ның асылына төшенә башлый. Гәрәеваның Зөбәйдәсе туктаусыз уйлый, аның җаны, күңеле, йөрәге аша йөз төрле бәрелешләр, мең төрле тойгылар уза. Спектакльне караганнан соң шагыйрә С. Сөләймpraнованың: «Наиләнең Зөбәйдәсе ягымлырак, кичерешләре нечкәрәк. Аны бөтен кире яклары белән яратасың. Наилә-Зөбәйдәнең «һич югы ике бүлмәле квартирасы, «Москвич» кына булса да машинасы, 300 дән дә ким түгел эш хакы булган кешегә генә кияүгә чыгам» дип йөрүләре дә Сөендек белән Зөфәрдән, үзен уратып алган мещанлыктан килү булып яңгырый. Наилә-Зөбәйдәнең бөтен ямьсез гадәтләре үз тирәсендәге туң йөрәкле кешеләргә җавап», дигән фикере белән тулысынча килешәсең.

Гәрәеваның Зөбәйдәсе тамашачы күңелендә ике төрле хис уята. Бер карасаң, ул аңардан, аның тышкы кыяфәтеннән, кыланышларыннан, аның туганнары белән булган мөгамәләсеннән көлә, икенче караганда, ул аны чын күңелдән кызгана, аның белән бергә әрни. Тамаша залы, гөр килеп, аның һәр сүзен, һәр хәрәкәтен көтеп ала. Артистка Зөбәйдәне тиз генә гаепләргә ашыкмый. Ул аның характерында барган үзгәрешләрнең объектив сәбәпләрен эзли, аларны аңларга һәм шулар аркылы Зөбәйдәне акларга омтыла. Кыскасы, ул Зөбәйдәнең язмышын чын драма итеп кабул итә. Менә шуңа күрә дә инде Гәрәеваның Зөбәйдәсе барлык шуклыкларына, кирелекләренә, тышкы кыяфәтендәге ясалмалыкларына карамастан, үзенең эчкерсезлеген, күңел сафлыгын тамашачыга бөтен тулылыгы, бөтен матурлыгы белән күрсәтә.

«Зөбәйдә — адәм баласы» спектакле шактый озын гомерле булды. Наиләнең Зөбәйдәсе Рәхиләдән ким популярлык казанмады. Бу образ Наиләнең табигатенә шул кадәр туры килде ки, бу рольдә хәтта башка берәүне күз алдына да китерү мөмкин түгел иде.

Ш. Хөсәеновның «Әни килде» спектакленә кадәр Гәрәева һәрвакыт диярлек уңай рольләрдә генә уйнап килде. Римма — аның беренче тискәре роле. Шуңа күрәдер, ахры, Наилә бу рольне ничектер яратып бетерми, ләкин дөрес һәм оста башкара. Беренче карашка, Зөбәйдә белән Римма образлары арасында бернинди дә уртаклык юк кебек. Ләкин ашыгыч нәтиҗә ясамыйк. Ялгызлык газапларыннан тәмам гаҗиз булган Зөбәйдәнең дә, Римма кебек үк, җиңел юлга басуы мөмкин түгел идемени? Әмма Римма — характеры, табигате белән бөтенләй икенче кеше. Аның дөнья белән танышлыгы Казанның Бауман урамыннан ары китми. Ул дөньяда бернәрсә белән дә кызыксынмый, берни белән дә мавыкмый. Кияүгә дә аны-моны уйлап тормыйча, башкалар чыкканга гына чыга. Сәярмы ул, әллә башка егетме — җитди мәсьәлә түгел. Тик аның кеше күзенә күренерлек чибәрлеге, бераз буй-сыны булсын да дәрәҗәсе булсын. Алар менә шушы тар бүлмәдә яшәячәкләр (студентка вакытта ярап торыр), менә болары Сәярның туганнары икән (я, хода, бигрәк күңелсез һәм кызыксыз кешеләр!), биергә чакыралармы? (бусы, һәрхәлдә, кызыграк)... Бер караганда Римма-Гәрәева сәхнәдә үзен гади, хәтта артык гади тота сыман. Ләкин шул ук вакытта аның һәр хәрәкәте, һәр сүзе, сәхнәдә аяк атлап йөрүләренә кадәр, Римманың үзенчәлекле характеры, кешелек сыйфатлары турында сөйли. Гәрәева, артистка буларак, бу очракта да үзенең сәхнә почеркына турылыклы булып кала. Ул бер-берсеннән аерылып торган төсләр кулланмый. Без яңадан Наиләгә хас йомшаклык һәм табигыйлек белән очрашабыз. Нечкә нюанслар, ярым тоннар, психологик штрихлар артистка тарафыннан монда да, һәрвакыттагыча, мул кулланыла.

Наилә Гәрәева иҗат иткән замандаш хатын-кыз образлары арасында иң мактаулы урынны, әлбәттә, «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Әсәл образы алып тора. Бу рольне башкарган өчен Н. Гәрәева Тукай премиясе лауреаты исеменә лаек булды.

Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» әсәрендә кешеләр язмышы, кешеләр тормышы бөтен катлаулыгы белән сурәтләнә. Пьеса, беренче карашка, бүгенге чордагы көндәлек вакыйгалар, кешеләр арасындагы гади мөнәсәбәтләр турында сөйли кебек. Ләкин шушы көндәлек тормыш, шушы көндәлек вакыйгалар артында никадәр эчке кичерешләр, дулкынланулар, уй-теләкләр, шигъри хисләр яшеренгән! Әсәрдә бүгенге көн тормышы, бүгенге көн образлары поэзия югарылыгында күрсәтелә. Бу исә театрга гаҗәеп бай материал, иҗади мөмкинлекләр бирә. Шул сәбәпле булса кирәк, «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә катнашкан күп кенә актерларыбызның иҗатлары ничектер бөтенләй яңача балкып китте. Шул исәптән, Гәрәева таланты да бу әсәрдә бөтен гүзәллеге, нәфислеге, шигъри матурлыгы белән күренде.



«Зөбәйдә — адәм баласы» спектаклендә Зөбәйдә.

Әсәрдәге Әсәл һәм Ильяс мәхәббәте — ике яшь йөрәкнең беренче талпынуы, хисләрнең беренче канатлануы ул. Тал чыбыгыдай нәфис гәүдәле, йөрәгенә ак болытлар пакьлеген, тау күлләре сафлыгын сыйдырган чем-кара сихри күзле бу кызга бер күрүдә гашыйк булмый мөмкин түгел. Менә аларның беренче очрашулары. Бу мизгелдә дөнья бары тик шушы ике гашыйкның мәхәббәте турында гына җырлый башлады, сәхнә рамкалары, сәхнә кануннары юкка чыкты, тирә-юнь кинәт киңәебрәк, яктырыбрак киткәндәй булды, җиһан шатлыклы моңга төренде. Гашыйкларның якты күзләреннән ургылып торган хисләр һәм тойгылар гаммасы тамашачы күңеленә күчте.



«Гүзәлем әсәл»дә Әсәл.

Әсәл мәхәббәте — горур мәхәббәт. Аңа ия булу — үзе зур куаныч, зур бәхет. һәм аңа бары тик кешелекле, Әсәлнең үзе кебек үк саф күңелле, намуслы булуың белән генә лаек була аласың. Әгәр инде ул мәхәббәтнең кадерен белмисең, аны күз карасыдай сакламыйсың икән, димәк, син үз-үзеңне бик зур нәрсәдән — бәхеттән мәхрүм итәсең.

Ул чакта театр белгечләре спектакльгә һәм, аерым алганда, Гәрәева иҗатына бик хаклы рәвештә югары бәя бирделәр. «Спектакльнең эмоциональлеге, аның кие-

ренке эчке динамикасы баш рольләрне — Әсәл һәм Ильясны башкаручы—Н. Гәрәева һәм Р. Тажетдиновка бәйле. Инде күп кенә спектакльләрдә төп һәм җаваплы рольләрне уйнаган бу яшь артистларның иҗаты камаллылар сәнгатендә шактый тирән эз калдырып өлгерде»[1]. «Әсәл образы әйтерсең лә табигатьнең үзе тарафыннан лиризмны, шигъриятне, хатын-кызга хас нәфислекне һәм мөлаемлекне үзенә туплаган талантлы яшь артистка Наилә Гәрәева өчен язылган. Аның Әсәле, сәхнәгә аяк атлап керү белән, тамашачыны үзенә буйсындыра, аның мәхәббәтен яулап ала — моны бары тик артистка һәм персонажның табигатьләре тәңгәл килү белән генә аңлатып булa. Ләкин бу образның әһәмияте тәңгәл килүдә генә түгел. Гәрәева Әсәл характерын сәнгатьчә осталык һәм нәфислек белән үсештә күрсәтә алды»[2].

«Гүзәлем Әсәл» спектакле — Г. Камал театрының соңгы елларда куелган иң уңышлы һәм театрның иҗат йөзен билгеле торган фәлсәфи карашлы спектакльләрнең берсе. Гәрәеваның бу спектакльгә керткән өлеше шактый зур, чөнки аның иҗат таланты, сәләте, художник буларак дөньяны тануы, аңлавы, бу образда бөтен нечкәлеге һәм кабатланмас үзенчәлеге белән яктырып күренде. Наилә Гәрәеваның нечкә лирикага, киашлы офыкларга, йолдызлы биеклекләргә омтылучы романтик пландагы артист-художник булуы бу образ аша тагын бер тапкыр расланды.



«Айдын» спектаклендә Гөлтекин.

В. Шекспирның «Чамасына күрә чарасы» һәм әзербәйҗан язучысы Җ. Җаббарлының «Айдын» спектакльләрендәге Н. Гәрәева тарафыннан иҗат ителгән Изабелла һәм Гөлтекин образлары — сәхнәдә яңача чишелешләре белән игътибарны җәлеп иткән характерлар. Ярсу хисле, йөрәгеннән яшьлек дәрте ташып торган Изабелла образы, Шекспирның һәр образы кебек үк, Гәрәеваның бөтен артистлык осталыгын эшкә җигүне таләп итте. Гәрәеваның Изабелласы — Шекспир геройларына гына хас көчле рухлы һәм һәрвакыт хакыйкатькә омтылучы шәхес. «Кечкенә гәүдәле, мөлаем яшь кыз эчке рухы белән саф, гөнаһсыз, акыллы. Анджелло белән очрашканда без аны яшьләргә хас эмоцияле, ашкынулы кыз итеп кенә түгел, бәлки фикер йөртә белүче, тормышны аңлаучы кеше итеп тә күрәбез. Изабелла, Гамлет кебек, әхлакый максималист, матур яшәргә омтылучан. Ул яшәү өчен генә түгел лаеклы яшәү өчен көрәшә»[3]. Һәм шул ук вакытта Изабелла-Гәрәева искиткеч грацияле, нәзакәтле һәм гаять инсафлы аристократка. Ләкин бу тышкы кыяфәтне сурәтләүдәге төгәллек образның эчке темасына, аның эмоциональ тональлегенә буйсындырыла һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, Гәрәева сәхнәдә классик репертуарга лаеклы образ иҗат итә.

---

[1] Р. Усманова. Навстречу счастью. «Советская Татария» газетасы. 20 апрель. 1967 ел.

[2] «Театр» журналы. 1970 ел. 11 сан.

[3] И. Иллялова. Чамасына күрә чарасы. «Социалистик Татарстан» газетасы. 12 январь. 1969 ел.

«Айдын» спектаклендә Гөлтекин образы да шундый ук газаплы эзләнүләр һәм эзлекле уйланулар нәтиҗәсендә туа. Әсәрдәге вакыйгалар 1915—1917 елларны үз эченә ала. Бу әсәрнең төп герое бунтарь йөрәкле Айдын моңа кадәр яшәп килгән канун һәм гореф-гадәтләрне, капитализмның алтынга корылган властен фаш итәргә омтыла. Тик ул сүздә генә шундый булып кала. Асылда Айдын массалардан ерак, коллективтан читтә, явызлыкны җиңәрлек көчләрне күрергә сәләтсез. Айдынның хатыны Гөлтекин исә — туры җанлы, сабыр холыклы гаять мөлаем хатын. Ул, Айдыннан үзгә буларак, аны коткару өчен актык сулышына кадәр көрәшә.

Мәхәббәтен, хыялын, хакыйкатен, идеалын югалткан хатын-кыз язмышы аша Гәрәева кешенең рухи көчен, тормыштагы кыюлыгын сурәтли. Шул көч һәм кыюлык Гөлтекинне тирә-юньдәге рәхимсезлектән, пычраклыктан, өметсезлектән котылырга өнди. Үлемне бу очракта Гөлтекин-Гәрәева бердәнбер котылу юлы итеп кабул итә.

Артистка Гөлтекин ролен югары хискә бирелеп уйнаса да, бу хис, бу темперамент акылга буйсындырылган. Шунлыктан аның уенында очраклы, чит интонацияләргә бөтенләй диярлек урын юк, һәм шул сәбәпле артистка үз ролен драматик киеренкелектә башкарып чыга. «Кайвакыт артистлар үз рольләрендә булмый яки шул рольгә ничектер кереп китә алмый, ә бу спектакльгә карата андый сүзне әйтәсе килми. Карагыз, Наилә Гәрәева коточкыч язмышка дучар булган Гөлтекин ролен никадәр зур осталык белән башкара. Сүз белән хәрәкәтнең чынбарлыктагыча бердәмлеге, сәхнәдәге тасвирлау чараларының билгеле бер идеал һәм эчтәлеккә ятышлысын гына куллана белү, күз карашы һәм йөз хәрәкәтенең җитезлеге, урынлы-урынсыз йөгәненнән ычкындырылмый торган эчке ялкын — болар барысы да безнең артистка өчен хас, шуңа күрә дә ул өеруча трагедия жанрындагы рольләрне — бу очракта бәхетсез Гөлтекин образын — ышандырырлык итеп, сәнгатьчә итеп бирә ала»[1].

Менә Гәрәева башкаруында француз драматургы Бомаршеның «Шау-шулы көн яки Фигароның өйләнүе» исемле комедиясендә асрау кыз Сюзанна роле. Сюзанна образы — үткен сүзле, зирәк һәм шаян карашлы, француз тапкырлыгын һәм нәфисләгән үз эченә алган миниатюр образ. Линия һәм штрихлардагы үзенчәлек, кыланышларда югары артистлылык һәм самимилек бу образны характерлауда кулланылган төп сыйфатлар. Үз чоры өчен (1779 елны язылган) политик комедия югарылыгындагы бу пьеса бүген татар сәхнәсендә күңелле, көлкеле вакыйгаларга, мажараларга, ситуацияләргә бай комедия (комедия положений) буларак куелган. Мондый әсәр артистлардан жанр үзенчәлеген нык тоеп, сатирик алымнарны мул кулланып, форма төгәллегенә исәп тотып, ачыктан-ачык театраль ирониянe үз эченә алган стильдә уйнауны сорый. Спектакльнең ритмы бу очракта үзе мәстәкыйль яңгыраш ала һәм артистның уены эчке дөреслек белән иркен театраль форманы бер бөтен итеп, бергә үреп бирүне таләп итә. Гәрәева Сюзанна образын менә шушы таләпләрне истә тотып иҗат итте һәм үзенең комик пландагы артистка буларак та сәләтле икәнлеген күрсәтте.

Н. Гәрәева иҗатының тагын бер матур ягына тукталып китми булмый. Наилә — театрның травестие: ул гаҗәп бер осталык һәм кыюлык белән малайлар ролен уйный. «Азат» спектаклендә Азат, «Остапның даны»нда Остап, «Чаткылар»да Сәетгәрәй һәм «Кыю кызлар»да шәкерт малай булып киенгән Бибкәй рольләре бу күзлектән — игътибарга лаеклы образлар. «Чаткылар»дагы Сәетгәрәй — кечкенә генә эпизодик роль. Ләкин Гәрәева башкаруында шаян һәм үткен авыл малаеның эчке дөньясы, аның характеры, аның язмышы сине бик тиз дулкынландырып өлгерә.

Образлылыкка, самимилеккә, фикер ачыклыгына ирешү — артистканың малайларны иҗат иткәндә из алдына куйган бурычлары менә шундыйлар.

Күрүебезчә, Гәрәеваның актерлык таланты күпкырлы, һәм шуңа күрә дә шигъри җанлы, зирәк акыллы, талантлы артистка Наилә Гәрәеваның үз чоры, шул чорның үзенә генә хас уй-фикерләре, теләкләре, мәхәббәте, яну-көюләре, мөһим проблемалары хакында сәхнәгә чыгып замандашы белән уртаклашуы, аның ышанычын, ихтирамын, хөрмәтен казануы, минемчә, бик табигый хәл.

[1] Х. Курбатов. Айдын. «Социалистик Татарстан» газетасы. 13 апрель. 1969 ел.

Һәрбер иҗат кешесенә хас булганча, Наиләнең иҗаты да тигез һәм туры юлдан гына бармый. Эзләнүләр белән бергә икеләнүләр, уңышлар белән уңышсызлыклар, хәтта кайвакытта үз-үзеңне кабатлаулар да була. Мисал өчен Д. Вәлиевнең «Намус хөкеме» драмасында Лина образына күз салыйк. Миңа калса, артистка бу образда «Әни килде»дәге Римма характерын кабатлый. Бу образны сатирик планда чишәргә омтылып, кирәкмәгән хәрәкәтләр ясый. Дөресрәге, бу очракта Наилә чама дигән төшенчәне онытып җибәрә.

Әйткәнемчә, Наилә, башка бик күп артистлар кебек үк,— минем якын танышым. Мин Наилә белән очрашып сөйләшергә, фикерләремне уртаклашырга яратам. Менә бүген дә мин Наилә янына килдем... Горький урамының Толстой урамы чатына җитәрәк ул: «Син бераз көтеп тор, мин Фәритне алып чыгыйм»,— дип, улы укый торган мәктәпкә кереп китте. Шактый көттем — Наилә юк та юк. Мин, Наиләне эзләп, Фәритнең класс бүлмәсенә кердем. Ә ул пальтосын салган, дәрес тактасы янына баскан: кулында акбур. Үзе тактага икс-игреклар яза, ә үзе кызып-кызып нәрсә турындадыр укытучы белән бәхәсләшә. Аларны балалар сырып алган. «Менә шулай, Фәрит укырга кергәннән бирле, үзем яңадан мәктәп укучысына әверелдем бугай инде»,— ди Наилә, елмаеп... Без өчәүләшеп Толстой урамыннан Казанка буена төшеп барабыз. Тау битеннән гөрләвекләр ага. Фәрит бер йомычка кисәге алды да аны гөрләвеккә агызып җибәрде. Ә үзе, күмелгәнче, шул йомычка артыннан карап калды. Әнисенең дә карашы шул якта. Әлбәттә, Фәрит өчен бу гади йомычка гына түгел, ә бәлки ак җилкәнле зур кораб. Кем белә, бәлки, Наилә үзе дә шундыйрак хис кичерәдер. Аның табигате, аның характеры өчен бу бик табигый.

Язгы гөрләвек тау битеннән җырлап һәм чыңлап Казанкага таба ага, Казанка Иделгә тоташа. Идел — диңгезгә.

Наиләнең иҗаты да, язгы гөрләвек кебек, үз җыры, үз тавышы белән татар театры сәнгатенә барып кушыла. Ә татар театры исә — күп милләтле совет сәнгатенең олы бер тармагы.

**Максим Глухов**

# ТАТАР ГРАФИКАСЫ

(20 нче елларда чыккан китап һәм журналлар буенча)

Революциягә кадәрге татар сынлы сәнгате турында сүз алып барганда хәзерге авторларның күбесе Габдулла Тукайның татар матбугаты үзенең милли рәссамнарына мохтаҗ булуы турында әйткән мәгълүм сүзләрен мисалга китерергә яраталар. Аннары татарлардан бер генә кешегә булса да югары художество белеме алу мөмкинлеген тудыру өчен, Галиәсгар Камалның алдынгы карашлы интеллигенциядән акча җыюны оештырып йөргәнлеген искә алып үтәләр. Болар, әлбәттә, шактый гыйбрәтле, ышандыра торган фактлар. Ләкин болардан чыгып кына, ул чорларда татарларның үзләренең бер генә профессиональ рәссамы да булмаган икән, дип нәтиҗә ясау да дөрес булмас иде[1]. Кызганычка каршы, кайбер иптәшләр кайчакта нәкъ менә шулай ашыгып нәтиҗә ясарга омтылалар да.

Алар бу мәсьәләдә үзләренә ышанычлы дәлил итеп менә нәрсәгә таяналар: имеш, ислам дине борын-борыннан тере җан ияләренең сурәтен ясауны тыеп килгән, шуңа күрә дә, имеш, татарлар арасында рәссамнар булмаган. Татарларның сынлы сәнгатенә һәм эстетик фикере тарихына кагылышлы барлык хезмәтләрдә дә диярлек менә шушы фикер үткәрелә.

Дөрес, ул иптәшләрнең дә сүзләрендә хаклык бар. Чынлап та, ислам дине мөселманнарга рәсем ясауны тыйган, бу эш белән шөгыльләнгән кешеләрне «кяфер» дип санаган. Әмма шул ук вакытта әлеге иптәшләрнең нәтиҗәләре белән дә тулысынча килешеп булмый. Ни өчен дигәндә, асылда эш менә болайрак тора: Коръәндә рәсем ясауны тыя торган бер генә сурә дә юк[2]. Алла һәм адәм сурәтләрен ясарга ярамый, бары тик агач чәчәк, һәм шуләр ише җансыз әйберләрне генә ясарга мөмкин икәнлеген әйткән сүзләр Коръән шәрехләренә соңыннан, дини фанатизмның һәм руханиларның ихтыяры белән генә өстәп куелган булса кирәк. Андый тыюлар Коръәннең соңгы басмаларында гына очрый.

Ислам диненең рәсем ясауга каршы булмаганлыгын мөселман сәнгате тарихын бик тирәнтен өйрәнгән галим Б. Деникe хезмәтләреннән дә күрергә мөмкин. Аның хезмәтләрендә, мәсәлән, хәлиф Абдел-Малик заманында Иерусалимдагы бер мәчетнең ишекләренә бик яхшы итеп Мөхәммәт сурәтләре төшерелгән булуы, ә мәчетнең стеналарына җәннәт һәм тәмуг рәсемнәре ясалган булуы бик ачык итеп әйтелгән[3]. Шул ук галимнең шәрык халыкларының рәсем сәнгатенә караган бүтән хезмәтләрендә дә мондый хәлнең гадәти булганлыгын күрергә мөмкин. Ә бу галимнең фикерләренә ышанмаска безнең бернинди дә нигезебез юк.

Аннары тагын шунысын да хәтердә тотарга кирәк: мәгълүм булганча, татар халкының үз кул көче белән көн күреп яшәүче күпчелек өлеше элек тән дә бик алай диндар булмаган лабаса. Чөнки ул гарәп телен белмәгән. Шуңа күрә аның

---

[1] Әйтик, шул ук XX йөз башында М. Галиев, Г. Гумеров һәм башка рәссамнар татар вакытлы матбугатына хезмәт күрсәтеп килләләр. Галиәсгар Камал үзе дә хәйран әйбәт рәссам була. (Бу турыда С. Ишморатованың 1948 елда «Габдулла Тукай» исемле китапта басылып чыккан «Тукай иллюстраторлары» исемле мәкаләсендә шактый тулы әйтелгән.)

[2] Коръән. И. Ю. Крачковский тәрҗемәсе һәм комментарийлары. Мәскәү. 1963 ел. Рус телендә.

[3] Кара: Б. Д е н и к е. Көнчыгыш сәнгате, Казан. 1923 ел. Рус телендә.




Госман Арсланов. «Безнең матбугат» җыентыгының тышлыгы. Казан. 1924 ел.

Корьән белән танышлыгы да чамалы, дин әһелләре белән алыш-биреше дә чикле булган. Сүз дә юк, руханилар элек-электән гади халыкны дини итәргә, дин кануннарына турылыклы булырга өндәп килгәннәр. Ләкин ул өндәүләр барлык кешегә дә бертөрле тәэсир итмәгән, гел дин кушканча гына йөрмичә, үзләре теләгәнчәрәк эш итүчеләр дә, әлбәттә, булган. Билгеле, реакцион милли изү хөкем сөргән ул заманнарда чын мәгънәсендә талант ияләренә дә үзләренең талантларын күрсәтү бик кыенга туры килгән. Ләкин, шулай булуга да карамастан, халык арасыннан талантлы кешеләр чыга торган һәм алар үзләренең эшләрен эшли торганнар.

Сынлы сәнгать өлкәсендә дә андый халык талантлары булган, әлбәттә. Матурлыкны тою хисе безнең халыкта бик көчле бит. Ләкин аларның исемнәре тарихка теркәлеп бармаган, кызганычка каршы, онытылган. Шуңа күрә без аларның үзләре һәм иҗатлары хакында иркенләп сөйли алмыйбыз. Шуңа күрә бу мәкаләдә без сүзне исемнәре һәм хезмәтләре билгеле булып та, соңгы елларда хаксызга онытыла башлаган профессиональ рәссамнарыбыз хакында гына алып барырга уйладык.

Эшне Мирзаҗан ага Байкиевтан башлап җибәрәсе килә. Бу сәләтле рәссамның иҗат мирасы, кызганычка каршы, әлегә бик аз өйрәнелгән. Риза Ишморат һәм Бакый Урманчеларның 20 нче елларда басылып чыккан мәкаләләреннән башка, аның хакында матбугатта бөтенләй берни дә язылмаган дияргә була. Ә бит ул, Пенза губернасының ярлы крестьян малае, үзенең тырышлыгы һәм зур сәләте булуы аркасында инде 1893 елда ук Петербургта барон Штиглицның[1] художество институтын тәмамлаган һәм соңыннан Эрмитаж скульпторлары арасында иң күренекле урыннарның берсен тоткан рәссам. Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Мулланур Вахитов сыннарын да татар скульпторларыннан беренче булып шул ук Мирзаҗан ага Байкиев иҗат иткән. Безнең сәнгать белгечләребез . менә боларны исләренә алырлар һәм М. Байкиев иҗатына тиешле бәяне бирерләр дип ышанасы килә.



Фаик Таһиров. Гадел Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» исемле җыентыгының тышлыгы. Казан. 1925 ел.

XX гасыр башында иҗат иткән профессиональ рәссамнарыбыз рәсем сәнгатенең төрле өлкәләрендә эш алып барганнар. Аларны саный башласаң, озынга китәр иде. Шунлыктан без ул рәссамнар

[1] Хәзерге В. Мухина исемендәге Югары кенкүреш сенгате училищесы.

ижатының тик бер генә ягына — китап басу белән бәйле график миниатюраларына гына тукталып үтүне кирәк таптык.

Мәгълүм булганча, татарларда китап баса башлау XVIII йөз ахырларында ук барлыкка килгән һәм бу өлкәнең үзенең бик бай тарихы бар. Әбрар Кәримуллинның әле узган ел гына Казанда рус телендә басылып чыккан «У истоков татарской книги» исемле китабында бу мәсьәлә шактый тулы яктыртылган. Ләкин, безнең карашыбызча, анда китапларның художество-полиграфик ягыннан ничек эшләнгән булулары бик аз чагылдырылган. Китапларны чыгаруда катнашкан рәссам-миниатюрчыларның исемнәре күрсәтелмәгән. Ә бу мәсьәлә шулай ук өйрәнелергә тиешле.

Әгәр узган гасыр урталарында басылып чыккан татар китапларын кулга алсаң, иң элек аларның тышлыклары, беренче һәм соңгы битләре, текст башлары, кызыл юлдагы беренче хәрефләре бик матур итеп, искиткеч зур зәвык белән эшләнгән булуларына игътибар итмичә мөмкин түгел. Алар барысы да татар халкының традицион орнаментларына нигезләнеп, бер күрүдә күңелгә кереп калырлык дәрәҗәдә үзенчәлекле итеп эшләнгәннәр. 1923 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Очерки истории об образованности и литературы татар» исемле хезмәтендә Җамал Вәлиди безнең халыкның кечкенәдән үк борынгы миниатюраларны һәм матур каллиграфияне яратып үсүен, укый-яза белгән һәр ата-ананың үз баласына матур язарга һәм китапларда очраган рәсемнәрне күчереп ясап барырга өйрәткәнлеген бик хаклы рәвештә билгеләп үткән. Әле XVIII гасыр азагында ук, дип яза ул, кульязма китапларны күчереп язу шәкертләрнең иң яратып эшләгән эше булып торган. Шул ук шәкертләр әлеге кульязма китапларын шыпырт кына, хәлфәләренә сиздермичә генә, төрле рәсем-миниатюралар белән дә бизәргә яратканнар.

Казанда татарча китаплар бастыра торган «Азиатская типография» ачылганнан соң китап бастыру эшендә актив катнаша башлаган беренче рәссам-миниатюрчылар да, мөгаен, әнә шул шәкертләр арасыннан чыккандыр.

Узган йөз урталарында яшәгән каллиграф Гали Мәхмүдовның исеме бик күпләргә мәгълүм. Аның турында күп кенә кешеләр мәкаләләр дә язып чыкканнар. Ләкин ул авторларның берсе дә Гали Мәхмүдовның рәссам-профессионал буларак эшләгән хезмәтләренә кагылмаганнар дисәк, ялгыш булмас. Бары тик күренекле сәнгать белгече, Казан һәм Татарстанның культура тормышында сизелерлек эз калдырган П. М. Дульский (1879—1956) гына бу мәсьәләгә кагылып узган һәм Гали Мәхмүдовның үз заманында «билгеле миниатюрчы-рәссам» булганлыгын әйткән. («Вестник Научного общества татароведения». № 9—10. 1928.) Халкыбызның революциягә кадәрге чордагы сынлы сәнгате тарихын махсус өйрәнгәндә бу өлкәдә эшләгән тагын бүтән кешеләрнең исемнәрен дә ачыкларга мөмкин булыр дип уйлыйбыз.

Ә хәзер милли графика сәнгате өлкәсендә аеруча актив эшләгән беренче татар совет рәссамнарының кайберләренә кагылып китик.

Казанда шактый гына рәссамнар булуга да карамастан, Татарстанда культура төзелеше башланган елларда безнең графика сәнгатебезнең хәле шактый кыен була. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен 1918—1922 елларда басылып чыккан китапларны кулга тотып карау да бик җитә. Ул китапларның художество оформлениеләрен һич тә әйбәт дип әйтеп булмый. Һәм бу аңлашыла да: озак елларга сузылган империалистик сугыш, егерме беренче елгы ачлык, полиграфик базаның булмавы һәм, ниһаять, рәссамнарның барысының диярлек ул елларда модада булган төрле агымнар — кубизм, постимпрессионизм, сюрреализмнар белән мавыгулары графика эшенең артка калуына да йогынты итмичә калмаган. Әмма, шулай булса да, революциядән соң бу өлкәдә дә зур җанлылык башлана. Интеллигенция вәкилләре генә түгел, элек кимсетелеп яшәгән эшче һәм крестьяннар да аң-белемгә, культурага омтыла башлыйлар. Публицистика теле, агитплакат теле хезмәт иияләре күңелендә зур яңгыраш таба. Яңа тормышны пропагандалау өчен яңача пропаганда чаралары да кирәк була. Графика сәнгатенә игътибар арта һәм рәссамнарның күбесе шул эшкә бик теләп алына.

Революциядән соңгы беренче елларда Казанда эшләгән татар рәссам-графикларының иң күренеклеләреннән берсе — Госман Арсланов. 1897 елда Пермь шәһәрендә туган, башта рус-татар мәктәбендә башлангыч белем алган, аннары Пермьдә реальное училищеда укыган, аны тәмамлаганнан соң Пермь университетының физика-



Дмитрий Красильников. Хәсән Туфан портреты. «Безнең юл» журналыннан алынды (1927 ел, 6—7 нче саннар).

математика факультетына кергән һәм шул ук вакытта төрле рәссамнардан рәсем дәресләре дә алып йөргән бу кеше 1918 елда Пермьдә яңа ачылган художество остаханәләрендә эшли башлый.

Арсланов реальное училищеда укыган елларында ук рәсем сәнгате белән бик нык кызыксына. Пермьдәге рәсем сөючеләр җәмгыяте тарафыннан оештырыла торган күргәзмәләрнең барысына да бик кызыксынып йөри. Аның бу мавыгулары диндар татарлар арасында нәфрәт тудыра, шуңа аны «кяфер» дип атыйлар. Ә әтиәниләре бу «денсез» эшләр белән шөгыльләнүне бөтенләй тыялар. Шуңа күрә Арслановка бу өлкәдә системалы белем алу мөмкин булмый.

Ихтимал, аның рәссамлык таланты шул килеш югалып та калган булыр иде. Ләкин меңнәрчә талантларны тоткынлыктан коткарган Октябрь революциясе Госман Арслановка да үз максатына ирешү мөмкинлеген ача: ул Казанга күчеп килә һәм графика өлкәсендә эшли башлый. Егерменче елларда басылып чыккан татар китапларының барысы да диярлек Госман ага Арсланов тарафыннан иллюстрацияләнгән. Ул эшләгән рәсемнәрне «Кызыл яшьләр», «Октябрь яшьләре», «Чаян», «Авыл яшьләре» һәм башка журналларда шулай ук бик еш очратырга мөмкин. Әлбәттә, ул рәсемнәр арасында ашыгыбрак эшләнгән, шуңа күрә уңышсыз чыкканнары да бар. Ләкин хәйран әйбәт ясалганнары да байтак. Госман Арслановның ул еллардагы график эшләренең иң уңышлыларыннан берсе, минемчә, «Безнең матбугат» исемле китапка эшләнгән тышлык (Казан. 1924 ел). Бу тышлык ике төрле төс белән эшләнгән. Аның вертикаль сызыклары — кызыл. Тышлыкның югары өлешенә өч ак медальон ясалып, шуларга кара төстәге стильләштерелгән гарәп хәрефләре белән китапның исеме язылган. Графика белгечләре бу хезмәтне уңышлы дип тапканнар һәм ул үз заманында Парижда үткәрелгән күргәзмәгә дә куелган булган.

Кызганычка каршы, Г. Арслановның мондый уңышлы эшләре күп түгел. Бу хәл, күрәсең, художество өлкәсендә аның белеме җитәрлек булмау белән аңлатылырга тиешледер. Әмма, ничек кенә булса да, без аны хөрмәт белән искә алырга тиешбез. Чөнки ул Октябрь революциясеннән соң татарлардан беренче профессиональ рәссам булган һәм татар графика сәнгатенә бөтен булган тырышлыгын биргән кеше.

Татар графикасында җуелмас эз калдырган рәссамнарыбызның икенчесе — Фаик Таһиров. Фаик Таһиров элекке Свияжск өязенең Олы Ачасыр авылында укытучы семья-



Дмитрий Красильников. Н. Хәйруллинның «Язгы җырлар» исемле җыентыгының тышлыгы. Казан, 1928 ел.

сында туа. Унбер яшеннән ятим кала һәм үз көнен үзе күрергә мәҗбүр була. Башта ул Казанга килә, аннары Екатеринбургка (хәзерге Свердловск) юл тота. Шунда җидееллык рус мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә укуы белән бер үк вакытта йомышчы малай хезмәтен дә үти, китаплар төпләү белән дә шөгыльләнә. 1920 елда Екатеринбург татар-башкорт педагогия техникумына укырга керә. Анда бер ел укыганнан соң шунда ук художество-тимерчелек остаханәләренә эшкә керә. Аннары Пролеткультның изостудиясендә эшли башлый һәм шунда сәнгать буенча дәресләр ала башлый.

1922 елның апрелендә, сәнгать-техника институтына укырга керү нияте белән, Фаик Таһиров Казанга килә. Ләкин ул бу институтта уку бәхетенә икенче елның көзендә генә ирешә.

Ул елларда инде китап басуның техник шартлары да сизелерлек яхшыра башлый. Мәскәүдә һәм Ленинградта графика сәнгатен конкурешта дә куллану алымнарының бик яхшы үрнәкләрен күрсәтә торган рәссам-графиклар үсеп чыга. Китапларның сыйфаты яхшыра. Башкаланың графика осталары төп ике агым тирәсенә тупланалар: берәүләре традицион-классик алымны һәм ретроспективизмны яклый, икенчеләре — конструктивистлар — китапларны яңа индустриаль алымнарга нигезләнеп чыгаруны алга сөрәләр. Татар рәссамнарыннан Фаик Таһиров соңгылары яклы була. Язучы Гадел Кутуй белән бергәләп, ул 1923 елда «Сульф» группасын оештыруда да башлап йөрүчеләрнең берсе була, «Бомба» исемле татар театр коллективы эшендә дә актив катнаша һәм, гомумән, егерменче елларда Казанның культура тормышында зур урын тота.



Дмитрий Красильников. Максим Горький портреты. «Авыл яшьләре» журналыннан алынды (1928 ел, 7 нче сан).

Ләкин Фаик Таһировның төп эше графика була. Кыска гына вакыт эчендә ул бу өлкәдә бик күп китапларга иллюстрацияләр һәм тышлыклар эшли. Аның Г. Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» (1924 ел), Г. Нигъмәтинең «Әдәбият дөньясында» (1925 ел), Ш. Усмановның «Памирдан радио» (1926 ел), К. Нәҗминең «Өермә» (1927 ел) исемле китапларына эшләгән тышлыклары, безнеңчә, аеруча оста эшләнгән. «Бу яшь рәссам — эшендә бик тырыш, уйлап табучан. Шуңа күрә аның графикасы, беренче карашка бик гади генә булып тоелса да, тегеләй бу мәсьәләне хәл иткәндә бик нык зәвыклы, оста һәм кыю эшләнгән була. Үз эшендә ул фотомонтаж, мозаикалар җыелмасы, акциденция һәм китапның формасын заманча ачып җибәрә торган яңа техник алымнар куллана. Китапның графикасын хәреф җыю сәнгате белән тулысынча бәйләп бирә». 1930 елда П. Дульский Фаик Таһировның иҗатын менә шушылай дип бәяли.

Ф. Таһиров иҗатына 1925 елда Парижда үткәреләчәк көнкүреш сәнгате күргәзмәсенә экспонатлар җыйган чакта ук игътибар итәләр һәм аның график хезмәтләрен дә шул күргәзмәгә алып баралар. Һәм шунысы кызыклы: Фаик Таһировның хезмәте ул күргәзмәдә дә югалып калмый. Республикабызның Арча һәм Дөбьяз районнарында эшләнгән тәсле күн әйберләре, Сабада һәм Балык бистәсендә эшләнгән ювелир әйберләре белән бергә Фаик Таһиров оформлениесе белән чыгарылган татар китабы да Париж күргәзмәсенә килгән тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. Тәнкыйтьче Я. Тугенгольд әлеге күргәзмә нәтиҗәләре турында язылган «Ис-

кусство народов СССР» исемле мәкаләсендә Ф. Таһиров графикасына да кагылып, аны күргәзмәгә куелган милли хезмәтләр арасында иң яхшыларыннан берсе дип билгеләп үтә. («Печать и революция» исемле җыентыкның 1927 елда чыккан сигезенче китабы.)

Гарәп шрифтын ачык һәм уңайлы итеп язу өлкәсендә дә Ф. Таһиров күп көч куйган кеше. Аның каллиграфик эзләнүләре нәтиҗәсендә китап һәм журнал тышлыкларында гарәп шрифтларын туры сызыклы геометрик рәсемнәр сыман итеп яза башлау гамәлгә кертелде. Яңалиф шрифтларын ничек яхшырак итеп язу буенча да Ф. Таһиров күп эш эшләде. Ул уйлап тапкан гади һәм аңлаешлы шрифт формалары хезмәт ияләренә укырга-язарга өйрәнгәндә, әлбәттә, зур ярдәм иткән булырга тиеш.

Егерменче еллар башындагы татар графикасының, инде әйтеп үткәнебезчә, уңышлары шактый зур. Ләкин, шуның белән беррәттән, аның бер үзенчәлекле кимчелеге дә булган. Хикмәт шунда, ул еллар графикасында кеше һәм гомумән тере җан ияләренең сурәтләре бөтенләй диярлек чагылдырылмаган. Хәтта талантлы рәссам Фаик Таһиров та кешеләр сурәтен үзе ясамыйча, коллаж алымы (рәсем өстенә кешеләрнең әзер сурәтләрен ябыштырып куюны шулай дип атыйлар) белән генә эш иткән. Монда, күрәсең, электән килгән традициянең тәэсире булгандыр. 1927 елга кадәр басылган китапларда рәссамнарыбыз тарафыннан ясалган кеше сурәтләренең бөтенләй диярлек очрамавын шуның белән аңлатмыйча башкача ничек аңлатмак кирәк!

Ләкин еллар үтү белән бу өлкәдә дә хәлләр үзгәрә. Безнең үз рәссамнарыбыз да кеше сурәтләрен ясаудан тартынмый башлыйлар. Шулай итеп, безнең үзебезнең дә график-портретчыларыбыз барлыкка килә. Әнә шундыйларның иң беренчесе итеп Дмитрий Красильниковны санарга кирәктер. Минзәлә өязенең Урта Пенәче авылында керәшен татары семьясында туган Дмитрий авыл мәктәбен тәмамлаганнан ары Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә.

Ләкин, сәнгатькә омтылышы зур булганлыктан, 1922 елда Пермь сәнгать остаханәсенә китә. Анда бер ел эшләгәннән соң Казанга сәнгать-техника институтына кайта. Шунда 1927 елга кадәр сәнгать белән шөгыльләнә, аннары Мәскәүгә барып, ВХУТЕМАСта (Югары сәнгать-техника остаханәләре) укый.

Красильников иҗатына бәя биреп, профессор П. Дульский менә болай дип яза: «Аның әсәрләренең стиле реалистик. Яраткан темасы — авыл, табигать һәм кешеләр. Д. Красильниковның графика техникасы күңелгә ятышлы, йомшак һәм төзек композициягә ия»[1].

Д. Красильников республикабызда басыла торган төрле журналларда да рәссам буларак шактый актив катнашып килгән. Аның рәсемнәрен «Авыл яшьләре», «Кызыл яшьләр», «Чаян», «Безнең юл» журналларында еш очратырга мөмкин. Татар язучыларының китапларын формалаштырып чыгару өлкәсендә дә Д. Красильниковның хезмәтләре зур. Алдагы биттә Д. Красильников тарафыннан иҗат ителгән һәм татар графикасында беренче оригиналь портрет булып саналырга хаклы булган ике хезмәтне тәкъдим иттек. Аларның берсе — заманында «Безнең юл» журналында басылып чыккан Хәсән Туфан портреты, ә икенчесе — бөек пролетар язучысы Максим Горький портреты. Бу соңгысын Д. Красильников 1928 елда М. Горький Казанга килгән вакытта «Авыл яшьләре» журналының заказы буенча натурадан эшләгән. Бу портретларның ни дәрәҗәдә оста эшләнүен укучылар үзләре хөкем итсен.

Татар рәссам-графиклары башлап җибәргән эстафетаны егерменче еллар ахырында Казан сәнгать техникумын тәмамлаган яшь рәссамнар Ш. Мөхәммәтҗанов, Г. Юсупов, Г. Кәримов һәм башкалар кабул итеп алдылар һәм уңышлы дәвам иттерделәр. Монда без, урын кысан булганлыктан, аларның тик берсенең — Татарстан китап нәшриятында озак еллар буена эшләп килгән һәм китапларны сәнгатьле итеп формалаштыру эшен яхшырту өчен күп хезмәт куйган Шакир Мөхәммәтҗановның бер эшен генә урнаштырабыз.

Утызынчы елларда графика өлкәсендә Байназар Альменов кебек осталар эшли башлый. Ә соңгы ун-унбиш елда бу өлкәдә яшь рәссамнардан Илдар Әхмәдиев, Тавил Хаҗиәхмәтов, Азат Садыйков, Эрот Зариповлар бик уңышлы эшләп киләләр. Ләкин татар совет графикасына нигез салган иптәшләрне дә без онытырга тиеш түгелбез.

---

[1] «Безнең юл» журналы. 6—7 саннар. 1929 ел.

**Ильтани Илялова,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# КЕШЕ—ҖИРНЕҢ БИЗӘГЕ

Без беләбез: кеше үзе, аның тормышы һәм теләк-омтылышлары элек-электән сәнгатьнең төп предметы булып килгән. Соңгы елларда әдәбият-сәнгатьнең кеше тормышына булган игътибары тагын арта төште. Бу бик аңлашыла. Фәнни-техник революция чорында, космик очышлар, җир юлдашлары, айгизәрләр һәм автоматика гасырында, экономика күз иярмәс темплар белән үскән чорда кешегә игътибар бер сәяси аспектта гына түгел, идеологик һәм фәлсәфи аспектта да нык көчәя. Үзенең саф «кешелек» хисләре һәм эшләре белән ул робот автоматлар арасында югалып калмасмы? Аларның колына әйләнеп бетмәсме?.. Соңгы елларда бу мәсьәләләр буенча бер дә юкка гына каты бәхәсләр алып барылмый.

Шуңа күрә театрның да кешегә, аның тормышындагы үзгәрешләргә аерата игътибарлы булуы табигый һәм аңлашыла торган хәл. Кеше һәм аның тормыштагы урыны. Кеше һәм җәмгыять. Кеше һәм әхлак нормалары. Формалашкан һәм формалашып җитмәгән шәхес. Бүгенге театрларны, шул исәптән Татар академия театрын да, нык уйландыра торган төп мәсьәләләр шулар. Академия театры куйган иң яхшы спектакльләрнең буеннан-буена, кызыл җеп булып, шул тема сузыла. «Гүзәлем Әсәл» һәм «Айдын»ның да, «Сүнгән йолдызлар» һәм «Кол»ның да үзәгендә шул тема ята. Шулай да әлеге мәсьәләләр аеруча кискен, анык һәм ачык итеп татар драматургларының соңгы ике-өч ел эчендә язылган пьесаларында күтәрелә.

Академия театрының бүгенге авторлары арасында төрле буын драматурглар бар. Аяз Гыйләҗев белән Шәриф Хөсәенов, мәсәлән, 50 еллардан бирле коллектив белән даими элемтәдә яшиләр. Щепкин исемендәге студияне тәмамлаган элекке актер Туфан Миңнуллин белән элекке геолог Диас Вәлиев исә театрга күптән түгел килгән кешеләр. Уртак яклары шунда, аларның һәркайсы театрга тормышның эченнән килде, аны белеп һәм өйрәнеп килде. Һәркайсының үз темасы, үз алымы бар. Лирик пландагы драмалар авторы А. Гыйләҗев усал, ачы телле Ш. Хөсәеновка охшамаган кебек, халык күңелендәге хисләрне бөтен нечкәлекләре белән тоя белүче Т. Миңнуллин да зур гомумиләштерүләр ясарга, интеллектуальлеккә омтыла торган Д. Вәлиевтән нык аерыла.

Дөрес, бу авторларның соңгы әсәрләре бер үк жанрга карый. Аларның һәммәсе дә психологик драма жанрында язылган. Ләкин никадәр төрле-төрле алар. Хикмәт сюжет аерымлыгында гына түгел, ә күтәргән мәсьәләләренең характерында, язылу алымнарында. М. Сәлимҗанов куйган «Әни килде», «Ир егетләр», «Намус хөкеме» һәм П. Исәнбәт куйган «Әңгер-мәңгер» спектакльләренең бөтен кыйммәте дә шунда, бер үк жанрда язылган пьесалар буенча эшләнүләренә карамастан, алар бер-берсен аз гына да кабатламыйлар [1].

---

[1] Ә бит андый куркыныч бар иде. Заманында психологик драма театрның иң яраткан жанры булып килде. Андый әсәрләрне сәхнәгә куюда билгеле бер штамплар, әзер схемалар да калыплашкан иде.

Әмма күтәргән мәсьәләләре, әдәби эшләнешләре һәм сәхнәгә куелышлары ягыннан никадәр генә аерылмасыннар, бу әсәрләрнең, жанр уртаклыгыннан тыш, тагын бер уртак яклары бар. «Дөньядагы иң куркыныч нәрсә — рухи торгынлык» — шушы сүзләрне аларның һәркайсына эпиграф итеп куярга була. Рухи торгынлыкка, тук һәм тыныч тормышка, мещан бәхетенә каршы язылган ул әсәрләр. Түбәндә китерелгән цитаталарга игътибар итегез:

«Тынгылыкта — кыргыйлык. Тынгылыкта — үз-үзеңнән һәм әйләнә-тирәңдәге кешеләрдән канәгать булу. Тынгылыкта — тормышның, прогрессның, хәрәкәтнең тукталуы».

«Икенче берәүләр үз йөрәкләрендәге чын вөжданны, пакьлек һәм намусны корыталар. Берәүләр идеаллар хакына... берәүләр — чүпрәк-чапрак, квадрат метрлар, дача, автомобиль өчен... рухи хәерчелек төрле күләмле...»

«Спектакль эгоизмга, рухи торгынлыкка, мещан бәхетенә каршы көрәшкә чакыра, юмартлыкны, ныклыкны, мәхәббәтне раслый».

Күрәсез, эчке мәгънәләре белән никадәр уртак бу цитаталар. Ләкин сүз аларда өч әсәр («Эңгер-меңгер», «Намус хөкеме», «Әни килде») турында бара[1]. Өч тәнкыйтьче, бер-берсен бөтенләй белмәгән килеш, төрле вакытта, төрле шәһәрләрдә академия театрының өч спектаклен карыйлар һәм бер уртак фикерне тотып алалар. Сүз мещанлыкка, рухи торгынлыкка, тынгылыкка каршы көрәш турында бара.

Әгәр бу пьесаларның сюжетына күз салсак, анда искитәрлек берни дә юк кебек. Авылдан шәһәргә үлем хәлендәге ана килә. Шул анага күп санлы балалары янында сыенып урын табылмый («Әни килде»). Егерме биш ел вакыт узганнан соң ике фронтовик дус очраша, берсе икенчесенә тормышта үз урынын табарга булыша («Ир егетләр»). Мәскәүдән ерак провинциягә яшь бер егет килеп чыга һәм үзенә ошаган кызны алып китә («Эңгер-меңгер»). Суд тикшерүчесе Равил кулына күптәнге бер «эш» килеп керә, бу «эшкә» аның әтисе, күренекле галим Арсланов та буталган икән («Намус хөкеме»)... Беренче карашка, бары шул гына. Шаккатырлык әйбер юк, һәркайда очрый торган гадәти хәлләр. Ләкин без сөйләгән кадәресе әлеге әсәрләрнең схемасы, тышкы канвасы гына. Шул канвага авторлар кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган катлаулы бизәкләр чигәләр.

Спектакльләрне сыйфат ягыннан тигез дип булмый. Беришеләре бик уңышлы, икенчеләре алай ук түгел. Ләкин алар шул яклары белән кыйммәтле, ул спектакльләрнең һәркайсында бүгенге академия театрына хас тенденцияләр чагыла, театрның замандашларыбызга игътибарлы мөнәсәбәте, аны аңларга һәм тамашачыга җиткерергә омтылуы сизелә. Һәм режиссерлар да пьесаларның нәкъ әнә шул якларына басым ясаганнар, чын белән ялганның көрәшен калку итеп күрсәтергә тырышканнар.

Әлеге әсәрләрнең барысы өчен дә уртак тагын бер сыйфат турында. Соңгы елларга кадәр без көнкүреш спектакльләренә, ничектер, кимсетебрәк карый, аларны искергән, архаик формага исәпләп йөри идек. Көнкүреш үзе куркыныч түгел, фикерне ваклау хисабына көнкүреш белән мавыгу куркыныч икән. Югарыда исемнәре телгә алынган спектакльләр тагын әнә шул турыда сөйли.

Без тикшерә торган спектакльләрне җәмәгатьчелек төрлечә кабул итте. Аларның кайберләре (мәсәлән, «Ир егетләр» бәхәсләр, каршылыклы фикерләр уятмады диярлек. Театр әсәрне куйды, тамашачы аны тормыштагы уңай башлангычны раслаган, совет кешеләренең ихтыяр көчен күрсәткән спектакль төсендә каршы алды. «Эңгер-меңгер»не бәяләүдә дә тәнкыйть нигездә бердәм фикердә булды. Г. Кашшаф та, Д. Вәлиев тә пьеса һәм спектакльне бүгенге мещанлыкка каршы юнәлдерелгән әсәр дип бәяләделәр. Ш. Хөсәенов белән Д. Вәлиев пьесалары буенча исә капма-каршы фикерләр, бәхәсле моментлар байтак булды. Хикмәт нәрсәдә соң? Нигә берише әйберләр бердәм кабул ителә, икенчеләре төрле бәхәсләр китереп чыгара?

Безнең уебызча, бу хәл әлеге пьеса һәм спектакльләрнең «сверхзадачасын» һәм буйдан-буйга бара торган төп хәрәкәтен төрлечә аңлау белән аңлатыла. Хикмәт әлеге әсәрләрнең төп идеясен ничек аңлауда. Чөнки мәсьәләнең икенче ягы — башкару

---

[1] Д. Валеев. Когда расходятся пути («Советская Татария» газетасы. 1971 ел. 8 апрель саны.); Р. Копосов. Не убивал, но предал («Комсомолец Татарии» газетасы. 1971 ел. 22 октябрь саны.); Л. Горова. Театр им. Г. Камала на столичной сцене («Московская правда» газетасы. 1971 ел. 14 июль саны.).

осталыгы, кайбер ваграк нәрсәләрне искә алмаганда, нигездә бер үк югарылыкта дияргә була.

«Ир егетләр»не сәхнәләштергәндә М. Сәлимҗанов үзенең игътибарын пьесадагы төп нәрсәгә — колхоз председателе, коммунист Мәрвәннең кешене аякка бастыру, совет кешеләренең тормышын яхшырту өчен актив төстә көрәшүен күрсәтүгә юнәлдергән. Һәм бу рольне башкаручы актерлар да (Г. Шамуков, Һ. Солтанов) тапталып, чәйнәлеп беткән трафарет җитәкче образын бирү юлыннан китмәгәннәр. Ул искиткеч тере, тулы канлы образ булып хәтердә кала.

...Заманча стильдә салынган кафеның (художнигы М. Сутюшев) киң тәрәзәләре аша шәһәрнең күп катлы йортлары күренеп тора. Кафеда буфетчы хатын Сәлимә (М. Миңнебаева) бар да, тагын тимер аяклы биек өстәл янында өстенә керләнеп беткән иске свитер, башына ямьшәйгән берет кигән, таушалган кыяфәтле бер кеше аракы эчеп тора. Шул чак кафега илле яшьләр тирәсендәге, тулы гәүдәле, мөлаем йөзле ир кеше килеп керә. Бер стакан минераль су сорап ала, буш өстәлләрнең берсе янына килеп эчә башлый. Нәрсә хакындадыр уйлана, күрәсең, кафедагы кешеләрне бөтенләй күрми. Шунда аңа нәрсәдер сорап свитерлы кеше мөрәҗәгать итә. Бу карап тормый гына җавап бирә. Җавап бирә һәм кинәт эчтән ничектер сискәнеп китә. Каршындагы кешегә күзе төшә, җентекләп карый башлый. Танып ала. Кулларын җәеп, иске свитерлыга ташлана, кочаклап ала. Егерме биш елдан соң ике фронтовик дус, ике кыю разведчик әнә шулай очрашалар. Берсе, соры костюм кигәне, Мәрвән, икенчесе Әхтәм исемле (аны РСФСРның халык артисты Ф. Халитов уйный.)

Тормышчан, кискен конфликтка корылган спектакль шулай башлана. Бу ике рольне академия театрының иң оста артистлары уйный, шуңа күрә спектакль дә кайнар, темпераментлы яңгырый, каршылыклар принципиаль югарылыктан торып хәл ителә. (Бу артистларның уенына сокланып утырганда, ирексездән башка шундый фикер килә: кайбер театр белгечләре әле һаман безнең артистларны сәхнәдә сабыр, тыйнак булырга чакыралар. Бу бәхәсле нәрсә, күрәсең. Кешенең чын хисләрен һәм эмоцияләрен сәхнәдән кысрыклый башласак, ул сабырлыкның нинди мәгънәсе калыр икән!)

Заманында Әхтәм талантлы архитектор була. Тормышның кайсыдыр моментында начар бәндәләр белән бәрелешә. Йомшак табигатьле Әхтәм җиңелеп кала. Шуннан ул үзен тормыш тарафыннан кыерсытылган кешегә санап йөри башлый, өметсезлеккә бирелә. Дөньядан, кешеләрдән зарланып йөрүче пессимистка әйләнә, эчүгә салыша. Янәсе, җир йөзендә гаделлек юк, янәсе, юньле кешегә тормышта рәт юк. Дөньяны, кешеләрне каргап йөри. Дусты Мәрвән белән очрашканнан соң да ул үзен һаман хаксызга рәнҗетелгән кеше төсле тота, елмаймый-көлми, күзләрендә битараф гамьсезлек. Кыяфәте җәзага хөкем ителгән кешенеке сыман. Ул әйтерсең лә юри шундый битлек кигән. Шулай да, күпме генә гамьсез булып кыланырга тырышмасын, күңеле яралы булуы, яраларыннан кан саркуы әллә каян сизелеп тора. Ләкин яраларын дәвалыйсы, төзәтәсе урында, Әхтәм аларны өзлексез борчып, җәфалап тора. Спектакльнең буеннан-буена Мәрвән Әхтәм өчен, аны аякка бастыру өчен көрәшә.

Мәрвән эшсез йөргән иптәшен үз янына, авылга алып кайта. Әхтәм монда да үзен рәнҗетелгән кеше кебек тота. Баштарак нечкә күңелле, артык мәрхәмәтле Мәрвән Әхтәмне аякка бастыра алырмы икән, дип шикләнеп утырасың. Бигрәк әдәпле кеше инде.

Шунда чираттагы бер күренеш башлана. Мәрвәннең өенә күрше колхоз председателе Зәйнуллин (артист И. Вәлиев) килә. Сөйләшә, бәхәсләшә башлыйлар. Йомшак күңелле, бик нәзакәтле Мәрвәнебез кинәт үз эше өчен яна, тартыша-сугыша белүче көрәшчегә әйләнә. Ул ялкынланып, темперамент белән кешеләрнең табигатьне харап итүләре турында сөйли. Ул күршесе белән шундый пафос, дәрт белән тартыша ки, тамашачыда аңа карата симпатия уяна, тыштан бер ягы белән дә аерылып тормаган бу кешедә чиксез көч, бетмәс-төкәнмәс энергия барлыгына ышана башлыйсың. Ул кычкырмый, йодрыкларын селкеми, нык тавыш, кире каккысыз дәлилләр белән үзенең хаклы булуын исбат итә.

Шушы күренешне дәшми генә Әхтәм күзәтеп тора. Зәйнуллин китә. Ул китүгә Әхтәм үзенең чираттагы скептик репликасын әйтеп ташлый. Мәрвән шартлар дәрәҗәгә җитә. Әхтәм белән очрашканнан бирле дәшми генә эчендә җыеп барган ачуы кинәт тышка бәреп чыга. Ул быелыр халгә

килә. Менә ул җентекләп, котырып бүлмә буйлап йөренә, атылып килер дә Әхтәмнең өстенә ташланыр төсле. Ул ачулы тавыш белән Әхтәмнең маска киеп йөрүе, тормыштан, андагы кыенлыклардан качуы турында сөйли, ниһаять, аны куркаклыкта гаепли.

Хәзергә бу кискен бәрелештә берәү дә җиңми җиңүен. Әмма без коммунист Мәрвәннең нык кеше булуына тәмам ышанабыз. Әхтәм, минем киләчәк буыннарда эшем юк, дип сөйләнә башлагач, Шамуков-Мәрвән зур горурлык белән үзенең коммунист булуын, шулай булгач, барлык кешеләр, җирдәге һәрнәрсә өчен җаваплы икәнен әйтә. Менә шул җаваплылык хисе аңа башлаган эшен ахырга кадәр илтеп җиткерергә көч бирә.

Кеше бәхете, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен үзен җаваплы итеп сизү хисе А. Гыйләҗевнең «Эңгер-меңгер» пьесасындагы Алим өчен дә хас. Бәлки, хәзергә ул анда интуитив төстә генәдер. Әмма әлеге хис аңарда бар. Бу кадәресенә шикләнмәскә мөмкин.

Алимны театрның яшь артисты И. Хәйруллин башкара, аларның икесенә дә 18 әр яшь. Зифа буйлы, төз гәүдәле, чибәр, нәфис йөзле, әле уйчан, әле шук карашлы бу егет үзенең замандашына бик тә якын булып чыккан. Дөрес, әлегә артист сәнгатьчә озталык мәсьәләсендә әллә ни ачышлар ясамый. Ул бары үзен, үзенең дөньяга карашын һәм дөньяны аңлавын уйный. Актер индивидуальлеге образның үзенчәлеге белән ифрат тәңгәл килгән.

Алим яшәүнең мәгънәсен эзли, кешенең кешелеге нәрсәдә, кеше нинди булырга тиеш — шуларны ачыкларга тели. Шул тынгысызлыгы, барын да аңларга тырышу хисе аны башкаладан ерактагы төбәкләрнең берсенә алып килә. Чулманда яшәүчеләрнең бертөсле тын тормышына ул саф җил кебек килеп керә.

Режиссер Алимны һәм аның провинциядә яшәүче туганнарын контраст буяулар аша күрсәтә. Бер якта тынгысыз күңелле, хәрәкәтчән Алим, икенче якта бөтенләй йомылып яшәүче провинция кешеләре. Аларның һәммәсе: Зөһрә дә (Р. Җиһаншина һәм В. Минкина), Нәби дә (Г. Надрюков һәм Ә. Гобәйдуллин), Марат та (И. Баһманов), Таштимер дә (Ш. Биктимеров) болай әйбәт кешеләр. Һәркайсы үз эшен намус белән башкара. Тамаклары тук, өсләре бөтен. Үз бакчалары, үз йортлары. Хәтта Иделдә «үз утраулары» дә бар, ял итәргә шунда гына чыгалар. Аларга тормыштан башка берни дә кирәкми. Ничектер башкачарак яшәү, нәрсәне дә булса үзгәртү турында уйламыйлар да. Шуңа да алар вәкарь белән генә сөйләшәләр, ашыкмый-кабаланмый гына йөриләр. Һәр җирдә тынлык, иминлек атмосферасы. Тик Зөһрә генә вакыт-вакыт уянып киткәндәй була, күзләрендә очкыннар кабынып ала, ләкин күп тә тормый, тагын сүнә. Читтән карыйсың, ниндидер тынлык, караңгылык. Үзеңне җәйнең иң эссе, иң көяшлы көннәрендә дә салкын, караңгы килеш кала торган тирән чокырга эләккән кеше кебек сизәсең.

Менә шушы тын даирәгә тынгысыз җанлы Алим килеп керә. Килеп керүе була, һәммәсе дә йокыларыннан уянып, сискәнеп китәләр. Берәүләр, Зөһрә кебек, аны аңлыйлар, икенчеләре, Нәби кебек, аны каргыйлар, өченчеләре, мәсәлән, Роза (Г. Исәнгулова), аңа гашыйк булалар.

Табигый, Алим мондый тын тормыш, зур эшләргә сәләтсез кешеләр белән килешә алмый. Шуңа ул Розаны алар кулыннан тартып ала, кыз Алим белән чын, зур тормышка кача. Аңа егетнең тынгысыз булуы, тормышны яратуы, яшәүнең мәгънәсен эзләве ошый.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, капма-каршы фикерләрне күбрәк «Әни килде» белән «Намус хөкеме» спектакльләре уяттым. Беренчесе бигрәк тә.

«Әсәрдәге вакыйгалар зур яңгыраш ала; спектакльдә күтәрелгән мораль проблемалар гаилә рамкалары белән генә чикләнеп калмый. Спектакль тамашачыларны күп нәрсәләр турында уйларга этәрә» [1].

Һәм күңелдә ихтыярсыздан ачулы сорау туа: шундый анага мондый балалар каян килгән? Җавапны пьесадан да, спектакльдән дә табып булмый» [2].

«Әсәрнең фәлсәфи фикере — кешенең иҗтимагый роле, аның гражданлык хисләре турында. Кеше нигә яши? Аның иҗтимагый тормышка керткән өлеше күпме?.. Тормышның ваклыклары, көндәлек мәшәкатьләре аша гражданлык мәсьәләсе күтәрелә» [3].

[1] «Московская правда» газетасы, 1970 ел, 14 июль саны.

[2] И. Якименко. Экзамен на зрелость. («Советская Татария» газетасы, 1970 ел, 29 июль саны.)

[3] Г. Кашшаф. Ни өчен яшисең? («Социалистик Татарстан» газетасы, 1970 ел, 9 июль.)

«Ш. Хәсәеновның мораль-этик мәсьәләләрне кузгаткан «Әни килде»се тормышны күзәтүдәге төгәллеге, характерларының күп сыйдырышлы булуы белән аерылып тора. Анда сатирик мотивлар әхлакый идеалны раслау белән бергә үрелә»[1].

Һәм, ниһаять, бер тәнкыйтьче пьесада һәм спектакльдә үз әниләренә урын таба алмаган балаларның бәхәсләреннән башка нәрсә күрми[2].

Шул рәвешчә, берәүләр спектакльне яхшы дип бәяли, анда тормыш тирәнлеге бар, совет кешесенең әхлакый идеалы чагыла ди, икенче кешеләр, «мондый балалар каян килгән» дип, пьесаны да, спектакльне дә юкка чыгаралар.

Баштан ук әйтеп куйыйк: кайберәүләр Ш. Хәсәенов әсәренең проблемасын начар балалар мәсьәләсенә генә кайтарып калдыралар икән, бу әлеге иптәшләрнең пьесаны аңламаулары турында сөйли. Алар иң өстә ятканны гына эләктереп алганнар. Әсәрнең икенче планы күп тапкыр тирәнрәк.

Аннан соң, «шундый яхшы ананың балалары нигә начар?» дип гаҗәпләнү дә урынсыз. Дөньяда мондый хәлләр тулып ята. Нигә Моцарт гениаль композитор булган да, сеңелесе алай була алмаган? Нигә В. И. Немирович-Данченко революцияне кабул итә, бөтен гомерен совет сәнгатен үстерүгә багышлап, СССРның халык артисты дигән мактаулы исем алуга ирешә, ә абыйсы эмиграциягә китә. Алар бер үк тәрбия алган кешеләр бит. Ни өчен гражданнар сугышы елларында бер үк ана балаларының берсе кызыллар, икенчесе аклар янында торып сугышкан? Саный китсәң, андый «ни өчен»нәр бик күп булачак.

Алай гына да түгел, «ни өчен ананың балалары начар» дип гаҗәпләнү үзе үк урынсыз. Әйдәгез, тикшереп карыйк әле, ананың балалары асылда нинди кешеләр һәм ни өчен алар әниләрен үз яннарына сыйдыра алмыйлар?

Вакыйга шулай башлана. Үлем хәлендәге ананы Казанга алып киләләр. Аны ерак юлга алып чыгып булмый. Димәк, Ташкентта яшәүче кызы һәм Ерак Көнчыгышта хезмәт итүче улы (Озакламый, ул Ватан иминлеген саклаганда һәлак була. Бу үзе үк ананың балаларына дөрес тәрбия бирүе турында сөйли) әниләрен үз яннарына ала алмыйлар.

Ватан сугышыннан гарипләнеп кайткан Инсаф үзе көч-хәл белән йөри, башы больницадан чыкмый. Шулай итеп, Казанда яшәүче балалары: Максуд, Ислам, Сәйяр кала. Максуд гаиләсе белән начар шартларда, баракта яши. Бик теләсә дә, әнисен үз янына алмый. Ләкин алга таба (әсәрне тәнкыйть итүчеләр моны ничек күрми калганнардыр), яңа квартирага ордер алуга, ул хатыны белән әнисе янына йөгереп килә, аны шатландыру һәм үзләренә алып киту өчен килә.

Кече улы Сәйяр яңа гына институт тәмамлаган, әле генә өйләнгән, үзе кешә почмагында яши. Ана ул яши торган квартирада торып кала да. Мин аларны бөтенләй акларга җыенмыйм. Аларның һәркайсының уңай яклары һәм җитешсезлекләре бар. Шуңа күрә алар тере, җанлы образлар булып чыкканнар да. Димәк, «нигә балалары начар» дип гаҗәпләнергә урын калмый. Юк, аларның барысы да начар түгел.

Ниһаять, Ислам. Авторның, режиссерның, шулай ук артистларның бөтен ачуы шушы кешегә каршы юнәлдерелгән дә. Монда Исламның кайчандыр эшче сыйныфы вәкиле булуы (ул пенсиягә хәтле шахтада эшләп йөри) бернинди роль уйнамый. Чөнки мәсьәлә анда түгел. Т. Уильямсның «Теләк дигән трамвай» исемле пьесасындагы Стэнли Ковальский Америкадагы эшче сыйныфын гәүдәләндерә алмаган кебек, Исламны да бездәге эшчеләрнең вәкаләтле илчесе дип әйтеп булмый. Ул сәүдә эшчесе, колхозчы, кыскасы, теләсә кайсы һөнәр кешесе булырга мөмкин. Хикмәт аның хезмәт иясе халыкның теге яки бу категориясенә керүендә түгел. Хикмәт аның мораль йөзендә, авторның һәм театрның аңа мөнәсәбәтендә.

Спектакльдә режиссер төп игътибарны Исламның башкалар белән бәрелешенә юнәлтә. Спектакльнең көче һәм кыйммәте шунда, рольләрне башкаручы артистларның барысы да тиешле югарылыкта булып чыккан (Ана — Г. Ибраһимова, Ислам — Ш. Биктимеров, Инсаф — Р. Таҗетдинов, Максуд — Г. Шамуков, Саима — М. Миңнебаева, Сәйяр — Н. Дунаев, Зөләйха — Г. Камалова, А. Галиева, Әлмөхәммәт — Ә. Зарипов, Римма — Н. Гәрәева). Алар менә дигән ансамбль тудыра алганнар.

---

[1] О. Кайдалова. Опираясь на традиции. («Правда» газетасы. 1970 ел. 1 август.)

[2] Г. Минский. Ике спектакль карагач. («Социалистик Татарстан» газетасы. 1970 ел. 9 июль.)

Артистлар тудырган образларның тормышчанлык көче тирән һәм ышандырырлык.

Ш. Биктимеровның үз герoeн оста итеп уйнавы аның бу өшеке типны кискен фаш итүе, актерның гражданлык позициясе турында сөйли. Артистның үзе башкара торган образга мөнәсәбәте ачык монда. «...Талантлы артист Ш. Биктимеров үз героен тәгәл буяулар ярдәмендә иҗат итә, әлеге шкурникны һәм үз-үзеннән канәгать хамны фаш итү өчен күп төрле детальләр тапкан»,— дип язды «Московская правда» газетасы.

Менә тормышка капма-каршы карашлы кешеләрнең бәрелешен, «кемнең кем булуын» ачып бирә торган бер күренеш.

...Иске агач йортның кысан кухнясы. Бирегә ананың барлык балалары җыелган. Әниләрен кем үз янына сыйдырырга тиеш — шул турыда очсыз-кырыйсыз бәхәс бара. Акрынлап бәхәс Ислам белән Инсаф тирәсендә туплана. Башта Ислам гайрәт чәчә. Ул искиткеч оятсыз тон белән, тыңкышлана-тыңкышлана, Инсафның борынына квитанцияләр төртә. Әнисенә акча салып торуы турында. Җыеп барган икән. Башкалардан да шундый ук квитанцияләр таләп итә. Янәсе, карыйк, күрик: кем әниләрен күбрәк ярата икән. Аңа, син әйбәт яшисең, гаделлек күзлегеннән караганда, әнине син алырга тиеш, диләр. Ислам, бу сүзне ишетүгә, бөтенләй аптырап кала. Аннан лач иттереп идәнгә төкерә дә ямьсез тавыш белән акырып җибәрә: «Гаделлек дисезме?» Шуннан мыскыллы тон белән «гаделлек»нең нәрсә икәнен аңлата башлый. Ничек ул, мескенгә салышып, собеска барган, үзен Ватан сугышы инвалиды итеп күрсәткән һәм машиналы булган. Менә сезгә гаделлек! Җиңгән кыяфәт белән туганнарына күз ташлый. Сугыш инвалиды Инсаф бусына ук түзә алмый. Таягы белән Ислам өстенә ташлана: «Менә сиңа гаделлек!» Исламның моңарчы аркаланып килгән ялган документын ерткалап ташлый. Ерткыч җанвар төсенә кергән Ислам идәнгә ташлана, кәгазь кисәкләрен җыя башлый. Әле генә «җиңүче» булып кыланган Ислам бер минутта кызганыч бәндәгә әйләнә дә кала.

Шулай тормыш чынлыгы туа. Анда өзлексез көрәш бара. Бу — диалектика. Бу — капма-каршы көчләр көрәше. Һәркем үз карашын, үз мөнәсәбәтен расларга тели. Бу безнең чынбарлык, совет чынбарлыгы. Шуңа күрә түбән җаннарга, хаиннәргә урын юк та. Шуңа да театр Ислам кебекләрне нәфрәт белән фаш итә. Шуңа да Ислам, аның яшәү рәвеше тамашачыларда тирән ачу уята. Спектакльнең озын гомерле булуы да шуның белән аңлатыла. Менә шуңа күрә «Әни килде»не уңай яктан бәяләгән, аның әхлакый яңгырашын һәм фәлсәфи пафосын тәгәл аңлаган тәнкыйтьчеләр күбрәк хаклы кебек.

Исеменнән үк күренгәнчә, «Намус хөкеме»ндә сүз әхлак мәсьәләләре турында бара. Һәм тагын, инде ничәнче тапкыр, театр үз яраткан темага мөрәҗәгать итә: кешенең кыйммәте нәрсәдә, шәхес нинди булырга тиеш? Бу мәсьәлә үз эченә кешенең тормышка мөнәсәбәтен дә, намус һәм хаинлек кебек мәсьәләләрне дә сыйдыра.

Шулай да, спектакльне тикшергәндә, берәүләр анда намус хөкемен күрү белән чикләнәләр, икенчеләре тирәнрәк катламнарны да күрәләр.

«Спектакль намусны уята... Спектакльдә Мансур Арслановның намус хөкеме турында сүз бара»[1]. И. Саттаровның фикере шундый. Р. Копосов башка төрлерәк, хакыйкатькә якынрак фикер әйтә[2].

Әйе, пьесада намус хөкеме бар, ул юкка гына шулай аталмаган лабаса. Чыннан да, әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр арасында: «Арсланов хатынын үтергәнмеюкмы?» дигәне дә бар. Ләкин бары шушы теманы гына күрү әсәрдәге иң төп мәсьәләләрне күрми калу дигән сүз. Анда ике туганның — Гариф белән Равилнең тормышка капма-каршы карашы төп урынны алып тора. Гуманист, чын, принципиаль коммунист карашы һәм «эре балыклар вак балыкларны ашап туена» дигән принцип белән яшәүче оятсыз эшкуар карашы.

Пьесадагы икенче бик мөһим момент — хаинлек, үз идеяләренә хыянәт мәсьәләсе. Бусы Арсланов белән бәйле тема. Әнә шундый җитди мәсьәләләр күтәргән өчен дә яшь авторның әсәре академия театры сәхнәсенә күтәрелә алды. Инде кат-кат төзәтә, редакцияли торгач, пьеса бераз таркауланыбрак калган икән, бусы башка мәсьәлә.

Гариф белән Равил очрашкан күренештә алар арасындагы конфликт иң югары ноктага җитәргә тиеш иде. Әмма, никадәр генә гаҗәп тоелмасын, иң кирәк моментта Равил сүзсез кала. Ул дәшми

---

[1] «Татарстан яшьләре» газетасы. 1972 ел. 20 январь.

[2] «Комсомолец Татарии» газетасы. 1971 ел. 22 октябрь.

генә энесенең мактанганын тыңлап тора. Бу рольләрне уйнаучы актерларга (Гариф — Ә. Шакиров, Равил — И. Юмагулов һәм Н. Дунаев) әсәрдәге әлеге кимчелекне үз карамакларындагы чаралар ярдәмендә (эчке монолог, эчке фикерләү, күз карашлары һ. б.) тулыландырырга туры килә.

Ә. Шакиров үз героен ифрат тәгәл уйный. Менә ул бөтен буена диванга сузылып яткан да күпне белгән, күпне күргән кеше тоны белән акыл сата: яшь белергә өйрәтә. Ул да түгел, сикереп торып, сеңелесенең иңнәреннән каккалый. Аның һәр адымыннан, һәр кыланышыннан, «ничек яшәргә кирәклеген миннән өйрәнегез», дигән нәрсә сизелеп тора. Йөзендә һәрчак иренчәк елмаю. Ул үзенең хаклы булуына тәмам ышанган кеше. Үз-үзен батыр тотуы да шуннан килә. Әнә ул, һәрнәрсәне булдыра, теләсә нәрсә эшләргә кулыннан килә торган кеше тоны белән, вертолет ярдәмендә футбол кырын киптерүе турында сөйли, башка «һөнәрләре» белән мактана...

Равилнең, кеше буларак, кыйммәтле ягы шунда, ул әрмый-талмый хакыйкать, гаделлек өчен көрәшүче. Аның суд тикшерүчесе булуы символик мәгънәгә ия. Ул хезмәтендә дә, тормышта да хакыйкать тарафдары. Ике артист та Равилнең төп сыйфатын дөрес чагылдыралар. Шул ук вакытта аларның рольләре бер-берсеннән шактый аерыла да. И. Юмагуловның Равиле акыллы һәм йомшак характерлы булса, Н. Дунаевныкы гасабирак, кискенрәк. Равил образының авырлыгы шунда, Гариф белән очрашканда аның каршы әйтер сүзе юк. Бары соңгы күренештә генә ул Гарифның әшәке фәлсәфәсенә тиешле отпор бирә. Бу — бөтен спектакльнең дә иң уңышлы күренеше. Нәкъ шул күренештә ул әтисен мораль хаинлектә гаепли.

Моннан 23 ел элек Арслановның хатыны үзен-үзе үтергән. Хәзер моның өчен берәүне дә гаепләп булмый, билгеле. Әмма намус хөкеме кала. Кызганычка каршы, пьесада да, спектакльдә дә мораль хаинлек, үз идеяләренә хыянәт итү темасы игътибардан читтәрәк калган. Шушы уңай белән, әсәрдә үткән мәсьәләләр күтәрергә, тамашачыларны галимнең бурычы һәм җаваплылыгы, саф акыл җимеше булган фәнни казанышларны ничек файдалану, фәндә интеллектуаль һәм мораль башлангычларның үзара бәйләнеше, галимнең иҗтимагый һәм гражданлык йөзе турында уйланырга мәҗбүр итәргә мөмкин иде.

23 ел элек Арсланов укытучысын һәм үзенең фәндәге алдынгы карашларын сата, элекке дошманнары, иске карашлы кешеләр лагерена күчә. Хаинлек темасы, аның зарары Гайсин катнашкан (Ш. Биктимеров) бер кечкенә күренештә генә чагылып кала. Шунда бу тема әзелә, алга таба дәвам иттерелми. Шуның нәтиҗәсендә Гариф белән Равил бәрелеше дә йомшартыла, хаинлек темасы, аны хөкем итү кайдадыр читтә кала, шуннан алгы планга юридик тема, җинаять тикшерү мәсьәләсе килеп чыга.

Әмма ни генә булмасын, И. Саттаровның «Үтергәнме-юкмы дигән сорау мораль мәсьәләне күмеп китә» дигән фикере артык берьяклы. Монда проблемалар юк дип зарланудан бигрәк, аларның тиешенчә хәл ителмәве турында сүз алып бару урынлырак булыр иде.

Нигездә нык кул белән эшләнгән бу спектакльләрдә аерым кимчелекләр бар. «Әни килде» бераз сузылган, озынгарак киткән. «Ир-егетләр» дә эпизодик рольләрне тасвирлаганда кара буяулар куерыбрак киткәли, «Эңгер-меңгер» таркаурак чыккан. Моннан тыш, яшь кыз Роза ролен бөтенләй башка пландагы актрисага тапшырып, режиссер да авторга аю ярдәме күрсәткән.

Академия театрының соңгы еллардагы спектакльләрен караганда башка шундый уйлар килә. Ул әсәрләрдә театр зур игътибар белән бүгенге кешеләрне өйрәнә, төрле ситуацияләр, кискен бәрелешләрдә аның чын йөзе ачыла. Аның юлына чәчәкләр җәелмәгән. Ләкин алар бирешми, кем тормышны битарафлык белән көрәш, прогресс, чын гуманизм, кеше дигән бөек исем өчен әзлексез көрәш дип аңлый, монда шулар җиңеп чыга. К. Симоновның әле сугыш елларында ук язылган «Шулай булыр да» дигән пьесасындагы майор Греч болай ди: «Ул талантлы түгел, ләкин ул кеше, ә кеше була белү — шулай ук талант, күп кешегә бирелми торган талант».

Шулай итеп, «кеше була белү» Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә заман темасына багышлап куелган спектакльләрнең төп темасы. Шуңа күрә тамашачы бу спектакльләрне яратып каршы ала. Шуңа күрә касса өстендә һәр көн: «Бүгенге спектакльгә билетлар сатылып бетте» дигән белдерү эленеп тора.

## Флүн Мусин

# ДОКУМЕНТАЛЬ МАТЕРИАЛ ҺӘМ АВТОР ФАНТАЗИЯСЕ

*(Бүгенге проза турында сөйләшәбез)*

Әгәр «Казан утлары» журналы башлап җибәргән бәхәс хакындагы фикерләремне сорасалар, мин иң элек аның бик вакытлы һәм ифрат кирәкле бер чара булуын әйтер идем. Чыннан да, хәзерге прозабызның гомуми хәле һәм үсеш юллары турында җитди төстә фикер алышу күптәннән сорала иде. Чөнки бу өлкәдә уртага салып сөйләшүне һәм бергәләп хәл итүне сорый торган мәсьәләләр күбәйде. Аларның кайберләрен үзенең әлеге сөйләшүне ачып җибәргән кереш мәкаләсендә Р. Мостафин шактый дөрес тотып алган.

Шул ук вакытта аның ул мәкаләсендә сүз башлыча 1971 елда чыккан әсәрләр турында бара. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, Р. Мостафин хәзерге прозага кагылышлы барлык мәсьәләләрне дә колачлый алмаган. Өстәвенә, тәнкыйтьче үзе билгеләп үткәнчә, 1971 ел проза әдәбияты өчен шактый төссез һәм уңышсыз елларның берсе булды. Һәм ул хәзерге прозаның торышы турында җитди сөйләшү алып бару өчен ныклы нигез бирә алмый. Кыскасы, кереш мәкалә башка чыгышларда киңәйтүне һәм шактый тулыландыруны сорый.

Мин үзем хәзерге прозаның тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтәрәк калып килә торган бер тармагына тукталырга уйлыйм. Сүз тарихи шәхесләрне гәүдәләндерүгә багышланган әсәрләр хакында бара.

«Үткәндәгеләргә илтифат — мәдәнилекне вәхшәттән аерып торучы бер сыйфат ул»,— дигән А. С. Пушкин. Искиткеч тирән мәгънәле сүзләр! Бу халыкның аң-белем һәм культура дәрәҗәсе никадәр югары булса, ул үзенең үткәне белән шул кадәр ныграк кызыксына дигән сүз. Һәм шулай да. Совет власте елларында илебездәге барлык милләтләрнең культуралары бик нык үсте, югары күтәрелде. Нәтиҗәдә һәр халыкның тарихи үткәненә игътибар да бермә-бер көчәйде, социалистик милләтләрнең үз тарихларын тирәнрәк һәм тулырак беләсе килү теләге нык үсте.

Үткәндәге тарихи шәхесләр белән кызыксынуның көчәюе шул хакта сөйли торган бер мисал була ала. Билгеле булганча, теге яки бу халыкның социаль-политик һәм рухи үсешендә зур роль уйнаган тарихи шәхесләрдә шул халыкның иң гүзәл сыйфатлары гәүдәләнә. Шуңа күрә мондый шәхесләр халык тарихының һәм халык рухының аеруча күркәм якларын ачарга мөмкинлек бирәләр. Бүгенге прозада тарихи шәхесләргә игътибар артуның төп сәбәпләреннән берсе шундадыр, күрәсең.

Матур әдәбиятта тарихи шәхесләрне ничек гәүдәләндерергә соң? Әйтергә кирәк, бу — тәнкыйтьчеләрне әледән-әле уйландырып-борчып торган төп мәсьәләләрнең берсе. Бу темага багышланган хезмәтләрдә еш кына тарихи шәхесне сурәтләгәндә документаль материал белән автор фантазиясен ничек бәйләү мәсьәләсе үзәккә куела. Чөнки мондый әсәрнең язмышы башлыча язучының әлеге мәсьәләне никадәр уңышлы хәл итә алуына бәйләнгән.

Үзебездәге тарихи романнарны бәяләүгә дә минем нәкъ менә шушы ноктадан карап якын киләсем килә. Иң элек А. Расихның «Ямашев» романына тукталыйк.

Башта ук шул кадәресен әйтергә кирәк, Ямашев образы татар әдипләренең игътибарын беренче мәртәбә генә җәлеп итми. Бу шәхескә беренче булып халык шагыйре Габдулла Тукай мөрәҗәгать иткән иде. Хөсәен Ямашев Тукайның дусты була. Әмма шагыйрьнең аңа багышлап шигырьләр язуы һич тә шәхси сәбәпләр, дуслык хисләре белән генә бәйләнмәгән. Моның җитдирәк сәбәпләре бар, һәм алар бөек шагыйрьнең идея-эстетик эзләнүләренә барып тоташа. Эш шунда ки, Тукай гомер буе дөньяда гаделлек һәм тигезлек өчен, изелгән һәм кимсетелгәннәрнең бәхете өчен көрәшүче актив геройлар турында хыялланып яши. Үзенең шушы хыялын да чагылдырып, 1906 елда ул «Хиссияте милләния» исемле мәкалә яза. Анда шундый юллар бар: «Милләт... халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби... фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ»[1]. Баштарак Тукай бу хыялын алдынгы шәкертләр белән бәйли, аларга зур өметләр баглый. Әмма торабара ул бу уеннан кайта һәм чын каһарманнарны патша самодержавиесенә каршы көрәшкә күтәрелгән кешеләр арасыннан эзли башлый. Һәм ялкынлы революционер Хөсәен Ямашев йөзендә шагыйрь үзе күрергә хыялланган геройны таба.

Ямашевның халык бәхете өчен куркусыз көрәшче булу сыйфатлары Тукайга беренче рус революциясеннән соңгы елларда тагын да ачыграк күренә. Күпләр, элекке идеалларыннан ваз кичеп, өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелгән бер чорда Хөсәен Ямашев элекке кебек үк энергия һәм тырышлык белән үзенең революцион эшен дәвам иттерә. Моның белән ул Тукайның тирән ихтирамын һәм мәхәббәтен казана, шагыйрь алдында халыкка турылыклы хезмәт итүче гражданин һәм көрәшче булып кала. Нәтиҗәдә «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» исемле мәгълүм шигырь языла. Тукай Ямашевны әле «көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез» белән, әле «язда елмайган кояш» белән чагыштыра. Шагыйрьгә бу революционер барлык кешеләрне тигез күрүе, тормыш пычрагын «гәүһәр кеби вөҗдан белән» үтүе, явызлыкка каршы аяусыз көрәшә белүе белән кадерле. Менә шундый сыйфатлары аны башкалардан күп өстен итә, күктәге якты йолдыз белән тиңләргә мөмкинлек бирә.

«Янә бер хатирам» исемле шигырендә исә Тукай Ямашевны «күктән иңгән тулган ай» белән чагыштыра. Кыскасы, әлеге шигырьләрдә герой-көрәшченең гомумиләштерелгән поэтик образы тудырыла. Шигырьләрдә Тукай иҗат иткән образның халык хыялында гасырлар дәвамында яшәп килгән традицион герой идеалына якын торуы шактый сизелә. Шагыйрь үз героен традицион шигъри образлар һәм чагыштырулар ярдәмендә күз алдына бастыра. Нәтиҗәдә шигырьләрдәге герой үзенең реаль прототибыннан шактый аерыла.

Ямашев шәхсенә алга таба «Безнең көннәр» романында Г. Ибраһимов мөрәҗәгать итә. Монда да әдәби герой белән прототип арасында тулы тәңгәллек эзләү дөрес булмас иде. Билгеле булганча, «Безнең көннәр» — татар халкының беренче рус революциясе чорындагы тормышын сурәтләүгә багышланган роман. Күп санлы образлар аша автор революция һәм реакция көннәрендә татар җәмгыятендәге төрле сыйныфларның һәм катлауларның үзүзләрен тотышын һәм рухи эволюциясен гәүдәләндерә. Романның нигезенә: «революциянең алдынгы төп... җитәкче көче— тик эшче сыйныф кына һәм аның партиясе большевиклар гына дигән»[1] фикер салынган. Менә ни өчен әсәрнең үзәк геройларыннан берсе итеп большевик Зариф Булатов образы, ә аның прототибы итеп Хөсәен Ямашев алынган. Г. Ибраһимов үз алдына профессиональ революционерның гомумиләштерелгән әдәби образын тудыруны максат итеп куйган. Шуңа күрә язучы Ямашевның тормышына һәм революцион эшчәнлегенә караган фактлар белән генә чикләнми. Ул үзенең иҗади фантазиясен дә ныклап эшкә җигә. Игътибар белән тикшергәндә, Булатов образында Ямашев өчен бик үк хас булмаган аерым детальләр һәм сыйфатлар да табарга мөмкин. Әмма иң төп мәсьәләдә роман герое белән аның прототибы бер-берсенә бик тә якыннар. Сүз революциянең җиңәчәгенә тирәнтен ышану, Ленин идеяларына ахыргача турылыклы булу, халык бәхете өчен

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 том. Казан. 1956 ел. 90 бит.

[1] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. III том. Казан. 1956 ел. 433 бит.

көрәштә батыр һәм кыю булу турында бара...

Алда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов әсәрләрендә без Хөсәен Ямашевның тарихи дөрес, реаль образын күрмибез әле. Әдипләр андый максатны алга куймаганнар да. Аларның нияте башкарак. Ямашев образы Тукай һәм Ибраһимовлар өчен нигездә үзләренең иҗади максатларын тормышка ашыру өчен җирлек, материал булып кына хезмәт иткән. Инде әйтелгәнчә, Тукай халык каһарманының поэтик образын гәүдәләндерүне максат итеп куйган. Ибраһимов исә профессиональ революционер образын тудырырга теләгән. Нәкъ менә шуның өчен дә алар конкрет документаль материал белән генә чикләнеп калмыйлар, бәлки үзләренең иҗат фантазияләрен дә ныклап эшкә җигәләр.

Хәзер А. Расих романын тикшереп карыйк. Бу әсәрдә Хөсәен Ямашев тормышын һәм эшчәнлеген гәүдәләндерүгә башкарак принциплардан чыгып якын киленгән. Ямашев образын тудырганда, язучы документаль материал белән иҗади фантазияне рациональ тәстә бергә бәйләргә омтыла.

Романда Хөсәен Ямашевның 1903—1905 еллардагы тормышы һәм революцион эшчәнлеге яктыртыла. Ямашевның тарихи дөрес образын тудыру максатыннан чыгып, язучы күбрәк реаль фактларга нигезләнеп эш итә. Әсәрдә тасвирланган вакыйгаларның күбесен (татарча беренче прокламация чыгару, татар эшчеләре өчен оештырылган социал-демократик түгәрәк, аның Кәрван-Сарайда уздырылган беренче утырышы, 1905 елның беренче маенда оештырылган массовка һ. б.) автор реаль тормыштан алган.

Билгеле, болар тарихта сакланып калган аерым фактлар гына. Бары шуларга гына нигезләнеп тулы канлы образ тудырып булмый. Ул фактларга җан өрергә, аларны тулыландырырга, баетырга кирәк. М. Әуэзов тарихи әсәр иҗат итүче авторның эшен соңга калган юлчы хезмәте белән чагыштыра. Юлчы «байтактан китеп барган кәрван тукталыш ясаган урынга килеп җиткәндә, учак инде бөтенләй диярлек сүрелгән була һәм ул анда бары сүнеп барган соңгы күмер кисәген генә таба. Шул күмер кисәген ул, өреп, дөрләтеп җибәрергә тиеш»[1].

А. Расихка да «сүнеп барган» тарихи фактларга шулай җан өрергә, аларны тормышның тулы канлы һәм җанлы күренешләренә әйләндерергә кирәк була. Мондый эшне иҗади хыял ярдәмендә генә башкарырга мөмкин. Язучы шулай эшли дә. Бу, барыннан да бигрәк, үзәк геройның рухи дөньясын, уй-кичерешләрен ачканда сизелә. Романның баштагы өлешендә яшь Хөсәеннең үлем түшәгендә яткан әтисе белән сөйләшүе, мәсәлән, тулысы белән автор фантазиясе ярдәмендә иҗат ителгән күренеш. Язучы бу күренешне яңарак кына революцион көрәш юлына баскан геройның дөньяга карашларын, яшәү максатларын ачыклау өчен кертә.

Иске тормыш шартларында дин-шәригать кануннарына буйсынып гомер кичергән Минһаҗ абзый үлем түшәгендә ята. Үләр алдыннан ул бердәнбер улына, «варис булып» каласы кешегә, үз тормыш тәҗрибәсенең «иң файдалы җимешләрен» тапшыра. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: беренчедән, ата кеше улына мәчетне онытмаска, муллаларга «һәр даим тиешле сәдакасын биреп» торырга куша. Чөнки, аныңча, «мулла — мәчет хуҗасы, ә мәчет — дин терәге, ә дин — халык терәге». Икенчедән, карт улына «фегнәче студиннәр, яһүдиләр белән» аралашмаска куша. Чөнки алар динне, шәригатьне «аяк астына салып таптыйлар». Өченчедән, Минһаҗ абзый улын киләчәктә үзен алыштырырдай сәүдәгәр итеп күрергә тели. Ата кешенең Хөсәенгә әйтәсе килгән сүзләре, бердәнбер «улына яхшылык теләп, үзе бик күп тапкырлар һәр ягын үлчәгән, бизмәнгә салган, яшәү өчен көрәш нәтиҗәсендә туган кагыйдәләр»е менә шулар. Үзе өчен иң якын һәм иң кадерле кеше тарафыннан әйтелгән бу сүзләр яшь Хөсәенне бер мәлгә аптыраштa да калдыра. «Ә, бәлки, ул хаклыдыр? Бәлки, школадагы алдынгы яшьләрнең янып, дәртләнеп йөрүләре узгынчы гына нәрсәдер? Бәлки, теге укучылар янына килеп йөрүче революционерлар кирәкмәс һәм гомердә дә тормышка ашуы мөмкин булмаган әйберләр турында сөйлиләрдер?..»

Шул рәвешчә, яшь егет алдында ике юл ачыклана. Аларның беренчесе — «тыныч, хәвефсез юл. Моның өчен Хөсәенгә бары тик әтисенең хәер-фатихасын алып, ул киңәш иткәнчә генә гамәл кылырга кала.

Ә икенчесе — куркынычлы, авыр юл. Монда сине мең төрле газаплар көтә.

---

[1] М. Ауэзов. Абай Кунанбаев. Статьи и исследования. Рус телендә. 1967 ел. 360 бит.

Син монда бернинди дә дөньяви рәхәтләр күрмәячәксең... Синең артыңнан өзлексез шымчылар сагалап йөриячәк. Тотылсаң, сине һич аямастан караңгы зинданга ташлаячаклар».

Заманның алдынгы революцион идеяләре, илдә күтәрелеп килгән революция дулкыннары тәэсирендә Хөсәеннең күзе ачыла, ул җиңел юлдан баш тартып, икенчесен — авырын, куркынычын сайлый. Алга таба язучы геройның үзе сайлаган юлдан тайпылышсыз атлавын шактый әзлекле сурәтли. Үзәк геройның тормыш, көрәш юлы һәм әсәрдәге башка вакыйгалар аерым-аерым новеллаларда яктыртыла.

Хөсәен Ямашевның революцион эшчәнлеге татар телендә беренче прокламация чыгарудан башлана. Аның бу эшен котлап, вакытында «Искра» газетасы, мәсәлән, болай яза: «Татарларның үз ана телендә чыккан прокламацияне кайнар рәвештә кабул итүләре комитетка шундый ышаныч бирә ки, ул листовкаларны бер үк вакытта ике телдә басып чыгару татар эшчеләрә массасына яктылык кертеп кенә калмаячак, бәлки моңарчы тик Казан капиталистларына гына файдалы булып, эшчеләр хәрәкәтенә һичшиксез зарар китергән милли дошманлыкны да тамырыннан җимерәчәк» [1].

Ямашев зур кыенлыклар белән башкарылган бу эшнең язмышы өчен баштарак бик нык борчыла. Борчылмаслык та түгел шул. Беренчедән, прокламацияләрнең жандармнар кулына эләгү куркынычы бар. Инде ул эшчеләргә исән-сау барып җиткән очракта, татар эшчеләренең прокламациядә язылганнарны аңламаулары мөмкин. Шунда ул гомерендә беренче мәртәбә туган тел турында уйлана. «Үз телеңне белми торып, халкыңа нинди дә булса ярдәм итү, аңа хезмәт итү һич мөмкин түгел» икән диган фикергә килә. Иртән уянса, күрше бүлмәдә әнисе Бибифатыйма белән бутышник Гайнулла чәй эчеп утыралар. Гайнулла, коты очып, бүген иртән аның будкасына кемнәрнеңдер «мөселманча язылган прукламация» ябыштырып киткәнлекләре һәм аны бик күп халык җыелып укуы турында сөйли. Шунда гына Ямашевның «күңелен куаныч рәхәте җылыта» башлый. Димәк, прокламация үз эшен эшләгән!

Язучы үз героен бер дә ялгышмый торган, барысын да белә, барысын да аңлый торган идеаль кеше итеп сурәтләми. Ул аны үсештә бирергә, авырлыкларны, тормышта очраган киртәләрне җиңә-җиңә чыныккан революционер итеп күрсәтергә омтыла. Бу яктан Алафузов заводы эшчеләреннән оештырылган яшерен түгәрәкнең бер утырышын тасвирлаган эпизод кызыклы. Анда большевиклар белән меньшевикләр арасындагы фикер каршылыклары тиксерелә. Ямашев эшчеләргә бу каршылыкның асылын, килеп чыгу сәбәпләрен аңлата. Сөйләшү дәвамында утырыштагыларның берсе большевикларның һәм меньшевикларның милли мәсьәләгә ничек караулары белән кызыксына. Ямашев бу сорауга ачык кына җавап бирә алмый. Чөнки үзе дә рәтләп белми икән. Икенче көнне үк ул үзенең остазы, танылган революционер А. С. Кулеша янына бара. Анда икенче күренекле революционер В. В. Адоратский белән очраша. Әлеге кыен һәм четерекле мәсьәләгә бергәләп ачыклык кертәләр.

Ямашевның рус революционерлары белән бәйләнеше турында сөйләгәндә, Я. М. Свердловның татар большевигына ясаган йогынтысына тукталып үтәсе килә. Мәгълүм булганча, социал-демократлар оешмасын ныгыту өчен, 1905 елның февралендә Свердлов Казанга җибәрелә. һәм ул Х. Ямашевның идея-политик үсешенә зур йогынты ясый. Бу хакта Х. Ямашевның тормыш һәм көрәш юлын җентекләп өйрәнгән тарих галиме Х. Хәсәнов болай яза: «Ул (ягъни Я. М. Свердлов — Ф. М.) аңа большевиклар белән меньшевиклар арасындагы идея каршылыкларының төп социаль сәбәпләрен, көннән-көн киңрәк җәелеп бара торган буржуаз-демократик революция шартларында ул каршылыкларның тагын да кискенрәк характер алуын дөрес һәм тирәнрәк аңларга булышты... Я. М. Свердлов Казанга килгәннән соң Х. Ямашев большевистик комитет составына кертелде һәм бик тиз аның күренекле членнарыннан берсенә әверелде» [2].

Романда исә бу мәсьәлә бик аз яктыртыла. Казанга килеп төшкәч, Свердлов:

— Сез менә шул иптәш белән очраштырыгыз әле, зинһар,— ди. Бу хакта сүз шуның белән бетә. Дөрес, әсәр ахырындарак полициядән яшеренеп йөргән Сверд-

[1] Цитата Х. Хәсәновның «Революционер-большевик Хөсәен Ямашев» исемле хезмәте буенча китерелә. Казан. 1959 ел. 40—41 битләр.

[2] Х. Хәсәнов. Революционер-большевик Хөсәен Ямашев. Казан, 1959 ел. 56—57 битләр.

ловның бер төнне Ямашевларда үткәрүе әйтелә. Ләкин әлеге очрашуның Хөсәенгә нинди дә булса йогынты ясавы күрсәтелми.

А. Расих Ямашевны төрле өлкәләрдә эш алып барган киң колачлы революционер итеп күрсәтергә тырыша. Татар эшче түгәрәкләре белән җитәкчелек итү һәм прокламацияләр бастырып таратудан тыш, ул крестьяннар һәм шәкертләр арасында революцион пропаганда эше белән дә шөгыльләнә. Бу яктан Ямашевның Чистай һәм Әлмәт якларында булуын, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре алдында чыгыш ясавын тасвирлаган новеллалар игътибарга лаеклы. Гәрчә автор фантазиясендә генә туган булсалар да, алар геройны күпкырлы революция көрәшчесе итеп күрсәтергә булышалар.

Мәгълүм булганча, Х. Ямашевның революцион эшчәнлеге аеруча активлашкан чор 1905 елгы октябрь вакыйгаларына һәм Октябрь стачкасы бастырылганнан соң киң колач белән кораллы восстаниегә хәзерлек барган көннәргә туры килә. Нәкъ шушы чорда Ямашев үзен «милләтчелекнең әсәре дә булмаган «ортодоксаль» социал-демократ» һәм җитлеккән революционер итеп таныта. Октябрь һәм ноябрь айларында Ямашев туып килгән революциянең максатларын аңлаткан, патша самодержавиесенең реакцион асылын рәхимсез фаш иткән һәм массаларны көрәшкә чакырган күп санлы прокламацияләр яза, милләтчелеккә, контрреволюцион «Мөселман иттифакына» каршы киеренке көрәш алып бара, төрле-төрле митингларда ялкынлы речьләр белән чыга. Әмма Ямашев эшчәнлегенең шушы иң әһәмиятле вакыты романда бик өстән һәм үтеп барышлый гына тасвирлана. Шушы урынга җитү белән язучы, ничектер, ашыга башлый һәм хикәяләүгә тизрәк нокта кую ягын карый. Аңлашыла ки, мондый хәл тарихи шәхесне дөрес күз алдына бастырырга комачаулый, аның объектив ролен кечерәйтеп күрсәтүгә китерә. Икенче яктан, образлы һәм эзлекле тасвирны коры публицистика белән алыштыру аркасында әсәр ахырына таба үзәк герой образы беркадәр тоныкланып кала.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, Ямашев әсәрдә үз чорының төрле иҗтимагый катлаулары белән якыннан кызыксынып һәм алар белән тыгыз бәйләнештә яшәгән хәлдә күрсәтелә. Шунлыктан шул чор тормышы романда киң колач белән сурәтләнә. Алгы планда Ямашевның көрәштәшләре — революционерлар тора. Бу персонажларның күбесе — тарихи шәхесләр. Я. М. Свердловтан тыш, әсәрдә И. А. Саммер, Н. И. Дамперов, В. В. Адоратский, С. А. Дридзо (Лозовский), Н. Н. Накоряков, А. С. Кулеша, Е. П. Табейкин, татар революционерларыннан Садыйк Сәгиев, Гафур Коләхметов, Габдрахман Мостафин, Мулланур Вахитов, Галимҗан Сәйфетдинов һ. б. күрсәтелә. Дөрес, бу геройларга Ямашевка бирелгән кадәр игътибар бирелми. Аларның күпчелеген автор аерым штрихлар белән генә гәүдәләндерә. Шулай да «укымышлы кыяфәтле, эре сөякле» Саммер, «һәрвакыт тыныч, гадәтенчә һәрбер сүзен үлчәп сөйли» торган Лозовский, «мәһабәт буйлы, яшь булса да чәче коелган, киң маңгайлы, ачык йөзле» Кулеша, «төптән юан, киң җилкәле» Табейкин һ. б. укучы күңелендә якты эз калдырып үтәләр. Тышкы кыяфәтләре буенча бер-берсеннән шактый аерылып торган бу кешеләрне революция эшенә бирелгәнлек, рухи оптимизм һәм зур ихтыяр көче үзара якынайта.

Татар революционерларыннан Садыйк Сәгиев образына чагыштырмача киңрәк урын бирелә. Бу образ мисалында язучы гади татар эшчесенең иҗтимагый-политик үсешен, революциянең аңлы солдаты булып җитлегүен күрсәтергә омтыла.

Романда Гафур Коләхметовны сурәтләү ягыннан кызыклы гына берничә эпизод бар. Герой Казанда революцион көрәш кызып киткән көннәрдә күрсәтелә. Бу көннәрне ул бик көтеп ала һәм, Октябрь стачкасы башлангач, авыруын онытып, урамга, көрәшкә күтәрелгән халык арасына ашыга. Гафур вакыйгаларның иң кызган урынына эләгә. Ул, башка революционерлар белән бергә, карагруһчылар һәм солдатлар тарафыннан камап алынган Дума бинасында кала. Шунда аңа Хөсәен бу куркыныч урыннан тизрәк китәргә тәкъдим итә. Аның бу вакыттагы уйларын автор болай тасвирлый: «Бәлки ул китә дә алган булыр иде, тик мондый хәлдә иптәшләренне ташлап китү коточкыч хыянәт булачак. Дөрес, ул рәсми рәвештә партиядә тормый. Ләкин эш андамыни? Гомере буена гаделлек өчен көрәшеп тә, эшчеләргә ирек яулау турында хыялланып та, шул эш хәвеф астында калганда качып китсә, кем булыр соң ул Гафур? Юк, андый нәрсә гомердә булмас. Үләр, бетәр Гафур, мәгәр андый хыянәт ясамас!»

Бу сүзләрдән Гафурның, гәрчә әле рәсми төстә большевиклар партиясендә тор-

маса да, инде революциянең турылыклы һәм җитлеккән көрәшчесе булуы ачыклана.

А. Расих романга татар интеллигенциясенең күп кенә күренекле вәкилләрен кертә. Аерым алганда, әсәр битләрендә без Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Шакир Мөхәммәдъяров, Солтан Рахманкулов, Әбүбәкер Терегулов һәм башкалар белән очрашабыз. Әмма аларның күпчелеге нигездә саналып кына үтелә.

«Ямашев» — әдәби әсәр. Шулай булгач, табигый, автор, тарихи шәхесләрне сурәтләү белән бергә, романга үз фантазиясендә туган геройларны да кертә. Әйтергә кирәк, бу очракта язучы үзен ничектер иркенрәк сизә, шуңа күрә образлары да җанлырак һәм кешечә табигыйрәк чыга. Андый образларның һәркайсы романда билгеле бер идея-фәлсәфи йөкләмә күтәрүе белән аерылып тора. Алар шул чорның кайбер әһәмиятле иҗтимагый-рухи тенденцияләрен чагылдыру максатына хезмәт итәләр. Ачыграк әйткәндә, язучы ул образларда беренче рус революциясенең төрле иҗтимагый катлауларга ничек тәэсир итүен гәүдәләндерә. Романда бигрәк тә эшче хатын Тәгъзимә, авыл ярлысы Фәрхетдин һәм интеллигент Җәгъфәр образлары, аларның гыйбрәтле рухи эволюциясе зур ышандыру көче белән тасвирлана. Икенчедән, бу персонажлар үзәк герой белән бәйләнештә күрсәтеләләр һәм аны ачу чарасы булып та хезмәт итәләр. Бу яктан Ямашевның Җәгъфәр белән булган мөнәсәбәтләре аерым игътибарга лаеклы. Башта үзен революционер дип атаган, халык бәхете өчен «бернинди чигенүләрсез көрәшергә, гомер буе көрәшергә ант иткән» Җәгъфәр, очраклы рәвештә генә төрмәгә эләгеп анда берничә ай ятып чыгу белән канатлары сынган мескен кош хәленә төшә. Шундый кызганыч хәлдә туган авылына кайтып барганда аны Ямашев очрата. Шунда алар арасында бик принципиаль сөйләшү була. Бу бәхәстә Ямашевның Җәгъфәрдән идея һәм әхлакый яктан никадәр өстен торуы, аның революция идеалларына ахыргача турылыклы булып калуы зур ышандыру көче белән ачыла.

А. Расих романын Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовларның алдарак искә алынган әсәрләре белән чагыштырып карасак, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин. Тукай белән Ибраһимов Ямашевның тормышын үзләренең иҗат фантазияләре аша үткәреп, аның нигезендә чын мәгънәсендә әдәби образ тудырсалар, Расих бу шәхеснең тарихи дөрес образын күрсәтүгә басым ясый. Шуңа күрә бу очракта документаль материалның роле бермә-бер үсә. Икенче яктан, бу хәл А. Расих романында рационализмның шактый көчәюенә китерә. Биредә рационалистик башлангычның көчәюе геройның иҗтимагый-политик һәм акыл эшчәнлеген алгы планга куеп һәм калку итеп гәүдәләндерүдә күренә. Бу әсәрдә тарихи шәхесне тасвирлауның төп үзенчәлекләреннән берсе шуннан гыйбарәт.

Г. Шәрипованың «Гафур гаиләсе» романы Ямашевның якын дусты һәм көрәштәше, татар пролетар язучысы Гафур Коләхметовка багышланган. Әмма тарихи шәхесне сәнгатьчә яктырту ягыннан бу ике әсәр бер-берсеннән шактый аерыла. Нигездә инде җитлеккән революционерның актив эшчәнлеген киң планда гәүдәләндерүгә багышланган «Ямашев» романыннан аермалы буларак, Г. Шәрипованың игътибар үзәгендә яшь Гафурның шәхесе формалашу, аның революцион көрәшкә килү юлы тора. Г. Шәрипова аны фәлсәфирәк планда яктыртырга омтыла. Романның прологын хәтерләткән беренче бүлекчәсендә автор тормыштагы төрле-төрле юллар хакында уйлана. Әйтик, егерменче йөз башындагы Казан шәһәренә төп ике юл белән килергә була. Аның беренчесе һәм иң яше — тимер юл. Әле яңарак кына салынган булса да, аның даны инде губернаның иң ерак почмакларына да таралып өлгергән. Икенчесе — чал Идел юлы. Кайдан башланганы билгесез булган бу зәңгәр юл Казанга киң һәм куәтле елгага әйләнеп килеп җитә. Болардан тыш, Казаннан губернаның төрле почмакларына почта юллары китә. Тагын әле авыл ара юллар, сукмаклар бар. Гафур шул юлларның кайсыннан китәр? Тормышның тимер юл һәм чал Идел кебек киң һәм олы юлыннан китәрме? Әллә инде басуларда һәм кара урманнарда югалып кала торган тар юлларга яки сукмакларга борылырмы ул?.. Менә шундый уйланулардан соң, Г. Шәрипова Коләхметовлар гаиләсенең тормышын сурәтләүгә күчә.

Халыкка күп кенә файдалы кешеләр, врачлар һәм укытучылар биргән бу гаилә турында автор тирән хөрмәт белән сөйли. Г. Шәрипова аны Казанның мещан һәм дин сазлыгына баткан караңгы татар бистәсендә үзенә бер якты утрау итеп

күрсәтә. Пенза якларыннан Казанга күчеп килгән күп санлы бу гаиләне бистә халкы сәерсенеп һәм г.җәпләнеп каршылый. Гаиләнең һәр члены беренче чиратта уңганлыгы, булганлыгы белән игътибарны җәлеп итә. Гаилә башлыгы Юныс абзый атаклы сабын кайнату остасы була, аш-су хәзерләүдә Газизә абыстайга тиңнәр булмый, аларның кызлары Гамбәр белән Шәмси матур чигүләре белән күпләрне таңга калдыралар... Коләхметовларның икенче күркәм сыйфаты — аларның саф күңелле һәм намуслы булуларында, горурлыкларын саклый белүләрендә. Бу сыйфатлары белән алар бистә халкының ихтирамын гына яулап калмыйлар, бәлки шәһәрнең иң тәкәббер байларын да үзләренә хөрмәт белән карарга мәҗбүр итәләр.

Шундый гүзәл сыйфатларга ия булган бу дус һәм бердәм гаиләне Г. Шәрипова шул чордагы татар җәмгыятенең төрле катлаулары белән бәйләнешкә кертә. Коләхметовларга ияреп, укучы сабын кайнату заводы эшчеләре арасына һәм ачлыктан җәфаланучы татар авылы Яуширмәгә барып чыга, татарская учительская школага һәм татар сәүдәгәрләре арасына үтеп керә. Шул арада автор, берничә генә штрих ярдәмендә, шушы төрле-төрле катлау вәкилләренең җанлы образларын да гәүдәләндереп өлгерә. Нәтиҗәдә роман битләрендә без дистәләрчә үзенчәлекле образлар белән танышабыз. Мәсәлән, тормыш, андагы гаделсезлекләр турында җитди итеп уйлана белүче Ярулла бабай, тормыштагы гаделсезлекләргә каршы көрәшкә күтәрелгән эшче егетләр Самат, Зариф һәм Мифтах, бик авыр тормышта яшәсә дә, рухы сынмаган, якты киләчәккә өметен өзмәгән авыл ярлысы Хисами, учительская школаның алдынгы карашлы укытучысы Григорий Феофанович, укучылардан горур табигатьле Кадыйр, акча өчен иманын сатарга әзер Харис, үзенең тормышын халык сәламәтлеге өчен көрәшкә багышлаган врач Искәндәр, клиент белән гадел булуны үзенең төп принцибы итеп куйган мадам Гаделлек (аның чын исем-фамилиясе Тереза Федоровна Гросс), сабын заводы хуҗасы Ишми Үтәмәсов һәм аның компаньоны Әпсәләм Апанаев, бай сәүдәгәр Садыйк, тәкәббер генерал хатыны Асма ханым һәм аның бирдәнбер улы Солтан-Мәхмүт һәм башкалар үзләренең үзенчәлекле сыйфатлары белән хәтергә кереп калалар. Автор дин әһелләрен сурәтләүгә, аларның сорыкортлык сыйфатларын ачуга шактый зур игътибар бирә. Бу яктан рус миссионеры Серафим, Хатип хәзрәт, мәзин Нигъмәтулла һәм Яуширмә авылы мулласы образлары кызыклы. Болар барысы революциягә кадәрге татар тормышының киң һәм катлаулы панорамасын күз алдына бастырырга булыша. Авторның бу чынбарлыкны, бигрәк тә аның көнкүреш ягын шактый тирән һәм конкрет белеп сурәтләве сизелә. Шуңа күрә бирелә шул чорның тормыш-көнкүреше, әйтик, А. Расих романындагыга караганда, җанлырак һәм тулы канлырак булып чыккан.

Сабын кайнату остасы Юныс Коләхметовның күп санлы балалары менә шундый киң фонда сурәтләнәләр. Аларга гаять кыен сынаулар аша үтәргә туры килә. Яуширмә авылында укытучылык итеп, крестьяннарның газаплы тормышын үз күзләре белән күргән Каюм актив көрәшчегә әверелә. Гамбәр белән Шәмси исә мөселман хатын-кызының аяныч язмышын үз җилкәләрендә татыйлар. Гамбәр үзе яратып Солтан-Мәхмүткә кияүгә чыга. Әмма Асма ханым аны, хәерче кызы дип, мыскыллап каршылый. Солтан-Мәхмүт кинәт кенә үлеп китКәч, Гамбәргә бу бай йортта яшәргә бөтенләй рәт калмый. Шәмси исә тагын да күңелсезрәк язмышка дучар була. Аны шәһәрдәге атаклы эчкече һәм сугыш чукмарына — Әпсәләм Апанаевның улы Хәмиткә кияүгә бирәләр. Хәмит хатынын баштан ук төрлечә кыерсыта, мыскыл итә, еш кына канга батырып кыйнап та ташлый. Нәтиҗәдә ир йортындагы тормыш Шәмси өчен тәмуг газабына әверелә. Гамбәр кебек, ул да мондый газапка озак түзеп тора алмый — ир йортын ташлап чыгып китә. Бу хәлләрдән соң Гамбәр белән Шәмсинең күп нәрсәгә күзләре ачыла һәм алар тора-бара яңа дөнья төзү өчен көрәшүчеләр сафына басалар.

Әйтергә кирәк, Юныс Коләхметов балаларының рухи эволюциясендә Гафурның роле зур була. Акыллы һәм эшлекле Гафур бу гаиләдә бик яшьли авторитет яулый, аның сүзләренә бөтенесе колак сала торган булалар. Гаилә тормышында елдан-ел роле үсә бару белән бергә, Гафур тора-бара романның да үзәк фигурасына әйләнә. Автор яшь геройның татарская учительская школада укыган елларын аеруча иркенләп тасвирлый, чөнки нәкъ менә шушы елларда Гафурның иҗтимагый-политик карашлары формалаша. Шул ук школада укыган Хөсәен Ямашевның Гафурга йогынтысы зур була. Хөсәен яр-

дәме белән Гафур революционерлар арасына үтеп керә, революцион әдәбият белән, Ленин әсәрләре белән танышып, һәм аларда үзен күптән борчыган сорауларга ачык җавап таба.

Г. Коләхметовның революцион эшчәнлеге исә әсәрдә бик өстән һәм үтеп барышлый гына күрсәтелә. Берничә мәртәбә Гафурның революцион прокламацияләр тәрҗемә итүе искә алына, бер тапкыр аның Ямашев белән Яуширмә авылына крестьяннарның тормышы белән танышырга барып килүе тасвирлана. Коләхметовның 1905 елда Казандагы революцион вакыйгаларда катнашуы да бары эпилогта гына телгә алынып үтелә. Гомумән, романда автор Гафурның революцион эшчәнлеген киң итеп күрсәтүне максат итеп куймаган, күрәсең. Коләхметовның пролетар язучы булып формалашуын җентекләп тасвирлау да автор планнарында каралмаган булган, ахры. Чөнки бу хакта да бер-ике информация бирү белән чикләнелә.

Җыеп әйткәндә, «Гафур гаиләсе»ндә үзәк геройның гражданин булып җитлегүен эзлекле рәвештә һәм нигезләп ачу алга куела. Автор үз героен шул чорның ачык сиземләрлек итеп гәүдәләндерелгән киң фонында күрсәтә. Гафурның характер үсешен ачарга алыну язучыны бу хакта хикәяләгәндә реаль фактлардан өскәрәк күтәрелергә һәм сәнгатьчә дәлилле фикер йөртүгә этәргән.

Тарихи шәхесне тасвирлауга багышланган өченче әсәргә — Җ. Тәрҗемановның «Көмеш дага» исемле романына килик. Биредә дөнья фәне үсешенә үзеннән зур өлеш керткән бөек галимнең формалашуын һәм аның ничек дөньякүләм әһәмиятле гыйльми ачыш ясавын яктырту үзәккә куела. Әйтергә кирәк, бу безнең әдәбият өчен шактый яңа тема. Шул ук вакытта бөек галим образын иҗат итүнең гаять катлаулы һәм авыр эш булуын да искәртәсе килә. Монда олы һәм үзенчәлекле фикер иясен һәм гыйльми һәм психологик яктан ышандырырлык итеп күрсәтергә кирәк. Моңа ирешү өзен язучының кеше күңелен яхшы белүе генә җитми, бәлки аңардан фән өлкәсендә бай мәгълүматлы һәм киң эрудицияле булу да сорала. Җ. Тәрҗеманов романында бу катлаулы мәсьәләләр ничек хәл ителә соң?

Романда бөек якташыбыз, атаклы математик Николай Иванович Лобачевскийның 1802—1826 еллардагы тормышы, ягъни аның Казан гимназиясенә укырга керүеннән алып математикада революция ясаган хезмәтен — «Геометриянең яңа нигезләре»н иҗат иткәнгә кадәрге гомере тасвирлана. Геройның бу юлы башлыча документаль материалга нигезләнеп яктыртыла. Шуңа күрә язучы геройны башлыча гыйльми даирәләрдә, гимназия һәм университет атмосферасында күрсәтә. Шул заманның иҗтимагый-рухи атмосферасын гәүдәләндерүгә исә аз игътибар бирелә. 1812 елгы Ватан сугышы турында автор, мәсәлән, түбәндәгечә яза: «1812 елгы Ватан сугышы башланды. Аның ялкыны Казанга килеп җитмәсә дә, шәһәр тормышына бик нык тәэсир итте. Французлардан куркып җылы ояларын ташлаган качаклар килде, Мәскәүдән иң югары хөкүмәт учреждениеләре күченде һәм шәһәргә хезмәткәрләр килеп тулды. Урта Иделдә урнашкан Казан вакытлыча Россиянең икенче башкаласына әйләнде». Бу хакта башка бер сүз әйтелми. Нәтиҗәдә Ватан язмышын хәл иткән һәм бөтен илдә патриотик хисләрнең нык көчәюенә китергән әлеге сугыш Лобачевскийга әллә ни тәэсир итми. Сугышның бетүе дә герой күңеленә бары шул елда аңа адъюнкт дәрәҗәсе бирелү белән генә кереп кала. Декабристлар восстаниесенең дә Лобачевскийга йогынтысы бик сизелми. Автор тарафыннан заманының прогрессив карашлы кешесе дип тәкъдим ителгән геройның үз чорының шундый гаять әһәмиятле тарихи вакыйгаларына ничектер битараф калуы күңелдә шик тудыра. Безнеңчә, мондый шәхес, яраткан фәне белән никадәр мавыкмасын, үз чоры тормышы белән дә якыннан кызыксынырга тиеш иде. Чөнки тарих атаклы галимнәрнең бер үк вакытта ялкынлы патриотлар һәм гражданнар да булганлыклары турында сөйли.

Лобачевскийның фәнни юлын һәм тарихи әһәмиятле гыйльми ачышын сурәтләүгә килсәк, биредә автор инде күп мәртәбә нигезлерәк һәм дәлиллерәк фикер йөртә. Ни өчен дисәң, бу хакта архивларда шактый бай материал сакланган. Автор алардан киң файдалана.

Лобачевскийга гаять кыен шартларда укырга туры килә. Гимназиядә һәм университетта дини-реакцион атмосфера хөкем сөрә. Администрация башлыча студентларны заманның «зарарлы» идеяләре һәм идеаллары йогынтысыннан саклап калу, гимназиядә һәм университетта урнаштырылган кырыс тәртипләргә буйсындырып тоту турында гына кайгырта. Лоба-

чевский исә шат күңелле һәм шук табигатьле үсмер була. Математикадан тыш, әдәбият һәм философия белән мавыга, иптәшләре белән шаярырга, күңел ачарга ярата. Шул сәбәпле, баштан ук ул администрациянең каты күзәтүе астына эләгә. Романда Лобачевский Казан гимназиясе һәм университеты тарихына начар даннары белән кереп калган ике реакционерга каршы куеп сурәтләнә. Аларның беренчесе — И. Ф. Яковкин башта гимназиянең, аннары яңа гына ачылган университетның ректоры була. Ул мөстәкыйль фикерле һәм сәләтле бу яшь егетне баштан ук дошман күрә һәм аны фән юлыннан читкә алып ташлау өчен кулыннан килгәннең барысын эшли. Казан университеты тарихына аеруча чирканыч фигура булып обскурант һәм карагруһчы М. Л. Магницкий кереп кала. Казан уку-укыту округы попечителе вазифасын башкарганда ул үзенең бөтен тырышлыгын университеттан «заманның зарарлы рухын, барысын җимерүче хөр фикерлелек рухын» кууга юнәлдерә.

Лобачевскийның шушы гаять кыен шартларда сайлаган юлыннан читкә тайпылмыйча бара алуын автор байтак дәрәҗәдә яшь геройга икенче төр кешеләрнең шифалы йогынтысы белән аңлата. Геройның фәндә беренче адымнары башта гимназиядә, аннары университетта укыткан Г. И. Карташевский һәм Н. М. Ибраһимов исемнәре белән бәйләнгән. Фәндә яңалыкка омтылган, тирән белемле һәм прогрессив карашлы бу кешеләр яшь Лобачевскийда фәнгә мәхәббәт хисе тәрбиялиләр, аны тынгысыз гыйльми эзләнүләргә рухландыралар. Шуңа күрә Карташевский белән Ибраһимов герой күңеленә иң кадерле кешеләре булып кереп кала. Үсә төшкәч, Лобачевскийга университет профессорлары М. Ф. Бартельс, Ф. К. Броннер, И. А. Литтров, Г. И. Солнцев һәм башкалар зур гына йогынты ясыйлар, кыен минутларда аңа ярдәм кулы сузалар.

Романда Лобачевскийның фәнгә һәм гомумән дөньяга карашларын ачуга шактый игътибар бирелә. Фәндә идеализмны яклаучы Никольский, Кондырев һәм башкалар белән бәхәсләрдә ул материалистик карашны алга сөрә. Ул фән, бу очракта геометрия, илаһи акыл тарафыннан уйлап чыгарылган, шуңа күрә аның кануннары абсолют дөрес дигән идеалистик карашка кискен рәвештә каршы чыга һәм моның киресен, ягъни геометрия нигезләрен үзгәртергә мөмкин булуын исбатларга тели. Әсәрдә Лобачевскийның мең еллар буена абсолют хакыйкать дип саналган нәрсәне — борынгы грек математигы Евклидның атаклы бишенче постулатын башкача исбатлауга килүе эзлекле рәвештә яктыртыла. Әмма бу ачышны Лобачевскийның замандашлары аңлый һәм бәяли алмыйлар.

«Көмеш дага»да бер нәрсәгә аеруча игътибар итәсе килә. Романда математика фәне белән бәйләнешле теоремалар һәм аксиомалар турында күп сөйләнелә. Аларның гади укучыларны пошамангa төшерүе, куркытуы бик мөмкин иде. Бәхеткә каршы, Җ. Тәрҗеманов бу куркынычтан байтак дәрәҗәдә котыла алган. Теоремаларны һәм аксиомаларны автор фәнни эзләнүләрнең киеренкелеген һәм драматизмын бирүдә шактый уңышлы куллана. Нәтиҗәдә беренче карашка күңелсез булып тоелган бу нәрсәләр әсәр битләрендә ничектер җанланалар һәм укучының игътибарын җәлеп итәләр. Ул теоремалар һәм аксиомалар нигезендә зур фәлсәфи мәгънәләр ятканын аңлап, без Лобачевскийның математик эзләнүләрен тирән кызыксыну белән күзәтәбез. Сүз уңаенда бу романның укучы өчен гыйльми яктан зур гына танып-белү әһәмияте булуын да әйтергә кирәк. Әсәрне укыганда без математика фәненең күп гасырлык тарихы, аның үткәндәге күренекле вәкилләре һәм мөһим мәсьәләләре турында популяр формада бирелгән бай мәгълүмат алабыз. Язучы үзен бу фән өлкәсендә киң эрудицияле кеше итеп таныта. Болар барысы, тулаем алганда, геройны чын мәгънәсендә галим итеп күрсәтергә, аның акыл көчен сиземләрлек рәвештә ачык гәүдәләндерергә булыша. Кыскасы, Җ. Тәрҗеманов романында Лобачевскийның зур галим булып җитлегүен күрсәтүгә басым ясала һәм бу процесс бай гыйльми җирлеккә нигезләнеп яктыртыла. Бу әсәрдә тарихи шәхесне гәүдәләндерүнең төп үзенчәлекләреннән берсе шуннан гыйбарәт.

А. Расих, Г. Шәрипова һәм Җ. Тәрҗеманов романнарын укыгач, шундыйрак бер нәтиҗәгә килергә була. Бу әсәрләрдә үткәндәге бөек тарихи шәхесләрне хәзерге идея-эстетик таләпләрдән чыгып әдәбиятта гәүдәләндерү буенча җитди эш башланды. Шул ук вакытта бу эшнең ярыйсы ук катлаулы һәм кыен булуы да ачыкланды. Документаль материалны иҗади фантазия белән бәйләве авторлар

өчен аеруча кыен икәне күренә. Әсәрләрдә, бигрәк тә А. Расих һәм Җ. Тәрҗеманов романнарында, тарихи фактлар автор фантазиясен чикләүләр кебек. Язучылар ул фактлардан өскәрәк күтәрелә һәм чынбарлыкка киңрәк карый алмыйлар шикелле. Нәтиҗәдә бу ике әсәрдә заманның иҗтимагый-рухи мохиты беркадәр ярлырак булып гәүдәләнә. Геройларны фән һәм җәмәгать эшлеклеләре итеп күрсәтүне алгы планга куеп, төп игътибарны шуңа юнәлтү сәбәпледер, ахры, әсәрләрдә герой тормышының шәхси ягына азрак дикъкать ителә.

Безнеңчә, бу хәлне, икенче яктан, авторларның документаль материалдан бик читкә китмәскә теләүләре белән дә аңлатырга мөмкин. Эш шунда ки, Ямашев белән Лобачевский тормышының бу әсәрләрдә сурәтләнгән чорына караган тарихи фактлар башлыча аларның иҗтимагый һәм фәнни эшчәнлекләрен генә ачыкларга булышалар. Геройларның бу дәвердәге шәхси тормышы турында исә тарихи мәгълүматлар рәтләп сакланмаган. Әйтергә кирәк, бу бушлыкны тутыруда иҗади фантазия зур булышлык күрсәтә алыр иде. Әмма А. Расих та, Җ. Тәрҗеманов та мондый эшкә ныклап алынмыйлар. Автор фантазиясенең көчсезрәк булуы романнарда рационалистик фикерләүнең бермә-бер көчәюенә һәм урыны-урыны белән хәтта сәнгатьчә фикерләүдән өстенлек алуына китергән. Биредә А. Расих белән Җ. Тәрҗемановның галим кешеләр булулары һәм фән дөньясына хас рациональ фикер йөртергә күнегүләре дә билгеле бер роль уйнагандыр, күрәсең. Язучылар күбрәк геройның акыл эшчәнлеген ачуга игътибар итәләр, интим уй-кичерешләр дөньясы белән исә азрак кызыксыналар. Шуңа күрә бу әсәрдәге тарихи шәхесләр башлыча акыл ияләре булып гәүдәләнәләр, ә хискә саран кешеләр булып чыгалар. Персонажларның берьяклырак, рационалистик рухта булуы сурәтләү чаралары һәм алымнарының да шактый бертөсле булуына китергән. Герой турында коры тел белән сөйләп бару өстенлек итә, образлы тасвир, герой характерын конфликтларда ачу җитенкерәми. Ахыр чиктә болар барысы әдәби анализның йомшаграк булуы турында сөйли.

Авторларның реаль фактларга булган мөнәсәбәте дә канәгатьләндереп бетерми. А. Расих та, Җ. Тәрҗеманов та күбрәк фактларны сөйләп бару белән чикләнәләр. Художник өчен ул гына җитми. Бу мәсьәлә уңае белән тагын М. Әуэзовка әйләнеп кайтасы килә. Абай Кунанбаевның замандашларының истәлекләрендә әледән-әле бер тарихи факт искә алына. Шулай бервакыт Хәдичә исемле кызны көчләп кияүгә бирмәкче булалар. Абай кызны коткарып кала. Күптән теш кайрап йөргән феодаллар, әлеге фактган файдаланып, шагыйрьгә һөҗүм оештыралар. Бу хәл 1897 елда була. М. Әуэзов шушы фактны үз романында ничек файдаланган соң? Әлеге мәсьәләгә тукталып, Л. Әуэзова түбәндәгечә яза: «Биредә әдип конфликтның тышкы ягын гына чагылдырган бу чыганакка турыдан-туры иярми, бәлки аның тирән психологик нигезен ача. Бу хәбәрне үзенең иҗат фантазиясе аша үткәреп, ул аны Абайны үтерергә теләүнең тагын да тирән сәбәпләрен ачыклау, шагыйрьнең үз сыйныфы белән конфликтын киң гомумиләштереп гәүдәләндерү өчен файдалана»[1]. А. Расих белән Җ. Тәрҗемановка исә тарихи фактларга әнә шундый аналитик караш җитенкерәми әле.

«Ямашев» белән «Көмеш дага»ның документаль нигезе нык булып, әдәби тукымасының йомшаграк булуын, безнеңчә, тагын авторларның үзәк геройларны тарихи яктан дөрес итеп күрсәтергә аеруча омтылулары белән аңлатырга кирәк. Нәкъ менә тарихи дөреслеккә зыян китерүдән шикләнү әдипләрнең иҗади фантазиясен артыграк тезгенли, документаль материалны сурәтләүгә аналитик караш белән килергә комачаулый кебек.

Инде әйтелгәнчә, «Ямашев» белән «Көмеш дага» романнары Ямашевка һәм Лобачевскийга багышланачак дилогияләрнең беренче китапларын тәшкил итәләр. Димәк, әле икенче китаплар да туарга тиеш. Аларда язучыларга геройлар тормышының тирән уй-кичерешләргә бай булган тагын да катлаулырак һәм авыррак дәверләрен яктыртырга туры киләчәк. Шуңа күрә туачак әсәрләрдә бу бөек шәхесләрнең олы рухы һәм образы сәнгатьчә тагын да тулырак һәм тирәнрәк булып гәүдәләнер дип ышанасы килә.

---

[1] Л. М. Ауэзова. Соотношение исторической правды и художественного вымысла в образе Абая. «Вестник Академии наук Казахской ССР», 1971 ел. 8 сан. 31 бит.

# ДИҢГЕЗДӘ СЫНАУ

Юк, бу — әдәби әсәрләрдә еш телгә алына торган җилкәнле кораб түгел, ә сәгатенә утыз километрдан артык тизлек белән йөзә торган XX гасыр теплоходы. Аның исеме дә чор батырлыгын гәүдәләндергән кешенеке — «Муса Җәлил».

Язучы Рафаэль Мостафин «Диңгез көндәлеге»[1] исемле китабында әнә шул теплоходта диңгез-океаннар гизүе хакында сөйли.

Диңгез — татар әдәбияты өчен яңарак, ятрак тема. Димәк, бу темага алынган язучыны күп кенә өстәмә мәшәкатьләр, уйламаган кыенлыклар көтә. Диңгез язучының өлгергәнлек дәрәҗәсен, талантын да сыный. Язучы өчен сынау булу өстенә, диңгез корабка утырып сәяхәткә киткән кешеләрнең түземлеген, ныклыгын һәм, димәк ки, социалистик җәмгыятьтә хөкем сөргән иҗтимагый мөнәсәбәтләрне дә сыный. Ул кешенә үзенең бушлыгы белән, чиксезлеге белән, куркыныч булуы белән сыный. Диңгез белән йөзгә-йөз очрашкан кеше алдаша, икейөзләнә алмый — синең алда үзенең бөтен характеры, бөтен асылы белән ачыла. Р. Мостафин китабын укыганда да без диңгезчеләрнең чын йөзләрен күрәбез. Алар арасыннан иң яктысы — капитан Роман Александрович образы. «Кешенең балаларга һәм җәнлекләргә карата булган мөнәсәбәтеннән аның асылын белеп була»,— ди бер урында автор. Бу сүзләр, барыннан да элек, нәкъ менә Роман Александровичка туры килә. Без юл буена аны әле аквариум янында, әле аю балалары, кечкенә маймыллар тирәсендә күрәбез. Көньяк Африка Республикасы яныннан узганда корабның руль җайланмасы «чыгымлый» башлый. Менә шул чагында без капитанны бөтенләй башка яктан күрәбез. Ул кырыс характерлы чын диңгезчегә, нык куллы җитәкчегә әйләнә. Кайберәүләр, ярдәм сорап, шушы республикага керик, диләр. Роман Александрович катгый баш тарта. Диңгездә давыл якынлашып килүгә дә карамастан, җайланманы үз көчебез белән төзәтәбез, ди. Һәм шулай эшлиләр дә. Валерий Кравченко, Николай Кожинов та диңгезче образын үзләренең матур сыйфатлары белән тулыландыралар. Ә диңгезче йөрәгенең иң тирән ачылган урыны, мөгаен, китапның түбәндәге юлларындадыр: «Тормышның ачысынтөчесен татыган диңгезчеләр меңә ял вакытларын ничек түземсезләнеп көтүләре, тизрәк ярга чыгарга ашкынулары турында сөйләделәр. Ә ярга чыгып ике-өч атна үтми, диңгезче күңелендә ниндидер бушлык, сагыш башлана, ул бушлыкны берни белән дә тутырып булмый икән, отпусканың икенче яртысында инде диңгезчеләр причалга килеп йөри башлыйлар, ерак сәяхәттән кайтучы корабларны каршылыйлар... һәм акча бетте дип ялганлап, рейска иртәрәк чыгаруларын үтенәләр».

Р. Мостафин бу сәяхәт вакытында сынауны художник буларак та уңышлы үткән дияргә була. Беренчедән, безнең күз алдына диңгез үзенең бөтен матурлыгы, зурлыгы белән килеп баса. Икенчедән, диңгез авторның үзен, аның хисләрен һәм фикерләрен дә бер баскыч югары күтәргән. «Гүзәллекне бөтен тирәнлеге белән тоя белгән кеше беркайчан да әшәкелек эшләми,— ди язучы,— чөнки әшәкелек аның асылына, эчке эстетик тоемына каршы килә».

Диңгездә йөзү язучыны олы җир, дөнья проблемаларыннан аз гына да аера алмый — аларның сулышын, көн вакыйгаларының кызулыгын тоеп тору Р. Мостафин китабына хас матур сыйфатларның тагын берсе. Аның сәяхәт юлы заманыбызның тыгыз проблемаларын ерып, аларның уртасыннан бара. Авторны гарәп ил-

[1] Р. Мостафин. Диңгез көндәлеге. Казан. 1972 ел.

ләре һәм Вьетнам язмышы, икегә бүленгән Корея борчый, интернационализм һәм милли мәсьәләләр, тормышта сәнгатьнең урыны, күп төрле башка нәрсәләр уйландыра. Менә Вьетнам ярлары буенда язылган бер юл: «Кояш кызарып баеганда мин янган джунгли исләрен сизгәндәй булдым».

Диңгездә булу язучының кешеләргә булган карашын да үткенәйтә. Чөнки диңгез — кешенең күңел көзгесе ул. Әгәр рухи дөньяң, хисләрең ярлы булса, күңел күзең начар күрсә, ул сиңа тыныч яки давыллы булып кына күренергә мөмкин. Ә Рафаэль Мостафин анда, маринист-рәссамнар кебек, онытылмаслык образлар таба. Менә «томанлы соры иртә. Акчарлаклар, ап-ак төнбоеклар шикелле, дулкыннар өстендә тирбәлеп утыралар... Иркә дулкыннар, наян көчекләр кебек, йомшак кына тәгәрәшеп килpoints». Бусы — диңгезнең тыныч чагы. Ә тузынгач, ачуы килгәч, ул менә нинди була: «океан офыктан-офыкка сузылып кайный, бытырдый, котырына... Зур дулкыннар, диңгезнең тыгыз мускуллары тартышкандай, уралып-уралып тәгәриләр».

Китапны укыганда, уңышлы табылган бу детальләр күз алдына диңгезне китереп бастыралар һәм ул диңгез, хәрәкәткә килеп, күңелдәге хис диңгезе белән бергә чайкала башлый.

Рафаэль Мостафин үзенең юлъязмаларын аерым китап итеп чыгарганда журнал вариантын бераз үзгәрткән. Бу үзгәртүләрнең күбесе файдага. «Казан утлары» журналында басылган вариантында ике урында шагыйрь Сибгат Хәким телгә алына иде. Ә китапта автор аны «өлкән бер шагыйрь» дип кенә биргән. Болай үзгәртү ничектер аңлашылмый һәм аз гына булса да әсәрнең ямен җибәрә. Дөреслек кирәк иде. Аннан соң, «аның күккә ашкан алты **манарасы** нәкъ хәнҗәрләр кебек **ялтырыйлар»** (26 бит), «ике **шаулы** урам чатына куелган таш һәйкәл» (120 бит) кебек җөмләләр дә урыны-урыны белән тешкә тиеп китәләр.

Ә тулаем алганда, диңгез кендәлеген укып чыккач, үз күңелеңнең әллә никадәр баеганын тоясың, сөенәсең һәм авторга ихлас күңелдән рәхмәт әйтәсең.

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

# ТАМЫРЛАР ДЫМГА СУСАМАСЫН

1972 елда дөнья күргән шигырь китаплары янына тагын бер җыентык — Шамил Маннаповның «Тамырлар»ы[1] кушылды. Китапның яхшы яклары нидә? Шигырьләр сәнгать кануннары таләбенә җавап бирәме? Китапның нинди җитешсезлеге бар? Һәр яңа китапны кулга алу белән укучы алдында шундый сораулар туа.

Җыентыкта шагыйрьнең бүгенге көн бурычларын яктырткан әсәрләре тупланган. Сүз Чаллы төзелеше турында барамы, тормышны сөючә гүзәл кешеләр турындамы — җыентыктагы һәр шигырьдән Шамил Маннаповның изге Татарстан җиренә карата булган чиксез мәхәббәтен күрәсең:

**Син шундый җир:**
**Бөтен дөнья буйлап**
**Таратса да төрле заман җиле,**
**Кайларда да ямен, тәмен җуймас**
**Туган җирем — Татарстан җире.**

Күп күргәнсең,
Күтәргәнсең күпне,
Өркетмәгән, селкетмәгән бере.
Халкым кебек чыдам авырлыкка,
Туган җирем —
Татарстан җире...

Күрәсез, яшь шагыйрь бүгенге көннең бөек үзгәрешләренә тарихи күзлек аша карый. Югарыда китерелгән юллар аның эчтәлеккә генә түгел, шигъри формага да таләпчән каравы, оригинальлеккә омтылуы турында сөйлиләр. Эчтәлекнең һәм форманың органик бәйләнешен аның «Тамырлар», «Иман», Әнвәр Давыдовның якты истәлегенә багышланган «Төзүчеләр...» исемле шигырьләре ачык күрсәтә. Болар, минемчә,— шагыйрьнең өлгергән, фикерле, кайнар хисле шигырьләре.

Шамил Маннаповның геройлары — төрле профессия кешеләре. Шигырьләрдә, әлбәттә, аларның исемнәре дә, фамилияләре дә күрсәтелмәгән, тик аларның һәм-

[1] Шамил Маннапов. Тамырлар. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1972.

мәсе дә безнең замандашларыбыз, алар ашкын хисле, кайнар йөрәкле совет яшьләре. Җыентыктагы шигырьләрнең иң зур күпчелеге тәзүчеләргә багышланган. Шуны да әйтергә кирәк, төзүчеләр турындагы шигырьләрнең күп булуы Маннаповны үз-үзен кабатлауга да китергәли. «Яңа йорт янында» шигырендә яңа төзелгән йорт — яшьлек белән, икенчесендә — яшь егет белән («Яшь егеттәй төп-төз йортлар калка»), «Күченү»дә иске өй ана белән («Син каласың боегып моңсу гына, карап калган кебек әнием») чагыштырыла.

Китапка кергән фәлсәфи дүртьюллыклар Шамил Маннаповның иҗатын яңа планда күрсәтә. Кеше, җир, дөнья турындагы фәлсәфи уйланулар Шамилнең халыкчанлыкка һәм тирән фикерләргә омтылучан шагыйрь икәнен раслый.

«Бер дуска», «Рәхмәт сезгә, кешеләр», «Каберлектә», «Шигырьләрем» кебек әйбәт шигырьләр белән беррәттән, җыентыкта әле «Алина», «Клуб мөдире сүзләре», «Маһруй әби теләге» кебек бик үк уңышлы булмаган әсәрләрнең дә урын алуы укучыны борчый.

Кайбер шигырьләрдә кыска гына фикерне дә озын шигъри юллар белән аңлатып бирергә тырышу («Аерылганда күңелем ташыса да...», «Алина», «Абыем, синең яуга киткән чагың...» шигырьләре) җыентыкның сәнгать көчен шактый киметә.

«Тамырлар» — шагыйрьнең өченче китабы. Аны укып чыккач, шундый фикергә киләсең: Шамил Маннапов китаптан-китапка үсә, камилләшә бара. Ул киләчәктә дә үз-үзенә таләпчән булсын, шигъри тамырлар дымга сусамасын дигән теләктә калабыз.

**ӘМИР МӘХМҮДОВ.**
Мәскәү.

# *БЕР КИТАП ТУРЫНДА ИКЕ ФИКЕР*

## ТОПОНИМНАР ТУРЫНДА ЯҢА ХЕЗМӘТ

Берәр төрле урынның, аерым бер территориянең топонимнарын өйрәнә торган фәнне топонимика дип атыйлар. Ул географик атамаларны, аларның килеп чыгышын, үсешен, бүгенге торышын, географик атамаларның мәгънәви әһәмиятен, лексик составын һәм фонетикасын, шулай ук аларның дөрес язылышын һәм бер телдән икенче телгә дөрес транскрипцияләнүен өйрәнә. Топонимиканың фәннәр системасында тоткан урынын билгеләгәндә, аның тарих, география һәм лингвистика фәннәре белән нык бәйләнешен һәм тыгыз элемтәдә булуын күрсәтеп үтәргә кирәк. Бу исә республикабыз топонимнары турында язарга алынган һәр кешедән күп көч, зур хәзерлек сорый. Икеләнмичә әйтергә мөмкин, Гомәр Саттаровның Татарстан топонимнары турындагы «Ни өчен шулай аталган?» исемле хезмәте[1] аның бу өлкәдә шактый хәзерлекле галим булуы турында сөйли.

Китапта күтәрелгән мәсьәләләр башлыча тарихи-лингвистик планда яктыртыла. Билгеле, Татарстан топонимнарына багышланган бу хезмәт фән өчен бөтенләй үк күтәрелмәгән чирәм түгел. Соңгы ун ел эчендә генә дә галимнәребез үзләренең фәнни хезмәтләрендә теге яки бу дәрәҗәдә топонимнар турында аерым мәгълүматлар биреп килделәр. Фәннең бу тармагы кайбер хезмәтләрдә, бигрәк тә Р. Сүбаева, В. Никонов һәм башка иптәшләрнең хезмәтләрендә, өлешчә яктыртылды. Бу өлкәдәге башка хезмәтләрдән үзгә буларак, Г. Саттаров китабы үзенең конкретлылыгы, барлык игътибарны Татарстандагы район һәм торак пунктларының исемнәренә, аларның этимологиясен ачыклауга юнәлдерелгән булуы белән аерылып тора. Бу исә авторга өйрәнелә торган мәсьәләләрне җентекләп тикшерергә һәм тирәнрәк анализ ясарга мөмкинлек биргән.

Ике бүлектән торган китапның беренче бүлеге Казан шәһәренә багышланган һәм төп ике мәсьәләне ачыклау максатыннан чыгып язылган. Беренчедән, Казанга кайчан

[1] Г. Саттаров. Ни өчен шулай аталган? Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел.

нигез салынган? Икенчедән, ул ни өчен «Казан» дип аталган? Шул ук бүлектә Казан урамнары исемнәрен өйрәнүнең торышы да яктыртыла.

Автор үзенең китабында төрле легендаларда, елъязмаларда һәм Казан турындагы китапларда булган күп төрле мәгълүматларга киң туктала, аларның һәрберсенә үзенең карашын һәм мөнәсәбәтен белдерә. Шәһәребезнең ни өчен «Казан» дип аталуы турында язганда, ул «Казан» сүзенең күп мәгънәлелеге шәһәр исеменең килеп чыгышына карата төрлечә фикер йөртүгә китергән; халык этимологиясе дә, галимнәрнең аңлатуы да шушы сүзнең теге яки бу конкрет мәгънәсенә нигезләнгән, дип белдерә.

Гомәр Саттаров, үз фикерләрен дәлилләү өчен, тарихи истәлекләргә, елъязмаларга, кабер ташларына, төрле газета-журнал битләрендә басылган материалларга һәм археологик казынуларга таяна. Ул шулай ук күп санлы архив материалларына, татар халкының риваятьләренә һәм башка чыганакларга туктала. Автор моннан 200 ел элек язылган Петр Рычков әсәрләренә, тарих фәнендә зур авторитетлар саналган В. Н. Татишев, К. Фукс, С. М. Шпилевский, В. В. Радлов, И. А. Износков, күренекле татар галиме Шиһаб Мәрҗани, күренекле совет галимнәре В. В. Бартольд, А. П. Смирнов, Б. Д. Греков, Н. И. Воробьев, Н. Ф. Калинин, А. Х. Халиков һәм башка галимнәрнең Казан шәһәре тарихына багышланган хезмәтләренә мөрәҗәгать итә. Шулай итеп, берничә гасырлар буена буыннан-буынга җыелып, тупланып килгән төрле кыйммәтле фикерләр, күптөрле капма-каршы карашлар чал тарих битләреннән безнең күз алдыбызга килеп баса.

Әнә шул гаять күп санлы материалларны Гомәр Саттаров фәндә ирешелгән бүгенге югарылыктан, бүгенге чор таләпләреннән чыгып өйрәнә. Шунысы характерлы һәм игътибарга лаеклы, автор теге яки бу галимнең дөреслеккә туры килмәгән карашына шул ук чорда яшәгән һәм эшләгән икенче бер галимнең авторитетлы хезмәтен каршы куя. Шул рәвешчә, капма-каршы фикерләр көрәше барлыкка килә. Чөнки һәр галимнең, һәр фикер иясенең үзенә күрә дөрес һәм бәхәссез дип санаган ышанычлы дәлилләре була.

Теге яки бу галимнең каршылыклы фикерләренә бәя биргәндә, Г. Саттаров еш кына «дөреслеккә туры килсә кирәк», «...белдерә дип, ялгышулары бар», «территория төшенчәсен белдерүе дөреслеккә якынрак», «барлыкка килгән дип карарга тиеш булабыз», «бу карашта хаклык бар дип саныйбыз» кебек җөмләләр куллана. Бу алым укучыларны уйланырга, фикер йөртергә мәҗбүр итә. Чөнки син, укучы буларак, зур кызыксыну белән төрле каршылыклы фикерләрне күңел аша уздырып, чагыштырып карыйсың, аларга төрле сораулар бирәсең һәм җаваплар эзлисең. Кайбер фикерләр белән килешәсең, икенчеләре белән бәхәскә керәсең.

Алга таба автор Казан шәһәре урамнарының элекке һәм хәзерге исемнәренә туктала. Ул шулай ук «күп нәрсә сөйли торган тарих хәбәрчеләре» булган урам исемнәрен алмаштыру-яңарту мәсьәләсен күтәреп чыга. Бу мәсьәләнең тирәнтен уйлап эш итүне сорый торган җаваплы һәм мөһим булуын әйтеп үткәннән соң, соңгы елларда бу өлкәдә башкарылган әһәмиятле эшләрне күрсәтеп уза, исемнәре аерым урамнарга бирелеп мәңгеләштерүгә, Казан топонимиясендә урын алырга лаеклы шәхесләрне — күренекле революционерларны, партия һәм совет дәүләте эшлеклеләрен, гражданнар сугышы каһарманнарын һәм Бөек Ватан сугышы геройларын, фән, әдәбият һәм культура өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәткән кешеләрне санап чыга. (Билгеле, китапта күрсәтелгән исемнәрне тулыландырырга һәм дәвам итәргә мөмкин булыр иде.)

Китапның икенче бүлегендә Г. Саттаров, топонимика фәнендә ирешелгән һәм билгеле булган гомуми принциплардан чыгып, Татарстан топонимиясен классларга бүлү мәсьәләсенә туктала һәм «туган ягыбызның тарихи үткәннәрен һәм хәзергесен танып белү өчен шулай ук зур әһәмияте булган» (78 бит) һәр районның исеме кайдан алынуын ачыкларга тырыша. Күп санлы тарихи чыганакларга һәм фәнни хезмәтләргә таянып эш итү нәтиҗәсендә, автор район исемнәренең этимологиясен шактый тулы яктыртуга ирешкән. Күпчелек район һәм шәһәр исемнәренең «үзенчәлекле һәм кызыклы» этимологиясен аңлаткан, халык массалары тудырган, халык арасында буыннан-буынга күчеп яшәп килгән, авыл һәм шәһәр картлары сөйләменнән язып алынган күп санлы борынгы шәҗәрәләрнең, риваятьләрнең һәм тарихи мәгълүматларның, беренче тапкыр буларак, аерым бер китапка өлешчә тупланып укучыларга җиткерелүе дә Гомәр Саттаров хезмәтенең кыйммәтен һәм әһәмиятен арттыра.

Китапның фәнни аппараты шактый бай. Алда бер тапкыр әйткәнчә, автор тарих, география, тел белеме, экономика, статистика, экономик география, матур әдәбият, тәнкыйть, фольклор һәм фәннең башка тармаклары буенча төрле вакытта, төрле илләрдә, республикаларда һәм өлкәләрдә, төрле телләрдә басылып чыккан зур күләмле монографияләрне, фәнни мәкаләләрне, тарихи истәлекләрне өйрәнеп, аларга азмы-күпме анализ ясаган. Китапта күрсәтелгән, төрле характердагы өзекләр китерелгән фәнни хезмәтләрнең саны гына да йөз иллегә җитә.

Билгеле, китапның кереш сүзе булып, анда топонимика фәне, аның максаты һәм бурычлары турында азмы-күпме мәгълүматлар бирелгән булса, йомгаклау сүзенең юк дәрәҗәсендә артык кыска булмыйча, анда тикшерелгән мәсьәләләр турында кыскача гына булса да берничә сүз әйтелеп киткәндә, хезмәт тагын да отышлырак чыккан булыр иде. Икенче бүлектә кайбер район үзәкләренең кайчан барлыкка килүе турында мәгълүматлар бирелүе, ә икенчеләре турында якынча гына да белешмә бирелмәве, кайбер урыннарда китапның теле кирәгеннән артык гадиләштерелүе, бер үк төрле фикернең берниндн үзгәрешсез берничә урында кабатлануы һәм башка шундый кимчелекләр очравы шулай ук китапның гомуми тәэсир көчен кимetә төшәләр.

Әйе, әлегә кадәр Казан шәһәре топонимиясен өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр юк дәрәҗәсендә иде. Топонимика фәне алдына тормышыбыз һәм практика куйган махсус бурычларны үтәү йөзеннән, үз алдына «совет кешеләрендә, аерата яшь буында, туган илгә тирән мәхәббәт, аны чын күңелдән ярату хисләре тәрбияләүгә зур ярдәм итәр» дигән олы максат куеп, галим Гомәр Саттаров топонимнарның бер өлешен өйрәнгән. Аның хезмәте — бу өлкәдә башкарылган беренче адым. Әмма тормыш һәм практика галимнәребез алдында тагы да зуррак һәм катлаулырак бурыч — республикабыздагы барлык-барлык авылларның, шәһәрләрнең һәм эшче поселокларының, кыскасы, Татарстан топонимиясен тәшкил иткән барлык топонимик классларның географик атамаларын махсус өйрәнеп, бу өлкәдә күп планлы, зур күләмле фундаменталь хезмәт тудыру һәм язу бурычын куя. Берничә еллар буена дәвам итәчәк бу эш аерата зур көч, тырышлык, төрле фән өлкәсендә эшләүче галимнәрнең, игътибарны бер максатка юнәлтеп, берләшеп һәм күмәкләшеп эшләүләрен таләп итә. Чөнки бүгенге көндә республика картасында булган авылларның саны гына да дүрт меңгә җитә. Шуны да истән чыгармаска кирәктер, төрле поселокларның һәм шәһәрләрнең барлыкка килүе, авылларның эшче поселокларына, эшче поселокларының шәһәрләргә әйләнүе — даими һәм өзлексез процесс. Совет власте елларында һәм Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорда гына да дистәләрчә авыллар, поселоклар һәм шәһәрләр барлыкка килде. Шул ук вакытта икенче бер процесс — кайбер кечкенә авылларның икенче бер зуррак авыл белән кушылу процессы дәвам итә. Бу, беренчедән, республикабызның ландшафт архитектурасы даими рәвештә һәм бертуктаусыз үзгәреп торуыннан килә. Икенчедән, соңгы елларда илебездә вак һәм кечкенә авылларны берләштерү процессы бара. Бу исә халыкның тормышын яхшырту, көнкүреш һәм төрле сәяси зәвыкларын тулырак һәм киңрәк канәгатьләндерү йөзеннән башкарыла.

Хәл үзеннән-үзе аңлашылса кирәк. Топонимика фәне алдында торган бурычлардан чыгып карасак, һәр авыл безнең өчен зур кыйммәткә ия булган тарихи чыганак, республикабызның тере тарихы. Еллар үткән саен, республикабыз картасында хәзерге вакытта булган кайбер авылларны бик теләсәк тә өйрәнә алмавыбыз мөмкин. Республикабызның тулы картинасын чагылдырган тарих — әлеге шул дүрт мең авылның да тарихы ул. Шул авылларның йөзеннән, унысыннан, хәтта берсеннән башка гына да Татарстан тарихы тулы була алмый. Республика авылларының, топонимнарының тарихын өйрәнү безнең буын өчен генә кирәк дип карау дөреслеккә туры килмәс иде. Ул безнең үзебез өчен дә, киләчәк буыннар өчен дә бер үк дәрәҗәдә кирәк һәм мөһим. Шуңа күрә Татарстан топонимнарын өйрәнүне бары тик галимнәр өстенә генә аударып калдырмыйча, бу мәсьәләне хәл итүдә республикабыз, шәһәрләр, районнар һәм авыллар җәмәгатьчелеге, урыннардагы музей һәм культура агарту учреждениеләре хезмәткәрләре, туган якны өйрәнү түгәрәкләре һәм мәктәп балалары гаять зур һәм мактаулы эш башкара алырлар иде дип әйтәсе килә.

**РАВИЛ ЛОТФУЛЛИН.**

# КҮТӘРЕЛӘСЕ ҮРЛӘР КҮП ӘЛЕ

Ономастика — ялгызлык исемнәр турындагы фән. Һәм аның бер елеше — топонимия Татарстанда да уңышлы үсеп килә. Безнең алдагы китап[1] та — яралып килгән топономия карлыгачларының берсе. Бу «карлыгач»ның канатлары безгә Казан шәһәре һәм Татарстанның районнары хакында, аларның исемнәренең этимологиясе (кайдан, ничек килеп чыгуы) турында мәгълүмат бирә.

Топономия — бик кызыклы фән. Ул төбәк, авыл, шәһәр, тау, елга исемнәренең серен ача. Ләкин топонимнарның серен табу җиңел түгел. Кайбер сүзнең мәгънәсен еллар буе эзләргә туры килә. Әмма бу эзләнүнең үз ләззәте, үз романтикасы бар. Топонимия тикшеренүләрдә тарих, археология, география, этнография, тел белеменә таяна. Шулай ук үзе дә башка фәннәргә ярдәм итә. Без кулга тоткан китап та үз эченә күп кенә тарих сәхифәләрен, лингвистик фактларны һәм эзләнүләрне, болар өстенә тагын этнографик материал, археологик ачышларны туплаган. Мәсәлән, бер Казан шәһәренең исемен ачыклау өчен генә дә авторга егерме биш галимнең хезмәтен өйрәнеп чыгарга туры килгән.

Гомәр Саттаров күп эзләнгән, күп белә. Күп кенә топонимнарны дөрес аңлап, «җиде серле» сүзләрнең дә эчтәлеген ачып бирә. Мишә — имән; Зәй — сәй-сай-су юлы-агым су; Бөгелмә — бөгелеп, борылып-борылып аккан елга; Чаллы — ташлы елга дигән сүз икән ләбаса. Ә Азнакай, Мамадыш һәм Тәтеш — кеше исемнәре, күрәсең. Бу топонимнарның сере яхшы тәфсилләнеп бирелә. «Казан урамнарының элекке исемнәре» дигән бүлек тә безгә бик ошады. Монда шәһәр тарихы чагыла.

Шуның белән бергә, хезмәт кимчелекләрдән дә азат түгел. Г. Саттаровның кирәкле һәм кызыклы бу китабында байтак топонимнарның мәгънәләре тулысынча ачылып, ачыкланып бетмәгән. Автор аерым сүз һәм топонимнарның мәгънәсен хата аңлый. Кайчакта ул, сүзләрнең тышкы охшашлыгын мәгънә берлеге дип белеп, әллә нинди нәтиҗәләр ясап ташлый (35 бит). Мондый ысул буенча барсаң, Байлар авылының исемен (Баулы районы) «бай кешеләр» дип әйтергә була. Ә ул — борынгы башкорт ыруының исеме. Аллә сакласын, «сыерчык» «бәләкәй сыер» булып китмәсен. Кукмара районындагы Манзарас авылының исемен дә «манзара»га бәйләү дөрес түгел. Ул, Зариф Бәшири әйтүенчә, «мазар асты»[2]ннан шулай үзгәргән. Җанлы шаһит булмаса, очын табарлык та түгел.

«Каран елга»ны җирдән чыккан су дип кенә аңлату шулай ук дөрес түгел (44 бит). Урман елгасы, караңгы чокырда, күләгәле җирдә башланган яки куе күләгәле чишмә «каран чишмә» (елга) дип йөртелә. Ачык урында башланган яки әрәмәсез елганы «аяз елга» диләр. «Каран»ның мәгънәсен менә бу строфа бик матур ачып бирә:

**Ирләр зарлана, җирләр саран, дип,**
**Җирләр зарлана, ирләр надан, дип,**
**Уңган ирләр дә, урман-җирләр дә**
**Җилгә зарлана, илләр каран, дип[3].**

Башкортстанда Бүздәк-Кандра станцияләре арасындагы тимер юл «Каран елга» һәм «Аяз елга» аша үтә.

Арча сүзен «ар»га (удмурт) илтеп бәйләү дә дөрес түгел (56, 90 бит). Арча — агач ул[4]. Җылы яктан килгән угыз, болгар, печәнәк, кыпчакларның ят агачны (чыршыны) элекке таныш сүз белән «арча» дип атаулары чынга бик якын килә.

«Шушма»ны (су исемен), чын атама дип уйлап, аны «шуу-шуышу»га тиңләп, «шуыша, су юлын үзгәртә торган елга» дип аңлата (96 бит). Үзәге үзгәрмәгән елга бармы соң бездә? Таш тарлавыктан акка елгалар гына юлын үзгәртә алмый.

Тамыр охшашлыгын сүзләрнең серен ачуда универсаль метод итү нәтиҗәсендә, Чирмешән — «чирмеш елгасы», Казан — «каз елгасы» булып киткән.

«Казан» — академик В. В. Радлов сүзлеге һ. б. буенча күп мәгънәле сүз: **туп** (пушка), **өзәңге, үлән, казан, полк, казан** (ыру), **таш ата торган машина**. Моның өстенә ул — кеше исеме дә. «Казан»ның төрле варианты кушылган авыллар Башкортстанда егерме. Мондый топонимнар

[1] Г. Саттаров. Ни өчен шулай аталган? Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел.

[2] Мазар — кабер, зират. Манзара — күренеш, пейзаж.

[3] Хөсәин Абушаев. Алтынчарым. Оренбург. 1915. Монда «каран» — караңгы дигән мәгънәне белдерә.

[4] Татарча-русча сүзлек. 41 бит.

Себердә, Казагыстанда, Кавказда, Кара диңгез буйларында, Пермьдә, Болгариядә бар. Күп җирдә ул «Казан халкы» дигән төшенчәне гәүдәләндерсә дә, мондый су, үзән, чокыр (ягъни су юлы), түбән җирләр бар. Шуннан чыгып, «казан» әгәр «каран»-га бәрабәр булмаса [1], казылма-чокыр — су юлы-су-елга төшенчәсен бирәдер. Хәер, «Казан» әгәр «каран»га кайтса да, барыбер «елга» булып кала.

Сүзне теләсә ничек ике кисәккә турап аңларга теләү аркасында, кайбер топонимнарны да автор бик «кызык» аңлый. «Аксубай»ны, икегә бүлеп, ак+субай дип, «ак сыбай» — «ак — рыцарь» итәргә һич нигез юк (85—86 бит). Халык телендә ул авыл Аксу! «Бай» кушымчасын аңа, әлбәттә, татар кушмаган. Аксу янында Карасу да утыра. Буа ягында дүрт Аксу, ике Суык-су авыллары бар. Урта Азиядә «ак су» дип кар суын, «кара су» дип җирдән чыккан суны әйтәләр. Бездә «ак су» күлдән агып чыккан су була. Тәмле суны шулай атау да ихтимал.

«Актаныш»ның акланыш-аклану дигән мәгънәсе дә бар, һәм ул — кеше исеме. «Ул тапмый» дип хурланган килен, варис биреп, акланып, баласы «Актаныш» аталу булган. «Апас» Габбас=Аббастан, Саба Сафа=Сападан килеп тугандыр?

[1] Г. Саттаров. Ни өчен шулай аталган? 44 бит.

«Баулы» да баудан түгел. Аны «Байлар» этнонимыннан (ыру исеменнән) табарга мөмкиндер. Баулы-Байлы шул ыруның баебәйе-бейе-биенең резиденциясе түгелме ул? [2] Хәер, «баулы»-«баглы» — күп мәгънәле сүз.

Минзәлә хакында гипотеза зур бирелгән (103—105 бит), ләкин чын этимология табылмаган әле. Юкка автор Әхмәд ибне Фазланны башкорт иле, Агыйдел, Ык, Минзәлә аша килгән, дип әйтә. Гарәп делегациясенә таянып, «Минзәлә»не ул гарәп сүзе «мәнзел»дән («туктау урыны») китермәкче (103—105 бит). Ләкин бу илчеләр Өстйорт, угыз, печәнәкләр иле аша үтәләр. Димәк, Каспий буеннанрак көнбатышка таба, аннан төньякка борылалар. Аларның Самар, Кинәл, Сокъ елгаларын кичүе мәгълүм. Ә Агыйдел, Ык, Минзәлә хакында Фазлан китабында сүз юк. «Минзәлә»нең мәгънәсе йорт, ил, туклыклы болын була.

Шулай итеп, топономиянең күтәреләсе үрләре бик күп әле. Шундый матур әйтелешле сүзләрнең (әйтик, Әгерҗе, Ышна, Чәтрән һ. б.) мәгънәсен эзләргә, эзләргә, табарга кирәк.

Гомумән алганда исә, без Гомәр Саттаровның бу китабын, татар дөньясында яңа фән күренеше булганга, кирәкле, файдалы хезмәт дип исәплибез.

**ЙОСЫФ ГӘРӘЙ.**

[2] Бу авыл шул ыру җиренең уртасындарак утыра.

Фәнис Яруллин

# КЕШЕНЕ КЕШЕЛӘР КҮТӘРӘ

Минем алдымда бик күп хатлар ята. Күршебез Башкортстаннан да, кайнар кояшлы Үзбәкстаннан да, Пермь, Свердловск өлкәләреннән дә, Татарстанның төрле районнарыннан да. Адреслары төрле булган кебек, хатларның авторлары да төрле кешеләр. Кайсы укытучы, кайсы пенсионер, кайсы мәктәптә укучы, кайсы сатучы. Төрле-төрле һөнәр ияләре язуга карамастан, хатларның күбесендә бер үк сораулар кабатлана. «Җилкәнне җилләр еккач» дигән повестьның герое Фәнияр чынлап та бар кешеме? Аның адресы ничек?.. Менә Мари республикасы, Бәрәңге районыннан Раушания Газимова: «Повестьның геройлары Фәнияр белән Илсөянең адресын сала алмассызмы? Олы йөрәкле, саф мәхәббәтле Илсөягә хат язып, аның белән якыннан танышасым килә»,— дип яза. Норлат районыннан Рәмзия Мәүлетова да: «Фәурия, Илсөя, Гаделшин, Гөлсәйдә, Нәсимә һәм Ризваннарның чын исемнәрен язып җибәрегез әле»,— ди. Свердловск шәһәреннән Янчурина Әлүдә хатында да шундый ук сүзләр. «...Оятыма каршы, Фәнияр Гатаулинның бер нинди шигырен дә укыганым юк, бәлки, игътибар итмәгәнмендер. Повестьны укыган көннән башлап, Фәнияр бер дә уемнан китми. Әгәр мөмкин булса, Фәнияр турында язып җибәрегез әле. Ул университетны тәмамлый алдымы? Шигырьләр язуын дәвам итәме? Кайда яши? Илсөя белән бергәме?» Пермь өлкәсе, Октябрь районыннан Нуриева Әлфирә дә: «Фәнияр абый әле дә исән микән? Шигырьләр яза микән?» — дигән сорау белән хат язган. Башкортстанның Кушнаренко районыннан 7 нче класс укучысы Ишморатов Илдар, Стәрлебаш районы, Ибрай авылыннан Хәйруллина Мөзәянә, Дүртөйледән Шәрипов Лотфи, Шараннан Сайгафарова Сәгъдәнә, Каридельдән Исмәгыйлова Әнисә, Туймазыдан Әхмәтшина Гөлчирә, Татарстан республикасы, Сарман районыннан Миннемөхәммәтова Фәния, Буадан Мөлекова Зәйнәп, Мияки авылыннан Әмирова Лилия, Свердловскидан Рамазановлар гаиләсе, Горький өлкәсеннән Йолдыз Әбүбәкирова, Садия Хәсәнова, Зеленодольскидан бер төркем кызлар, Ижевскидан Мәрданова Нурания, Аксубай районы, Ибрайкино кызлары һәм башка бик күпләр шушыңа охшашлы сораулар белән мөрәҗәгать иткәннәр.

Язучы иҗат иткән әсәрнең укучылар күңелендә фикер кузгатуы автор өчен күңелле хәл, әлбәттә. Безнең укучыларыбыз — хәзер зур культуралы, киң эрудицияле, әдәбиятның бөтен нечкәлекләрен тирәнтен аңлаучы, шул ук вакытта ифрат дәрәҗәдә кешелекле кешеләр. Аларның Фәнияр, Илсөя, Нәсимә һәм повестьтагы башка геройларның алдагы язмышлары хакында чын-чынлап борчылып, уйланып, кирәк булган очракта ярдәм кулы сузарга әзер торып язылган хатлары — әнә шул хакта сөйләүче матур дәлил. Повестьта сурәтләнгән вакыйгаларның тормыштан алынганмы яки автор фантазиясе белән уйлап чыгарылганмы икәнлеген ачыкларга тырышу да әдәбият сөючеләрнең шушы кешелекле сыйфатыннан килә булса кирәк. Чөнки чынбарлыкка нигезләнеп язылган әсәрләр (билгеле, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары булган очракта) укучыны

битараф калдырмыйлар, аларның тәэсир көче зуррак була. «Бу автобиографик әсәрме? Фәнияр дигән кеше автор үземе?» дип сораучыларга болай җавап биреп булыр иде: повесть авторның тормышына нигезләнеп язылган, ләкин автобиография түгел. Әсәрдә сурәтләнгән чорда Фәнияр белән авторның язмышлары уртак булса да, хәзер аларның тормыш юллары аерылды. Чөнки әдәби әсәр геройлары үз язмышлары белән яши башладылар. Автор аларны нинди хәлдә сурәтләп туктаса, алар шул рәвешчә генә яши алалар. Ә инде авторның хәзерге тормышына килгәндә, алда ул хакта әйтелер.

Бу уңайдан без хәзер ике нәрсәне ачыкларга тиешбез: тормыштагы вакыйга һәм әдәби әсәрдәге вакыйга. Боларның икесенә тигезлек билгесе куярга мөмкинме? Билгеле, мин биредә әдәбият теориясенә кереп китәргә җыенмыйм. Бары тик әле әйтеп узган ике дәреслекне ачыграк күзаллау өчен, бер мисал китерергә уйлыйм. Әйтик, тауда бер таш ята ди. Тирәюнендә сирәк-мирәк үләннәр үсә, үләннәрдә чикерткәләр сайраша, астында кәлтәләр мәш килә. Кыскасы, ташның үз мохите, үз яшәеше бар. Ерактан караганда, ул таш тауның түшендә бер сәдәф кенә. Шуңа күрә аңа игътибар итүче дә юк. Тау башына менгән кешеләр аның өстенә дә басып үтәләр, утырып ял да итәләр. Менә бер вакыт тауга скульптор килә. Нииндидер интуиция көченә таянып, ул бу таштан мәһабәт сын ясап булырын аңлый һәм әллә никадәрле ташлар арасыннан нәкъ менә шушысын сайлап ала да аның артык җирләрен юна башлый. Таштан искиткеч әйбәт сын туа. Һәм ул сын, мәйдан уртасына басып, икенче гомерен яши башлый. Әдәби әсәрдәге вакыйга белән тормыш материалы арасында да менә шушындый охшашлык бар дисем килә. Ләкин әдәбиятның үз кануннары, скульптураның үз кануннары бар. Скульптор ташның артык җирләрен юнса, язучы инде үз хыялындагыларны өстәп тә, тормыштагы теге яки бу вакыйганы берләштереп тә, төрле кешедәге сыйфатларны бер характерга туплап та бирергә хаклы.

Повестьны укыган кешеләр хәтерлиләрдер, аның башына документаль әсәр дип куелмаган. Хәтта документаль әсәрләрдә дә теге яки бу дәрәҗәдә авторның үз фантазиясе чагыла, бары тик ул тарихи дөреслеккә генә туры килсен. Биредә әсәрдәге кайсы вакыйга автор тормышында булган, кайсы уйланылган икәнен тикшереп тормастан, кайбер сорауларга кагылып үтәсе килә. Бер укучы болай ди: «Син армиягә киткәндә безнең авыл китапханәсендә өлкән яшьтәге апа эшли иде бит. Нишләп йөргән кызыңны китапханәгә китереп керттең?»

Әйе, тормышта, бәлки, Фәүрия — башка һөнәр ияседер. Ләкин хикмәт анда түгел. Авторның бурычы геройларының характерларын һәрьяклап ачудан гыйбарәт. Аннары мәсьәләнең икенче ягы да бар: моңарчы әдәбиятта күп тапталган сукмактан качарга тырышу. Минем карашымча, Фәүриянең китапханәдә эшләве ул кызның гына түгел, Фәниярның да кайбер сыйфатларын ачарга ярдәм итә. Аның китаплар укырга, китаплар төпләргә яратуы һәм тагын шундый беренче карашка вак булып күренгән детальләр аша геройның эчке культурасы, аны уратып алган мохит укучының күз алдына килеп баса. Әлбәттә, автор башка юл белән дә геройдагы бу сыйфатларны ача алыр иде, ләкин әдәби әсәр язганда отышлырак дип уйланган вариантны сайлыйсың.

Инде икенче бер сорауга кагылып үтәсе килә: «Нишләп Фәнияр Нәсимәгә өйләнми? Аның мәхәббәтен кире кагып, Фәнияр начар эшли бит»,— диләр. Автор Фәниярны нииндидер идеаль кеше итеп сурәтләми. Аның ялгышлары, шуклыклары, тиктормаслыгы, күп вакытларда үзен-үзе йөгәнли алмый торган гадәте бар. Кыскасы, яшьләргә хас дуамаллык та, тәвәккәллек тә аңарда тулып ята. Ләкин ул бер нәрсәгә бара алмый — ялганлауга. Әгәр ул, күңелендә Нәсимәгә мәхәббәт тумаган хәлдә (Фәнияр Нәсимәне яхшы кеше, ышанычлы дус, тугры иптәш буларак якын итә) тормыш корырга ниятләсә, бу Фәнияр белән Нәсимәгә яңа бер фаҗига гына китерер иде. Укучының болай дип әйтүе мөмкин: «Нәсимәдән дә колак каксa, Илсөя дә очрамаса?» Билгеле, алдан һәммәсен әйтүе кыен, әмма тормыш Фәниярга яшәүнең нинди дә булса яңа рецептын бирер иде.

Безнең яшьләребез батырлык турында күп уйлыйлар. Моны әлеге хатлардан да күрергә мөмкин. Менә Мөслим районы, Баек авылында яшәүче Асия Мингазова хатыннан берничә юл: «Кул-аякларым да исән, бар җирем дә килгән кебек. Ә менә иң кирәге — миндә ихтыяр көче юк». Тормыш бездән иң зур ихтыяр көчен кайчан таләп итәчәген без белмибез. Кеше

йөрәге — атылмаган вулкан кебек. Кеше үзе дә эчендә нинди көч яшеренеп ятканын белми. Менә бер вакыт ярыңа китереп басалар да, вулкан, утлы ташкынга әверелеп, югарыга ургыла башлый... Газинурларны, Зояларны, Гастеллоларны искә төшерик. Безнең изге Ватаныбызга дошман үзенең пычрак кулы белән сузылгач, аларның йөрәгендәге ачу, вулкан булып, дошман йөзенә атылды. Бу батырлыкны эшләгәнче, алар, бәлки, үзләрендә нинди дәһшәтле көч яшеренеп ятканлыгын белмәгәннәрдер. Билгеле, Фәниярны бу батырлар белән чагыштырып булмый. Тормыш аның алдына бөтенләй башка шартлар, башка сынаулар китереп куя. Аның фаҗигасенең авырлыгы — озак еллар буе сузылуында. Кеше, үзенең бөтен ихтыяр көчен туплап, бер мизгел эчендә әллә ниләр эшләп ташларга сәләтле. Чөнки ул тормыш сынавының вакытлыча гына икәнен белә. Ә инде авырлыклар гомер буе сузылса, монда фейерверктай бер яктырып алу гына җитми, ә һәр көн, һәр сәгать, һәр минут йөрәгеңне учың белән кысып, сыкранмыйча, кешеләргә үзеңнең кимлегеңне күрсәтмичә яшәү сорала. Кайсыдыр бер шагыйрь: «Озакка сузылган фаҗига фаҗига түгел, көн дә күргән кайгы кайгы түгел»,— дип язган иде. Мин бу шагыйрь белән бәхәскә керергә җыенмыйм. Җавапны һәр кеше үз язмышына таянып әйтер.

Хатларның кайберләрен язмышлары Фәниярныкы белән охшаш кешеләр яза. Башкортстан республикасы, Кушнаренко районы, Калтай авылында яшәүче Басыйров Марс: «Мин 1956 елдан бирле авыру белән көрәшәм, операция дә ясадылар, санаторийларда да булырга туры килде, тик файдасы аз, аякларым йөрми»,— дип яза. Ләкин Басыйров төшенкелеккә бирелмәгән, шул килеш урта мәктәпне тәмамлаган. Башкорт дәүләт университетының филология факультетына укырга кергән. Район газеталарында шигырьләре басыла икән. Өйләнеп, тормыш корып җибәрүдән дә өметен өзми. Мин аның хыялларының тормышка ашачагына ышанам. Безнең арабызда, үз бәхетләрен корбан итеп булса да, башкаларга бәхет бирергә өзер торучы, үтә нечкә күңелле, үтә кешелекле Илсөяләр бар. Миңа килгән хатларның авторлары да — күбесе кызлар. Бу — безнең кызларыбызның изге җанлылыгын раслаучы матур дәлил. Батырлык турында фикер йөрткәндә үз янәшәбездәге менә шушындый тирән хисле, сизгер күңелле хатын-кызлар турында да онытмыйк. Алар безнең тупасланган күңелләребезне йомшарталар, караңгы өйләребезгә якты нур сибәләр, югалган ышанычыбызны кайтарырга ярдәм итәләр. Кыскасы, батырлыкның күбрәк өлеше аларга төшә. Бу сүзләремне янә бер кат раслау өчен, Башкортстаннан Земфира исемле 18 яшьлек кызның хатыннан өзек китерәм: «Безнең авыл больницасында 1945 елгы бер егет ята. Рәзиф абый ул. Ул 1970 елда, июнь аенда сөт ташучы машина белән ауган һәм аның арка мие зарарланган. Җәрәхәтләре, яралары бик күп. Рәзиф абыйга бик кыен. Бер ел Уфа больницасында да дәваланып кайтты, берничә операция дә ясатты, ләкин өметләнерлек нәтиҗә күренми. Мин бик еш аның янына барам. Аның сүзләренә караганда, Рәзиф абыйның бик яшисе килә. Шундый ягымлы, эчкерсез, тыныч холыклы абый ул. Сез үзегезнең повестегызда Фәнияр исемле егет турында язасыз. Дөресме ул? Аның чыннан да куллары йөри башладымы?»

Бу хаттан Земфираның Рәзиф язмышы өчен никадәр борчылуы, чын йөрәктән ярдәм итәргә әзер торуы бик ачык күренә. Рәзиф берәр вакыт аякка баса алырмы — анысын белеп булмый. Земфираның язуына караганда, ул хәзер өметсезлеккә дә бирелгәли икән. Әмма янында Земфирадай кайгыртучылар булганда, Рәзифнең дә үз-үзен табачагына ышанасы килә.

Әйе, яшерен-батырын түгел, бездә әле медицинаның көче җитмәгән авырулар да күп. Бу бигрәк тә нерв өлкәсендәге чирләргә кагыла. Мондый кешеләргә күбрәк игътибар кирәк. Алар кешеләр кайгыртуын тойсыннар. Кешеләргә яхшылык эшләүдән дә зуррак бәхет юк. Шушы бәхетне татып калырга ашыгыйк.

Ләкин кайбер хатларга караганда, безнең арабызда әле кешеләр ярдәменә, кешеләр игътибарына мохтаҗлар да бар. Бераз озынрак булса да, мин бирегә бер хатны күчереп үтәм. Аны Бөгелмә районы, Карабаш поселогыннан Әминова Галия язган: «Мин сигезенче класста укыганда авырып киттем. Зур өметләр белән Казанга операциягә бардым. Операция уңышсыз чыкты. Операция урыннарым төзәлгәч, миңа хәзер район больницасында да карый алалар дип, өйгә озаттылар. Бер вакыт бер журналдан доктор Красов турында укыдым. Ул хәрәкәтләр нәтиҗәсендә аякка баскан икән. Мин дә үземчә

физкультура ясый башладым. Беренче уңышлар озак көттермәде, сул аягым сизә, бармакларым хәрәкәтләнә башлады. Ләкин мине көзән җыерулар (спастика) җәфалый. Район врачларына, курортка яки Казанга барсам, рәтләнмәмме, дигән идем. Курортка йөрми торганнарны алмыйлар, ә Казанда сиңа операция ясадылар инде, диделәр. Сәламәтлек саклау министрлыгына да язып карадым. Аннан яшь кенә бер врач килеп, мондый чирдән терелүче юк, дип китте. Шулай да терелү өметемне өзмим. Кул эшенә өйрәндем. Ләкин бездә тегү фабрикасы да, чәчәкләр ясый торган җир дә юк. Бәлки, шундый инвалидлар эшли торган җирләр бардыр. Әгәр шундый эшкә урнаша алсам, үземне бик бәхетле сизәр идем. Эшең белән кемнедер шатландырсаң, үзең аннан да ныграк сөенәсең бит».

Галия көче җитәрдәй эш сорый. Карабаш поселок Советы яки башка җитәкчеләр аның зарына колак салсалар, бәлки, ярдәм итәрләр. Совет илендә тәрбияләнеп үскән кеше өчен иң куркыныч нәрсә — эшең белән ил табынына үз өлешеңне кертә алмау. Килгән хатларның берсендә дә материаль тормыш шартларыннан зарлануны ишетмисең. Апас районы, Дәвеш авылыннан Әфләтунова Гөлсем хаты да Галия сүзләре белән аваздаш. «Мин дә авыру кыз,— дип яза ул.— Тик, эшли алмыйсың дип, миңа эш бирмиләр. Минем теләгем кая булса да тегүгә керү. Хәзер миңа 29 яшь. Миңа нишләргә инде?»

Бу иптәшләргә ничек җавап бирергә соң? Билгеле, безнең илебездә инвалидлар өчен аерым интернатлар бар. Ул интернатларда сәләтеңә, көчеңә карап эш тә бирәләр. Ләкин бу әле мәсьәләнең бер ягы гына. Күп кенә авыруларның үз туганнары, үз ата-аналары янында яшәп файдалы эштә катнашасылары килә. Мондый очракта инде урындагы җитәкчеләрнең сизгерлеге, кешелекле булулары сорала. Теләгән очракта өйдә эшләрдәй эшне һәркайда табарга мөмкин. Бары тик күңел сизгерлеге генә кирәк. Тегеләй эшлә, болай ит дип, тормышта беркемгә дә әзер рецепт биреп булмый. Һәркем язмышны үзенчә җиңә, һәркем үз сукмагын үзе яра. Тик шуны онытмыйк: нинди якты юлдыз да үзе генә караңгы төнне яктырта алмаган кебек, нинди көчле ихтыярлы кеше дә ялгызы батыр була алмый.

Кешене кешеләр күтәрә.

Повестьтагы Фәнияр язмышына гына кайтыйк. Әгәр дә хәтерсез Нәсимәләр, Илдус Гаделшиннар, Илсөя булмаса, Фәнияр шагыйрь дәрәҗәсенә күтәрелә алыр идеме? Укучылар, бәлки: мондый хәл бары китапларда гына була, диярләр. Юк, дуслар, китапта гына түгел, тормышта да моңа охшашлы язмышлар күп. Мин бу повестьны язган вакытта үз тормышымдагы вакыйгаларга гына таяндым дип уйлаган идем, ә миңа хатлар килә башлагач, алай гына түгеллегенә ышандым. Безнең яшьләребезнең тамырында Корчагиннар, Җәлилләр каны ага. Алар нинди генә шартларда да югалып калмыйлар.

Инде хәзер хатлардагы төп сорауларга гына җавап бирәсе калды шикелле. Алар автор белән Фәниярны бер кеше итеп алып, Фәниярның яки авторның хәзерге хәле, кем белән яшәве турында сорыйлар. Мин инде югарыда әдәби әсәр герое Фәнияр турында әйтеп үткән идем, шуңа күрә хәзер автор буларак берничә сүз әйтергә уйлыйм.

Әйе, автор Фәнияр кичергәннәрнең барысын да кичерде. Моннан ике ел элек университетны тәмамлап, диплом алып чыкты. Күргәнегезчә, һаман да язу эше белән шөгыльләнә. Сәламәтлеге — повестьта сөйләнгән Фәниярныкы кебек. Янында тормыш дусты Нурсия һәм әнисе бар. Берничә ел элек аны язучылар үз сафларына алдылар. Адрес сораучыларга хәзергә төгәл адресны биреп булмый, чөнки өй адресының үзгәрүе көтелә. Авторга хат язарга теләүчеләр журнал адресына яки Язучылар союзына яза алалар. Автор Язучылар союзы һәм һәртөрле редакцияләр белән тыгыз элемтәдә тора.

Соңгы сүз итеп сезгә, дуслар, кайгыртучан һәм кешелекле хатларыгыз өчен дә, киләчәк язмышым өчен чын күңелдән борчылуыгыз өчен дә зур рәхмәтемне белдерәм. Сезнең кайгыртуларыгыз минем йөрәгемә көч һәм җылылык биреп тора, дуслар.

# УЛ ҺАМАН ДА БЕЗНЕҢ АРАДА

Шушы елның октябрендә шагыйрь Гали Хуҗиевның тууына 60 ел тулды. Укучылар күңеленә үзенең матур-матур шигырьләре һәм поэмалары белән кергән Гали Хуҗиев поэзиягә утызынчы еллар башында килә. Аның беренче җыентыгы 1936 елда басылып чыга. Шул көннән алып ул дистәләрчә китаплар иҗат итте һәм татар совет поэзиясен үстерүгә зур өлеш кертте.

Гали Хуҗиев 1912 елда Татарстанның элекке Кайбыч районы Карамасар авылында туа. Башта җидееллык мәктәптә, аннан югары уку йортына хәзерлек курсларында укый. Яңа тормыш төзүче яшьләрнең алгы сафында атлап бару теләге һәм ашкынулы хисләр белән янган яшь егет 1929 елда комсомолга керә. 1937—1941 елларда, эштән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый.

Тормышка, табигатькә һәм барыннан элек кешеләргә бөтен йөрәге белән гашыйк булып яшәгән шигъри җанлы Гали Хуҗиев матбугат эшенә көннән-көн якынрак килә. Башта ул «Кызылармеец» газетасында әдәби сотрудник, 1934 елдан «Яшь сталинчы» газетасының җаваплы секретаре һәм редактор урынбасары булып эшли. Күп тә үтми, Гали Хуҗиевны ВЛКСМ өлкә комитетының пропаганда буенча секретаре итеп күтәрәләр. Һәрбер совет кешесе өчен зур сынау булган дәһшәтле сугыш көннәрендә шагыйрь үзе теләп фронтка китә. Воронеж һәм Беренче Украина фронтларында татар телендә чыгып килгән газетаның секретаре булып эшләгәндә ул совет сугышчыларын җиңүгә рухландырган күп санлы шигырьләр, поэма һәм мәкалә, очерклар яза. Эльба буйларында һәм Австрия кырларында, туып-үскән якларын сагынып, илнең бәйсезлеге өчен көрәшеп йөргән шагыйрь сугыштан соң яңадан тыныч хезмәткә кайта. Аның өлкә партия газетасының үз хәбәрчесе, яшьләр газетасының җаваплы редакторы һәм Татарстан язучылар союзының әдәби консультанты булып эшләгән чаклары безнең һәркайсыбызның хәтерендә.

Матур, төз гәүдәле, мөлаем гына елмаеп йөрүче сабыр табигатьле Гали Хуҗиев һәрвакыт тормышның алгы сызыгында торып иҗат итәргә омтылды. Аның шигырьләренә, баллада һәм поэмаларына замандашларыбызның эшләрен олылау, аларның теләк-омтылышларын мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга тырышу хас. Моны бигрәк тә аның поэмаларына карата әйтергә була. Кешенең бәхетле, тыныч хезмәткә мәхәббәте, туган ил, ирек өчен көрәше һәм шул көрәштәге батырлыгы — Гали Хуҗиевның поэма һәм балладаларында нигездә әнә шул темалар күтәрелә. Аның төрлесе төрле вакытта иҗат ителгән «Россия», «Гражданин, солдат, шагыйрь», «Идел хикәясе», «Күңел яктысы», «Испания улы», «Янар йөрәкләр», «Безнең Муса», «Каенсар», «Салават күпере» поэмаларында, «Сергей Чекмарев белән очрашу», «Капитан Русанов», «Ә ул җырлый» һәм башка балладаларында безнең бүгенге чынбарлыгыбыз шактый тулы һәм калку гәүдәләнде. Туган илгә мәхәббәт, совет кешесенең кирәк чакта Ватан өчен үлемгә барырга да әзер торуы «Россия» поэмасында аеруча көчле тасвирлана:

Һәммәбезгә газиз бишек булган,
Һәммәбезне сөйгән Россия;
Йөрәклрдән гомер китми торган,
Соры шинель кигән Россия,—
Синең өчен, җирең-суың өчен
Ничек итеп корал алмассың?
Илең бәхетен, анаң, балаң бәхетен
Саклау өчен ничек бармассың!

Шагыйрь үзенең күп кенә әсәрләрендә халык бәхете, кешелек бәхете хакына корбан булган каһарманнарга дан җырлый. Аның каләмдәш дуслары Фатих Кәрим һәм Муса Җәлилгә багышланып язылган поэмаларын һәрвакыт дулкынланып укыйсың. Совет кешеләренең якын дусты, күренекле чех язучысы Юлиус Фучик, Сталинград өчен көрәштә һәлак булган һәм татар, рус егетләре белән бер кабергә күмелгән испан улы Рубен Ибаррури образлары да Гали Хуҗиевның башка геройлары кебек үк күңелгә тирәнтен кереп урнашалар.

Гомеренең соңгы елларында шагыйрь икеләтә энергия белән эшләде. «Каенсар», «Тормышка кайту», «Янар йөрәкләр», «Җил тула җилкәннәргә», «Тәрәзәләр таңга карый» кебек әсәрләр күтәрелгән темалары буенча да, образлылыгы, эчтәлеге ягыннан да шигъриятебезнең үсүенә сизелерлек йогынты ясадылар. Бөек юлбашчыбыз Ленинга тирән ихтирам, киләчәк тормыш өчен гомерләрен биргән каһарманнарны хөрмәтләп искә алу, үзен һаман да комсомол, яшьлек сафында итеп тою — аның соңгы поэма һәм шигырьләрендә әверүчә көчле яңгырый.

Гомерем кырын ничә барладым,  
Күп түгелме кысыр җирләре?  
Юлым ерак... Күңелем корабын  
Ерак әйди заман җилләре.

«Гомер китабы» шигырендәге бу юллар шагыйрьнең туктаусыз эзләнүе, язылган кадәресе белән канәгатьләнеп, тынычланып калырга теләмәве турында сөйли. Әйе, ул соңгы сулышына кадәр дәртләнеп-ялкынланып иҗат итте, кулыннан каләмен төшермәде. Сугышка кадәр үк үзен җилкендергән Ленин темасына мөрәҗәгать итеп, «Ильичның анасы» исемле поэмасын һәм күп кенә шигырьләр язды. Үзе туктаусыз иҗат итү белән бергә, Гали Хуҗиев яшь каләмдәшләренең иҗатлары белән даими кызыксынып торды, аларның һәрбер яңа әсәрен күздән кичереп, башлап язучы теге яки бу авторның иҗатына карата үзенең фикерен белдерә торды. Гали Хуҗиев, гомумән, яшьләрнең иң яраткан, үз иткән өлкән каләмдәше иде. Тәҗрибәле шагыйрь үзе дә алар арасында кайнады, алар белән үзенең иҗат планнарын һәрвакыт уртаклашып яшәде. Киләчәктә кәгазь битләренә төшәргә тиешле матур-матур уй-фикерләре, хис-тойгылары бар иде әле аның. Ләкин вакытсыз килгән үлем аңа күңелендә йөрткән планнарын тормышка ашырырга ирек бирмәде. Бөтен барлыгы белән тормышка гашыйк булып яшәгән шагыйрь 1966 елның яңгырлы көзендә безнең арабыздан китте. Ләкин аның җырлары һаман да безнең белән бергә яши, замандашларыбызны эштә дә, иҗатта да яңа үрләр яуларга чакыра.

**РӘШИТ ГӘРӘЙ.**

# КОММУНИСТ КАДРЛАР МӘКТӘБЕ

*(ТКУ оештырылуга 50 ел)*

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң хуҗалык һәм культура мәсьәләләрен дөрес хәл итәргә сәләтле кадрлар хәзерләү максаты белән яшь Совет иленең барлык почмакларында диярлек төрле характердагы курслар, партия-совет мәктәпләре оештырыла башлый, институтларда һәм техникумнарда белгечләр хәзерләүнең сыйфатына игътибар көчәя, институтлар һәм техникумнар каршында эшче факультетлары (рабфаклар) һәм хәзерлек бүлекләре ачыла. Татарстанда беренче рабфак 1919 елда, ә татар яшьләрен институтка хәзерләү өчен махсус рабфак 1920 елда ачыла. Бу рабфакларда 1920—1921 уку елында ук 696 студент укый.

Партия, совет һәм хуҗалык органнарында җитәкче постларда эшләүче кадрлар нигездә партия-совет мәктәпләрендә әзерләнә. Татарстанда (ул чакта Казан губернасы) беренче партия мәктәбе 1919 елда ачыла.

1922 елның октябрендә Татарстанда 4 партия-совет мәктәбе (аларның икесе Казанда, берсе Чистайда, берсе Минзәләдә) була.

Шул ук елның ахырында Казандагы татар һәм рус партия мәктәпләре ике секциядән торган Өлкә партия мәктәбе итеп берләштерелә. Аңарда 524 кеше укый. Минзәлә һәм Чистай мәктәпләрен дә исәпләгәндә, партия-совет мәктәпләрендә укучылар саны 800 дән артып китә. Бу мәктәпләр 1922 елда гына да партия, совет һәм профсоюз органнарында һәм культура-агарту өлкәсендә эшләү өчен 339 кадр хәзерләп чыгаралар. Аларның яртысыннан артыгы татарлар була.

Партия X съезды кабул иткән яңа курс — яңа экономик политика — партия, совет һәм хуҗалык органнарына кадрлар хәзерләү системасын нык үзгәртүне, аның сыйфатын яхшыртуны таләп итә. Әнә шуны истә тотып һәм РКП(б) Үзәк Комитеты күрсәтмәләренә таянып, партиянең Татарстан өлкә комитеты 1922 елның язында ук инде коммунистик университет ачуга әзерлек алып бара. Өлкә партия-совет мәктәбендә укучыларның аеруча сәләтлеләре махсус группага күчерелә һәм аларны коммунистик университетка әзерләү башлана. Сентябрь аенда партия өлкә комитеты бюросы университетның уставын һәм лекторлар-укытучылар составын раслый. Университет Мәскәүдәге Свердлов исемендәге университет тибында өч еллык уку срогы белән төзелә. Ул Татарстан Коммунистлар университеты (ТКУ) дип атала.

ТКУның туган көне итеп 17 ноябрь исәпләнә. Нәкъ менә 1922 елның 17 ноябрендә партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумы Татарстан Коммунистлар университетын төзү турында махсус карар кабул итә.

ТКУ ун ел эшләү дәверендә берничә үсеш чоры кичерә. 1925 елда ул Идел-Кама буе халыкларының коммунистик университеты итеп үзгәртелә. Университетта рус һәм татар бүлекләреннән башка чуваш, мари, удмурт һәм мордва бүлекләре ачыла. Нәтиҗәдә, студентларның милли составы шактый үзгәрә. Мәсәлән, 1926—1927 уку елында ТКУда 187 татар, 40 рус һәм 99 башка милләт вәкилләре белем ала.

ТКУ татарлардан фәнни-педагогик кадрлар әзерләүгә дә зур әһәмият бирә. Шул максат белән 1925 елда университет каршында фәнни сотрудниклар бүлеге булдырыла. 1930 елда ул аспирантура итеп үзгәртелә. ТКУда дистәләгән фәнни һәм педагогик кадрлар үсеп чыга һәм алар Казанның бүтән югары уку йортларында да зур фәнни-педагогик эш алып баралар.

ТКУга студентлар кабул иткәндә укучыларның сыйнфый һәм милли ягына, партия-совет эшендәге тәҗрибәсенә, гомуми һәм политик белем дәрәҗәсенә нык игътибар ителә.

ТКУ студентлары шәһәр партия-совет оешмаларында һәм авылларда практика үтәләр, зур җәмәгать эшләре алып баралар. Алар авылларда коллективлаштыру эшләрендә, партия-совет оешмаларының эшен җанландыруда актив катнашалар. Кыскасы, бу елларда ТКУ коллективы партиянең генераль линиясен үткәрүдә республика партия оешмасына зур ярдәм күрсәтә.

ТКУ бетереп чыгучылар партиянең шәһәр һәм район комитетлары секретарьлары, район һәм шәһәр советлары башкарма комитетлары председательләре, совхоз һәм МТС директорлары булып эшлиләр. З. Тинчурин, Г. Халик-Садрый, Я. Ярмәки, Ф. Мөсәгыйть, К. Гобәйдуллин, Ф. Яһудин, К. Абрамов кебек башка бик күп иптәшләр мәгариф һәм матбугат органнарын җитәклиләр.

1932 елда партия Үзәк Комитетының карары нигезендә, башка Коммунистик университетлар кебек үк, ТКУ да Татарстан югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбе итеп үзгәртелә.

1937—1946 елларда җитәкче партия-совет кадрлары кыска сроклы курсларда һәм бер еллык партия мәктәпләрендә әзерлек үтәләр. 1946 елда Казанда ике еллык өлкә партия мәктәбе ачыла. 1953 елның көзеннән ул өч еллык итеп, ә 1956 елда дүрт еллык итеп үзгәртелә. Бүгенге көндә исә партия-совет һәм хуҗалык җитәкче работникларының белемен күтәрү марксизм-ленинизм университетында алып барыла.

ТКУдан соң Татарстанда оештырылган төрле типтагы партия-совет мәктәпләре Коммунистик университетның укыту-тәрбия өлкәсендә туплаган бай тәҗрибәсеннән киң файдаланалар. Шуңа күрә моннан 50 ел элек оештырылган Татарстан Коммунистлар университетының югары белемле марксист кадрлар әзерләүдә, димәк, республикабызның экономикасын һәм культурасын күтәрүдә, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә күрсәткән хезмәтләре һичшиксез зур игътибарга лаек.

**К. ФӘСӘХОВ.**

## Галимҗан Насыйров

# ӘЛЕ ЯРЫЙ ХАТЫН БАР

ЮМОРЕСКА



Саргаеп беткәне өчен түгел, нужа кушканга алмаштырдык без стена газетасының бу номерын.

Гөнаһ шомлыгына каршы, соңгы номерга такмак-табышмак урнаштырган идек, янәсе, начарлыкның тамырын кисүдә үзебезгә генә хас оригинальлек уйлап тапканбыз.

Такмакның тарихы бик гади иде.

Бервакыт мин кибеткә килеп кердем. Сатучы ялгызы елап утыра.

— Ни булды, Зәйнәп?

Бу миңа күтәрелеп карады да үпкәле тавыш белән болай диде:

— Син, Мөхәммәт, редактормы?

— Әйе, стена газетасыныкы...

— Мин дә «Правда»ныкы димим әле. Вәт шул. Авылда бер апа бар, җанымны кыйный инде, зар елата. Шуны тәнкыйть итәр идең.

— Заметка яз.

— Заметка? Үтерә бит ул аннары мине, үтерә... Әле бүген әнә балык сатып алды. Башын үлчәтмәде, кистереп ташлатты.

— Кем соң ул?

— Үзең беләсең бит...

Мин каян белим. Белмим. Белсәм дә заметкаң булмыйча тәнкыйтьләмәс идем. Ярамый. Тәртибе шулай. Сатучы Зәйнәп мине аңламады, үпкәләде. «Сатучыны мәсхәрәләргә ярый инде, аның яклаучысы юк шул» дип моңаеп калды.

Чынлап хәтеремдә калмаган, икенче көннеме, өченчеме, саклык кассасында контролер Фәһимә дә шулайрак зарланды. Янәсе, авылда бер явыз хатын бар, бәгырьләрне өзгәли, теңкәне корыта, тәкатьне ала. Кем икәнен контролер да әйтүдән баш тартты.

— Әйдә, чукынсын, чәкүшкәң орынмасын...

...Балалар бакчасында булган хәл кылт итеп хәтергә килеп төште. Бакча мөдире бик зарланган иде.

— Нишлим инде, бер ана килә дә, балама нәрсә ашатасыз икән, яле,— дип, тикшергән булып, өч-дүрт кәтлитне сыпырып китә. Санаулы аш бит дисәм, эт итеп сүгә, ояты да юк... Җир бит инде, җир бит...

— Кем соң ул? — дип соравыма:

— Юк-юк, әйтәмме соң, тәмсез теле белән әллә ни ишеттерер. Тигәнәктән ерак булуың хәерле, чабуыңа эләкмәс.

Ни өчен шул бер «дилбегәсез нәмәстәдән» бөтенесе курка. Юк, моны болай калдырырга ярамый. Нинди формада булса да кычытканларга кирәк, юморның-сатираның файдасы тиярга тиеш...

Редколлегиядә киңәш-табыш итәсе булдык. Чактаныштан килгән әдәбият укытучысы озак тыңлап та утырмады, нәрсәдер язарга тотынды.

— Булды, егетләр!..

— Нәрсә булды?

— Бүре дә тук, сарык та исән. Табышмак-такмак урнаштырабыз. Менә ул. Укытучы һаваланып укырга кереште:

Авылыбызда бер апа бар,
Ачуы чыкты исә,
Белми хакны, бинахакны,
Бәгырьләреңне кисә.

Магазинга килеп керсә,
Зилзилә булып исә:
«Балыкны башын кисеп бир,
Жалу язам, югыйсә!»

Балалар да поса, кача,
Бакчага килеп керсә,
Дер-дер килеп калтырана
Килене аны күрсә.

Күзләреннән аю куркыр,
Кулын изәп «мин» дисә.
Исемен әйтеп бирегезче,
Тормасын ул белмичә.

— Ярыймы? Яраса, менә шул. Заметкаңың астына: «Кем икәнен конкретлаштырып, табышмакны ачыклап, хәбәр бирегез, җавабы киләсе номерда урнаштырылачак» дип язарсыз.

Һәм шундый карарга килдек тә.

Газетаны элгән атнада ул-бу ишетелмәде. Тынычлап йокладык.

Икенче атнада берьюлы алты төймә мепробомат йотарга туры килде. Йотып тынычлансаң ярар иде әле...

Иртә белән безне, редколлегия составын, авыл Советына чакырдылар.

Газета авыл Советы органы — нишләп тә булмый, бардык. Авыл Советы председателе белән янәшә түбән оч Хәерниса утыра. Аларга каршы безгә урын тәкъдим иттеләр. Гаепле кешеләр кебек ни буласын көтеп утырабыз. Бакырчы килене дигән кушамат иясе, әлеге Хәерниса күз бәбәкләре белән безне тишкәли. Бакырчыдан киявен ияртеп кайтканнан бирле бу хатын бераз гадәтсезләнә дә төшкән икән, сәламебезне дә кабул итмәде:

— Әйтеп карасыннар менә, ни өчен мине мыскыл итеп такмак чыгарганнар. Мин балалар бакчасында, сөйләшә-сөйләшә, кем әйтмешли, четыри гуләшә ашаган идем, шуның өчен мыскыл иттегезме? Ач заманмы? Әйдәгез, үзегезне бер табак пилмән белән тыгындырып җибәрәм...

— Хәерниса апа, сезне язмадык бит! — дип акланырга маташкан идек, китте бу тезеп:

— Алайса, нигә бөтен урам миңа төртеп күрсәтә, көтү куарга барырлыгым калмады.

— Сиңа төртеп күрсәтеп ялгышалар...

— Бер дә ялгышмыйлар!

Хәерниса апаны көчкә тынычландырдык. Без чыгып киткәндә, шулай да:

— Мин сезгә күрсәтермен әле,— дип бармак янап калды.

Безне озата килгән авыл Советы председателе:

— «Каракның бүреге яна» шушы була бугай инде,— дип көлеп барды.

Кояш төшлеккә күтәрелмәгән иде әле, безне колхоз идарәсенә чакырдылар. Газета — правление органы, нишләп тә булмый, бардык. Анда, кисәү белән сугып, иренең күзенә ак төшергән Әнисә утыра. Ул әлеп үк алды:

— Балалар бакчасына аяк басканым да юк, нигә мине газетада мыскыл иттегез?

— ?!

— Җилкәләрегезне сикертмәгез, мин сезне судка бирәм. Суга төшкән тавык ясыйм әле мин сезне?

— Сезне язмадык.

— Һе, язмадыгызмы?! Апагыз, күгәрченкәйләрем, сигезне бетергән ул, тугызда тугыз атна йөргән, бик белә... Аттым шул, кистем дә аттым балык башын. Зәйнәп симез күркә ул, хәленнән килсә, балык мичкәсен дә үлчәүгә салыр иде...

— Без сине күздә тотмаган идек,— дидем мин, курка-курка гына.

— Койрык болгама! Котылмакчы буласыңмы? Тот капчыгыңны, коткарырмын мин сине.

— Валлаһи, син түгел!

— Алайса, шул! Кем икәнен күрсәтеп иртәгә яңа газета чыгарган булыгыз!.. Чыгармасагыз, белермен нишләтергә!

...Кичкә таба безне парткомга чакырдылар. Газета — беренче чиратта ук, партком органы — бардык. Анда Әтрәмән тыкрыгында яшәүче Заһирә карчык утыра. Аяк очына, идәнгә зур сумкасын куйган. Шәлен салып, кулына тоткан.

— Исәнмесез! — дидек без керә-керешли үк.

— Исән булмасак, нишләрсез? — дип, әтәчләнеп җавап кайтарды Заһирә карчык.— Килен-аждаһа сүзе белән кешене газетада мыскыл итәргә ничек сәвисегез җитте?

— Ул материалда сезнең исем аталмаган бит,— дидек беравыздан.

— Не сми! — дип кычкырып җибәрде Заһирә.

— Монда тыныч кына аңлаша торган урын,— диде партком секретаре, каршы сөйләргә урын калдырмыйча.— Я, Заһирә әби, ни өчен ул материалда сезне язганнар дип уйлыйсыз? Газетаны яхшылап укыдыгызмы?

Заһирә карчык сумкасын ачып безнең газетаның йомарланып беткән юмор өлешен чыгарды.

— Укымыйча тагын... Киленем Фәһимә әллә кайчаннан бирле теш кайрап йөри инде миңа... Карагыз аны, опережение язмасагыз, судка бирәм, Мәскәүгә барам.

— Опровержение димәкче буласыз... Ләкин ул материал бит бүтән кеше турында язылган, аны юкка чыгарып булмый.

— Кем турында язылган, әйт... Ә, ә! Телең йоттыңмы?!.

Сүзгә партком секретаре да катнашты:

— Жанр сайлау буенча сез отышлы юл тапкансыз, егетләр.
— Отышларында эшем юк. Кем турында яздыгыз, шуны әйтегез! — дип бәйләнүен белде Заһирә карчык.
Кинәт башымны бер нур яктыртып узды.
— Кем турында язылган дисеңме? Шадия турында, хатыным турында язылган,— дип кычкырганымны үзем дә сизми калдым.
— Ә, алай булса ярар. Туктале, тукта, фәрештә кебек кешене — Шадияне ник мыскыл итәсең?
— Анда синең эш юк инде, ул минем хатын...

Бичарадан ни чара дигәндәй, стена газетасының чираттан тыш номерын чыгарырга туры килде.
Иң аска, «редколлегия» сүзе белән күзгә сеңеп беткән заметка ящигы рәсеме арасына «опрежение» дип язып куйдык.
«Такмак-табышмакта Заһирә Гыймранова, Әнисә Кураева, Хәерниса Абдуллова турында язылмаган. Зерә кәпрәймәсеннәр»,— диган төзәтмә иде ул.

## Галимҗан Латыйп

## Ике күрше

Хәерниса карчык
Үзенең күршесе Розочканы,
Йөгерә-атлый үтеп барганда
Туктатты:
— Нихәл, кызым,
Исән-сау гына йөрисеңме,
Кая ашыгасың бу чаклы?!

Әллә кияүгә-мазарга чыгасыңмы?

— Чыгам шул, әбекәем,
Чыгам, чыгам!..
Көндәшләремә үч итеп,
Ачудан!

— Алай икән, кызым,
Алай икән...
Төенчегең бик бәләкәй
Күренә түгелме соң?!

— И... и... и, Хәерниса әбекәем,
Сезнең заманда гына бит ул:
Ястыгы, түшәге,
Чыбылдыгы, мендәре,
Табасы-табагачы,
Өс киемнәре...
Олавы белән төягәннәр,
Бер дә инде
Дөньяның җаен белмәгәннәр.
Хәзер бит заманасы ул түгел.

— Алай икән, кызым,
Алай икән!
Без бит гомерлеккә чыга идек!
Хәер, ун-унбиш көнгә
Шунысы да бик җиткән!

## Бүкән

(мәсәл)

Шатлана ди бүкән,
Яклана ди бүкән,
Мактана ди бүкән:
Бу дөньяда миндәй
Кем бар икән бүтән.

Утыртсалар, утырып торам,
Яткырсалар, ятып торам,
Пычак тисә, чыра булам,
Балта тисә, утын булам.

Телем-тешем дә юк минем,
Кырган эшем дә юк минем.
Чөнки бит мин бүкән, бүкән,
Ни кирәк соң миңа бүтән.

Ак ни миңа, күк ни миңа,
Бар ни миңа, юк ни миңа.
Мин соң әле нәрсә монда!
Бер миннән генә калганмы?!
Үтәр әле фани дөнья.

Мине болай үз итәләр,
Какмыйлар да, сукмыйлар да.
Чөнки бит мин тел тидермим,
Каршы килмим котбыйларга.

«Ә» дисәләр, «ә» димен мин,
«Я» дисәләр, «я» димен мин.
Чөнки бит мин бүкән, бүкән,
Ни кирәк соң миңа бүтән.

# Хәйдәр Гатин

## Үкенечле үтенеч

Үтенеч язып җибәргән
Аюга бер Сукыртычкан;
«Зинһар, булыша күрегез,
Бик интегәм,— дип,— ачлыктан.

Кышка җыйган азыкларым
Бозылдылар яңгыр үтеп».

— Йокым килә,— дигән аю,
Киерелгән тәмле итеп.—

Бераздан соң... хәл итәрмен...—
Кулын терәп маңгаена,
Күзләрен йомган икән дә
Уянган ди май аенда.

Шуннан, булышырга дигән
Ашыгыч карарга килеп
Барса, әйткәннәр: — Үлде,— дип,—
Моннан дүрт-биш ай элек.
Әгәр сине шундый язмыш
Көтә икән — бик кызганыч!

## Исем кодрәте

Йөрмәсен дип гомер буе
Мескен генә булып Куян,
Көтмәгәндә Аю аны
Урманга баш итеп куйган.

Элекке чак булса, Бүре
Тиз ботарлап ташлар иде.
Аннан бер куак төбендә
Тәмләп кенә ашар иде.

Хәзер песи кебек басып
Йөри Куян тирәсендә.
...Менә нинди зур кодрәт,
Көч бар икән бу исемдә.

## СССРның 50 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Ярославль өлкәсенә, бөек рус шагыйре Н. Некрасовка багышланган шигырь бәйрәменә, Татарстан язучылар союзыннан өлкән шагыйребез Ә. Исхак барды. Ул меңләгән шигырь сөючеләргә Н. Некрасовның барлык әсәрләре диярлек татар теленә тәрҗемә ителүе һәм татар укучыларының Н. Некрасов әсәрләрен А. Пушкин, М. Лермонтов әсәрләре кебек үк якын күрүләре, яратып укулары турында сөйләде.

* * *

Июль аенда Төмән өлкәсендә СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән совет әдәбияты көннәре булып узды. Бу олы бәйрәмгә Болгария, Венгрия, ГДР, Польша, Чехословакия язучылары һәм шулай ук илебезнең тугандаш халыклар әдәбиятлары вәкилләре катнашты. Татарстан язучылар союзыннан Төмәнгә Ә. Исхак белән С. Сөләйманова барды. Язучылар завод-фабрика эшчеләре, колхозчылар, нефтьчеләр белән очрашып, иҗат планнары турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Пенза өлкәсендә, М. Лермонтовның туган җире Тарханда, бөек шагыйрь истәлегенә багышланган шигърият бәйрәме уздырылды. Бәйрәмгә Мәскәү, Пенза, Куйбышев, Саратов, Горький, Чабаксар, Воронеж, Йошкар-Ола һәм башка шәһәрләрдән әдипләр җыелдылар. «Әдәбият дуслыгы— халыклар дуслыгы» дигән девиз белән үткән бу бәйрәмгә Татарстан шагыйре Роберт Әхмәтҗанов катнашты һәм шигырьләрен укыды.

* * *

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән шагыйрь Р. Мингалимов һәм җырчы Г. Ильясов Молдавиянең виноградчылык белән шөгыльләнүче алдынгы районы Каларашта булдылар. Алар район үзәгендә һәм авылларда халык белән очраштылар, чыгышлар ясадылар. Молдаван дусларга Татарстанның культура һәм сәнгать яңалыклары, КамАЗ төзелеше, нефть районнары турында сөйләделәр.

* * *

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән Литва ССРның комсомол Үзәк Комитеты иҗат оешмалары белән берлектә зур иҗат семинары үткәрде. Анда республиканың яшь иҗат көчләре — шагыйрьләр, рәссамнар, артистлар һәм композиторлар катнашты. Бу семинарда Литва ССРның партия һәм комсомол җитәкчеләре, министрлары, күренекле язучылары, газета-журнал редакторлары чыгыш ясады. Алар иҗат яшьләре алдында торган мөһим бурычлар турында сөйләделәр, яшьләрне кызыксындырган сорауларга җаваплар бирделәр.

Семинарга илебезнең төрле республикаларыннан, өлкәләреннән кунаклар чакырылган иде. Безнең республикадан кунак булып барган шагыйрьләр Р. Гатауллин һәм Т. Камалиев Литва яшьләренә татар культурасының, татар әдәбиятының үткәне, бүгенгесе турында сөйләделәр, әдәби кичәләргә, очрашуларга катнаштылар.

* * *

Җәй айларында Мәскәүдә СССР халыкларының иң күренекле сәнгать осталары СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышлап концертлар бирделәр. Татарстанның халык артисты И. Шакиров та үзе җитәкчелек итә торган «Идел» ансамбле белән шушы олы җыр бәйрәменә катнашты һәм зур уңыш казанды.

* * *

Чаллыда документаль фильмнар фестивале тәмамланды. Кама автозаводы төзүчеләренә Казан, Куйбышев, Саратов кинохроника студияләре Идел буенда Ленин булган урыннар һәм шул урыннардагы зур төзелешләр турында сөйләүче әсәрләр күрсәттеләр.

Татар халкының музыка культурасын чагылдырган киң экранлы «Туган як моңнары» картинасы, «Чуваш легендасы», «Мордовиядә яз», «Хәерле көн», «Минем Казаным» картиналары аеруча тирән эчтәлекле һәм сәнгатьчә эшләнгән дип табылды.

СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган документаль фильмнар фестивале өч көн дәвам итте. Кино осталары Чаллы шәһәренең «Чулпан» кинотеатрында, клубларда, төзелеш мәйданнарында эшчеләр белән очраштылар.

* * *

СССРның халык артисты, танылган дирижер Натан Рахлин җитәкчелегендәге Татар дәүләт симфоник оркестры Кисловодскидагы, Ленинградтагы уңышлы гастрольләрен тәмамлады. Оркестр Кисловодск һәм Ленинград шәһәрләре хезмәт ияләрен рус классикасы һәм чит ил музыкасы, С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Ә. Бакиров, Ф. Яруллин һәм республикабызның башка композиторлары әсәрләре белән таныштырды.

Оркестр, Казанга кайткач, М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында концертлар бирде. Программада тугандаш халыклар музыкасына аеруча киң урын бирелгән иде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәт казанышлары өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, түбәндәге иптәшләргә Татарстан АССРның мактаулы исемнәре бирелде.

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты Һидиятулла Айнятулла улы Солтановка — Татарстан АССРның халык артисты дигән мактаулы исем;

Татарстан АССР җыр һәм бию ансамбле солисткасы Фирдәүс Салих кызы Васильевага, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Наилә Хәким кызы Гәрәевага, Николай Иванович Дунаевка, В. И. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры артистлары Коршок Юрий Александровичка, Маклакова Людмила Васильевнага, Татар дәүләт республика күчмә театры артистлары Гатаулла Исай улы Нуруллинга, Люция Абдулла кызы Фарсинага Татарстан АССРның атказанган артисты дигән исем;

Татар дәүләт республика күчмә театрының баш художнигы Баландин Петр Александровичка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем бирелде.

## ЯКТАШЫБЫЗ — КОНКУРС ЛАУРЕАТЫ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчысы Г. Ильясов халык музыка коралларына кушылып халык җырларын башкаручыларның Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыкты һәм Бөтенроссия конкурсы лауреаты дигән мактаулы исемгә лаек булды.

## ТАТАРСТАН ҺӘВӘСКӘРЛӘРЕ БАШКОРТСТАНДА

Күптән түгел генә Башкортстанга «Татарстан моңнары» дигән концерт программасы белән Татарстан профсоюзлары үзешчән сәнгать коллективларының йөздән артык вәкиле барды.

Байтагы республика һәм Бөтенсоюз конкурслары лауреатлары булган бу коллективлар Уфа шәһәренең хезмәт ияләре белән очраштылар. Уфа химия заводының Ял базасында оештырылган дуслык кичәсендәге чыгышларда татар һәвәскәрләре белән беррәттән башкорт һәм башка милләт вәкилләре дә катнашты. Һәм бу кичә чын мәгънәсендә халыклар дуслыгы бәйрәменә әверелде.

Уфа резина-техник ясалмалар заводы культура сараенда булган концертны В. И. Ленин исемендәге Казан культура сараеның татар хоры башлап җибәрде. Бу хор чыгышын да, ТАССРның X еллыгы исемендәге культура сараеның «Юность» халык хореография ансамбле һәм Куйбышев исемендәге клубның «Чулпан» халык бию һәм «Саз» җыр ансамбльләре чыгышларын да Уфа тамашачылары алкышлап каршылады.

Уфа моторлар төзү заводы культура сараенда узган концерт та зур уңыш казанды.

## ТАҖИК ТЕЛЕНДӘ

Таҗикстанның «Ирфон» китап нәшрияты татар, башкорт, дагстан халыкларының күренекле шагыйрьләре Муса Җәлил, Мостай Кәрим, Рәсүл Гамзатов әсәрләреннән төзелгән җыентыклар бастырып чыгарды. Муса Җәлилнең «Моабит» циклыннан күп кенә шигырьләрне таҗик теленә А. Кахори тәрҗемә иткән, китапка сүз башын Т. Нурмөхәммәт язган.

## МАКТАУГА ЛАЕК КИТАП

Балалар өчен язылган китаплар буенча үткәрелгән Икенче Бөтенроссия күргәзмәсендә 1971 елны Мәскәүдә басылып чыккан «Герой-шагыйрь эзләре буйлап» дигән китап идея-художествосы ягыннан да, эчтәлеге һәм оформлениесе буенча да югары бәя алды. Һәм бу китапның авторы Р. Мостафин, редакторы Г. Кәримова, оформление рәссамы Р. Ременников РСФСР Министрлар Советы каршындагы Матбугат комитетының, РСФСР Язучылар союзының һәм РСФСР Художниклар союзының Мактау дипломнарына лаек булдылар.

## «АВТОГРАФЛЫ КИТАПЛАР»

Караганда телевидениесе даими рәвештә «Автографлы китаплар» дигән әдәби тапшыру күрсәтеп килә. Студиягә язучылар илебезнең төрле почмакларыннан автографлы китаплар җибәрәләр. Н. Тихонов, В. Закруткин, Э. Межелайтис, А. Мохтар, С. Михалков, татар язучыларыннан һәм шагыйрьләреннән С. Хәким, Г. Әпсәләмов, З. Нури, Р. Мостафиннарның карагандалыларга бүләк итеп җибәргән китаплары буенча оештырылган тапшырулар да тамашачылар күңеленә хуш килде.

## ДУСЛЫК КИТАБЫ

Моннан берничә ай элек Украинада «Пеан дружбы» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Анда СССРдагы барлык республикалардан да диярлек шигырь үрнәкләре бар. Китапка РСФСР шагыйрьләреннән В. Маяковский, М. Исаковский, А. Твардовский, К. Симонов, А. Прокофьев, Н. Тихонов, С. Щипачев, С. Данилов, Д. Кугультдинов, С. Кудаш, П. Хузангай һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләре, татар шагыйрьләреннән Ә. Баяновның «Икмәк» дигән шигыре кертелгән.

## КИТАП — ХАЛЫККА

Кукмара китап кибетендә һәрвакыт тәртип һәм монда һәрвакыт кирәкле китабыны табарга мөмкин. Китап кибете мөдире С. Гатауллина, сатучылар С. Имамиева, З. Хөрмәшина китапны пропагандалауга зур әһәмият бирәләр. Район үзәгендә нинди генә җыелыш, киңәшмә яки конференция үткәрелсә дә, алар инициативасы белән һәркайда китап сәүдәсе оештырыла. Шуңа күрә елның алты ае эчендә генә дә биредә 38 120 сумлык китап сатылды.

## ДҮРТ МИЛЛИОН ТИРАЖ БЕЛӘН

Республикабызның фән җәмәгатьчелеге Россиядә татар телендә беренче китап чыгаруның 250 еллыгын билгеләп үтте.

Татар телендә китаплар үнсигезенче йөздә Мәскәү һәм Петербург шәһәрләренең рус типографияләрендә басыла башлый. Ә 1800 елны Казанда татар китапларын басу өчен аерым типография оештырыла.

Бөек Октябрь революциясеннән соң Татарстанда китап басу эше искиткеч киң колач алды. Бүгенге көндә Татарстан китап нәшрияты Россия Федерациясендә иң зур нәшриятлардан санала. Нәшрият ел саен татар телендә генә дә 4 миллион гомуми тираж белән 250 исемдә китап бастырып чыгара.

## КҮЧМӘ КҮРГӘЗМӘ

Чистайда Казан сынлы сәнгать музееның күчмә күргәзмәсе оештырылып, Х. Якупов, А. Родионов, М. Усманов, М. Семенов, С. Лывин, Д. Кузнецов кебек күренекле рәссамнарыбызның 53 картинасы куелды. Күргәзмәдә татар халкының Совет власте елларындагы материаль һәм рухи үсешен чагылдырган картиналарга, шәһәр һәм авыл алдынгыларының портретларына аерыча киң урын бирелгән.

## МУЗЫКА МӘКТӘБЕНӘ — 40 ЕЛ

Казандагы П. И. Чайковский исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе ачылуга кырык ел тулды. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Р. Яхин, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор А. Монасыйпов, композиторлар С. Гобәйдуллина, Р. Билялов, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, пианист Н. Сабитовская, ТАССРның атказанган артисткасы, җырчы Г. Сәйфуллина, сәнгать фәннәре кандидатлары З. Сәйдәшева һәм П. Исәнбәт, ТАССРның атказанган культура эшлеклесе, Казан музыка училищесы директоры М. Гомәрев һәм башкалар музыка дөньясына үзләренең беренче адымнарын шушы мәктәптән башладылар.

Балаларга музыка белеме һәм эстетик тәрбия бирүдә мәктәпнең укытучылар коллективы бүген дә армый-талмый эшли.

## ЯҢА ФИЛЬМ

Татарстан композиторлары һәм Казан дәүләт консерваториясе укытучылары Казан телестудиясе киногруппасының яңа эше белән танышып, Н. Җиһановның «Алтынчәч», «Җәлил», «Гүзәл Нэҗери» опера һәм балетларыннан өзекләрне берләштергән «Нәҗип Җиһанов» исемле музыкаль фильм карадылар.

Режиссер В. Беспалов, сценарий авторы Р. Румянцева опера һәм балетларның эчтәлекләрен ачып бирә торган мавыктыргыч фильм иҗат иткәннәр. Сәнгать осталары телестудиянең яшь киногруппасын уңышлы адым белән кайнар котлады.

## МӘСКӘҮ КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең А. Яблочкина исемендәге Үзәк актерлар йорты фойесында «Күп милләтле совет театрының чәчәк атуы» исемле күргәзмә ачылды.

Күргәзмәгә куелган экспонатлар арасында афишалар, декорация эскизлары, спектакль программалары бар. Күргәзмәдә Казан театрларына да зур урын бирелгән. Алар мәскәүлеләрне һәм башка кунакларны М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия һәм В. И. Качалов исемендәге драма театрына караган экспонатлар күренекле драматурглар, режиссерлар, театр художниклары, актерларның иҗатлары белән таныштыралар.

## ТАТАР БАЛЕТЫ — ЯРОСЛАВЛЬДӘ

Быел М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының гастроль репертуары гаять бай. Анда «Севилия чәч алучысы» (К. Россини), «Кармен» (Ж. Бизе), «Шүрәле» (Ф. Яруллин), «Аккош күле» (П. Чайковский), «Бахчасарай фонтаны» (Б. Асафьев), «Ике легенда» (Н. Җиһанов) һәм башка популяр әсәрләр бар.

Театр быелгы гастрольне Ярославль шәһәренең Ф. Г. Волков исемендәге драма театрында ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Ә. Бакировның Г. Тукай һәм халык әкиятләре мотивлары буенча эшләнгән «Су анасы» балеты белән башлап җибәрде. Ярославльлеләр бу балетны җылы кабул иттеләр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Биектау районында СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышлап әдәби очрашулар уздырылды. Татарстан язучылар союзының пропаганда бюросы тарафыннан оештырылган бу шигъри бәйрәмдә шагыйрьләр Г. Латыйп, Ә. Рәшитов, М. Әгъләмов, нәфис сүз белән артистлар Х. Җәләлев, М. Шиһапов катнашты.

Шагыйрьләр җәйләүләрдә, печән җыючылар янында, кичен культура йортларында колхозчыларны Туган ил, партия, замандашыбызга багышланган шигырьләре белән таныштырдылар, артистлар Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм бүгенге татар һәм тугандаш халыклар шагыйрьләренең әсәрләрен укыдылар.

* * *

Казанның М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында әледән-әле язучылар, рәссамнар, артистлар, фән эшлеклеләре ял итәргә җыелган халык белән кызыклы очрашулар үткәрәләр. Шундый очрашуларның берсендә шагыйрь Т. Камалиев шигырь сөючеләрне яшь шагыйрьләр иҗаты белән таныштырды, рус һәм татар телендә үзенең шигырьләрен укыды.

* * *

Н. Гастелло исемендәге дружина пионерлары чакыруы буенча Татарстан китап нәшрияты редакторы, яшь шагыйрә Р. Вәлиева Башкортстанга барып Борай районының 2 нче урта мәктәбендә очрашулар үткәрде. Ул укучыларга балалар өчен Татарстан китап нәшрияты чыгарачак яңа китаплар турында сөйләде. Р. Вәлиеваның үз шигырьләрен дә укучылар зур кызыксыну белән тыңладылар.

* * *

Бер төркем яшь шагыйрьләр — З. Насыйбуллин, М. Әгъләмов, Ф. Сафин, М. Газар һәм шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов Куйбышев районы авылларында булып, игенчеләр, терлекчеләр, авыл интеллигенциясе алдында үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Бүгенге татар әдәбияты һәм сәнгате турында сөйләделәр.

Очрашулардан соң Куйбышев районының комсомол җитәкчеләре яшь шагыйрьләргә район халкы исеменнән рәхмәт әйтеп, киләчәк иҗатларында зур уңышлар теләп калдылар.

* * *

Әгерҗе районы китапханәсендә журналист М. Насыйбуллинның «Без капчыкта ятмый» дигән очерклар җыентыгы буенча зур сөйләшү булды. Сөйләшүгә автор үзе дә катнашып, китап сөючеләргә әлеге китапның язылу тарихын, үзенең иҗат планнарын сөйләде. Укучыларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирде. Ә укучылар китапка карата фикерләрен белдерделәр, авторга файдалы киңәшләр бирделәр.

# ОРЕНБУРГ ШӘЛЕ

ҖӘУДӘТ ФӘЙЗИ көе.

СИБГАТ ХӘКИМ сүзләре.






Оренбург ягын сагына күңел,
Искә төшә сабый чакларым...
Әй, атаклы шул Оренбур шәле,
Җил-давылдан мине сакладың.

Оренбур шәлләре мамык,
Оренбур шәле дебет.
Мәхәббәтем алда кебек,
Өзелми һаман өмет.

Оренбур шәле җылы һәм йомшак,
Уйларыма батам, ябынсам.
Шул Оренбур шәле кебек мине
Давылларда җылыт, яр булсаң.

Оренбур шәлләре мамык,
Оренбур шәле дебет.
Мәхәббәтем алда кебек,
Өзелми һаман өмет.

Оренбур шәле челтәрле бизәк,
Кышкы юллар төсле каймалар.
Язларымны хәтерләтә торган
Андый шәлләр тагын кайда бар?

Оренбур шәлләре мамык,
Оренбур шәле дебет.
Мәхәббәтем алда кебек,
Өзелми һаман өмет.

*Хөрмәтле укучылар!*

СССР төзелүгә илле ел тулуга багышланган 12 нче сан ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Салих Батыевның «Тугандаш халыклар гаиләсендә» дигән мәкаләсе белән ачыла. Журналның бу санына кергән һәр материал илебез халыкларының дуслыгы, Советлар иле ирешкән уңышлар турында сөйли.

Бу санда без игътибарыгызга берьюлы өч повесть тәкъдим итәбез. Аларның берсе Фатих Хөснинең «Без яшь идек...» дигән әсәре. Беренче мәхәббәтнең уянган чагы, яшьлекнең сафлыгы, матурлыгы турындагы лирик повесть. Чаллы төзүчеләренә багышланган «Урамнар кичәя» дигән повестьны Барлас Камалов язган. Гөлшәһидә журналыбызның яңа авторы. Казан дәүләт университетын тәмамлаган Шәһидә Максудова озак еллар буе Әлмәт, аннан соң Казан китапханәләрендә эшли. «Минем кала алуым» дигән әлеге повесть яшүсмер бер баланың сәнгатькә килгән елларын сөйли. Аның ашкынуларын, шатлыкларын, кайгы-хәсрәтләрен тормышчан эпизодлар аша тасвирлый бирә. Бу әсәр — авторның үзенең дә беренче тапкыр «кала алуы».

Рөстәм Мингалимовның «Күз карасы» дигән поэмасы да КамАЗ төзүчеләренең героик хезмәтен җырлый. Роберт Әхмәтҗанов бу санга «Гомер учагы» дигән шигырьләр циклы белән катнаша.

Әлки Фатихының бары тик «матур Фатих» дигән кушаматы гына була. Аның җире дә, аты-сыеры да булмый. Җитмәсә, бере арты бере биш кыз бала туып тора. Ни эшләргә! Бу сорауга Бөек Октябрь революциясе җавап бирә. Фатих абзыйның семьясыннан партия эшлеклеләре, атаклы артистлар, укытучылар һ. б. күренекле кешеләр чыга. Сез боларның барысы турында да Асия Хәсәнованың «Батрак Фатих кызлары» дигән очеркын укыгач белерсез.

Журналыбызның бу санында әдәби тәнкыйтькә зур урын бирелде. Илдус Ахунҗанов, Рәшит Гәрәй, Фатыйма Ибраһимова мәкаләләреннән бүгенге татар әдәбиятына кагылган кайбер фикерләрне укырсыз. Болардан тыш Флорид Әгъзәмовның «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы» дигән публицистик мәкаләсе, Марсель Зариповның «Яшел хәзинә» очеркы, Яхъя Абдуллинның мәдәният тарихына караган зур мәкаләсе, Луиза Шәйдуллинаның пирамидалар иленә сәяхәте турындагы язмалары, «Безнең календарь», әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелде.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210